UvA-DARE (Digital Academic Repository)

# Габделбари Исаев. Дини әсәрләр

Bustanov, A.K.

Link to publication

*Citation for published version (APA):*
Bustanov, A. K. (2019). Габделбари Исаев. Дини әсәрләр. Kazan: Kazanskaia nedvizhimost'.

**General rights**
It is not permitted to download or to forward/distribute the text or part of it without the consent of the author(s) and/or copyright holder(s), other than for strictly personal, individual use, unless the work is under an open content license (like Creative Commons).

**Disclaimer/Complaints regulations**
If you believe that digital publication of certain material infringes any of your rights or (privacy) interests, please let the Library know, stating your reasons. In case of a legitimate complaint, the Library will make the material inaccessible and/or remove it from the website. Please Ask the Library: http://uba.uva.nl/en/contact, or a letter to: Library of the University of Amsterdam, Secretariat, Singel 425, 1012 WP Amsterdam, The Netherlands. You will be contacted as soon as possible.

*UvA-DARE is a service provided by the library of the University of Amsterdam (http://dare.uva.nl)*

Download date: 18  2019

Әл-Хафиз Кәләмуллаһ
Әл-Хаҗел-Хәрәмәйн
Мөфти

Габделбари хәзрәт
ИСАЕВ

# ДИНИ ӘСӘРЛӘР

Казан, 2019

Китап «ТАИФ» җәмгыятенең һәм Мәрҗани Фондының
матди ярдәме белән нәшер ителде

This publication was supported by the Dutch Scientific Foundation (NWO) in the framework of the research project «The Russian Language of Islam».

*Төзүчесе*
Әлфрид Бостанов

**Габделбари хәзрәт Исаев. Дини әсәрләр** / Төзүчесе Ә.К. Бостанов. – Казан: Издательский дом «Казанская недвижимость», 2019. – 224 б.

© Гали Абдулбариевич Исаев, наследник, 2019
© А.К. Бустанов, автор введения, составитель, 2019
© Э. Димасов, дизайн обложки, 2019
© А. Даулетчин, редактор арабских текстов, 2019
© ЗАО «Издательский дом «Казанская недвижимость», оформление, 2019



# Эчтәлек

Кереш сүз.....5
Коръән тәфсире.....51
Сүрә «Фатиха» – «Әлхәм» сүрәсенең кыскача тәрҗемәсе.....51
«Бакарә – Сыер» сүрәсе.....75
Коръән тәфсире (икенче варианты).....84
Госман нөсхәсе.....90
Ислам дине: иман, игътикад, намаз һәм фәлсәфәсе.....102
[Ислам динендә хатын-кыз].....126
Русия мөселманнары һәм мөфтиләр-казыйлар турында кыскача мәгълүмат (гыйнвар 1979).....149
Ленинград шәһәре мәсҗед җамигенә ай кую бәйрәме.....151
Диния Нәзарәтенең 1959 нче ел чыгарган фәтвасе.....153
Хатлар.....156
Мөфти Шакир Хыялетдин белән хат язышу.....156
Мөфти Шакир Хыялетдиновка һәм Уполномоченныйга рәсми хат.....158
Мөхәммәд-Парса Ахатовка (Киев шәһәре) шәхси хатлар.....176
[Габделбари хәзрәтне Ленинград мәчетеннән төшерү турында] Мөнәҗәтләр.....206
Габделбари Исаевның мөфти булуы хакында.....219
[Тәрҗемәи хәлем].....223

# Кереш сүз

Әлфрид Бостанов

XX гасыр – татар тарихында гаҗәеп бай һәм катлаулы чор. Бу дәвердә татарның югары шәһәр мәдәнияте югалтулар кичерә, ачы язмышка дучар була. Һәрхәлдә, бүгенге көндә әлеге вакыйгаларның сәбәпләре (чыны, уйдырмалары) төрле яклап өйрәнелә, ачыклана. Безнең максатыбыз – халыкның башыннан кичкәннәрен кабаттан торгызу түгел, ә татар җәмгыятенең үсешенә зур өлеш керткән, шундый катлаулы шартларда да милләт язмышына битараф калмаган күренекле шәхесләребезнең эшчәнлеген барлау. Бу сүзләребез артык «пафослы» яңгыраса да, динсезлек һәм үз асылыңнан ераклашырга мәҗбүр булган заманда яшәп тә, дин юлында актив эшчәнлек алып барган аерым шәхесләребезнең тормыш юлы, теләк-омтылышлары, изге ниятләре хәзерге һәм киләчәк буыннарның игътибарына, уңай бәясенә лаек, чөнки бу кешеләр югары татар мәдәниятенең җәүһәрләрен саклап кала алганнар.

Әле күптән түгел генә үз милли йөзеңне күрсәтү, туган телдә сөйләшү, милли мәсьәләләрне кайгырту кебек гамәлләр халык арасында тыелган дәрәҗәдә иде. Башкалардан аерылып торган фикерен белдерүдән куркып, гади кеше чын исемен яшерә, бүтәннәрдән аерылып тормаска тырыша. Һичшиксез, бу юл күпләрнең хәтерен үзгәртә: үз асылын оныттыра, халкыбызның гореф-гадәтләреннән баш тартырга мәҗбүр итә. Башкача әйткәндә, Совет заманы халык өчен зур сынаулар чоры була.

Пәйгамбәребезнең хәдисендә әйтелгәнчә, кыямәт көне якынлашканда, адәм баласы, уттан ерак торган кебек, диннән дә читләшергә ашыгыр. Мондый галәмәт Совет заманында да милли мәсьәләләргә бәйле рәвештә күзәтелә: күпләр миллилектән котылу юлын сайлый. Ләкин андый кешеләргә гаеп тагарга хакыбыз юк. Сүзебез ул заманда башка юлдан китүчеләр хакында булачак. Максатыбыз – шул дәвердә яшәгән шәхесләрнең тормышын өйрәнеп, диннең һәм милләтнең катлаулы тарихына күзәтү ясау, үткәндәге күпкырлы вакыйгаларга шаһитлар күзлегеннән карау.

Китабыбыз оныттырылган һәм күп мәртәбәләр гаделсез шартларга куелган күренекле шәхесләребезнең берсе – Ленинград мәчетенең имамы, гомеренең соңгы елларында Диния нәзарәтендә мөфти вазыйфасын башкарган Габделбари Низаметдин улы Исаевка (1907-1983) багышлана.

Габделбари Исаев үз вакытында милләтебезнең иң атаклы галимнәреннән гыйлем алып, имам вазыйфасын башкара, аннары большевиклар һөҗүменнән

котылыр өчен гаиләсе белән Урта Азиягә китә. Ил өчен иң авыр вакытта хәзрәт Бөек Ватан сугышында катнаша. Күп авырлыклар аша үтеп тә Габделбари хәзрәт дин юлын ташламый: Уфаның 2нче мәхәллә имамы һәм Диния нәзарәте әгъзасы булып эшли һәм 1956 елда Ленинград мәчетенең имамы буларак раслана. 1975-1980 елларда Габделбари Исаев мөфти вазыйфаларын башкара. Хәзрәт үз гаиләсе белән Ленинград шәһәрендә утыз елга якын тора. Монда ул элекке татар фикри традицияләрен дәвам итеп, күпсанлы дини эчтәлекле шигырьләр иҗат итә, атна саен вәгазьләр укый һәм зур әһәмияткә ия булган дини әсәрләр яза. Әлеге кыйммәтле хәзинә хәзрәтнең туганнарында бүгенге көнгә кадәр саклана.

Бу мәкаләдә хәзрәтнең тормыш юлын һәм иҗатын, шул бай документаль чыганакларга таянып, берникадәр яктыртасыбыз килә. Кереш мәкаләбездә Исаевларның гаилә архивында сакланган фоторәсемнәргә һәм кульязма чыганакларга еш мөрәҗәгать ителәчәк, ләкин игътибарлы укучы аларны гади иллюстрация, мисал рәвешендә генә кабул итмәскә тиеш, чөнки һәр тарихи чыганакның (бигрәк тә визуаль чыганакның) үзенчәлеге бар.

XX гасырда кеше үзе турында сөйләгәндә төрле ысуллар кулланган. Фотосурәтләр дә, билгеле, әлеге ысулларның берсе. Димәк, аның хосусый сыйфатлары, аерым визуаль теле дә булырга тиеш. Бу зур фәнни мәсьәләне монда тулаем ачыкламыйча калдырабыз, игътибарлы укучыны без китергән рәсемнәргә карап, үз фикерләрен тупларга һәм хосусый тикшеренүләрне укырга чакырабыз.[1]

1950 елда Габделбари хәзрәт тарафыннан төзелгән гаилә шәҗәрәсенә күз салсак, Исаевларның тамыры Чыңгызханның гаскәр башлыгы Майкы бигә барып тоташканын күрәбез. Бу үзенчәлек башка шәҗәрәләрдә дә күзәтелә: хәзерге Башкортстан республикасы чикләрендә урнашкан татар кабиләләренең күбесе югарыда искә алынган Майкы бине үзләренең төп бабасы буларак таныйлар[2]. XIX гасыр башында бу нәселнең бер өлеше хәзерге Башкортстан республикасы Бәләбәй өязенең Югары Аташ авылына килеп урнаша. Габделбари хәзрәтнең әтисе Салих улы Низаметдин (1871-1952) – Уфа шәһәрендә сатучы, әнисе Мөхәммәдхафиз кызы Фәхрелҗамал, мөселманнар киеме

1. Ali Behdad, Camera Orientalis: Reflections on Photography of the Middle East (Chicago and London, 2016); Elizabeth Edwards, The Camera as Historian: Amateur Photographers and Historical Imagination, 1885-1918 (Durham and London, 2012). Без ясаган кайбер күзәтүләрне монда укып була: Бустанов А.К. Ислам и язык советской визуальности // Материалы Международной научной конференции «Азиатская Россия». Омск, 2015. С. 30-32.

2. Michael Kemper, Sufis und Gelehrte in Tatarien und Baschkirien, 1789 - 1889: der islamische Diskurs unter russischer Herrschaft. Berlin, 1998. S. 370, 382.

сатучысының кызы була. Менә шушы гаиләдә 28 гыйнвар көнне дөньяга ирбала килә. Сабыйга исем кушу бәйрәменә Уфа шәһәренең 3нче мәчете имам-хатыйбы, Диния нәзарәте әгъзасы Сабирелмөхсин хәзрәтләре[1] чакырыла.

Малайга алты яшь тулгач, әтисе Низаметдин улын «земский ышкулга» укырга бирә. Күп еллар узгач, бу мәктәптә укыган чакларын Габделбари хәзрәт үзенең истәлекләрендә искә ала: «Ул ышкулда иртән бер сәгать дин укытыла, аннан падишаһ дога[сы] булып, дәрес башлана иде. Моның соңында унбер яшемдә минем әнкәй Башкортостанның Әсән мәдрәсәсенә Коръән[не] хифз (=ятлау) итергә илтеп куя, анда, исемен белмим, әгъма (=сукыр) бер кари (=Коръән белгече) була. Ул бик усал, бик кыйный торган була. Бу авылдан бер атна, ун көннән соң качамын. Шул җирдән 18-20 километр чамасы Түйлүгән дигән авылга Хәбибәриҗал Габделкадыйри кари хәзрәткә илтеп тапшыралар. Ул 35 яшьләрендә була. Бик гайрәтле һәм требовательный (=таләпчән) була. Әлбәттә, ул вакыт гамәлгә куелган кыйнау монда да бар иде, ләкин мин үзем бер генә тапкыр кыйналдым, бәлки әткәйнең ярдәмле булуы файда иткәндер. Анысын ачык белмим, тик бер генә кыйналуымнан шулар дип шәкертләр әйтә иде»[2].



Салих улы Низаметдин Исаев (1865-1952)

Хәбибәриҗал хәзрәт Уфа губернасы хөкүмәтеннән Түйлүгән авылының беренче мәхәлләсе имамы һәм мөдәррисе вазыйфаларын башкарыр өчен рәсми кәгазьне (указны) 1915 елның 18 февралендә генә ала. Күргәнебезчә, моңа кадәр ул хәлфә булып тора, ә 1915 елда имтихан биреп, указ алганнан соң, имам була. Белеме тирән булса кирәк: халык аны зурлап, «хәзрәт» дип йөртә.

Безнең кулда Хәбибәриҗал хәзрәтнең шәхси тәрбия алу буенча «уку кануны программа»сы бар. Бу кызыклы документ бер битлек кульязма рәвешендә

1. Кызганыч, бүгенге көндә татар дини зыялылары турында тулы мәгълүмат булмаганлыктан, махсус тикшерү оештырмый торып, бу һәм башка галимнәр, имамнар турында берни әйтеп булмый.

2. Габделбари Исаев. "Тәрҗемәи хәлем". 1а бит.




Исаевлар шәҗәрәсе. 1950 елда Габд




...делбари Исаев тарафыннан төзелгән.



Указъ ЕГО ИМПЕРАТО

САМОДЕРЖЦА

изъ Уфимскаго Гу

Башкиру дд. Тюлюгановой Белебеевска

въ томъ, что онъ, Абдулкадыровъ . соотвѣ

свидѣтельства Комиссiи Басимскаго Высшаго Началь

русской разговорной рѣчи и умѣнiи читать по-русски

ховномъ Собранiи испытанiю въ знанiи правилъ Маго

имамъ-хатыпомъ и мударрисомъ и со

соб. мечети Белебеевскаго уѣзд

состоявшемуся 18 февраля 1915 г. утвержден

почему и обязывается вести себя въ этомъ званiи прил

Алкорана, во всемъ по данной имъ присягѣ, и отъ вс

возложенномъ на него званiи. Причитающiйся гербовы

Сов

№ 691

У сего

Хәбибәрижал хәзрәткә



рскаго величества,

всероссійскаго,

бернскаго Правленія

... уѣзда Хабибрияалу Абдулкадырову

...тственно представленнаго имъ въ Губернское Правленіе

... училища отъ 20 Сентября 1914 г. за № 487 въ знаніи

...и по учиненному въ Оренбургскомъ Магометанскомъ Ду-

...метанской религіи оказался быть способнымъ

...гласно желанію прихожанъ д. Тюлюгановской

...да, по постановленію Уфимскаго Губернскаго Правленія,

...ъ къ означенной мечети имамомъ,

...ично, какъ надлежитъ вѣрному и усердному служителю

...ѣхъ и каждаго имѣетъ быть признаваемъ и почитаемъ въ

...й сборъ уплаченъ Февраля 21 дня 1915 года.

...тника

Дѣлопроизводитель

БИРЕЛГӘН МӘНШУР (УКАЗ)



اعوذ بالله من الشيطان الرجيم بسم الله الرحمن الرحيم

الحمد لله رب العالمين الصلاة والسلام على رسوله سيد المرسلين.

مين اوزم اوفا شهرنده ١٩٠٧ نچی يل هجری برله ... نچی يل عيد قربان کوننده

يعنی 28 نچی غينوارده سهشنبه کون دنياغه کيلدم. آتام نظام الدين صالح اوغلی

اوفا شهرنده ساتوچی بولا. انکام قمر الجمال محمد حافظ قزی مسلمانلار کيبی ساتوچی

بالاسی بولا.

سيکز ايلی بيرنچی اوفاده 3 نچی مسجدده امام خطيب ديپيه نظام تبلهٔ آغراس

صاب المحسنا حضرتلری بولا.

بالا واقتمده آلتی ياشلاردا مين زيهسکه اشکولگه اوقورغا بيردیلر اول اشکولاردا

شرتلی ... سعادت دين اوقتدلار آنده پادشاهکه دعا بولدی. درس ياشلاردا ايدی

سوکت صوکفدا 11 ياشمده، مين انکار باشقرتستانده ~~...~~ لهسان

مدرسه‌سنه قرآن حفظ ايتارگه ايلتب قويا. آنده استاد بلميم اعمی

قاری بولا. اول بعد اوسال بيک قيزيق تدرعاشه بولا.

بو اولدا آتنا اوچ کوننده صوک قاپمی سول بيردی. 18، 20 کيلاميترلر

جاماسی تدبلگه ديکه آولدا حبيب الرجال عبد القادر قاری حضرتلرنه ايلتب

تاپشرالار. اول 35 ياشلرنده بولا. بيک عبيرت تک هم تربيتلی بولا

البته اول واقت عملگه تدبلهات قيناو موندا هم بار ايدی. لاکن مين اوزم

يرگن تابقر قيناليم. بلکه انکا نيک ياردم بولوب قالدی انيکده

آنسی آچيق بلميم نيک برگنده قيناولو ... لار ديب ... لاکن الله

بو اولدا درس ترتيبی مين اوزم بيک فقير هم بيک مهربانلر خير الله يايلاردا

تورشم آلار ... برلن ايکه ... ايدی. لاکن مين بالا ايب بورتالر ايدی

قارده. الحمد لله آلار هر کون دعا قالدر ... يورت الله قبول ايتسون

قريه ... صوک قرائت تکلالف آنده درس آلب قاتيب کيتو. درسی هرکونه

قرائت ايکی بيت بر تمو بيروله ايدی يعنی قرانک برنچی يارتسی 240 کوننده

اوزلدی. آنده صوک ايکنچی يارم ياشلارده. لاکن ايندی بو واقتا

اولگر يارم تاغنه ا بر اربع درس برله تکرار ياشلارده يعنی 6 بيت حفظا

Габделбари Исаевның «Тәрҗемәи хәлем» кульязмасы

сакланып калган. Аның язылу тарихы ачык күрсәтелмәсә дә, югарыда китерелгән сүзләргә таянып, документның инкыйлаб вакытына карагандыгын фаразларга була. Битнең бер ягында дәресләр тәртибенең искесе сызылып беткән, икенче ягында яңа җәдвәл язылган. Әүвәлге дәресләр тәртибе буенча яшь Габделбари әл-Аташый башка бер шәкерт – Габделхәй бине Габделхәлим әт-Түйлүгәни белән бергә укый. Атна дәвамында, көн саен укыйлар. Шимбә, дүшәмбе, чәршәмбе көннәрендә мөхтәсар, хисап, Коръән һәм гарәп теле (сарыф) укытыла; якшәмбе, сишәмбе, пәнҗешәмбе тәфсир, география, Коръән, гарәп теле өйрәнелә. Коръән уку, ятлау һәм тәфсир өйрәнү өчен махсус җомга көн калдырыла.



«Уку кануны программасы»

Документның икенче ягында Габделбариның исеме генә теркәлгән. Исеме янына «хафиз кәләмуллаһ» дигән титулы да куелган. Димәк, Хәбибәрижал хәзрәт җитәкчелегендә яшь шәкерт Коръән Кәримне тулысынча ятларга өлгерә. Моңа карамастан, алар остазы белән көн саен изге китапны кабатлап, укып торалар, мөхтәсәр белән тәфсир көнаралаш өйрәнелә, гарәп теленә дә игътибар зур була. Соңыннан, бу фәннәргә өстәп, шимбә көнне «Мең дә бер хәдис» китабын укыйлар, якшәмбе, сишәмбе, пәнҗешәмбе көннәрендә – «Мишкәт шәриф» хәдисләр җыентыгын, дүшәмбе белән чәршәмбе кабат хәдис өйрәнәләр. Атнаның башка көннәреннән аермалы буларак, җомга көне тулысынча Коръәнгә багышлана.

Ул замандагы шәкертләр тормышын төгәлрәк күзаллау өчен, Габделбари хәзрәтнең тәрҗемәи хәленә кабат күз салыйк. «Бу авылда дәрес тәртибе. Мин үзем бик фәкыйрь һәм бик миһербанлы Хәйруллаһ бабайларда тордым. Алар әби берлән икәү генә иде, ләкин мине «балам» дип йөртәләр иде. Хәзер дә, әлхәмдулиллаһ, аларны һәр көн догадан калдырганым юк, Аллаһ кабул итсен. Иртә намаздан соң – Коръән тыңлату, аннан – дәрес алып кайтып китү. Дәрескә һәр көн Коръәннән ике бит – бер «сөмен» (=сигезе) бирелә иде, ягъни Коръәннең беренче яртысы 240 көндә узылды. Аннан соң икенче ярымы башланды. Ләкин инде бу вакытта әүвәлге ярымын тагын да бер «әрбагъ» – дүрт бит берлән тәкрар (=кабатлау) башланды, ягъни алты бит хифз (=ятлау) итергә туры килде. Бик авыр иде, хәттә хәзрәтемез миңа: «Бик авыр бара, син әллә туктыйсыңмы?» – диде. Мин: «Юк, Ходайга тапшырдым,» – дидем һәм дәвам иттем. (Шуны әйтергә кирәк, мин унбер яшемдә сарыф, нәһү укыган идем. Миңа бераз шул ярдәм бирде). Шулай итеп, беренче ярымны тагын алтмыш көндә тәкрар (=кабатлау) ителеп, икенче ярым әле ерак китмәгән иде. Моның соңында беренче ярымны ярты пара берлән тәкрар башланып, икенче ярым яртылаша башлаган иде. Бер айдан беренче ярым бер пара берлән тәкрар башланып әл-хасыйл (=кыскасы), беренче ярым нык күңелгә беркетелде, икенче ярым бер тапкыр хифз ителеп чыкты. Менә моннан соң кичке белем алу дәресе башланды, ягъни кем ясигъ намазыннан соң хәтта ярты төннәр узганчы тәфсир, хәдис, гыйльме фикыһ һәм башка дәресләр кертелә башлады»[1].

Димәк, 1921 елда, Габделбари Исаевка ундүрт яшь тулгач та, ул беренче мәртәбә хәтем кыла башлый, ягъни Коръән Кәримне өч ел эчендә ятлый. Тәрҗемәи хәлендә хәзрәт үзенең тәрбия алу турындагы хатирәләрен дәвам итә: «Моның соңында Уфа шәһәре Зияэтдин Камали[2] хәзрәтләренең Галия мәдрәсәсенең программасы буенча дәрес алып, 1926 елда Диния нәзарәте хозурында Ризаэддин Фәхреддинов мөфти хәзрәтләренә имтихан иттем. Имтиханда Зияэтдин әл-Камали, Мәһди Магъкүли, Җиһангир Абызгилдин, Кәшшаф Тәрҗемани, Мөхлисә Бубый һәм башкалар катнаштылар. Ошбу имтиханда имамлык дәрәҗәсенә шаһәдәтнамә бирелде һәм шул ел Башкортостан Чакмагыш нәхиясенә (=волостьтә) табигъ (=урнашкан) Каряуды авылында хәтме Коръән итеп, шул җиргә имам булып калдым».

Телгә алынган шаһәдәтнамә хәзерге вакытта да исән, анда түбәндәге сүзләр язылган: «Башкортстан җөмһүрияте Бәләбәй кантоны Чакмагуш воло-

1. Шул ук әсәр. 16 бит.

2. Бу галим турында тулырак мәгълүмат: Камали З.Д. Философия ислама: в 2 т. Т. 1. Часть 1. Философия вероубеждения / пер., вст. сл., прим. и ком. Л. Алмазовой. Казань, 2010. С. 9-57.

сте Югары Аташ авылының Габделбари бине Низаметдин 1927 елда 22 декабрьдә Дизия нәзарәте хозурында кылынган имтиханында имам вә ибтидаи (=башлангыч) дини мөгаллимлек дәрәҗәсенә лаеклы табылганлыктан, Диния нәзарәтенең ошбу 1927 ел 22 декабрьдә булган карарына муафыйк Габделбари бине Низаметдин мәзкүр Бәләбәй кантоны, Рәҗәб волосте, Югары Каряуды авылының беренче мәхәлләсенә имамлык мәнсәбенә (=вазыйфасына) тасдыйкъ кылынып, канунның 8нче фасыйл 7нче маддәсенә муафыйк ошбу мәншур (=указ) бирелде». Бу тарихи документ Диния нәзарәтенең мөһере белән сугылып, мөфти Ризаэддин бине Фәхреддин һәм казый Мәһди Максуди имзалары белән раслана. Өйрәнелгән чыганакларга нигезләнеп, шунысы аңлашыла: кайбер тарихчыларның «Габделбари хәзрәт төпле ислам тәрбиясе алмаган,»[1] – дигән сүзләре чынбарлыкка туры килми.

Яшь имам авылга кайткач, әкренләп тамыр җәяргә, гаилә корып җибәрергә ниятли. Әтисе Низаметдин улы Габделбари белән бергә үз авылыннан чыгып, тирә-яктагы татар-башкорт авылларыннан кәләш эзләргә тотыналар. Иске Биккенә авылында мөэззин булып эшли торган Мирзашәриф Вәлидановның берничә матур кызы була һәм Исаевлар аларның берсен яшь хәзрәткә хатынлыкка сайларга телиләр. Ләкин сайлау эше авыр башлана: биш кыз арасыннан сайларга туры килә. Мирзашәриф үзенең – Мөсәввәмә исемле олы кызын – кияүгә бирергә тели, әмма беренче килүдән соң ук, ни сәбәпледер, ризалыгын бирми. Низаметдин бабай бу хәлне: «Ярый, инде көмеш булмаса, алтын табылыр», – дип хәерлегә юрап куя. Башка йортларда да Аташ авылының кодаларын кире борып җибәрәләр, кызларын бирергә риза булмыйлар. Шуңа күрә Низаметдин белән Габделбари хәзрәт янәдән Мирзашәриф хәзрәтнең ишегалдына кайтырга мәҗбүр булалар. Мирзашәриф Вәлиданов та, ниһаять, үз ризалыгын белдерә.

Габделбари хәзрәт үзенең булачак хәләл җефете белән танышу мизгелләрен бик матур итеп тасвирлый: «Шул Каряуды кариясында имам булып торган вакытымда үзебезгә кода булган ихтисаб идарәсендә мөшәвия (=янәшә) булып хезмәт итүче Байбулат авылының имамнары булган Шаһигәрдән Хәмзин аркылы Иске Биккенә авылында мөэзин ихтисаб идарәсенең хәзинәдәре (=кассир) булган Мирзашәриф Вәлидан углы Вәлиданов хәзрәт берлән танышлык иттек. Бәлки авыл арасы ерак кына булса да, һәр көн очрашулар булып торды.

1. Мәсәлән: Утябаев А., Хисамов Г. Муфти Нурмухамет хазрет Нигматуллин. Документальная повесть. Уфа, 2014. С. 46, 207; «за плечами [Исаева] было только образование в сельском медресе деревни Тюлюганово Бирского кантона БАССР, полученное уже в советские годы (1926 г.)» http://www.idmedina.ru/books/history_culture/minaret/9/habutdin.htm.



Центральное Духовное Управление Мусульман.

Свидетельство.

Дано сие Центральным Духовным Управлением Мусульман гр-ну дер. Верхне-аташевой, Чекмагушевской волости, Белебеевского кантона АБССР Абдулбарию Низамуддинову в том, что он, Низамуддинов, в качестве избранного в установленном порядке прихожанами соборной мечети дер. Верхне-Карьявдинской Языковской волости Белебеевского кантона АБССР был подвергнут в присутствии Центрального Духовного Управления Мусульман 22 декабря 1927 г. испытанию в должном знании правил шариата и согласно постановлению сего Управления, состоявшегося 22 Декабря 1927 года в силу п. 7-го, § 8-го Устава Духовной организации Мусульман утвержден в звании имама вышеозначенной мечети, вследствие чего ему, Низамуддинову, вменяется в священную обязанность пребывать в строгом послушании постановлениям С'езда Мусульман, вести себя как то приличествует духовной особе, как учителю и наставнику своей духовной паствы, быть верным и искренним служителем Ислама, дабы своим рачительным служением вере и заботой о своих духовных чадах стяжать уважение и почитание всех и каждого.

Декабря 22 дня 1927 г., г. Уфа.

Председатель Муфтий Р. Фахретдин

Член Духовного Управления М. Макулов

Секретарь

Делопроизводитель Исхаков

Аташ авылының имамы Габделбари



روسیه مسلمانلرینڭ مرکز دینیه نظارتی

منشور

باشقردستان جمهوریتی بله به‌ی کانتونی رجب ولستی نڭ یوقاری قاریاودی
— اینچی محله مسلمانلارینڭ نظامغه موافق صایلاولارینه کوره باشقردستان جمهوریتی
بله به‌ی کانتونی چاقماغوش ولستی، یوقاری آتاش آولینڭ -
عبد الباری بن نظام الدین ۱۹۲۷ نچی ییلده ۲۲ نچی دیکه‌برده دینیه نظارتی
حضورنده قیلنغان امتحاننده امام وابتدائی دینی معلملک درجه‌سینه لیاقتلی
تابلغانلقدن دینیه نظارتنڭ اوشبو ۱۹۲۷ نچی یل ۲۲ نچی دیکه‌برده
بولغان قرارینه موافق عبد الباری بن نظام الدین مذکور بله به‌ی
کانتونی، رجب ولستی، یوقاری تاریاودی آولینڭ اینچی محله‌سینه
امام ملق منصبینه تصدیق قیلنوب قانوننڭ ۸ نچی فصل ۷ نچی ماده‌سینه موافق اوشبو
منشور بیرلدی. بناءً علیه مذکور عبد الباری بن نظام الدین افندی
اوزینی دینی مربی ومرشدلرگه مناسب ادب اوزرنده توتارغه، اسلام دینی ندوه‌سینڭ
قرارلارینه اطاعت ایتارگه، شرع شریف که اخلاص ایله خادم بولورغه همده بو منصبینڭ شرفینی
صاقلاغان حالده اوزیده باشقالاردن حرمت قیلنورغه تیوشلیدر.

بو منشور بیرلدی ۱۳۴۶ نچی سنهٔ هجری ۲۷ نچی جمادی الاخری‌ده،
میلادی ۱۹۲۷ نچی یل ۲۲ نچی دیکابرده اوفا.

مفتی: رضاء الدین بن فخر الدین
قاضی: مصدری معقولی
سرکاتب: [illegible]
اش اشقاروچی: [illegible]

УПРАВ. МУСУЛЬМАН

и Исаевка бирелгән мәншур (указ)



Исаевлар йорты ишегалдында. Архиерей бистәсе, Уфа. 1954/55 еллар

Ул зат Аллаһның рәхмәтендә булсын. Үткен фикерле, киләчәкнеерактан тәкъдир итүче (=күрүче) зат булды. Шулай танышып йөри торгач, Шаһигәрдән хәзрәт аркылы үзләренең беренче хөрмәтле баласы булган, гафифә һәм гакыл сахибе булган, яңа гына бәлагатькә ирешкән кыз-баласыны безләргә мәңгелек юлдаш, бәхет-сәгадәткә җитәкче булган Мөсәввәмәне Мирзашәриф хәзрәт безгә җефетләндерергә разый булып, без фәкыйрьне бу бәхетләргә мөшәррәф итте. Аллаһның рәхмәтендә булсыннар. Аны ошбу ел 1927 ел ахырлар, 1928 ел башлары иде. Әл-әҗил җәләлә (Аллаһы Тәгалә) бу бәхетенә безләргә һәдия итте». Чыннан да, гаилә бәхете аларны беренче йортта ук көтеп ала: 1928 елның декабренда уздырылган никахтан соң, Мөсәввәмәне белән Габделбари хәзрәтнең гаиләсендә берсе артыннан берсе ун бала дөньяга килә. Алар, уртак тормыш корып, илле дүрт ел буе, кайгылы һәм куанычлы мизгелләрен бергә кичерәләр. Беренче булып дөньяга 1930 елда Рәшидә исемле кыз килә. Аның артыннан – һади (1934-1938), Зөлфия (1932-1934), Фия (1938), Мөнәвәрә (1940), Зөлфирә (1944-1947), Разинә (1947), Рәшид (1950-1952), Гали (1953) һәм Тимерболат (1955-2012).

Ә бу күренештә – тормыш чәчкәсе.
Рәттән башка – анасы-әнкәсе.
Йомшак кына алдымда торган
Яңа тормышның первай чәчкәсе.

Фикерләр күчеп башка уйларга –
Калмады вакыт сикереп уйнарга.
Син ата дигән сыйфатлар хәзер
Күренеп чыкты төскә, буйларга.



1927 елда хәзрәт укуын дәвам итә (укуның кайдалыгы мәгълүм түгел). Гыйлемгә омтылышы турында ул автобиографик шигырендә болай яза:

Бу күренешемдә ыстудент идем –
Кулымда китап, галстук кидем.
Барлык күңелдән укуны сөйдем –
Тырышсам, кеше булырмын, дидем.

Барлык теләгем укуда иде –
Карап белерсез рәсемнән мине.
Чәчәкне әле сөрелдермәгән
Салкын зәһәрле тормышның җиле.



Шигырьнең соңгы юлларында «салкын, зәһәрле җил»гә ишарә ясалган. Тормышның бәхетле сәгатьләре авыр чорга туры килә. Билгеле, яшь Совет хөкүмәте ислам диненә башта ук һөҗүм итми, үз көчен башка өлкәләрдә куллана. Әмма тора-бара дин тоткан кешеләрнең, ислам диненә өйрәтүчеләрнең яңа заман дошманнарына әйләнүләре ачыклана. Илебездә дингә һәм ирекле фикер йөртүгә каршы репрессияләр, халыкка һөҗүм башлана. Иң тырыш һәм акыллы шәхесләр я юкка чыгарылалар, я



Габделбари хәзрәт. Уфа шәһәре. 1933 ел.

Ватаныбыздан китәргә мәҗбүр ителәләр.

Бу авыр хәлләр турында Габделбари хәзрәт үзе дә яза, әмма язмаларда нәфрәт хисе түгел, ә кайгы, хәтта ниндидер оптимизм, киләчәккә ышаныч хисе тоемлана: «Бертөрле төзелештән икенче төрле төзелешкә күчү өчен күп көчләр кирәк һәм корбаннар да булуы мөмкин, чөнки авыр тормыш булса да, адәм баласы суга кунган, канына шул сеңгән булу сәбәбендә аны каннан чыгарып яңа фикер кертү өчен көрәш-корбансыз булмыйдыр. Безләр дә шушы кампаниягә туры килеп, 1929-30 елларда бераз авырлык күрергә туры килде».

«Төзелеш» сүзен хәзрәт туры мәгънәдә куллана. 1929 елда Габделбари Исаев пролетариат сафларына керергә була. 1950 елда үзе төзегән гаилә фотоальбомында шундый шигъри юллар бар:



Эшче вакытым бу күренешемдә:
Башта фурашка, пальто өстемдә,
Десятник булып эш алып бардым,
Яңа төзелеш балта эшендә,

Чын күңел берлән эшне күрсәтеп,
Ударник – бу күптән теләгем,
Чын көчләрем белән ныгыды хәзер,
Алырлык түгел эшчән беләгем.

Әмма эштә тырышлык күрсәтеп кенә һөҗүмнән котылу мөмкин булмый: 1930 елның 13 февралендә Габделбари Исаевны, дин әһеле буларак, Аташ авылында кулга алалар һәм берничә айга «төзәтү йортына», ягъни «исправительная колония»гә урман кисәргә җәза билгелиләр. Андагы хәлләр җиңелдән булмый:

колониядәгеләрне авыр эштә тозлы балык һәм «баланда» белән генә «сыйлыйлар», шунлыктан Габделбари хәзрәткә тозлы балык исе гомер буе төрмә хәлләрен хәтерләтә, бу ис нәфрәттән башка хис уятмый. Хәтта күп еллар үткәч тә, хәзрәт үз өендә тозлы балык исен килгәнне яратмый.

Яшь дин галимнәренең остазы Ризаэддин бине Фәхретдин, тагын да курыкынычрак хәлләр киләчәген белеп, яңа буынны кисәтергә тырыша: «Бу вакытларда Диния Нәзарәтендә мөфти Ризаэддин Фәхретдинов хәзрәтләренә барып, иттифак иткәннән соң, бу затлар: «Сез – яшьләрсез, сезгә киләчәк вакытында күп хезмәтләр йөкләтелер. Ошбуның өчен, саклану өчен, Урта Азиягә китеп торыгыз», – диде. Һәм шул киңәш берлән Урта Азиягә барып урнашып, анда да, зур галимнәр аркылы хисап эшләре хезмәтенә кереп, имамлык эше дә алып барылды». Ягъни төрмәдән чыгып, бер ел үткәннән соң, яз җиткәч, Исаевлар (бер яшьлек Рәшидә белән) Урта Азия якларына, Ош шәһәренә юнәләләр. 1931-32 елның кышында хәзрәт балта эшендә эшли. Яңа төпләнгән җирдә ул теләсә-нинди эшкә тотынырга әзер була. Шулай да җирле халык, аның дин әһеле булганлыгын белеп, Габделбари хәзрәтне имам вазыйфасын үтәргә чакыра. Бу чакыручыларга ияреп, хәзрәт берзаман басмачыларга юлыга һәм тиз арада качып китәргә мәҗбүр була.



Хәзрәт имам булып торган урын әлегә төгәл билгеле түгел, ләкин югарыда искә алынган гаилә альбомында Габделбари хәзрәт 1931 елда үзенең Урта Азиядә булуын тасвирлый:

Урта Азия – комлык даласы,
Кайларда булмый адәм баласы.
Яңа төзелеш төзү эшендә
Казахстанның Чымкент каласы,

Аякта итек, башымда ителпәк.
Казак булырга тырышкан димәк!
Казак теленә өйрәнгән кеше
Килеп чыгалый татардан сирәк.

Кызганыч, әлеге чор турында бик

аз мәгълүмат сакланган, ләкин кулыбызда булган документарга таянсак, 1934 елда Исаевлар кабат Уфага кайткан булалар. Сәбәбе – Исаевлар Урта Азиядә булганда, Мөсәввәмәненең әтисе Мирзашәриф Вәлидановның кулга алынуы һәм 1934 елда төрмәдә ачлыктан үлеп тә китүе. Мирзашәриф төрмәгә эләккәнче, аның хатыны вафат була һәм биш сабый бала ятим кала. 1933 елда иң олысына – Мәсгудә апага – 10 яшь тулган була. Бу баланы да башта әтисе Мирзашәриф белән бергә төрмәгә ябалар, ләкин тиздән җибәрәләр. Калган балаларны авыл читендә утыртып калдыралар, йортларын, хөкүмәт файдасына дип, тартып алалар. Авылдагы күршеләре, балаларны кызганып, аларны урамнан ала. Бу ятимнәрне ялгызлыктан һәм ачлыктан коткарыр өчен, Урта Азиядән кайткан Габделбари хәзрәт белән Мөсәввәмә апа аларны тәрбиягә алалар. Шушы вакыттан Исаевларның тормышында Уфа чоры башлана.

«1934 елларда Диния Нәзарәтендә Ризаэддин хәзрәт берлән очрашу булып, Нәзарәтнең әгъзасы булып үткәрдем. Аллаһның рәхмәтендә булсын». Бу вакыйгалардан соң озак та үтми, бөек остаз мөфти Ризаэддин хәзрәт вафат була: «1936 ел мәрхүмнең дәфенендә (=күмелүендә) әнзәл кылып (=ирешеп) һәм Габдерахман Рәсүл хәзрәтенә мөфти тәгъйин иттегендә (=билгеләнгәндә) әнзәл итә (=килә) алдык. Әлхәмдүлиллаһ!» – дип яза Габделбари Исаев.



Исаевлар йорты ишек алдында. Архиерей бистәсе, Уфа. 1954/55 еллар

Уфада урнашу өчен, хәзрәт Архиерей бистәсендәге Михайловка урамы 19 а адресы буенча үз йортын сала. Совет кануннарына каршы төшмичә, шәһәрдә рәсми регистрация белән яшәр өчен, Габделбари хәзрәт колхозда әгъза булып кала һәм колхоз җитәкчелегеннән, шәһәрдә вакытлыча эшләр өчен, төрле «ысправка»лар ала.

Уфада Габделбари Исаев кабаттан төрле эшкә тотына: төзәтү берләшмәләрендә эшли, соңыннан Утильзаготовитель артеленә урнаша. Яңа Совет хөкүмәтенең тормыш тәртибе рәтләнгәч, Исаевларның да тормышы үзгәрә, бу үзгәрешләрне ул чордагы фоторәсемнәрдән ачык күрергә була.

Диния Нәзарәте ул вакытта бөтенләй буш тора: хәзрәтнең укытучыларын яңа хөкүмәт төрмәгә утырта яки лагерьларга озата, күпчелеге шунда үтереләяки төрле газаплардан үзләре вафат була. Бу дәвердә Ватаныбызда югары ислам мәдәнияте көчләп юкка чыгарыла. Билгеле, күп еллар дәвамында бу авыр хәлләр турында хәзрәт берни яза алмый диярлек. Аның язмаларында ул чорга кагылышлы: «Бу вакытларда дәүләт хезмәтен дә, Нәзарәт хезмәтен дә алып бардык», – дигән юлларын гына очрата алабыз.

Габделбари хәзрәт гомеренең беренче дәверенә, ул чорга бәйле тарихи фактларга күзәтү ясаганнан соң, мондыйрак нәтиҗәләр чыгарырга була. Беренчедән, гражданнар сугышына, ачлыкка һәм башка күптөрле кыенлыкларга карамастан, инкыйлабтан соң да төрле татар авылларында дини тәрбия бирү процессы туктамаган. 1920 елларда чит илләргә, Бохарага яки Мисырга бармыйча да, җирле галимнәрдән белем алып булган, Диния Нәзарәте дә имамлыкка указлар биргән.

Икенчедән, авырлык килгән чорда яшь татар зыялылары юкка гына Урта Азиягә китмәгәннәр. Габделбари хәзрәт искә алган ул яктагы «зур галимнәр» Уфа белән тыгыз бәгланышта торганнар булса кирәк. Бәлки үзләре дә хатлар язышып, бер-берсенә йөрешеп, ил күләмендә бәйләнештә торганнардыр. Һәм, өченчедән, без танышкан чыганакларда Габделбари хәзрәт «яңа тормыш төзү» процессын шома гына барган итеп тасвирлый. Гәрчә хәзерге тарихи әдәбиятта Ватан сугышларының икесе арасындагы вакытны караңгы итеп сурәтләү, милләткә һөҗүм ясау, китапларны яндыру, ислам динен юк итү чоры итеп карау киң таралган.

Габделбари хәзрәт, яхшылыкка өмет итепме, ислам диненең үсешенә ышаныпмы, Нәзарәттә булган кыенлыклар, низаглар турында язмый. 1970 елларда ул: «Яңа төзелеш корбансыз булмый», – дигән сүзләр язып калдыра. Монда, әлбәттә, хәзрәтнең «торгынлык» чоры күзлегеннән фикер йөртүе ачык булса да, бу сүзләр аерым әһәмияткә ия. Алар безгә гомуми татар тарихында

Совет чорының ролен башкача күзалларга мөмкинлек бирә. Бу чорны, чыннан да, бары югалту-кайгыдан торган чор буларак, берьяклы гына бәяләп карарга кирәкме? Габделбари хәзрәтнең тормыш юлы бу сорауга җавап булып тора.

***

Гаилә фотоальбомына әйләнеп кайтыйк. Бер урында, Сталин чорында яшәвен сурәтләү өчен, Габделбари хәзрәтнең укучыны ике фоторәсемне чагыштырып карарга чакыруын күрәбез.



1938 ел

План үтәргә ярышкан дәвер.
Алдынгылардан исәпләнеп,
Бишьеллык план дүрт елда тулды –
Чын күңел биреп, эшләгәч белеп,
«Ыстахановец» исем бирделәр.
Тикшерү өчен күпләр килделәр.
Шушы рәсемне түшереп алып,
Кызыл тактага мактап алдылар.



Фронттан кайтып күрешкән чакта,
Атамның яше сиксәндә иде.
Ике рәсемне чагыштырганда,
Таный алырсызмы икән соң мине?
Унынчы рәсем сугыштан элек,
Унөченчесе – сугыштан кайткач.
Нигә үзгәреш зур икәнне
Әйтеп бирермен, рәсемнән тапкач.

Үзгәреш чыннан да зур була. Пролетариат сафларына баскан Габделбари Исаев сугыш сынауларыннан бөтенләй икенче кеше булып кайта. Сугыш чоры Исаевның үзе язган тәрҗемәи хәлендә кыскача гына тасвирлана. Ул чор хәзрәт өчен аеруча мөһим: Ватаны өчен көрәшкән, кан түккән кеше үз хакын белдерүне дә урынлы таба. 1970 елларда Саклану министырлыгына җибәргән рәсми хатта Габделбари Исаев сугыш тәҗрибәсен тәфсилләбрәк сурәтли. Түбәндәгедән үзгәреш сәбәпләре дә аңлашыла:

«Я был призван в 1941 году в июне месяце из города Уфы Башкирии и меня зачислили в 441 саперный батальон, где я кончил курс по подготовке хим.инструкторов, поскольку я в 1939 году был инструктором ПВХО (противовоздушная и противохимическая оборона), подготовил

допризывников, за что получил благодарность Башквоенкомата. В лагере Чебаркуль мне присвоили воинское звание старший сержант. Наш батальон со всеми дивизиями был направлен на фронт в ноябре или октябре 1941 года. Мы прибыли в город Лехославль, откуда уже пешком в город Калинин. В декабре с участка фронта г. Торжок и Ржев был ранен под Ржевом. Помню, нас включили в пехотинские части, наш капитан был товарищ Плотников. Он погиб под Ржевом. Я его отправил в тыл, но сам в это время был ранен. Лежал в селе, имя которого не помню. После нас окружили, мы ходящие солдаты сумели вырваться из окружения и за железной дорогой стояли советские воиска. Они нас проверяли и отправили в тыл между г. Сычевка и Белым. Мы долго ходили и прибыли в город Неледово, где партизанский отряд нас несколько человек встретили, кормили и отправили в госпиталь (в монастыре), но нас повторно бомбили. Машина горела, ходящие спасались в лесу, дошли до госпитали. После обработки отправили пешком до станции Кукушкино. Оттуда поездом до Москвы, там лежали в госпитале (помню это местечко, Кремлевские санитары). После выздоровления отправили в часть 1034 краснознаменного полка. Уваровка, Гжацк, Можайск. В лесу нас назначили в часть, а меня оставили в комендантской части, где я охранял Красное Знамя, был разводящим. После меня отправили в пехотинское училище, г. Уфа. Это март месяц 1942 года. Там я учился до октября месяца. После отправили на фронт. В ноябре месяце нас отправили на Сталинградский фронт, звание не успели получить. В полку я служил на интендантской службе, по званию был старшиной. После занятия города Калач, в конце ноября я был ранен под деревней Платоновка, оттуда направили в госпиталь, город Зиметчина, где я лежал до марта месяца, где был комиссован. В приволжском военном округе дали удостоверение инвалида отечественной войны 3 группы по зрению 008-01. После возвращения состоял в учете Ждановского военкомата, я поступил на работу в Министерство коммунального хозяйства и заготовки для военных и других материалов. Получил медаль за Победу в Уфе, медаль за трудовую доблесть в Уфе, медаль за победу (75 г.) в городе Ленинграде».[1]

Монда һәм югарыда күрсәтелгән фоторәсемдә, әлбәттә, аның йөзендә

1. Оригинал орфографиясе саклана.

ватанпәрвәрлек хисе чагыла. Ике мәртәбә җәрәхәтләнгән, күзе сукырая язган мөселман кешесе совет Ватанын ихлас ярата. Бу күренеш, гомумән, Рәсәйдәге ислам тарихын өйрәнү өчен бик әһәмиятле. Чөнки Советлар Союзы өчен көрәшкән мөселманнар аны диннәренә каршы дошман ил буларак түгел, ә үз Ватаннары дип күрәләр, анда ислам дине өчен махсус урын таләп итәләр, мәчетләрне яңадан торгызуны сорый башлыйлар. Бу борылышны «мөселман ватанпәрвәрлеге» дип атасак, ялгышмабыз һәм аның тамырлары Бөек Ватан сугышына барып тоташа.[1]

Уфага кайтканнан соң, Габделбари хәзрәт үз вазыйфасын яңадан башкарырга мөмкинчелек таба: ул яңа торгызылган Диния Нәзарәтендә эшли башлый һәм 1948 елда Уфада мөселманнар съездында катнаша. Шул вакыттагы сирәк фоторәсемнәрдә без большевиклар һөҗүменнән соң исән калган голамә – дин әһелләрен күрә алабыз. Сугыш кыенлыкларыннан соң да мәчетләрдә гади халык күпләп җыела. Дин әһелләренең күпчелеге, сугыш беткәннән соң, бигрәк тә Сталин үлгәннән соң, шәһәрләргә күчәләр һәм анда еш кына яшерен рәвештә дин сабакларын укыталар.

«Шәһәр» турында сүз алып барганда шунысын искә алырга кирәк: әлбәттә, ул вакытта Уфа шәһәренең чите гади авылдан әллә ни аерылып тормаган. Рәсемнәргә күз салсак, арттагы планда – беркатлы агач йортларны, ә алар янында гади кешеләрне күрербез. Шулай да халыкта ул чордагы шәһәр мәдәниятенең киң таралган бер билгесен – эшләпәләр киюне искәртергә кирәк. Фотосурәтләрдә бу еш күренә.

Түбәндәге ике фотосурәт профессионал фотограф тарафыннан төшерелгән; кызганыч, аның турында бернинди мәгълүмат юк. Күргәнебезчә, фотографның эше күпләрне кызыксындыра, еш очракта кешеләр камерага карап төшәләр. Гади кешеләр рәсемгә төшереләчәкләрен алдан ук белмәгәннәр дип фаразларга кирәк, шуңа күрә фото өчен махсус киенеп тормаганнар. Фотосурәтләрдә этнографик реализм сизелә: кешеләрнең киемнәре, йөзләренә чыккан хисләре, хәтта ни рәвешле утырулары – бар да бик табигый күренә. Инкыйлабка кадәр ясалган фоторәсемнәр белән бу рәсемнәрнең аермасы зур. Беренчеләре күбрәк театр сәхнәләренә охшаш булса, икенчеләрендә төшкән кешеләр

1. Moritz Florin, "Becoming Soviet through War: The Kyrgyz and the Great Fatherland War," in: Kritika 17/3 (2016), 495-516. Бу күренешне Беренче дөнья сугышы чоры белән ул дәвердә язылган бәетләр нигезендә чагыштырсак, шактый аерманы күрәбез. Ул вакытта мөселманнарда башка дин солдатларына тискәре карашлар һәм сугышта катнашып, көрәш алып баруның максат-мәгънәсен аңламау ачык күренә: Danielle Ross, "Fighting for the Tsar, Fighting Against the Tsar: The Use of Folk Culture to Mobilize the Tatar Population during World War I and the Russian Revolution," Gearoid Barry, Enrico Dal Lago, Roisin Healy (eds.) Small Nations and Colonial Peripheries in World War I (Leiden, Boston, 2016), 211-229.



Габделбари хәзрәт Уфадагы 2нче мәчеттә гает намазын алып бара



Габделбари хәзрәт Уфадагы 2нче мәчеттә гает намазын алып бара

йөзендә тормыш кайгысы чагыла, ачы чынбарлык беренче планга чыга[1].

1953 елда беренче мәртәбә хаҗга барып, берничә ел Уфа шәһәрендәге 2нче санлы «Зират» мәчетендә имам-хатыйб вазыйфасын үтәгәннән соң, 1956 елда Габделбари хәзрәт Ленинград шәһәренә җибәрелә. Андагы мәчет сугыштан соң бик авыр хәлдә була, шуңа күрә яңа мөфти Шакир Хыялетдинов (1890-1974) Ленинград шәһәренә махсус килеп, мәхәлләгә яңа имам тәкъдим итә; мәчетне кабаттан эшләтә башлау, ремонтлау һәм дин эшләрен рәткә кертү Габделбари хәзрәт өстенә йөкләнә. Ул вакытта мәхәллә зур була һәм, нигездә бер генә милләт вәкилләреннән тора. Бу мәхәллә эчендә кайберәүләр яңа имамга зур ышаныч белдерсәләр, икенчеләр, киресенчә, Габделбари хәзрәткә зыян салырга тырышалар.

Габделбари хәзрәтнең 50 яшьлек юбилеена багышланган мәҗлестә мәхәлләдә булган кыенлыклар искә алына, аларны без махсус тәбрикләү хатыннан укый алабыз:

> «Выступление верующего мусульманина Хусаина Камалетдинова на торжественном обеде, посвященном пятидесятилетию со дня рождения имам-хатыба Абдулбарий Исаева 26 января 1957 года.
>
> Уважаемый юбиляр имам-хатыб Ленинградской мечети Абдулбарий Исаев!
>
> Дорогие товарищи и друзья.
>
> Сегодня мы с Вами находимся на торжественном приеме, посвященном пятидесятилетию со дня рождения нашего уважаемого юбиляра Абдулбарий Исаева. В этот торжественный вечер мы с Вами должны заглянуть на наш пройденный путь. Пройденный наш путь был не легким. На нашем пути встречались бугры и овраги. Временами мы об эти бугры спотыкались. Как Вам известно, Ленинградская мечеть продолжительное время не функционировала. Это произошло потому, что во время финской компании, а в последствии Великой отечественной войны верующие мусульмане, как и все народы Советского Союза, по зову Коммунистической партии и Советского Правительства, ушли на фронт защищать свою Социалистическую Родину. Следовательно, в связи с этими событиями, верующих мусульман, посещающих мечеть, осталось очень мало – одни старики, и конечно они не смогли содержать мечеть

1. Мисал өчен, инкыйлабка кадәр шәһәрдәге татар гаиләләрендә төшерелгән фоторәсемнәр Лилия Габдрафикованың: «Татарское буржуазное общество: стиль жизни в эпоху перемен» китабында китерелә. Казань, 2015.




Ленинград мәчете – ремонт алдыннан, 1956 ел

и поэтому мечеть была закрыта. После окончании Отечественной войны мусульманы Ленинграда стали ходатайствовать об открытии мечети.



Мөфти Шакир Хыялетдинов Ленинград мәчетендә.
13 май 1956 ел.

18 декабря 1955 года Ленинград облетела радостная весть. Постановлением Совета Министров РСФСР от 12 декабря 1955 года мечеть передается мусульманам Ленинграда. В быстрейшем освобождение мечети приняло активное участие большое количество верующих мусульман. И вот наступила долгожданная заветная мечта. Для торжественного открытия мечети в Ленинград прибыл Председатель Духовного Управления мусульман Европейской части СССР и Сибири Муфтий Шакир Хеялетдинов со своим верным и испытанным соратником имам-хатыбом Абдулбарий Исаевым. В этот день было пролито от радости не мало слез.

В своем выступление в мечети во время молебня Муфтий заявил, что дела мечети он передает в надежные руки, энергичному имам-хатыбу Абдулбарий Исаеву, и что мусульманы Ленинграда за судьбу мечети могут быть спокойны. Начинается ремонтно-восстановительные работы мечети. На этом пути с первых же дней наш юбиляр встречает большие трудности. Находятся люди, которые начинают всячески тормозить ход ремонтных работ. Появляются люди грязных дел, которые стараются растранжировать общинные деньги. Разгадав замыслы этих людишек, имам-хатыб со всей своей твердостью, могучей и кипучей энергией дает решительный отпор. Многие здесь сидящие еще не знают, какая была

эта борьба. Старое руководство двадцатки, во главе с Богдановым, не желали считаться с коллективом, начали партизанщину. Без совета и согласия мутаваллиата они пытались разбазаривать на право и на лево общинные деньги, их поддерживали влиятельные товарищи. Наш юбиляр этого не испугался и вступил в борьбу. Он мужественно, последовательно и убедительно фактами показал лицо и замыслы этих людей. В конце концов он победил. Победила справедливость. Этой первой победой в очищении от нечести мутаваллиата Абдулбарий Исаев спас Ленинградскую мечеть от удара в спину сзади. Если глубоко осмыслить значение этой борьбы, можно сказать, что это борьба была тяжелая и упорная, но крайне необходимая для нормальной работы мечети.

После реорганизации мутаваллиата и новых выборов двадцатки начались повседневные упорные работы по восстановлению мечети. Все Вы сидящие здесь прекрасно знаете, сколько труда и энергии вложил в это благородное дело наш дорогой уважаемый юбиляр Абдулбарий Исаев. Вы могли его видеть с раннего утра до поздней ночи то около маляров и штукатуров, то у столяров и электромонтеров, то у кровельщика на



«Имам-хатыйб Габделбари Исаев хезмәт бүлмәсендә».
1950 еллар. Ленинград шәһәре.



«Ленинград мәчетенең торак йорты, ремонтка кадәр. 1956 ел»



«Ленинград мәчетенең торак йорты, 1957 [елда] ремонттан соң»

крыши. Имея технический и практический опыт, исходя из расчета, что во чтобы то не стало восстановительные работы закончить за летный период. Абдулбарий Исаев все вопросы решал реалистически с учетом всех плюсов и минусов. Как Вы знаете, огромные основные восстановительные работы были закончены до наступления холодов. Это вторая победа под непосредственным руководством нашего имам-хатыба. Мечеть, которая в течение 17 лет не ремонтировался, а только разрушался была восстановлена в рекордный срок в течение 4-5 месяцев. В этом исключительная заслуга уважаемого юбиляра имам-хатыба Абдулбарий Исаева.

Мусульманы Ленинграда видя, что руководство мечети находится действительно в надежных руках, все больше и больше начали объединяться вокруг имам-хатыба, и с каждым днем стало увеличиваться количество верующих мусульман, посещающих мечеть на молебен. А это значит, начала с новой силой развиваться идея Ислама.

Восстановление мечети в такой короткий срок была возможна исключительно благодаря повседневной практической работе, проявленной энергии и настойчивости нашего многоуважаемого юбиляра Абдулбарий Исаева. Заверения Муфтия о том, что судьба мечети передается в надежные руки, полностью оправдались.

Дорогой имам-хатыб, Ваш благородный труд, проявленная энергия в восстановления мечети, в сплочения мусульман в проведении идеи ислама, верующие мусульманы Ленинграда никогда не забудут.

Дорогой имам-хатыб Абдулбарий Исаев!

От имени и по поручению верующих мусульман Ленинграда и от себя лично, от всей души приветствую и поздравляю с пятидесятилетием со дня Вашего рождения.

Желаю от всего сердца, молю Аллаха, чтобы он дал Вам здоровья, личного счастья, долгих и долгих лет жизни на благо развития идеи Ислама, на благо укрепления дружбы между народами и мира на земле»[1].

Бу тәбрикләү хаты – Исаевның мәхәллә эчендә дошманнары булуына ишарә. Моны ул үзе дә 1959 елда Диния Нәзарәтенә адресланган хатында

1. Текст үзгәртүсез бирелә.

ачык белдерә: «Беренче көннән башлап ук Совет вәкиле – уполномоченный иптәш Васильев тарафыннан катгый каршылыкны күрә башладым». Моннан күренгәнчә, Ленинград мәхәлләсендә 1950 елларда башланган ызгышлар дәүләт тарафыннан, төгәлрәк әйткәндә, уполномоченный Васильев тарафыннан оештырыла. Моны мөфти Шакир Хыялетдинов та яшерми. Габделбари Исаевның ачулы хатларына җавап язганда, ул үз мөмкинлекләренең бик чикләнгән икәнен күрсәтә: «Имамлыктан сезне төшереп ташлау минем хакым түгелдер. Царь хөкүмәте заманы түгел, бәлки демократия әсасенә корылган Совет дәүләтендә яшибез. Бу берәү халык кулында, бездә түгел, Габделбари әфәнде».[1] Халык теләкләрен, гадәттә, дәүләт оешмалары яхшы белә. Васильев мәхәллә эчендә низагларны ни өчен барлыкка китергән? Ни өчен Габделбари Исаевтан котылырга тырышкан? Безнеңчә, бу табигый сорауларга җавап бик гади: Габделбари хәзрәт шәһәр мөселманнарын берләштерергә өлгереп, мәхәлләдә дан казана һәм һәр эштә үзен мөстәкыйль тота. Нәтиҗәдә, 1967 елда Габделбари Исаев Ленинград мәчетенең имамы вазыйфасыннан азат ителә. Әлеге вакыйгаларга бәйле документлар белән бу китапта танышып була. Документлардан күренгәнчә, мәхәллә эчендә булган кайбер кешеләр, бозык тәртипләр кертер өчен, имамны төшерергә телиләр һәм "уполномоченный", ахыр чиктә, аларга ярдәм итә.

***

Мәчеттәге вазыйфаларыннан тыш, Габделбари хәзрәт үз гомерендә бик күп хезмәтләр язарга өлгерә. Язганнарның күпчелеге теге яки бу дәрәҗәдә Коръән белән бәйле. Мондый үзенчәлек Исаев хезмәтләренә аерым игътибар таләп итә. Габделбари хәзрәт эшчәнлегенең бу үзенчәлеген тирәннән аңлар өчен, без тарихи контекстка күз салдык.

Торгынлык чорында, диннең беренчел чыганакларына, ягъни Коръән белән хәдисләргә мөрәҗәгать иткәндә, совет заманының прогрессив риторикасына һәм модернизациягә йөз тотыла. Дин белгечләре Коръәнне совет чынбарлыгына мөмкин кадәр якынайтып тәрҗемә итәргә омтылсалар да, дәүләт түрәләре, катгый чикләр куеп, хәтта советлаштырылган ислам әдәбиятын күпләп нәшер итүдән тыялар. Советлар Союзында дингә каршы алып барылган

---

1. Бу хатлар Габбас хәзрәт Бибарсовның шәхси архивында, "Дела покойного муфтия Шакира Хиалетдинова" дип исемләнгән махсус папка эчендә саклана. Тулы текстларын түбәндәге "Хатлар" бүлегендә карагыз.

пропаганда аркасында рәсми ислам дискурсының яшәвенә өмет өзелә. Бу инкыйлабка кадәр белем алган соңгы буын дин әһелләрен күңелендә тулысынча өметсезлек хисе уята.[1] Торгынлык чорында алар: "Ахыр-заман якынлашты", - дигән фикер белән үлеп барганнар. Тик, берничә ел үтүгә, ил буенча яңадан мәчетләр ачыла башлый.

Советлар чорында ислам дини тәгълиматы репрессияләр, рәхимсез атеистик сәясәт аркасында яшәүдән туктый дигән фикерне фәнни әдәбиятта еш очратырга туры килә. Бу чордагы ислам мәдәниятенең фаҗигале югалтуларын инкяр итү дөрес булмас иде. Шулай да, минем фикеремчә, Совет заманында дини традицияләр тулысынча юкка чыкмыйлар, еш кына алар башка формага керәләр. Мәсәлән, мин җомга вәгазьләре, дин мәсьәләләренә ачыклык керткән шәхси хатлар[2] кебек ислам әдәбияты жанрларының үсүен илдәге дини вазгыять белән турыдан-туры бәйләп карыйм. Ә аларның кайберләре, гомумән, инкыйлабка кадәрге юнәлешләрне дәвам итә. Шул исәптән, дини шигърият һәм, бигрәк тә, төрки телдәге Коръән тәрҗемәсе.

Коръән - һәр мөселман өчен ислам турындагы төп белемнәрнең чыганагы. Мәгълүматларга караганда, һәрбер мөселманның, ягъни шәхеснең[3] Коръәнгә йөз тотуы 1910-1920 елларда башлана. Моның сәбәбе - Муса Бигеев (1973-1959), Зыяэтдин Камали (1873-1942), Борһанетдин Шәрәф (1883-1942), Мөхәммәд-Садыйк Иманколый (1870-1932) кебек танылган дин әһелләренең, бер-бер артлы, Идел буе төрки телдәге Коръән тәрҗемәләрен чыгаруы[4]. Коръәнне бу рәвешле үз

---

1. Бу өметсезлек кайбер әдәбият белгечләре арасында да сизелә. Мәсәлән, Бустанов Ә.К. Татар археографы Альберт Фәтхинең шәхси архивы // Фәнни Татарстан, 2015 (1), 112-126 б.; Бустанов А.К. Пересмотр концепций советского ислама: Зайнап Максудова и изучение татарской литературы // Ислам в мультикультурном мире. Казань, 2014. С. 482-488.

2. Боларның мисаллары бу китапка кертелгән.

3. Шәхес (individual) дигәндә мин соңгы вакытта көнбатыш әдәбиятында таралган фәнни бәхесләрне истә тотам. Аларның төп фикере – совет заманында кешеләр үзләрен һәм үзләре яшәгән җәмгыятьне тәсвирлау өчен яңа тел һәм ысуллар таба. Бу турыда тулырак: Halfin Igal, Hellbeck Jochen. Rethinking the Stalinist Subject: Stephen Kotkin's "Magnetic Mountain" and the State of Soviet Historical Studies // Jahrbuecher fuer Geschichte Osteuropas. Vol. 44 (1996); Хеллбек Й. Личность и система в контексте сталинизма: попытка переоценки исследовательских подходов // Крайности истории и крайности историков. Сб. статей к 60-летию проф. А. Ненарокова. М., 1997. С. 195—207; Hellbeck Jochen. Writing Self in the Time of Terror: Alexander Afinogenov's Diary of 1937 // Self and Story in Russian History / Eds. Laura Engelstein, Stephanie Sandler. Cornell University Press, 2000. P. 69-93; Idem. Speaking Out: Languages of Affirmation and Dissent in Stalinist Russia // Kritika. № 1/1 (Winter 2000). P. 71-96; Idem. Diary of Stepan Podlubnyi, 1931-1939 // Stalinism: New Directions / Ed. Sheila Fitzpatrick. L.; N.Y.: Routledge, 2000; Idem. Working, Struggling, Becoming Stalin-Era Autobiographical Texts // Russian Review. 2001. July. P. 340-359; Halfin Igal. From Darkness to Light: Student Communist Autobiography during NEP // Jahrbuecher fuer Geschichte Osteuropas. Vol. 45. 1997. № 2. P. 210-236.

4. Батыркаев Т. Кораническая экзегетика мусульман Поволжья и Приуралья (конец XVIII- начало XX вв.) // Памятники письменности Востока 2 (9), 2008. С. 104-130.

итү госманлылардагы охшаш хәрәкәт белән якынча бер үк вакытта бара[1]. Һәм бу процесс үз тамырлары белән исламның әүвәлге дәверләренә, мөселманнар алып барган бәхәсләргә барып тоташа. Ул заманда дин әһелләренең бер төркеме Коръәнне туган телдә укуны хуплап чыгалар (сүз еш кына фарсы теле хакында бара)[2]. Соңрак, халык арасында дин тарату мәсьәләсе, нигездә, чишелгәч, Коръән теленә мондый караш маргиналь булып санала башлый. Милләтчелек һәм тел мәсьәләсенә карата фикерләр үзгәрү тәрҗемә итү идеясен яңадан торгызырга мәҗбүр итә. Тел мәсьәләсе дигәннән, монда әдәби төрки тел дә (аны алынмалардан арындырып, гади халыкка якынайту), изге Коръән теле дә күздә тотыла. XX гасырның беренче утыз елларында Коръәннең иң түбән белемле кеше дә укып аңлый алырлык нөсхәсен булдыру максатыннан эш башкарыла. Ләкин төрле вакыйгалар сәбәпле, Россия империясенең – соңгы, Советлар чорының беренче елларындагы Коръән тәрҗемәләре я онытылып, я репрессияләр вакытында югалып калалар, үз укучысына барып ирешмиләр.

Сталиннан соңгы чорда рәсми исламны, мөфтиятләр эченә кертеп, институтлаштыру[3] совет мөселманнары өчен Коръән тәрҗемәсен дәвам итүгә этәргеч бирә. Безгә бу чорда башкарылган ике тулы Коръән тәрҗемәсе мәгълүм. Шуларның берсенә кагылышлы мәгълүмат өчен без студентыбыз Мансур Газимҗановка рәхмәтле. Ул Казан архивында Норлатта яшәгән пенсионер Мотыйгулла Сөнгатуллинның (1891-?) дин эшләре бүлеге мөдиренә исемләнгән мөрәҗәгатен тапкан. Бу хатта ул Коръәнне тулысынча тәрҗемә итеп бетерүен һәм аны нәшер итү ниятен белдерә. Хөкүмәт каршы килмәсә дә, гарәп шрифтлары белән алар гына эш итәләр дип, аны Урта Азия һәм Казахстан Диния Нәзарәтенә, Ташкентка юллый. Шулай итеп, бу хезмәтнең эзләре Ташкент тирәсендә югала да. Моның белән бәйле документны биредә тулысынча китерү урынлы дип табабыз:

---

1. Госманлы тәрҗемәләр турында тулырак бу китаптан белеп була: Brett Wilson, Translating the Qur'an in an Age of Nationalism: Print Culture and Modern Islam in Turkey. London: Oxford University Press, 2014.

2. Бу турыда бик тәфсилле һәм төпле монография бар: Travis Zadeh. The Vernacular Qu'ran. Translation and the Rise of Persian Exegesis. Londod: Oxford University Press, 2012.

3. Совет мөфтиятләренең барлыкка килүе махсус диссертациядә өйрәнелдә: Eren Tasar, Soviet and Muslim: The institutionalization of Islam in Central Asia, 1943–1991. Ph.D., Harvard University, 2010.

г. Москва, Кремль
Председателю Совета министров
товарищу Косыгину А.Н.
от пенсионера – Сунгатуллина М.Б. (1891 г.)
проживающего: ТАССР, г. Нурлат – Октябрьский,
ул. Западная, 19

## Заявление

Обращаясь к Вам вторично с заявлением, прошу Вас убедительно удовлетворить мою просьбу к публикации Корана.

Довожу до Вашего сведения о том, что счел своим долгом вложить свой труд по линии религии, т.е. в опровержении и переводе Корана с арабского на татарский язык, над которым работал в течение 40 лет (с 1920 – 1967 г.) еще с тех времен, когда был в милицейской службе.

Руководствуясь словами В.И. Ленина, что «религия дурманит народные массы». Я прочел множество религиозных книг в поисках правдивости выдержки В.И. Ленина. Прочитав 138 раз Коран и убедившись в правдивости В.И. Ленина, что существующая религия до переходного и после переходного периода от капитализма к социализму была предназначена с целью наживы, обмана и одурманивания народных масс отдельными верхушками буржуазии. Коран с арабского языка во многие национальные языки переводился в искаженном виде. Я же, будучи участником двух Отечественных войн и находясь на службе в милиции в период Гражданской войны неустанно (тайком от знати религиозных верхушек) решил заняться переводом и опровержением искаженных пунктов Корана, издан[н]о[го] [в] 1312 году в г. Багдаде. По арабскому корану 1312 г. (существует) и написана одна единственная вера для всех национальностей и народностей на земном шаре, но муллы прошлых столетий в интересах обмана народных масс написанную веру (одну) с арабского Корана разделили на множество частей, что является ложью. Мой скромный труд – перевод Корана с арабского на татарский язык с опровержением в 1460 страниц, который написан собственноручно, прошел следующие рецензии:

по направлению секретаря ЦК КПСС т. Брежнева Л.Н. (у которого был на приеме 24 января 1967 г.) был на приеме в Смоленском бульваре г. Москвы у Пред. Совета по делам религий т. Саидбаева, который, одобрив мою рукопись, направил в духовенство Узб.ССР г. Ташкент.

С 10 мая 1967 г. – 31 июля 1967 г. все муллы действующих мечетей Узбекистана и Казахстана, прочитав мою рукопись в опровержении и переводе с арабского на татарский язык (Корана), были потрясены лживостью существующей религии, а также были признательны, что моя рукопись с опровержением в переводе является тем фактом, что для всех национальностей и народностей написана одна единственная вера по Корану, изданного в 1312 г. гор. Багдад.

Прошу Вас дать разрешение об издании мою рукопись.
Прошу просьбу удовлетворить. С просьбой к Вам
Сунгатуллин М.Б.
ТАССР, г. Нурлат – Октябрьский,
Ул. Западная, 14.[1]

Бу кызыклы документның теле аерым игътибарга лаек. Дәүләт башлыкларына мөрәҗәгать иткәндә, үз тәрҗемә эшенең дингә каршы булуын күрсәтеп (моның чыннан да шулаймы икәнлеген, төп нөсхәсен күрмичә әйтеп булмый), Сөнгатуллин үз максатларын совет идеологиясе телендә аңлата. Дәүләт хезмәткәре (хәтта милиция хезмәткәре) һәм Ватан хакына кан түккән кеше буларак, аның бурычы – кешеләргә Коръән сүзен аңлатып, ислам динен дөрес аңлауга өндәү. Сөнгатуллин фикеренчә, ул вакыттагы дин төрле хата-ялгышларга бай, ул гади кешеләрне алдау өчен, буржуаз түрәләрне баетыр өчен шулай эшләнгән. Марксистик риторика биредә мөһим роль уйный, чөнки 1920-30 елларда пролетар галимнәр арасында ислам дине хакында күпсанлы бәхәсләр алып барыла. Уйдырма дәлилләргә нигезләнеп, алар ислам динен халык массаларын изәр өчен булдырылган дип карый, шуңа күрә бу дин яшь Совет дәүләте тарафыннан һөҗүм ителеп, юкка чыгарылырга тиеш була.[2] Әмма Сөнгатуллинның максаты башка төрлерәк була: ул Багдад шәһәрендә бастырылган Коръәннең «төп нөсхә»сен алып, ислам диненең саф дин икәнлеген раслый, элек ясалган тәрҗемәләрнең хаталарын төзәтә.

XIX гасыр ахырында һәм XX гасыр башында ислам дөньясында динне кеше уйдырмаларыннан, төрле бидгатьләрдән пакьләү хәрәкәте киң тарала.[3] Коръән

1. Государственный архив Республики Татарстан. Фонд Р-873, оп. 1, д. №25, л. 25. Монда текст үзгәртүсез бирелә.

2. Бу бәхәсләр, чынлыкта канлы һөҗүмгә юл ачтылар: Michael Kemper, “The Soviet Discourse on the Origin and Class Character of Islam, 1923-1933,” Die Welt des Islams vol. 49/1 (2009), 1-48.

3. Ingeborg Baldauf, “Jadidism in Central Asia within Reformism and Modernism in the Muslim World,” Die Welt des Islams 41/1 (2001), 72-88.

һәм хәдисләргә зур игътибар бирү белән бергә, «хак ислам динендә булмаган» хорафатларга каршы чыгу – әлеге хәрәкәтнең бер мисалы. Сөнгатуллин Россиядәге надан муллаларның хаталарын чит илдән китерелгән чын Коръән абруена каршы куя. Аның фикеренчә, бу хаталарга рәддия (кире кагу) язу ярдәмендә ислам диненең чын мәгънәсен аңлап була. Кызганыч ки, Сөнгатуллин тәрҗемәсе дөнья күрми. Киләчәктә аның кульязмасы әле табылыр дип өметләник.

Икенче тәрҗемәченең язмышы отышлырак булып чыга. Коръәнне ундүрт яшендә тулысынча ятлаган Габделбари Исаев изге Китапны төрле яклап өйрәнүгә күп көч куя. Аның «гыйльми шәҗәрәсе», карашларының чыганагы түбәндәгедән гыйбарәт: аңа остазы Зыяэтдин Камали зур йогынты ясый. Зыя Камали Уфадагы яңа ысуллы Хөсәения мәдрәсәсендә, аннан соң Каһирәнең әл-Әзһар университетында Мөхәммәд Габдуһ (1849-1905) кулы астында белем ала. Мөхәммәд Габдуһ ислам реформачылыгының төп идеологы, илһамландыручысы. Ул, шулай ук, Коръәнгә күләмле аңлатмалар бирүче автор буларак билгеле[1]. Остазлары үрнәгендә Габделбари Исаев гомерен Коръән гыйлеменә багышлый. Шул рәвешле, Исаевта Коръән текстына юнәлү белән бергә, исламны прогрессив ясарга теләүче җәдидчеләргә хас булган пуритан-лык берләшә.

Реформаторларның иҗтимагый челтәре транцнациональ булганлыктан, репрессия чорын өлешчә үткәреп җибәрә. Уфада һәм Ленинградта яшәгән дәвердә Исаев совет җәмгыятенә шактый уңышлы кушылып китеп, чын совет кешесе кыяфәтен ала: авыр кул эшеннән дә баш тартмый, күкрәге дә сугыш медальләре белән тулы. Әмма шул ук вакытта, безнең фикеребезчә, Исаевның самими ихласлыгы, Советлар Союзында шәригать буенча яши алу мөмкинлегенә инануы рәхимсез чынбарлык белән яңадан каршылыкка керә. Әлеге чынбар-лыкта Коръәнне аңлату, тәфсирли белүдән бигрәк “большевикларча сөйли алу”[2] кыйммәткә ия. Ягъни торгынлык чорында, җәмгыяви төрлелек шартла-рында, совет тормышының иң ихлас тарафдарлары да чыга алмаслык кысалар һәм чикләр була.

Исаевка үз гомерендә ислам оешма-институтларын ике мәртәбә калды-рырга туры килә. Беренче мәртәбә ул, 1967 елда, имам буларак, мәчетне яхшы хәлгә китереп, ремонтлап чыккач, үз вазыйфасыннан китәргә мәҗбүр була. Сәбәбе – җирле («уполномоченный» юллаган) провокаторлар белән ике ара-да чыккан каршылык. Бу өлкәне бер дистә елга калдырып торганнан соң, 1975

1. Мөхәммәд Габдуһның унике томлык «Тәфсир Мәнар» әсәре 1927 елда дөнья күрә.

2. Stephen Kotkin, Magnetic Mountain: Stalinism as a Civilization. University of California Press, 1997.



# طبّ نبوی

محرری :

مجلس طبیهٔ ملکیه وصحیهٔ عمومیه وجمعیت طبیهٔ عثمانیه اعضای مؤسسه‌سندن
وپارسك (معارف قدیمهٔ شرقیه جمعیت علمیه‌سی) اعضاسندن مکاتب
عالیهٔ شاهانه علم حیوانات معلمی میرآلای

دوقتور حسین رمزی

П. Камалединъ
ИМАМЪ ХАТЫБЪ
МУДАРРИСЪ

مندرجات :

محافظهٔ صحت بدنیه ومداوات طبیه وحمیات وتداوئ بالماء وعلل
ساریه وامر تحفظیه وتطبب حقلرنده قرق ایکی عدد احادیث
نبویه‌یی شاملدر

معارف نظارت جلیله‌سنك ٤٦١/١٦٣٨ نومرولی و فی ١٧ کانون اول
سنه ٣٢١ تاریخلی رخصتنامه‌سنی حائزدر

طابع وناشری : شرق کتبخانه‌سی صاحبی حاجی قاسم

مهرسز نسخه‌لر ساخته‌در

استانبول

باب عالی جاده‌سیده رشید افندی خاننده ٢٨ نومرولی قصبار
مطبعه‌سنده ایکنجی دفعه اوله‌رق طبع اولنمشدر

١٣٢٤

Зыя Кәмали тарафыннан Габделбари Исаевка бүләк ителгән «Тыйбе нәбәви» исемле китап.

елда Исаев үз карьерасының чәчәк аткан чорын Уфада, мөфти вазыйфасында башлап җибәрә. Анда ул, атеистик пропагандага колак салмыйча, мәгърифәт эшен җәелдереп, бер төркем дини әсәрләр, җомга вәгазьләрен нәшер итәргә ниятли.[1] 1977 елның февраль аенда хәзрәт үз язмышы турында мондый шигырьләр яза:



Әлхәмдүлиллаһ, мең хәмедләр,
Ирештердең бөек теләккә!
Сабыр иттем, Ходам хаккы өчен,
Авыр булганда да йөрәккә.
“Сабырлыкның төбе – сары алтын”,
Моны әйткән бөек бабайлар.
Миңа дошман булган надан халык
Исе китеп карап калалар:
Кайда барсам, миңа бөек хөрмәт,
Бар да хезмәт итә алдымда.

Безнеңчә, Исаевның совет тормышын никадәр идеальлаштыруы Ленинград кешесе Хәнифә Җамалиева белән низаглы язышуда ачык күренә. Җамалиева аны үз хатларында дәүләт милкен талаучы, әхлаксыз кеше дип атый. Аның максаты Исаевны хур итү булса кирәк. Хатның икенче нөсхәсен Җәмалиева «махсус оешмалар»га җибәрә. Мөфтинең җавап хаты күтелгәнчә килеп чыга. Шундый ук типта җавап язып, административ чаралар куллану урынына, ул Коръән-хәдис өзекләреннән торган күп битле хат юллый. Гаепләүләрне аерым-аерым кире кагып, Исаев, мәсәлән, менә болай яза:

“Хәнифә, әлбәттә, мин сезне белмим. Сезнең белән аралашкан кеше түгел. Шулай ук безнең хәлебездән бер тиенлек кенә хәбәрегез дә юк, ләкин сезнең ахмаклыгыгызга исем китә. Һәм вакытым булмаса да, ошбу язуны сезгә язуны зур бурычларымнан саныйм, чөнки «Мин динле», - дип,

1. Аның турында тулырак түбәндәге Мөхәммәт-Парса Ахатов (Киев шәһәре) белән язушулы хатларында карагыз.

юлдан чыккан кешеләрне мөфти булу мөнәсәбәте белән юлга төшерү бөек һәм тиешле бурычлардан. Аллаһ Җәллә-җәләлә Коръән Кәримдә һәрбер адашкан кешене юлга төшерү һәр мөэминнең бурычы итеп куйган, чөнки әгәр дә мин сезгә аңлатмасам, моның өчен мин Аллаһ хозурында җавап бирәчәкмен. Ләкин бәгъзе бер мәгънәсез кешеләрне юлга Аллаһ төшермәс, бәндә төшерә алмауны һәм ачык белдергән."

Совет чоры җәмгыятендә низагларны чишүгә мондый караш, мөгаен, уңышка юлыга алмыйдыр.[1] Шунлыктан нәтиҗәсе дә билгеле. Үз вазыйфаларын калдырып китәр алдыннан, Исаев махсус тикшерү оешмаларына мөрәҗәгать итәргә карар кыла. Бастырып чыгу үтенече белән, үзенең төп хезмәтләрен, Коръән, хәдис тәрҗемәләрен, вәгазьләр җыентыгын җибәрә (бу урында югарыда телгә алынган Мотыйгулла Сөнгатуллинны искә төшерергә кирәк). Мөфтинең мондый активлыгы хөкүмәткә хуш килми: 1980 елда Исаев мөфтият эшен калдырырга мәҗбүр була. Бу вакыйганы төрле кешеләр төрлечә аңлата. Без фактларга таянып, шуны әйтә алабыз: беренчедән, Ленинградтагы имамлык вакытыннан ук Исаев мөфти Хыялетдиновтан үзен кире Уфага җибәрүне сорый һәм, икенчедән, Исаевның хатларыннан ачык күренгәнчә, ул Уфадан китәргә җыенмый, киресенчә, мөфти булуны килештереп (хезмәтнең авырлыгына карамыйча), бу вазыйфада ислам диненә файда китерә алуына ул чын күңелдән ышанган була. Нәкъ менә бу ышаныч аның өчен зур хатага әйләнә.

Габделбари Исаевның шәхси архивында гаҗәеп күп санда кульязмалар саклана. Аларның бер өлешен без бу җыентыкка кертәбез. Әлеге язмалар аша аның иҗади остаханәсе, Коръәнне күпьеллар дәвамында өйрәнүе хакында, турыдан-туры, төрле юрауларга ышанмыйча, хөкем итәргә була. Исаевның барлык язма мирасы теге яки бу дәрәҗәдә Коръән белән бәйле. Хәтта дусларына юлланган шәхси хатлары да Коръән өзекләре, шуларның тәфсирләре белән тулып ята. Коръән тәрҗемәсенең беренче караламалары 1950 елларга – Ленинградтагы, я тагын да иртәрәк – Уфадагы имамлык чорына карый.

Исаев методикасы Коръән аятьләре язылган карточкалар ясаудан гыйбарәт. Аларны ул атна саен алып барылган вәгазьләргә әзерләнү өчен куллана. Кайберләрендә тәрҗемә итү омтылышлары да очрый. Аннан соң ул карточкаларны классификацияләп (төрләргә бүлеп), татар теленә тәрҗемә итү эшен башлап җибәрә. Карточкаларга нигезләнеп, Исаев Коръәнгә, пәйгамбәрләргә,

---

1. Замалеева җибәргән хат тибындагы шикаятьләр совет чорында ничек эшләгәннәрен Шейла Фицпатрик китабыннан белеп була: Фицпатрик Ш. Срывайте маски! Идентичность и самозванство в России XX века. М., 2011. С. 237-274.

христиан, яһүд диненә, космос белән бәйле аятьләргә багышланган әсәрләр яза. Барлык материалларны Габделбари хәзрәт, иң элек, җомга вәгазьләрендә сөйләп карый. Нәтиҗәдә, вәгазь жанры сугыштан соңгы чорда дини фикер матрицасы буларак яши.

Хәзрәтнең тагы бер теләге – Коръәнне татар теленә тулысынча тәрҗемә итеп, аны русчага күчерү. Татарчага тәрҗемәнең бердәнбер нөсхәсе Габделбари хәзрәтнең кызы Фия ханымның шәхси архивында, Дүшәнбе шәһәрендә сакланып кала. Кульязманың тулы күләме – 1289 бит. Бу китап киң җәмәгатьчелеккә аталганга күрә, аны Габделбари Исаев кирилл хәрефләре белән яза. Шуңа күрә текст эченә мишәр диалектына караган кайбер үзенчәлекләр белән бергә шактый күп орфографик һәм стилистик җитешсезлекләр дә кереп кала, аларны безгә төзәтергә туры килде.

Шуның белән беррәттән Исаев совет мөселманнарына ислам фәлсәфәсен җиткерергә тиешле үзенең төп хезмәтен – «Ислам дине»нең берничә вариантын булдыра. Коръән Мөхәммәд Габдуһ тәфсиренә таянып тәрҗемә ителсә, бу хезмәте исә Зыяэтдин Камалига булган сылтамалар белән чуарланган. Шулай итеп, бу мисалга таянып, Брежнев «торгынлыгы»ндагы ислам реформациясенең иҗтимагый чалтәрен күзәтә башларга була.

Шуны әйтергә кирәк: Исаев Коръәннең рус тәрҗемәләренә дә, миссионер-шәрыкчеләр тәкъдим иткән Коръән гыйлеменә дә катгый тәнкыйди караш йөртә. «Ислам дине» хезмәтендә ул болай яза:

> «Коръән переводлары да күбесе куркыныч, ислам диненең катгый дошманнарыдыр. Бигрәк куркыныч: хәзерге вакытта балалар рус хәрефе белән русча гына укый беләләр. Шулай булгач, Саблуков тарафыннан русча тәрҗемә ителгән Коръәнне укып, шуннан мәгълүмат алган кеше ничек итеп ислам диненең хакыйкатен дөрес аңлап дөрес хөкем итә алсын?! Саблуковның переводы баштан азагына кадәр меңләрчә хата, бозык, ислам диненә пычраклык тутырылган. Шулай ук Казимирский переводы да хата, ифтира, истиһзадыр. Инде Крачковский перевод булса, дөрес, ул - гарәп телен чын белүче, ләкин Коръәнне тәрҗемә итү өчен тел белү генә җитмидер. Тел белү берлән генә Аллаһның хөкемен дөрес аңлап булмыйдыр. Коръәнне дөрес аңлау өчен ислам динне тәмам белүче булу ләземдер».

Монда шунысы мөһим: Исаевны исламның руслаша баруы борчымый (бу



٢ البقرة ١٣٦

قولوا امنا بالله وما انزل الينا
وما انزل الى ابراهم واسحق ويعقوب
والاسبط وما اوتى موسى وعيسى
وما اوتى النبيون من ربهم لا نفرق
بين احد منهم ونحن مسلمون.

Коръән белән эшләү үрнәге. 1960 еллар. «Сыер», 136.



مباحث اللباس والزينة
اللباس والزينة ٨ آيت

Коръәннең тематик тәрҗемәсе. 1970 еллар, Уфа.
Кием һәм зиннәткә (бизәкләүгә) багышланган өлеш.

процесс ун-егерме елдан соң гына ачыкланачак).[1] Рус тәрҗемәләрен тәнкыйтьләгәндә, ул совет шәрыкчеләренең абруйлы фикерләрен шик астына куя. Аның әйтүенә караганда, ислам турындагы ялгыш уй-хөкемнәрдә хисапсыз китап авторларының хәбәрдарсызлыгы гаепле. Һәм исламның «чын» эчтәлеген Коръән аңлатмаларына гына мөрәҗәгать итү ачыклый ала. Бу рәвештәге караш һәм христиан миссионерларын тәнкыйтьләү (Брежнев чорындагы Уфа, Ленинградта алар, аңлашыла, юк иде инде) – Исаев хезмәтләренең традицион өлеше. Ул, үз чиратында, тамырлары белән Якын Көнчыгыш һәм Рәсәйдә мөселманнар-христианнар арасындагы әдәби яктан бай, динара монazaралар традициясенә барып тоташа.

Игътибарны җәлеп иткән тагын бер мәсьәлә - «чын», «саф» исламны күрсәтергә теләүче Исаев текстларының совет космонавтикасы чорына сылтамалар белән тулы булуы. Бу аспектка бәйле лексиканың тулысынча рус алынмаларыннан торуы бер дә гаҗәп түгел, гәрчә алар гарәп язуында язылсалар да. Мәсәлән, Коръәндәге «күк»не аңлаткан «сәмәвәт» сүзе (к.с. سماء) Исаевта «планета» кебек тәрҗемә ителә (аның фикеренчә, «күк»тә бушлыкка, яки космоска ишарә бар); планеталарның үз орбиталары буенча хәрәкәт итүенә дә Коръәндә طباقا - «дәрәҗәләр, рәтләр» сүзе табыла. Космос төзелеше Исаевны бик кызыксындыра.

«Ислам дине» хезмәтенең күпчелек битләрендә Исаев Коръән һәм хәдистән галәмнең космик төзелешенә кагылышы булган өземтәләр китерә һәм аларны, мөгаен, совет космонавтикасы казанышларыннан тәэсирләнеп яза. Коръәнне аңлатуга төгәл фәннәр аша якын килүенең сәбәбе – классик тәфсирләрдән тыш Европа галимнәре тәрҗемәләрен актив куллану. Димәк, Исаев шәрыкъ халыкларының артта калуы хакындагы ориенталистикада күптән яшәп килгән фикерне кабатлый: мөселманнар Коръән хикмәтен кулланмыйлар, европалыларның техник өлкәдә шактый алга китүләре моның белән аңлатыла. Фәкать Коръәнне дөрес аңлау җитә. Мөселманнар алдында, европалылар очрагында кебек үк, мәгърифәт, хаклык ишекләре ачылачак. Бу караш XIX гасыр ахырында - XX гасыр башында Якын Көнчыгыш, Россия империясендәге ислам реформаторларының Коръәнгә мөрәҗәгать итеп, технологияләрне Европадан үзләштерергә кирәк дигән тәкъдиме белән тулысынча туры килә[2].

1. Bustanov A.K., Kemper M. Islamic Authority and the Russian Language: Studies on Texts from European Russia, the North Caucasus and West Siberia. Amsterdam, 2012.

2. Ingeborg Baldauf, "Jadidism in Central Asia within Reformism and Modernism in the Muslim World," Die Welt des Islams. Vol. 41, Issue 1 (March 2001), 72-88; Khalid A., The Politics of Muslim Cultural Reform: Jadidism in Central Asia. Comparative Studies in Muslim Societies, 27. Berkeley: University of California Press, 1998.



کتاب حاجی زین العابدین تقیوفنگ اهتماميله

چاپ اولنوبدر

كتاب كشف الحقايق

عن نكت الايات والدقايق

تفسير قرآن شريف ترک آذربايجان ديلينده

اوچنجی جلد

مؤلف و ناشری : اقل العلما مير محمد كريم نجل

الحاج مير جعفر العلوی الحسينی الموسوی الباكوی

صدر غوبرنسكی مجلس و قاضی ولايت باكو

١٥ ماه شعبان سنه ١٣٢٢

«كاسپی» غزته‌سنگ بخاريه مطبعه‌سنده چاپ اولندی

Коръән тәфсиренә багышланган «Китаб кашфел-хакаик» исемле китапның тышында: «1965нче ел октябрь 14ндә Эчке Русия һәм Сибирия мөселманнарының Диния Нәзаратында рәис әл-хаж мөфти Шакир б. Шәехелислам Хыялетдинов җәнабләренең һәдиясе тапшырылды Ленинград җамигендә имам-хатыйб әл-хаж казый Габделбари б. Низаметдин Исаевка» дип язылган.

Карашларның бу рәвешле туры килүе бер дә гаҗәп түгел, чөнки Исаев - әлеге интеллектуаль традициянең турыдан-туры варисы. Күңелне боза торган бердәнбер әйбер – Советлар Союзында дингә мөрәҗәгать итү берничек тә

киләчәк прогресс белән ассоциацияләнми, ә киресенчә. Исаев хезмәтләрендәге чишелә алмаячак төп каршылык та шул: инкыйлабка кадәрге ислам реформизмыннан калган күзаллаулар Брежнев торгынлыгы чорында искелек калдыгы булып күренә. Исаев ничек тырышса да, ислам белән прогресс төшенчәләре ул чорда капма-каршы мәгънәдә йөриләр.

Коръәндәге иҗтимагый терминологиягә Исаев, шулай ук, прогрессив төсмерләр кертә, шуңа күрә дә фи'атун сүзен, аның синонимнарын да группа сүзе белән тәрҗемә итә. Хатын-кызларның исламдагы роленә кагылышлы сорауларга да ул прогрессив күзлектән чыгып карый. Бу мәсьәләләргә ул үз китабында («Ислам дине») тулы бер бүлек багышлап, бу юнәлештәге Коръән аятьләрен тәкъдим итә. Анда хатын-кыз - җәмгыятьнең тигез хокуклы бер өлеше.

Калдырылган намазлар, аларны каза кылу темасы Исаев аңлатуларында аерым игътибарга лаек. Монда Совет җәмгыятенә хас хезмәт культы ачык күренә. Бу уңайдан Киевтагы хезмәттәше Мөхәммәт-Парса Ахатовка язганда, ул эшче һәм эшсез кешеләрнең аермасын төгәл күрсәтә. Эшсезләр, лаеклы ялдагылар фаизат-манәнтум хәлендә булганга, намазны үз вакытында кылырга тиешләр. Ә эшчеләр үзләренә яраган вакытта гына түгел, кылу ысулын үзгәртеп, басып, хәрәкәттә, уй-фикердә намаз кыла алалар икән. Чөнки намаз максаты дип тәзкият ән-нәфс – йөрәк сафлыгы санала. Мондый катгый булмаган фикерләрнең сәбәбе дә билгеле: бер яктан, Совет чынбарлыгын күз алдында тоту зарурлыгы булса, икенче яктан, ритуаль гыйбадәтсез дә мөселман булып санала алу ихтыяҗы. Бу компромисс карашны да Исаев Коръән тәфсире нигезенә сала.

Исаев очрагында ислам дискурсының советлаштырылуы дини тәгълимат дәлилләренең катгыйлыгы белән каршылыкка керми. Монысы ачык күренә. Аның барлык шәрехләүләре я Коръәнгә, я хәдискә яисә элекке дин белгечләре хезмәтләренә нигезләнә. Моннан тыш, кайбер вакытта Исаев совет кануннарына сыя алмый торган катгыйлык күрсәтә: Мөхәммәд-Парса дустының карак җәзасы турындагы соравына ул Коръәннән тиешле мисал белән җавап бирә (5:38). Кулны кисеп алу хакындагы бу мисалны ул, дөрес, тәрҗемәсез (шәрехләүгә урын калдырыпмы) тәкъдим итә. Әлеге җавапка нигезләнеп, билгеле, Киевта каракларның кулын кисәргә тотынмыйлар (урлау булган очракта «шәригать» кануннары буенча да хөкем чыгару мөмкин түгел диярлек). Шулай да бу очракта Исаев карашларында исламны советлаштыруга ике төрле фикер урын алганы ачык күренә. Һәм моның нигезен, һичшиксез, «ислам асылына кайту» риторикасы, Совет космонавтикасы һәм ислам җәмгыяте реформасына җәдиди

карашлардан һ.б. торган гаҗәеп синтез тәшкил итә.

***

Ленинград шәһәренә кайтканнан соң, Габделбари хәзрәтнең бөтенләй яшисе килми башлый: гомер буе ислам дине өчен көрәшкәннән соң, ул бу көрәшнең файдасызлыгын ачык күрә. Совет дәүләтендә шәригать буенча яшәрү өчен ирек юклыгын аңлый. Көне-төне язган бер дистә кулъязма әсәрләренең берсе дә дөнья күрми. Әмма хәзрәтне тагын да көчлерәк кайгы сагалый: 1982 елның 3 августында Габделбари хәзрәтнең хәләл җефете вафат була. Бу кайгыдан хәзрәт айнымый, иң якын дустын югалту аның өчен бик авыр була. Сөйгән хатынына багышлап, ул бер җыентык шигырьләр иҗат итә һәм аларны магнитофонга да яздырып калдыра. Хәзрәтнең соңгы шигырьләре өметсезлек белән тулы, аның өчен бар дөньяның яме югала башлый. Нәтиҗәдә, башыннан кичкән кайгыларга Габделбари хәзрәтнең йөрәге түзми. 1983 елның 13 ноябрендә иртәнге сәгать биштә фани дөньяны калдырып китә. Бу китапны бастыру һәм Габделбари Исаевның исемен, мирасын халыкка кайтару гаделлекне урнаштыруга бер адым булыр иде дип өметләнәбез.



Дөрес, балаларым искә алыр,
Сирәк булса да, дога барыр.
Минем каберемә кем дә бармас,
Догадан рухым мәхрүм калыр.
Мин, хәмедләр булсын, тулы Коръән һәр көн укыйм,
Искә алам барлык әрвахларны:
Ата-аналарны, бабаларны-балаларны,
Мөэминнәрне, якын дусларны.
Гамәлемне тулы үтим, шөкер Хакка.
Үти бардым, мең шөкерләр, һәм яшь чакта.
“И Ходаем, кабул ит –”, дип, “– Ялвар мине.”

# Коръән тәфсире

## Мөкаддимә[1]

### «Фатиха» сүрәсе – «Әлхәм» сүрәсенең кыскача тәрҗемәсе

«Фатиха» сүрәсе хакында, гомумән, тәфсирләр күп булса да, аның «юктыр бөек идеге»[2] хакында һичбер тәфсир изахы[3] сөйләп күрсәтмәгән «Тәфсир мәнар» Мөхәммәд Габдо хәзрәтләре изахы язмыштыр. Җиребездә Зыяэтдин әл-Камали хәзрәтләре «Фәлсәфә гыйбадәтия» китабында бик кыска хәлдә «Фатиха» сүрәсенең никадәр олуг идеген[4] белдермеш. Ошбуларга игътибар итеп, халык арасында «Фатиха» сүрәсенә бик түбән караулары саесыннан[5] җомга вәгазьләре тәртибендә язмак булдым.

«Фатиха» сүрәсе хакында мөэминнәр арасында сүзләр бик түбән йөртелә, кемнән генә сорасаң да: «Әлхәм», «Кул һүвәллаһ»ны беләм, моннан артык барып булмый», – дигән сүзне ишетерсез. Менә шул «Әлхәм», «Фатиха» сүрәсе хакында Коръән Кәримнең хөкеме ни? «Фатиха» сүрәсен белә алабызмы? Әлбәттә, аны белә-аңлый торган кеше юктыр. Кара син, гыйбарәсен[6] дөресрәк белсәк, Аллаһның кәламе[7] идегене аңласак, мең-мең шөкрана кылырга тиешледер.

«Фатиха» сүрәсе – «мифтахел Коръән»дер, ягъни бөтен Коръәннең ачкычыдыр. Бөтен Коръән шундадыр. Шулай булгач, бу – гаять олуг сүрәдер. «Фатиха» сүрәсе – өммел-Коръәндер[8]. Аллаһ Тәбарәкә вә тәгалә аңлый алган кешеләр өчен «Фатиха» сүрәсе турында Коръән Кәримдә ачык рәвештә аңлатып: سَبْعًا مِّنَ الْمَثَانِي وَالْقُرْآنَ الْعَظِيمَ, – диеп әйтер дә («Хәҗәр», 87). Ягъни: ««Фатиха» сүрәсе Коръән Кәримнең сигез өлешеннән җидеседер», димәктер. Димәк,

1. Мөкаддимә - кереш сүз.

2. Юктыр бөек идеге – аннан да бөегрәк булмаганы.

3. Изах – аңлатма.

4. Идеген – булганын.

5. Саесыннан – ягыннан.

6. Гыйбарә - аңлатма.

7. Кәлам – сүз.

8. Өммел-Коръән – Коръән анасы.

«Фатиха» сүрәсенә бөтен Коръән кереп беткән, тик пәйгамбәрләрнең аерым тарихлары гына кермәгәндер. Ошбуның аңлаган кешеләргә «Фатиха» сүрәсе белән үз гомеренә вәгазь сөйләсә дә, сөйләп бетерү мөмкин түгелдер.

Кыскача гына рәмз[1] рәвешендә сөйләп чыгу мөмкиндер, ләкин Коръән Кәримнең кай[2] аятьне тотып, вәгазь ясалса да, «Фатиха» сүрәсендә барчасы да бардыр. Ошбу өчен тәрҗемә ителгән бәгъзе[3] бер аятьләргә игътибар белән карап барырга кирәк булыр. Менә шул бөек булган «Фатиха» сүрәсе – «Әлхәм» хакында беркадәр тәрҗемә ясарга җөрьәт иттем.[4] Аллаһ җиңеллек бирсен.

Намазларда «Фатиха» сүрәсен уку – бөек догаларда һәм тәмам Коръән уку дәрәҗәсендәдер. Ошбу «Фатиха» сүрәсе – бөек дога, бөек ялвару булганы өчен, «Тәмамында кабул итсен» дигән ният берлән, «Амин» диеләдер.

Моның соңында, ягъни «Фатиха» сүрәсе соңында, намазларда бер-ике яки берничә сүрә кушылып укудан максат. Намаз укучының ялваруының кабул булуына рух кертәдер. Аллаһның кәламе – Коръән Кәримгә таянган вакытта гына кабул булуына ишарәдер. «Фатиха» сүрәсе бөтен Коръәндә сөйләнәчәк сүзләрне кыскача рәвештә үз эченә алганы өчен, Коръән Кәримнең кай гына урыныннан укысаң да, «Фатиха» сүрәсендә сөйләнгән хакыйкатьләрне сөйләве ачык рәвештә мәгълүмдер.

الْحَمْدُ لِلَّهِ [Әлхәмдулиллаһ]

Мәзмүнә[5]: барлык мактаулар Аллаһка гына хастыр. Аллаһтан башка мактаулы зат булу мөмкин түгелдер. Аллаһка хәмд-мактау рәвешле[6] була. Барлык йөреш-торышлар, хәрәкәт, гамәл вә гыйбадәтләр, хәер-ихсаннар, гаилә тәшкил итүләр[7], гаилә тәрбия итүләр, барлык хезмәтләр, әгәр дә Аллаһ боерганча үтәлсә, бар да Аллаһка хәмд, Аллаһны мактау буладыр.

Димәк, адәм баласы дөньяга килү белән, Аллаһка хәмд вә сәнәдә буладыр.

---

1. Рәмз – ымлау, ишарә ясау.
2. Кай – кайсы.
3. Бәгъзе – кайбер.
4. Җөрьәт итү – юнәлү.
5. Мәзмүнә – мәгънәсе.
6. Рәвешле – дәвамлы.
7. Гаилә тәшкил итү – гаилә булдыру.

Ягъни адәм баласы хәяткә[1] Аллаһ әмере белән киләдер. Ул шул Аллаһның әмерен гамәлгә куядыр. Ошбуның өчен Коръәни Кәрим һәрбер дөньяга килүче адәм баласын фитрый[2] иман берлән вөҗүдкә[3] килүне тасдыйк кыладыр[4]. «Рум», 30: فَأَقِمْ وَجْهَكَ لِلدِّينِ حَنِيفًا ۚ فِطْرَتَ اللَّهِ الَّتِي فَطَرَ النَّاسَ عَلَيْهَا ۚ لَا تَبْدِيلَ لِخَلْقِ اللَّهِ, ягъни адәм балаларына боерыладыр: «Сез шул пакь булган, дөрес булган динегездә каим[5] булыгыз, шул дин берлән вөҗүдкә килдегез. Бөтен булган адәм балалары шул дин берлән вөҗүдкә киләдер. Бу – Аллаһның хөлкәтедер[6]. Сез аны алыштырмагыз».

Шул дөньяга килгән вакытта, Аллаһның әмеренә итагать итү[7] – фитрый[8] иманнандыр. Ошбу алыштыру хаинлектер[9]. Мәгълүмдер ки, рухлар халык кылынган[10] вакытта да, адәм балаларының барчасының рухлары да: «Җәнәбе хакка калу – белерсез»[11], – дип җавап бирделәр. («Әл-Әгъраф», 127) Ягъни: «Дөреслектә, без Сине Рабби Аллаһ итеп таныйбыз», – дип, җавап бирделәр.

Адәм баласы ошбуларны аңламыйдыр һәм аңлатучы, төшендерүче дә булмаган. Тик тел берлән «Әлхәмдүлиллаһ» дип әйтсәң генә, Аллаһны тану, Аллаһны мактау була дип хис кылынган, ләкин бу телдән мактау буладыр. Гамәли мактау адәм баласының һәрбер эшләренә хыянәтенә катнашкандыр, ягъни мәхлукатларга, адәм балаларына файда китерү өчен булган бөтен хәрәкәтләр, йөреш-торышлар – һәркайсы ялгыз Аллаһка хәмедтер[12], Аллаһны мактау була. Әгәр дә адәм балаларына зыян итүдән саклансак, бу Аллаһка да хәмедтер, Аллаһны мактаудыр.

Аллаһ боерганча кылынган һәрбер гамәл, хезмәт, нинди генә хезмәт булмасын, Аллаһка хәмедтер. Мәсәлән, берәү станокта хезмәт итә яки каравылда (охрана) тора. Шул хезмәтләрнең эшләп чыгарган нәрсәсе (детальләр) адәм

---

1. Хәят – тормыш.

2. Фитрый – тумыштан булган, табигый.

3. Вөҗүд – барлык, бар булу.

4. Тасдыйк кылу – раслау.

5. Каим – туры, тотучы.

6. Хөлкәт – тәртип, төзелеш.

7. Итагать итү – буйсыну.

8. Фитрый – табигый.

9. Хаинлек – хыянәт.

10. Хәлык кылынган – барлыкка китерелгән.

11. Белерсез – һичшиксез.

12. Хәмед – мактау.

балаларының файдасы өчен хәзерләнәдер. Бу да – Аллаһка хәмедтер. Аллаһ Тәбарәкә вә тәгалә адәм балаларына хезмәт итү берлән әмер итте:

فَامْشُوا فِي مَنَاكِبِهَا وَكُلُوا مِن رِّزْقِهِ («Мөлек», 15), ягъни: «Жирнең иң авыр урыннарында булса да, үзегезнең ризыкларыгызны эстәгез». Вә шул хезмәт бәрабәренә алынган маллар, акчалар фәкать гаиләсене тәрбия итү өчен, үзенең сәламәтлеге-хәятне саклау өчен булгач, бу да Аллаһка хәмедтер.

Моның соңында нинди генә изге гамәл, хәер-ихсан кылынмасын – барчасы да Аллаһка хәмде-сәнәдер, Аллаһны мактаудыр. Бу хәер ихсаннар, гаилә тәрбия итүләре Корьән Кәримдә боерылгандыр: وَآتِ ذَا الْقُرْبَىٰ حَقَّهُ وَالْمِسْكِينَ وَابْنَ السَّبِيلِ وَلَا تُبَذِّرْ تَبْذِيرًا («Бани Исраил», 26), ягъни: «һәрбер өстеңдә хак булган бәндәнең хакын ригая кыл[1], ягъни балаларыгызны, ата-анагызны тәрбия итегез. Моннан соң арткан малың булса, фәкыйрь-мескеннәргә, дини эшләрне алып баруда ингам-ихсан[2] итегез, яныңнан чыгарып, таратып бетермәгез. Аллаһ Тәбарәкә изгелекне таратып бетерергә кушмыйдыр, ягъни һәрбер хәер-ихсанны икътисад берлән эшлә», димәктер. һәрбер яхшы эш Аллаһка хемде-сәнәдер, юлда башка адәмнәргә зарар итә торган ташны алып читкә кую да хәмде-сәнәдер. Ошбуның өчен Аллаһ Табарәкә вә Тәгалә хәмед вә сәнәне күп әйтү белән боергандыр: اذْكُرُوا اللَّهَ ذِكْرًا كَثِيرًا وَسَبِّحُوهُ بُكْرَةً وَأَصِيلًا («Әл-Әхзаб», 41-42), ягъни: «Сез Аллаһны һәрбер эшегездә зикер итегез. Сез Аллаһны күп зикер итү белән боерылгансыз, кичә вә көндезләр зикердә булыгыз», – димәктәдер.

Аллаһ тарафыннан тәкъдир ителгән эшләргә кайгы вә мосыйба[3] вакытларында сабыр итә белү, тәхәммелле[4] булу – Аллаһны тәгъзыймдер[5], Аллаһка хәмд-сәнәдер, чөнки: وَاصْبِرْ عَلَىٰ مَا أَصَابَكَ ۖ إِنَّ ذَٰلِكَ مِنْ عَزْمِ الْأُمُورِ («Локман», 17). Корьән Кәримдә бу тугрыда, ягъни сабырлык хакында житмеш аять бардыр. Мөхәммәд Габдуһ тәфсирендә сүрәтел «Гаср» адәм балаларының кайгы вакытларында, кайгыларыннан нәжәт[6] өчен диелә. Ошбуның өчен сабырлык Аллаһ Тәбарәкә вә Тәгалә өчен иң олуг хәмедтер. Бәрабәр[7] адәм балаларына килгән шатлыклар вә һәрбер эшләрнең уңышлы булуы – барчасы да Аллаһның

---

1. Ригая кылу – хөрмәт итү.

2. Ингам-ихсан – яхшылык эшләү.

3. Мосыйба – авырлык.

4. Тәхәммелле – түземле.

5. Тәгъзыйм – олуглау.

6. Нәжәт – котылу.

7. Бәрабәр – барлык, бергә.

тәкъдире дип, аңлый белү – хәмде-сәнәдәндер. Аллаһ тарафыннан бирелгән бәхетләрне кадер-хөрмәтне белү һәм артык маллардан тиешле рәвешле ингам[1] бирү ихсан кыла. Исраф, хәрәм эшләрдән саклана белү – бу да Аллаһка хәмедтер. Коръән Кәримдә: وَلَاتُسْرِفُوا ۚ إِنَّهُ لَا يُحِبُّ الْمُسْرِفِينَ диелә («әл-Әнгам», 131), ягъни: «Әрәм итә күрмәгез, тиешсез җирләргә, хәрәм эшләргә малларны исраф итмәгез. Аллаһ Тәбарәкә һәрбер әрәм итүче, исраф итүчене сөймидер». Синең кулыңа калган олугларны: ата-аналарны, әби-бабайларны тәгъзыйм-хөрмәт итү, олуглау, аларга миһербанлы, шәфкатьле булу, алар аркасында үзеңнең адәм хәленә килүеңне аңлап, аларга һәрвакытта йомшак сүзләр, ярдәмле булу – Аллаһка бөек хәмдедер.

Коръән Кәримдә وَقَضَىٰ رَبُّكَ أَلَّا تَعْبُدُوا إِلَّا إِيَّاهُ وَبِالْوَالِدَيْنِ إِحْسَانًا («Бәни Исраил», 23), ягъни Аллаһ Тәбарәкә бәндәләргә боерадыр: «Аллаһның таныган рәвешле ата-анага да үзеңнең бәндәчелекне белдерү, йомшак табигатеңне мәрхәмәтле булырлык өйрәтү, үз ата-аналарыңа кадер-хөрмәт күрсәтү; аларга ачуланып кычкыру – көфрән нигъмәтедер. وَلَئِن كَفَرْتُمْ إِنَّ عَذَابِي لَشَدِيدٌ («Ибраһим», 7), ягъни «Әгәр дә Аллаһының бөек нигъмәтләренең кадер-хөрмәтен китермәсәгез, минем газабым катыдыр», – дип тәнбиһ кыладыр.[2] Һәрбер әгъзаларыңны тиешле рәвешле файдалана белү – Аллаһка хәмде-сәнәдер. Мәсәлән, аяк, кул, тел вә күзләр, гакыллар адәм балаларына Аллаһ тарафыннан әманәт итеп тапшырылгандыр. Син ул әманәтләрне тиешле рәвешле файдалану белән җибәрелгәнсен. Бу әгъзалар фәкать башка адәм балаларына файдалы истигъмал[3] өчен бирелгәндер. Ошбуның өчен һәрбер әгъзалар тик адәм балаларына файдалы эшләрне генә эшләргә тиешледер: وَلَا تَقْفُ مَا لَيْسَ لَكَ بِهِ عِلْمٌ ۚ إِنَّ السَّمْعَ وَالْبَصَرَ وَالْفُؤَادَ كُلُّ أُولَٰئِكَ كَانَ عَنْهُ مَسْئُولًا («Бани Исраил», 36), ягъни: «Сиңа Аллаһ тарафыннан бирелгән һәрбер әгъзаң – колак, күзләрең, йөрәк һәм башкалар – һәркайсы мәшгуль булачактыр, соралачактыр».

Бәндәләрнең һәрбер кылган гамәлләреннән әгъзалары җавап бирер. Сиңа җавап бирергә ирек бирелмәс. الْيَوْمَ نَخْتِمُ عَلَىٰ أَفْوَاهِهِمْ وَتُكَلِّمُنَا أَيْدِيهِمْ وَتَشْهَدُ أَرْجُلُهُم بِمَا كَانُوا يَكْسِبُونَ («Ясин», 65), ягъни: «Әгъзаларга кыямәт көнендә мөһер куелыр, куллар-аяклар җавап бирер, ошбуның өчен һәрбер эшләгән эшне, сөйләнгән сүзләрне Аллаһ боерганча эшләнергә тиеш, бу – Аллаһка бөек

1. Ингам – яхшылык.

2. Тәнбих кылу – үгетләү.

3. Истигъмал – гамәл.

хәмед вә сәнәдер. Гомумән, тел әгъзасы дөнья-хәятендә күбрәк эшне эшлидер, ләкин телләребез фәкать Аллаһка зикер дәрәҗәсендә булган сүзләрне генә сөйләргә тиешледер. Тел башкаларга карата һичбер сүз сөйләргә тиешле түгелдер. Гайбәт сөйләү, сүз йөртү, яла ягу, ялганга шаһадәт бирү кебек куркыныч сыйфатлардан сакланган вакытта, телнең һәрбер сүзләре – Аллаһны мактаудыр, хәмед вә сәнәдер һәм башка әгъзалар да шулай уктыр.

Гакыл нигъмәте – Аллаһ тарафыннан адәм балалары өчен бигрәк олугъ нигъмәттер. Адәм баласы башка мәхлукатларга караганда фәкать гакыл саясында өстен булыр, хөрмәтле булыр. وَلَقَدْ كَرَّمْنَا بَنِي آدَمَ («Бани Исраил», 70), ягъни «Адәм балаларын хөрмәтле кылдым». Ошбуның өчен гакылларыбыз, бигрәк тә башка адәм балаларының файдасы өчен, истигъмал итүгә бурычлыдыр. Бу Аллаһка, Аллаһның бөек нигъмәтенә ризалык белдерү, Аллаһны мактау, хәмед вә сәнә буладыр. Гакылларны башка адәм балаларына һәм җәмигъ[1] мәхлукатларга, зарарлы булган җирләргә истигъмал итү – олугъ гөнаһтыр, Аллаһның бөек нигъмәтенең кадер-хөрмәтен җибәрү буладыр. Нәфесләргә хуҗа була белү, нәфесләрне аздырмау – Аллаһка хәмед-сәнәдер. Адәм балаларын дөньяда кадер иткән кыямәт көнендә һәлакәтлеккә төшергән нәрсәләр – нәфесләрдер. إِنَّ اللَّهَ لَا يَظْلِمُ النَّاسَ شَيْئًا وَلَكِنَّ النَّاسَ أَنفُسَهُمْ يَظْلِمُونَ (Сүрә «Юныс», 44) «Аллаһ Тәбарәкә вә Тәгалә адәм балаларына һичбер вакыт золмәт итмидер, бәлки адәм балалары нәфесләренә хуҗа була алмый, үзләренә үзләре золмәт итәдер. Гакылларны дөрес йөртә белү, тәфәккүрле[2] булу – мөэминнәр өчен Аллаһ тарафыннан катгый әмердер, ягъни ачык рәвештә әмер ителгәндер. يَا أَيُّهَا الَّذِينَ آمَنُوا قُوا أَنفُسَكُمْ وَأَهْلِيكُمْ نَارًا وَقُودُهَا النَّاسُ وَالْحِجَارَةُ («Тәхрим», 6), ягъни «И мөэминнәр! Сез үзләрегезне дә һәм әһелегезне дә ут газабыннан коткарыгыз!» Ягъни адәм балаларының һәрбер хәрәкәте Аллаһны мактаудыр. Аллаһка хәмед-сәнәдер, «Әлхәмдүлиллаһ» дигән сүздер. Һәрбер әмерләрне җиренә җиткерү, һәрбер тыйганнардан тыелу – хәмде-сәнәдер. يَا أَيُّهَا الَّذِينَ آمَنُوا إِذَا قُمْتُمْ إِلَى الصَّلَاةِ فَاغْسِلُوا («Әл-Мәидә», 6) Моны кыла белү – хәмде-сәнәдер. فَمَنْ شَهِدَ مِنكُمُ الشَّهْرَ فَلْيَصُمْهُ («Әл-Бакарә», 185) шулай кыла белү – хәмде-санадыр. وَآتُوا الزَّكَاةَ («Әл-Бакарә», 110) моны үтә белү – хәмде-сәнәдер. وَلِلَّهِ عَلَى النَّاسِ حِجُّ الْبَيْتِ («Ал Гыймран», 97).

1. Җәмигъ – барча.

2. Тәфәккүрле – уйлаулы.

رَبِّ الْعَالَمِينَ [Раббел-галәмин]

Бөтен галәмнең Раббысы, тәрбиячесе – ул Аллаһ дип тану. Бөтен хәяттә, тереклектә һәм үлгәннән соң да булачак эшләр – һәркайсы Аллаһның бөек тәрбияеседер дип танудыр. Адәм баласының һәрбер әгъзаларның хилкәте[1], хәрәкәтләре, гакыл, тәфәккүрләре, күрү вә ишетү куәтләре, сизү вә тәнне белү куәтләре – һәркайсы Аллаһның Раббы сыйфатыны тасдыйк итәдер[2] дип танудыр.

Галәмнең яшәп килүе һәм киләчәктә яшәве, хәятнең яшәп килүе – Аллаһның бөек Раббы сыйфатыннандыр. Кичә-көндезләрнең булуы, табигатьнең һичбер үзгәреш булмый тәбдил[3] кылынып торуы, ягъни үз вакытында һәркайсының булып торуы, җир вә күкләр дә, барлык мәхлукат, планеталарның хәяте вә аларның һәркайсы үз вакытында, үз даирәсендә хәрәкәт итүе – Аллаһның Рабб әл-галәмин сыйфатыдыр. وَكُلٌّ فِي فَلَكٍ يَسْبَحُونَ («Ясин», 40), إِنَّ فِي خَلْقِ السَّمَاوَاتِ وَالْأَرْضِ وَاخْتِلَافِ اللَّيْلِ وَالنَّهَارِ لَآيَاتٍ لِّأُولِي الْأَلْبَابِ («Әл-Гыймран», 190). һәр фәләкъ[4] үз орбитасында йөзеп тормактадыр. Җир вә күкләрнең яратылышында, кичә-көндезләрнең үз вакытында алышынып торуларында гакыл ияләренә күп эшләр бардыр. Бу да Аллаһның Рабб сыйфатын тасдыйк кыладыр. Коръән Кәримдә бу турыда аятьләр бик күптер. Бу урында бер аять кенә язылып китәдер. Кичә-көндезләрнең һәм ел фасылларының бер дә алыштырылмый, һәрвакыт бер хәлдә булып торулары һәм алыштырырга мөмкинлек булмавы, елларның унике ай булып торуы – Аллаһның Рабб сыйфатыдыр. إِنَّ عِدَّةَ الشُّهُورِ عِندَ اللَّهِ اثْنَا عَشَرَ شَهْرًا فِي كِتَابِ اللَّهِ («Тәүбә», 36), ягъни «Аллаһ Тәбарәкә хозурында ел фасыллары унике булып, хәлык[5] кылынуы Коръәни Кәрим берлән тасдыйк ителде». Җир хәятендә: җирнең адәм балаларының хәятне саклар өчен файдаланырга уңайлы, һәрнәрсәне үстерерлек хәлдә булуы һәм җирнең, үзенең зурлыгына карамастан, адәм балаларына яшь яшәү мәтагъ[6] булыр. Аллаһының Раббел-галәмин сыйфатыдыр. أَنَّ الْأَرْضَ يَرِثُهَا عِبَادِيَ الصَّالِحُونَ («Әнбия», 105) «Аллаһ Тәбарәкә әйтәдер: «Тәхкыйк, бер җирне шул җирдән файдалана белүчеләр өчен мирас иттек, ягъни адәм балаларының ирегенә

1. Хилкәт – тән төзелеше.

2. Тасдыйк итү – исбатлау.

3. Тәбдил – алышу.

4. Фәләкъ – монда планета мәгънәсендә кулланыла.

5. Хәлык – яралту, юктан бар итү, барлыкка китерү, ясау.

6. Мәтагъ – ләззәт.

куйдык», – димәктер.وَالْأَرْضَ مَدَدْنَاهَا وَأَلْقَيْنَا فِيهَا رَوَاسِيَ وَأَنبَتْنَا فِيهَا مِن كُلِّ شَيْءٍ مَّوْزُونٍ («Хәҗәр», 19) «Аллаһ Тәбарәкә әйтә: «Бер җирне төшердек һәм ул җиргә зур-зур таулар халык кылдык, һәм ул җирдә, мәгълүм булган кадәр, һәртөрле шәйләрне үстердек», – димәктер. Шул иген үсемлекләрнең үсеп, нигъмәт булып җитешүе, Аллаһының күктәге ягъмурлар белән булуы – Аллаһының Раббел-галәмин сыйфатыдыр.وَاللَّهُ الَّذِي أَرْسَلَ الرِّيَاحَ فَتُثِيرُ سَحَابًا فَسُقْنَاهُ إِلَىٰ بَلَدٍ مَّيِّتٍ فَأَحْيَيْنَا بِهِ الْأَرْضَ بَعْدَ مَوْتِهَا ۚ كَذَٰلِكَ النُّشُورُ («Мәләикә», 9) һәм فَأَخْرَجْنَا بِهِ ثَمَرَاتٍ مُّخْتَلِفًا أَلْوَانُهَا («Мәләикә», 27) Аллаһ Тәбарәкә күктәге болытларны җилләр белән куып-китереп, үлеп яткан үсемлекләрне торгызды һәм үсемлекләр, җимешләрнең төрле нәүгъләрдә[1] булуы, төсләре төрле булуы барчасы да - Аллаһының Раббел-галәмин сыйфатыдыр.

Көндезләрнең адәм балаларының мәнфәгате өчен мәсләхәт булырлык дәрәҗәдә яктыртылып чирагъ-шәмнәр кылуы – تَبَارَكَ الَّذِي جَعَلَ فِي السَّمَاءِ بُرُوجًا وَجَعَلَ فِيهَا سِرَاجًا وَقَمَرًا مُّنِيرًا («Фуркан», 6) Аллаһының бөек хикмәтләре мөбарәк булуы – ул Аллаһ күк йөзенә мөхәккәм рәвештә яктыручы шәмнәр куюы, ягъни кояш-айны куюы – Аллаһының Раббел-галәмин сыйфатыдыр. Кичәләрнең караңгы булып, адәм балаларына ял-истирәхәт өчен уңайлар булуы – Аллаһының Раббел-галәмин сыйфатыдыр.

وَجَعَلْنَا اللَّيْلَ لِبَاسًا ﴿١٠﴾ وَجَعَلْنَا النَّهَارَ مَعَاشًا ﴿١١﴾ «Ән-Нәбә», 10-11) «Кичәләрне сезгә истирәхәт өчен, уңайлы рәвештә кылдык. Көндезләрне дөнья мәгыйшәт өчен уңайлы кылдык», - димәктер.

Бөтен дөнья хәятендә, галәмдә булган шәйләрнең фәкать адәм балаларының файдасы өчен булып, һәркайсының бәндәләргә мәтагъ булуы, бәндәләрнең файдасы өчен халык кылынуы – Аллаһының Раббел-галәмин сыйфатыдыр. أَلَمْ تَرَوْا أَنَّ اللَّهَ سَخَّرَ لَكُم مَّا فِي السَّمَاوَاتِ وَمَا فِي الْأَرْضِ وَأَسْبَغَ عَلَيْكُمْ نِعَمَهُ ظَاهِرَةً وَبَاطِنَةً («Локман», 20) «Аллаһ Тәбарәкә җирдә вә күктә булган байлыкларны сезгә мөсәххәр кылуы, аермалар кылуы – сезнең ирегегездәдер. Аллаһының күзгә күренгән һәм күренмәгән байлыклары булуы – Аллаһының Раббел-галәмин сыйфатыдыр. Ягъни җирнең эчендәге булган барлык мөгъдәннәр[2] вә күк йөзендә булган бөтен планеталар адәм балаларына файдалану өчен халык кылынды. Хәтта Аллаһының мөлектән әс-сәмәвәт вәл-әрд булган мәхлукатләре, фәрештәләре дә адәм балаларына мәтагъ булуы, сәҗдә кылуы – бу һәм

1. Нәүгъ – төр.

2. Мөгъдән – минерал.

Аллаһының Раббел-галәмин сыйфатыдыр. وَلَقَدْ خَلَقْنَاكُمْ ثُمَّ صَوَّرْنَاكُمْ ثُمَّ قُلْنَا لِلْمَلَائِكَةِ اسْجُدُوا لِآدَمَ فَسَجَدُوا («Әл-Әгъраф», 7) Аллаһ Тәбарәкә әйтәдер: «Адәм баласыны яраттык, адәм сурәтенә ирештердек, моның соңында Аллаһының туры булган фәрештәләргә, адәм баласына сәҗдә кылу берлән боердык. Фәрештәләр сәҗдә кылдылар.» Бу һәм Раббел-галәмин сыйфатыдыр. وَمِنْ آيَاتِهِ أَنْ خَلَقَ لَكُم مِّنْ أَنفُسِكُمْ أَزْوَاجًا لِّتَسْكُنُوا إِلَيْهَا وَجَعَلَ بَيْنَكُم مَّوَدَّةً وَرَحْمَةً – Аллаһ Раббел-галәмин сыйфатыдыр. وَاللَّهُ خَلَقَكُم مِّن تُرَابٍ ثُمَّ مِن نُّطْفَةٍ ثُمَّ جَعَلَكُمْ أَزْوَاجًا – Аллаһ Раббел-галәмин сыйфатыдыр.

Бу тугрыда язарга безнең кыска гакылның һәм кодрәтеннән киләчәк түгелдер, ләкин аңлаган кадәр язылып үтеп, Аллаһының Раббел-галәмин сыйфатын һичкем тәкъдир кылып бирәчәк түгелдер. Әлхәмдүлиллаһ Раббел-галәмин.

الرَّحْمَن [әр-Рәхман] сыйфаты:

Аллаһ Тәбарәкә вә Тәгаләнең мәрхәмәтле зат идегене белдерәдер. Бу турыда тәфсир «Хазин» الرحمن في الدنيا علي كل عالم و ألمُؤمنين و الكافرين дип белдерәдер. Ягъни: «Аллаһының Әр-Рахман сыйфаты дөнья йөзендә булган бөтен мәхлукатлар өчен мөэмин-кәфер булып та карамастан, Әр-Рахман сыйфатына барчасы да керәдер,» димәктер.

Иң бөек мәрхәмәтләреннән берсе: адәм баласы дөньяга хәлык кылынмастан элек, Аллаһны тәгъриф[1] кылгандыр, дөньяга хәлык кылынуы – Аллаһының көдрәтенә итагатьтер. Ошбуның өчен һәрбер дөньяга килүче адәм баласы фитрый иман берлән дөньяга киләдер. Бәләгатькә ирешкәнче, Аллаһының бөтен кодрәтләренә итагать итәдер. Бу хәлне сабыйларның әхлак вә табигатьләреннән карап, белеп буладыр. Кайчан гакылы тәмам ирешеп куәт кеsргәч, гыйлемлек-белем алгач, бәндә Аллаһының барлык әмерләренә каршылык итә башлыйдыр, хәтта әстәгыйзубиллаһ, Аллаһны да тәгъриф кылмыйдыр, танымыйдыр, инкяр итәдер, гөнаһ кыладыр. Ләкин мәрхәмәт иясе булган Аллаһ бәндәләрнең шул бөек гөнаһларын да, әгәр Аллаһка кайта белсәләр, мәгъфирәт итәдер, ярлыкыйдыр. Бу – Аллаһының бөек мәрхәмәтеннәндер. Әр-Рахман сыйфатыннандыр. إِنَّ اللَّهَ يَغْفِرُالذُّنُوبَ جَمِيعًا ۚ إِنَّهُ هُوَ الْغَفُورُ الرَّحِيمُ («Зөмәрә», 53) «Аллаһ Тәбарәкә - барлык гөнаһларыгызны да гафу итүчедер. Ул

1. Тәгъриф – тану.

Аллаһ - мәгъфирәт сахибе, мәрхәмәт сахибедер», - димәктер. Аллаһ Тәбарәкә вә Тәгалә бәндәләрне үз араларында милләт, сыйныф, кабиләләргә аермыйдыр, бәлки бөтен адәм балаларын ир вә хатынны бертигез хокуклы итеп хәлык кылгандыр. Тик артыклык адәм балаларында Аллаһыдан җен саклана белүчеләрдә генә булуны белдереп, إِنَّ أَكْرَمَكُمْ عِندَ اللَّهِ أَتْقَاكُمْ («Хөҗәрәт», 13) «Аллаһ хозурында сезнең хөрмәтле булганнарыгыз – Аллаһтан чын курка белүчеләрегездер», – диде. Бу һәм Аллаһының әр-Рахман сыйфатыдыр.

Шөгъбәләргә, кыйблаларга аерылулар бере берлән бере танышу өчен генә хезмәт итүне белдерде, бу һәм Әр-Рахман сыйфатыдыр. لِتَعَارَفُوا («Хөҗәрәт», 12).

Адәм баласы башка мәхлукатләрдән артык итеп халык кылынса да, гакыл берлән мөшәррәф[1] булса да, бозыклык кыладыр, ләкин мәрхәмәт сахибе булган Аллаһ бозыклар өчен, шул вакытта ук хәлык кылмыйдыр. Әгәр дә башка хезмәтләре адәм балаларының файдасы өчен булса. وَمَا كَانَ رَبُّكَ لِيُهْلِكَ الْقُرَىٰ بِظُلْمٍ وَأَهْلُهَا مُصْلِحُونَ («Һүд», 117) – Бу да Аллаһының бөек мәрхәмәтедер, Әр-Рахман сыйфатыдыр.

Аллаһ Тәбарәкә адәм балаларын бозыклыклары өчен һәлак итмидер, Аллаһының башка адәмнәренә файдалы хезмәтләре өчен саклыйдыр. Барлык мәхлукатләр адәм балаларына дөнья көтү өчен, барлык табигать адәм баласының уңаена муафыйк[2], хәлык кылынгандыр. Димәк, хәяттә булган бөтен шәйләр бәндәләргә лаякатлы[3] булуы – Аллаһның Әр-Рахман сыйфатыдыр. Адәм балалары өчен Аллаһ Тәбарәкә вә Тәгалә шул кадәр хөрмәт күрсәтәдер, хәтта адәм баласы вафат булса, җәсәден, әгъзасын ихтирам итәргә, казып, җиргә күмергә әмер иткәндер. Бу да Аллаһының Әр-Рахман сыйфатыдыр.

خَلَقَهُ فَقَدَّرَهُ ﴿١٩﴾ثُمَّ السَّبِيلَ يَسَّرَهُ ﴿٢٠﴾ ثُمَّ أَمَاتَهُ فَأَقْبَرَهُ ﴿٢١﴾
ثُمَّ إِذَا شَاءَ أَنشَرَهُ ﴿٢٢﴾

(«Габаса», 19-22) Аллаһ Тәбарәкә: «Адәм балаларын хәлык кылдык, аның бөтен эшләрен тәкъдир кылдык, чикләдек, адәм баласына җиңел юллар күрсәттек. Әгәр дә вафат булсалар, аларны кабергә күмәргә әмер иттек», – дип олуг ихтирам белдерәдер.

Адәм баласының үз әгъзасы, организмы - һәркайсы мөкәммәл рәвештә махсус хезмәттә булуга лаякатлы итеп төзелгәндер. Бу да бөек Аллаһының

1. Мөшәррәф – олыланган.

2. Муафыйк – яраклы.

3. Лаякатлы – яраклы.

мәрхәмәтеннән, Әр-Рахман сыйфатыннандыр.

Мисал өчен, бер кечкенә әгъзаны алыйк. Адәм баласы шиштәге һаваны танаудан[1] эчәдер. Менә шул танауның эчендә кечкенә төкләр бар, алар һавада булган ярамас микробларны, зарарлы шәйләрне тотып калу өчен хезмәт итәдер. Әгәр дә бу төкләр булмаса, адәм балалары һавадагы һәртөрле ярамас микробларны сулап, һәлакәткә дучар булыр иде. Бу да Аллаһының рәхмәт сыйфатыдыр. Бөтен әгъзалар шул рәвешледер.

Табигать үз вакытында набататларны[2] үстерү өчен, эсселек-хәррәрәт[3] хасил булуы, набататлар өлгергәч, салкын һавалар барлыкка килүе, һәрбер набататның тәнәфес-каникул вакыты булып калуы – бу да Аллаһының мәрхәмәтедер. Табигатьтә һәрбер әклимнең[4] үзенә махсус адәмнәре, хайваннары хәлык кылынуы – бу да Аллаһының бөек мәрхәмәтеннәндер. Аллаһ Тәбарәкә вә Тәгаләнең йөз рәхмәте булып, моннан бер рәхмәте дөнья хәятенә бирелгәндер. Шул бер рәхмәт саясында гакыллар житешмәслек мәхлукатлар, набататлар, планеталар бәндәләргә мөсәххәр[5] кылынгандыр. Бу - бөек мәрхәмәттер. 99 рәхмәт йәүме кыяməттә[6] булачактыр. Дөньядагы бер рәхмәтнең хисабына чыгу мөмкин түгелдер. Йәүме кыямəттә гакыллар житешә алачак түгелдер. Бу турыда Рәсүлемез димештер.

## الرَّحِيم [әр-Рәхим] сыйфаты

Йәүме кыямəттә Аллаһ мәрхәмәт итәчәктер, димәктәдер: **الرحيم هذا فقط على المؤمنين يوم القيامة** Аллаһ Тәбарәкә вә тәгалә тарафыннан Әр-Рәхим сыйфаты йәүме кыяməттә булачак сыйфат, ләкин фәкать мөэминнәр өчендер. Адәм балалары дөнья хәятенә хәлифәтел-әрд[7] булып хәлык кылынды.

Адәм баласына Аллаһның мөлкет әс-сәмават вәл-әрд булган. Аңа фәрештәләр дә сәждә кылды, чөнки адәм баласы хөрмәтле булып хәлык ителде. Адәм

1. Танау – борын.
2. Набат – үсемлекләр.
3. Хәррәрәт – эсселек.
4. Әклим – ел фасылы.
5. Мөсәххәр – буйсындырылган.
6. Йәүме кыяməттә – кыямәт көнендә
7. Хәлифәтел-әрд – урынбасар.

балалары гакыл саесында, гакыл берлән мәшрәф[1] кылынды.

Адәм балалары хак берлән батыйлны[2] аеручы булу өчен, Аллаһ Тәбарәкә адәм балаларына беренче вәхидә үк гыйлем-мәгърифәт юлларын әмер итте. «әл-Галәк», 1-5:

اقْرَأْ بِاسْمِ رَبِّكَ الَّذِي خَلَقَ ﴿١﴾خَلَقَ الْإِنسَانَ مِنْ عَلَقٍ ﴿٢﴾اقْرَأْ وَرَبُّكَ الْأَكْرَمُ ﴿٣﴾
الَّذِي عَلَّمَ بِالْقَلَمِ ﴿٤﴾عَلَّمَ الْإِنسَانَ مَا لَمْ يَعْلَمْ ﴿٥﴾

Аллаһының әмере: «Укы, үзеңне җир йөзендә хәлык кылган Аллаһның исеме берлән укы. Адәм баласы галәктән[3] хәлык кылынды. Һәм моны хәтереңдә тот: хөрмәтле булган Аллаһ адәм балаларына каләм гыйлемен өйрәтергә әмер итә. Шул каләм гыйлеме саесында адәм балалары моңа кадәр белмәгән бөтен нәрсәләрне белерләр», - дип белдерде. Һәм гыйлемлек саесында адәм балаларының дәрәҗәсе фәрештәләр дәрәҗәсенә ирешүне белдерде. يَرْفَعِ اللَّهُ الَّذِينَ آمَنُوا مِنكُمْ وَالَّذِينَ أُوتُوا الْعِلْمَ دَرَجَاتٍ («әл-Мөҗәдәләт», 11) Гыйлемлек бирелгән бәндәләрнең Аллаһ Тәбарәкә һәрвакытта дәрәҗәсен күтәрелүне белдерде. Дөнья хәятендә адәм балаларына канун-закон итеп китаплар индерелде, Адәм пәйгамбәрдән башлап шул канун булган китапларына килде.

إِنَّ هَٰذَا لَفِي الصُّحُفِ الْأُولَىٰ ﴿١٨﴾ صُحُفِ إِبْرَاهِيمَ وَمُوسَىٰ ﴿١٩﴾ («әл-Әгъләә», 18-19) «Бу Коръән Кәримдә булган канунар - Адәм пәйгамбәрдән башлап, Ибраһим вә Муса пәйгамбәргә дә бирелгән китаптыр. Менә шул китапларын аңлату-өйрәнү өчен пәйгамбәрләр-рәсүлләр җибәрелде». هُوَ الَّذِي أَرْسَلَ رَسُولَهُ بِالْهُدَىٰ وَدِينِ الْحَقِّ لِيُظْهِرَهُ عَلَى الدِّينِ كُلِّهِ («әл-Фәтх», 27) «Ул Аллаһ -шундый Аллаһтыр: үзенең рәсүлләрен-пәйгамбәрләрен ислам канунарын өйрәтү өчен җибәрде, хак берлән батыйлны аеру өчен, хак булган динне, дөреслекне аңлату өчен ул пәйгамбәрләр килде,» - димәктер. Ләкин шул пәйгамбәрләр хакыйкатьне өйрәтү юлы берлән, вәгазь-нәсыйхәт юлы берлән алып бардылар, бәндәләрнең ышану яки ышанмавын үз ихтыярларына калдырдылар. Ягъни адәм балалары ирекле булды, чөнки гыйлемлек саесында адәм балалары хакыйкатьне үзләре аңларга тиешле идекне белдерде. فَمَن شَاءَ فَلْيُؤْمِن وَمَن شَاءَ فَلْيَكْفُرْ («әл-Кәхф», 29), لَا إِكْرَاهَ فِي الدِّينِ («әл-Бакарә», 256) «Теләгән кеше ышанадыр, теләмәгән кеше инкярь итүдә иреклеедер. Ислам динендә бертөрле дә көчләү юктыр,» – димәктер. Бу да Аллаһының Әр-Рәхим

1. Мөшәррәф - олыланган.

2. Батыйл – ялган.

3. Галәк - кан куерыгы.

сыйфатыдыр. Ислам дине пәйгамбәрләренә динне өйрәтүдә бәндәләр үз гакылы берлән тәфәккүр[1] кылып әйтергә ирекле кылды.

فَبَشِّرْ عِبَادِ ﴿١٧﴾ الَّذِينَ يَسْتَمِعُونَ الْقَوْلَ فَيَتَّبِعُونَ أَحْسَنَهُ («әз-Зөмәрә», 16-17) «Сүзне ишетү берлән күркәм булганына, хәсәнәте күп булганына иярергә», - диеләдер.

Ләкин адәм балалары Аллаһка иман китерүдән баш тарттылар. Кайберләре иман китерсә дә, Аллаһ тарафыннан боерылган гамәлләрне үтәмәделәр, тыйганнардан тыелмадылар, баш тарттылар: «Хәяттә Аллаһның һичбер эше юк, минем гакылым бар, көчем бар, һәрнәрсәне үзебез булдыра алабыз», - диделәр. Көчсезләргә җәбер-золым иттеләр, теләсә ни кылуга үзләрен ихтыяр иттеләр. Мәгълүмдер ки, адәм баласының табигате ашыгычтыр. Уйламастан, һәрбер зарарлы эшләрне ашыгып эшли, үзенә файда итә торган эшләрне читкә җибәрәдер. Бу сыйфат Корьән Кәримдә ачык күрсәтеләдер: وَيَدْعُ الْإِنسَانُ بِالشَّرِّ دُعَاءَهُ بِالْخَيْرِ ۖ وَكَانَ الْإِنسَانُ عَجُولًا («Исраил», 8) «Бәндәләр начарлыкны сөеп, яхшылыкны читкә ташлаучы булсалар да, Аллаһ Раббел-галәмин үзенең Әр-Рәхим сыйфаты берлән йәүме кыяметтә мәрхәмәт итәчәктер.»

Шуны хәтергә китерергә кирәк: мөэминнәр дөнья хәятендә Аллаһ боерганча, тугры бара алсалар, ягъни башка бәндәләргә зарар тидермичә, хыянәт итмичә, саф көч берлән яшәсәләр, шул хезмәтләре - ахирәтлек гамәлләредер, – дип, Аллаһ Тәгалә шатлыклар белдерәдер. Бу да Әр-Рәхим сыйфатыдыр. وَلَا تَنسَ نَصِيبَكَ مِنَ الدُّنْيَا ۖ وَأَحْسِن كَمَا أَحْسَنَ اللَّهُ إِلَيْكَ ۖ وَلَا تَبْغِ الْفَسَادَ فِي الْأَرْضِ ۖ إِنَّ اللَّهَ لَا يُحِبُّ الْمُفْسِدِينَ («Кысас», 77) Аллаһ Тәбарәкә мөэминнәргә белдерәдер: «Син шул дөнья көтү эшендә ахирәтлек кирәген онытма. Ахирәтлек итеп дөнья көтү өчен, башка адәм балаларына, мәхлукатларга күркәм сыйфатлы булырга, ягъни бәндәләр берлән ачу тотмаска, дошманлык итмәскә, бәндәләрнең кимчелекләрен гафу итәргә, гафу итешергә кирәк. Кыскача әйткәндә, Аллаһ Тәбарәкә вә Тәгалә нинди гөнаһлар кылсаң да, һичбер зарар китерми, саклап калдырадыр. Нигъмәтләре берлән хөрмәт итәдер, сәламәт саклыйдыр. Ошбуның өчен Аллаһ Тәбарәкә أَحْسَنَ اللَّهُ إِلَيْكَ димештер. Димәк, мөэминнәргә Аллаһының рәхмәтенә тоташу өчен, ахирәтлек гамәлләр хәзерләү өчен, әллә нинди аерым гамәлләр эзләп йөрисе юк икән. Тугры хезмәтең, адәмнәргә мәрхәмәтле булуың - ахирәтлек гамәлеңдер. Бу да Аллаһының Әр-Рәхим сыйфатыдыр. Дөньяда вакытта Аллаһыны яд итеп, Аллаһтан сакланып, гамәл итүчеләр өчен ахирәт

1. Тәфәккүр – уйлау.

көнендә Аллаһының рәхмәте насыйп булачагын киләсе аятьләр белдерәдер.

وَأَمَّا مَنْ خَافَ مَقَامَ رَبِّهِ وَنَهَى النَّفْسَ عَنِ الْهَوَىٰ ﴿٤٠﴾ فَإِنَّ الْجَنَّةَ هِيَ الْمَأْوَىٰ﴿٤١﴾

(«Ән-Нәзәгать», 30-31) «Бер мөэмин Аллаһтан куркып, Аллаһ хозурына очраячагын яд итеп, нәфсенә хуҗа була алса, тәхкыйк, моның урыны җәннәттер», – дип, Әр-Рәхим сыйфатны белдерәдер.

Адәм балалары баш тартса да, гөнаһ кылса да, Аллаһ Тәбарәкәнең Әр-Рәхим сыйфаты бәндәләрне гафу итү берлән вәгъдә итәдер. إِنَّ اللَّهَ يَغْفِرُ الذُّنُوبَ جَمِيعًا («әз-Зөмәр», 53), ягъни Аллаһ Тәбарәкә барлык гөнаһларыгызны да гафу итәчәктер дип, бәшәрәт[1] белдерәдер. Аллаһ Тәбарәкә бәндәләрнең бозыклык кылуларына карамастан, башка адәм балаларына файдалы гамәлләре өчен, һәлак итмәячәген белдерәдер. وَمَا كَانَ رَبُّكَ لِيُهْلِكَ الْقُرَىٰ بِظُلْمٍ وَأَهْلُهَا مُصْلِحُونَ («Һүд», 117) «Аллаһ Тәбарәкә шундый карияләрне[2] бервакытта да һәлак итмидер, кайсыдыр ки адәм балаларына файдалы гамәл кылдылар». Бу да Аллаһының Әр-Рәхим сыйфатыдыр. Бу – Әр-Рахман һәм Әр-Рәхим сыйфатыдыр. Дөнья хәятендә булган барлык гамәл–гыйбадәтләр, хәрәкәт, йөреш–торышлар, хезмәт вә башкалар – һәркайсы Аллаһ боерганчы булган вакытта ахирәтлек өчен кирәкле гамәлдер. Бу Аллаһның бөек мәрхәмәтеннәндер.

Тугры булганда, хакыйкатьне аңлап гамәл кылганда, Аллаһының йәүме кыяматтәге рәхмәтенә дә тоташачакмыз, иншәАллаһ.

مَالِكِ يَوْمِ الدِّينِ [Малики йәүмеддин]

Аллаһны Кыямәт көненең хуҗасыдыр дип тану – бу да Аллаһ Тәбарәкә вә тәгаләнең бәндәләренә бөек мәрхәмәтедер. Ягъни إِنَّ اللَّهَ يَغْفِرُ الذُّنُوبَ جَمِيعًا булгач, Аллаһ Тәбарәкә вә Тәгаләнең ялгыз үзе хөкем итүе мәрхәмәтедер. Адәм балаларының хисап көннәре булачактыр, ягъни дөньяда кылган һәрбер гамәлләрдән хисап бирәчәкбез. وَوُضِعَ الْكِتَابُ فَتَرَى الْمُجْرِمِينَ مُشْفِقِينَ مِمَّا فِيهِ وَيَقُولُونَ يَا وَيْلَتَنَا مَالِ هَٰذَا الْكِتَابِ لَا يُغَادِرُ صَغِيرَةً وَلَا كَبِيرَةً إِلَّا أَحْصَاهَا («Әл-Кәһф», 49) «Кыяматтә һәркемнең дөнья тереклегендә кылган гамәлләре әлләренә[3] куелыр, шул вакытта адәм балаларыны үкенеч, бу көндә дөньяда кылган гамәлләребезнең олуг вә кечекләре - бар да саналып куелган», - диерләр.

Аллаһ Тәбарәкә үзе малик йәүм әд-дин сыйфаты берлән сыйфатланган

1. Бәшәрәт – шатлык хәбәре, хуш хәбәр.

2. Кария – авыл.

3. Әлләренә – кулларына.

булгач, гадәләт[1] берлән хөкем итәчәктер. Ошбуның өчен, иманлы бәндәләр өчен хосусый льготалар булачактыр. وَنَضَعُ الْمَوَازِينَ الْقِسْطَ لِيَوْمِ الْقِيَامَةِ فَلَا تُظْلَمُ نَفْسٌ شَيْئًا ۖ وَإِن كَانَ مِثْقَالَ حَبَّةٍ مِّنْ خَرْدَلٍ أَتَيْنَا بِهَا ۗ وَكَفَىٰ بِنَا حَاسِبِينَ («әл-Әнбия», 67) Аллаһ Тәбарәкә әйтә: «Без йәүм кыяməттә шундый мизаннар[2] куярбыз һичбер адәмгә золым ителмәс. Бер кешенең тузан кадәр генә эше булса да, җәзасы җибәрелер. Хисап итү йөзеннән Аллаһ Раббел-галәмин үзе җитәдер». Бу да Аллаһының рәхмәт сыйфатыдыр, чөнки Аллаһ үзе - малик йәүметдиндер. Аллаһ Раббел-галәмин үзе йәүм кыямәтнең хуҗасы булгач, мизаннарында гадәләт кылыр. Мөэминнәр өчен һәрбер эшендә игътибар ителер. Кечкенә изге гамәлләрендә әллә ничә мәртәбә арттыру берлән вәгъдә итәдер. مَن جَاءَ بِالْحَسَنَةِ فَلَهُ عَشْرُ أَمْثَالِهَا ۖ وَمَن جَاءَ بِالسَّيِّئَةِ فَلَا يُجْزَىٰ إِلَّا مِثْلَهَا وَهُمْ لَا يُظْلَمُونَ («әл-Әнгам», 160) «Бер мөэмин дөнья йортында изгелек иткән булса, Аллаһ Тәбарәкә вә Тәгалә аның изге гамәлен берничә мәртәбә артык хисап итер. Әгәр дә явызлык кылган булса, кылынган явызлык кадәр генә җәза кылыныр, арттырылмас». Аллаһ Тәбарәкә золымлык итәргә теләмидер. Бу да малик йәүм әд-дин сыйфатыдыр, зур мәрхәмәттер.

Шулай ук дөнья йортында кылынган изге гамәлләр, явыз сыйфатларыбызны, явызлыкларыбызны җую турында Аллаһ Тәбарәкә бәшәрәт белдерәдер. إِنَّ الْحَسَنَاتِ يُذْهِبْنَ السَّيِّئَاتِ («Һүд», 114) «Дөреслектә, кылынган изге гамәлләр явыз гамәлләрне бетерәдер.» Димәк, бу һәм Раббел-галәминнең мәрхәмәтедер, малик йәүм әд-дин сыйфатыдыр.

Аллаһ Тәбарәкә вә тәгаләнең кыямәт көнендә малик булуы мөэминнәр өчен хисапсыз җиңеллекләр бирәдер. Мөэмин җәннәт әһеле булса, ата-аналарын, хатынын, балаларын да үзе янына чакыруга хакы буладыр. Аллаһ чакыруга рөхсәт итәдер. ادْخُلُوا الْجَنَّةَ أَنتُمْ وَأَزْوَاجُكُمْ تُحْبَرُونَ («Әз-Зәхрәф», 70) «Сез җәннәткә үзегез һәм хатын-балаларыгызны да хәвефсез алып керегез», - димәктер. Бу да Аллаһының малик йәүм әд-дин сыйфатыдыр.

Адәм балаларының дөньяда яшәгән вакытларында таул әл-әмәл[3] берлән яшәве, ягъни адәм баласының үлем сәгате билгеләнми, бәлки, һичшиксез, хәят диңгезендә яшәве, кай вакытта үлүне белми баруы – дөнья көтү өчен гаять файдалы, зур өметле бер эштер. Әгәр бәндәләр кай вакытта үлүләрен белсәләр

1. Гадәләт – гаделлек.

2. Мизан – үлчәү.

3. Таулел-әмәл - гел өметле булу.

иде, яки булмаса, кыямәтнең кай вакытта булыр белеп торсалар иде, әлбәттә, дөнья көтүдә һичбер кызык, ләззәт, тәм тапмаслар иде, бәлки, һәлакәткә илтер иде. Аллаһ Раббел-галәмин малик йәүм әд-дин булгач, бу эшләр берлән дә үзе фәрман итәдер. Кыямәтнең һәм үлемнең аңсыздан килүе, бәндәләрнең һәрвакытта сакланып, Аллаһка истигъфар кылып[1], дөнья көтүдәге һәрбер гамәлләрен ахирәт гамәле итеп хәзерләнеп торуларына бик зур сәбәптер. Бу Аллаһның бөек мәрхәмәте һәм малик йәүм әд-дин сыйфатыдыр. **مَّلَكُ الْمَوْتِ الَّذِي وُكِّلَ بِكُمْ ثُمَّ إِلَىٰ رَبِّكُمْ تُرْجَعُونَ** («Сәҗдә», 11) «Аллаһ Тәбәрәк бу эшләр турында үлем фәрештәсе Газраилгә викәләт2 биргәндер. Ул кешеләрнең вафатын белеп, җаннарын алачактыр. Аллаһ хозурына тапшырачак».

Аллаһ Тәбарәкә вә Тәгаләнең дөньяда булган рәхмәтеннән, Әр-Рәхман сыйфатыннан иң олугысы - гакыл нигъмәте. Шул гакылны дөрес тәдбир[3] итә белү, дөрес файдалану аркасында, бәндәләр җәннәт берлән мәшрәф[4] буладыр. Шул гакылны дөрес йөртә белмәү аркасында, гөнаһ кылып, җәһәннәм берлән хөкүм ителәдер. Ләкин малик йәүм әд-дин булган Аллаһ иман саесында, рәхмәте саесында мәгъфирәт[5] итсә, көдрәтеннән киләдер, ягъни хөкемне алыштыру Аллаһ өчен бик җиңелдер. **يَمْحُو اللَّهُ مَا يَشَاءُ وَيُثْبِتُ وَعِندَهُ أُمُّ الْكِتَابِ** («Әр-Рәгъд», 39) «Аллаһ Тәбарәкәнең үз ихтыярында, хозурында кылынган хөкемне мәх кылу, ягъни бетерү Аллаһ өчен бик җиңел». Аллаһ Тәбарәкә вә Тәгаләнең кыямәт көнендә үзе хуҗа булуы – бөек мәрхәмәттер. Ошбуның өчен **لَا تَقْنَطُوا مِن رَّحْمَةِ اللَّهِ** («Әз-Зөмәр», 53): «Аллаһының рәхмәтеннән бер вакытта да өмет өзмәгез»,- диелгәндер.

**إِيَّاكَ نَعْبُدُ** [ийййәкә нәгъбүдү]

«И Аллаһ, сиңа гына гыйбадәт кыламыз, сиңа гына бәндәчелекне белдерәбез», – дигән сүз буладыр. Габделлек нәрсә идекне белү өчен, «Фатиха» сүрәсенең барлык аятьләрендә дә сөйләп узган Аллаһының рәхмәте, мәрхәмәте өчен, үзенең Аллаһның бәндәсе итеп тану, белү һәм буйсыну китерелгән. **تعبد لك** адәм баласының һәрбер хәрәкәт, йөреш-торышларында, барлык хезмәтләрендә,

---

1. Истигъфар – гафу үтенү.

2. Вәкиләт – хокук.

3. Тәдбир – идарә итү.

4. Мөшәррәф – олыланган.

5. Мәгъфирәт – гафу.

мәгыйшәт[1]-көнкүрешләрендә, гомумән, барлык дөнья, барлык табигатьтә, әгәр дә адәм баласы аңлый алса, габделлекне белдерү сыйфаты бардыр. Бәндәчелекне белү, аңлау, Аллаһ хозурында үзеңне мәхлукат итеп тану - бөтен хәятеңдә булган хәрәкәтләр, гамәлләр, бөтен көчләр, гакыл-тәдбирләр, хезмәт итүләр, гаилә тәшкил итүләр, гаилә тәрбия итүләр, гыйлем-мәгърифәт, һөнәр-сәнгать өйрәтү эшләре. Әһел булган кешеләр берлән җефетләндерү[2], истикъбаль[3] адәмчелек хәятенең дәвамына хезмәт итүләр, балаларны башка адәм балаларына файдалы балалар итеп калдыру, үзеңне тәрбия итеп үстергән ата-аналарны ихтирам итүләр, вафат булган булсалар, яхшылыклары берлән яд итүләр, көчең җитсә, тиләвәте[4] Коръән уздыру – болар һәркайсы Аллаһның әмередер. Аллаһының әмере булганы өчен дөрес юл берлән саф-хыянәтсез эшләнгән вакытта, һәркайсы Аллаһка бәндәчелекне белдерүдер, إِيَّاكَ نَعْبُدُ дигән аятьне гамәли эшләүдер.

Аллаһ тарафыннан мөэминнәргә боерылган фарз-важиб изге гамәлләр буладыр. Барчасы да рухани тәрбия булып, боларны булдыра алган тәкъдирдә генә, адәм балалары әхлакый тәрбия алган, Коръән әмеренчә гамәл итүче булып, халис[5] Аллаһка бәндәчелекне ихлас күңелдән белдерүчедер, ягъни إِيَّاكَ نَعْبُدُ гамәли рәвештә кылучыдыр.

Хыянәттән саф булу, агырлык кайгылы вакытларда сабыр-тәхәммелле булу, барлык эшләрне Аллаһның тәкъдире дип таный белү, аңлау – Аллаһка бәндәчелек белдерүдер. Гомумән, бөтен хәяттә вә сихәттә булган терек, вә үлгәнәнн соң булган һәм булачак эшләр - Аллаһ тәкъдире дип, гамәл итә белү – Аллаһка бәндәчелекне белдерү, إِيَّاكَ نَعْبُدُ сыйфатыдыр.

وَإِيَّاكَ نَسْتَعِينُ [вә иййәкә нәстәгыйн]

«И Аллаһ, барлык эшләрдә син безгә генә ярдәм эстибез, синнән без дөнья вә ахирәт эшләребездә ярдәм итүче», - дип, тәкъдир итә белү. Адәм балаларының нинди диндә булуларына карамастан, яки җирдә динне тәгъриф[6] кылмаучылар да, һәрбер эшләрендә – кирәк хәерле эш булсын, кирәк хәвефле эш булсын, һич тә күренмәгән бер көчкә мөхтаҗдыр. Әйтерсең, авырлык вакытларында

1. Мәгыйшәт – тормыш.

2. Җефетләндерү – өйләндерү.

3. Истикъбал – кабул итү.

4. Тиләвәт – Коръәнне матур тавыш белән уку.

5. Халис – ихласлы кеше.

6. Тәгъриф кылу – монда: санлау, ихтирам итү, белү.

шул көч аңа рух кертә, ярдәм бирә дип, хис кыладыр, тынычлык табадыр. Менә шул сыйфат وَإِيَّاكَ نَسْتَعِينُ дер.

Шушы Аллаһтан ярдәм эстәү - адәм балалары арасында ике кыйсымдыр, ягъни ике төрледер. Кайберләре телдән генә ярдәм сорыйдыр. Кайберләре чын күңелдән, бөтен сәбәпләренә керешеп ярдәм эстидер. Аллаһының ярдәме кыйблага каршы тезләнеп сорау берлән генә булмыйдыр (ул да кирәк, мөэминнең догасын кабул итүне Аллаһ Тәбарәкә вәгъдә итте). وَإِذَا سَأَلَكَ عِبَادِي عَنِّي فَإِنِّي قَرِيبٌ ۖ أُجِيبُ دَعْوَةَ الدَّاعِ إِذَا دَعَانِ ۖ فَلْيَسْتَجِيبُوا لِي وَلْيُؤْمِنُوا بِي لَعَلَّهُمْ يَرْشُدُونَ («Бакара», 186) «Әгәр дә бәндәләр мине кайда дип сорасалар, мин аларның яннарында, догаларын кылсалар, мин шундук кабул итәрмен», - диде. Ягъни Аллаһтан ярдәм сорау, дога ләземдер[1]. Ләкин дога кылу берлән, сәбәбенә керешүгә кирәк. Аллаһының ярдәмен ихласый ният, саф күңел берлән хыянәтсез сорау. Шул соралган нәрсәләрнең сәбәбенә керешергә кирәк, чөнки

كُلِّ شَيْءٍ سَبَبًا ﴿٨٤﴾ فَأَتْبَعَ سَبَبًا ﴿٨٥﴾ («Әл-Кәһф», 84-85): «һәрбер эшләр сәбәбенә керешкәннән генә буладыр. Аллаһка тапшырып, Аллаһтан ярдәм сорап, эшләнгән эшләрнең нәтиҗәсе ачык рәвештә булмаса да, шул ярдәм сорау аркасында, Аллаһ Тәбарәкә ошбу ярдәмнәрне бирәдер: 1) җан тынычлыгы артадыр; 2) әгъзаларның сәламәтлеге артадыр; 3) һәрбер эшләр уңышлы буладыр, гомернең бәрәкәте артадыр. Нигъмәтләрнең, тапкан малларның бәрәкәте артадыр. Башка адәм балаларына, гомумән, мәхлукатларга миһербан-шәфкатьле булынадыр. Менә шулар бар да Аллаһтан ярдәм сорауның нәтиҗәседер, وَإِيَّاكَ نَسْتَعِينُ дер.

Хәяттә теләкләрнең, сораган ярдәмнәрнең көне-сәгате берлән килмәве ихтималдыр. Моның сәбәбе: Аллаһ Тәбарәкә бәндәләргә фәкать хәерле булган эшләрне генә насыйп итәдер. Тиз вакыт эчендә теләкләр кабул булмавы яки сораган нәрсәнең булмавы бәндәләрне икенче бер хәвефле, афәтле булган нәрсәләрдән саклау өчендер. Булмаса, Аллаһының бөек сыйфатларыннан إِنَّمَا أَمْرُهُ إِذَا أَرَادَ شَيْئًا أَنْ يَقُولَ لَهُ كُنْ فَيَكُونُ («Ясин», 82 нче аять) «Аллаһ Тәбарәкә бер шәйне булдырырга теләсә, бул диячәк һәм шул сәгатьтә булачактыр», - димәктер. Бу сыйфат وَإِيَّاكَ نَسْتَعِينُ сыйфатыдыр.

اهْدِنَا الصِّرَاطَ الْمُسْتَقِيمَ [иһдинас-сырател-мөстакыйм]

«И Аллаһ, син безләрне үзең сөйгән, тугры булган юлларга күндер», ягъни тугры юлга керүгә ярдәм бир, дигән сүз буладыр. الصِّرَاطَ الْمُسْتَقِيمَ – адәм

---

1. Ләзем – тиеш.

балаларының башка, үзе кеби адәм балаларына, гомумән, мәхлукатларга зарар тидерүдән сакла, димәктер. Ислам дине – саф, тугры, хыянәтсез инсаннар арасында өлфәт-мәхәббәт, татулык, гадәләт берлән яшәргә дәгъват итә торган дин мөкаддәстер.

ادْخُلُوا فِي السِّلْمِ كَافَّةً («Бакарә», 208) «Җөмләгездә татулык, мир (тынычлык, иминлек) саклау юлында булыгыз», - дип әмер итәдер. Ислам дине бервакытта да, бер урында да башка үзгә рәвешле адәм балаларына гына түгел, бәлки бөтен мәхлукатларгә зарар итүдән катгый мәнигътер[1]. Ислам дине адәм балалары арасында һәрвакытта итагатьлек, тынычлык, өлфәт, мәхәббәт булуын өстен куя. Һәрвакытта яхшылыкка, татулыкка дәгъват иткән кеби, хәзер яшәгән адәм балаларына әүвәл вакытта булып узган ата-бабаларын өшкермәскә (хурламаска), тәнәтмәскә (алдамаска), гайбәт сөйләмәскә, нәсел-нәсәбен тыйнап йөрмәскә боерадыр.

تِلْكَ أُمَّةٌ قَدْ خَلَتْ ۖ لَهَا مَا كَسَبَتْ وَلَكُم مَّا كَسَبْتُمْ («Әл-Бакара», 134) «Әүвәлдә булып узган өммәтләр алар үз дәверләрендә булып узганнардыр. Аларның кылган эшләре - үзләре өчен, сезләрнең кылган эшләрегез сезнең өчен», - дип узган өммәтләрнең нәсел-нәсәбләре арасында дошманлыктан саклап киләдер. Бу турыда катгый әмер итәдер.

Бу исә - Аллаһ Тәбарәкәнең اهْدِنَا الصِّرَاطَ الْمُسْتَقِيمَ дип, соралган юлыдыр, мәрхәмәтедер. Коръән Кәримдә الصِّرَاطَ الْمُسْتَقِيمَ гә һичкемне көчле дәгъват итү юктыр. Бәлки الصِّرَاطَ الْمُسْتَقِيمَне бәндәләр үзләре эзләп табарга һәм шул юлдан барырга тиешледер. Рәсүлемезгә Коръән Кәримдә قل дип килгән, ягъни «Ул الصِّرَاطَ الْمُسْتَقِيمَне син төшендер, юлларын күрсәт», - дип боерылган: قُلْ إِنَّنِي هَدَانِي رَبِّي إِلَىٰ صِرَاطٍ مُّسْتَقِيمٍ دِينًا قِيَمًا مِّلَّةَ إِبْرَاهِيمَ («Әл-Әнгам», 161) «Син адәм балаларына мин сезне тугры булган юлга дәгъват итәм», - дип әйт. Ул шундый юлдыр: ислам дине шул «сыйрател мөстәкыйм» берлән барадыр һәм ул Ибраһим пәйгамбәр вакытында ук өйрәтелгәндер.

الصِّرَاطَ الْمُسْتَقِيمَ – Аллаһка тапшырудыр, عملا قولا و ايمانا و تسليما علي الحل الوجه فهو اول المسلمين و اخلص الموحدين و افشع العابدين – тел берлән гамәли рәвештә чын ышанган хәлдә, чын күңелдән мөслим булган хәлдә, камил йөрәк берлән, الصِّرَاطَ الْمُسْتَقِيمَ мөселман булучылык ихлас күңел берлән Аллаһны вахданият[2] берлән тану һәм гамәл-гыйбадәтләрдә Аллаһтан чын куркып, хо-

1. Мәнигъ – тыелган.

2. Вәхданиять – Аллаһны бер дип тану.

шугъ[1] берлән үтәүдә табыладыр. الصِّرَاطَ الْمُسْتَقِيمَ бәндәләрне ике дөнья сәгадәтенә тоташтырадыр (سعادة الذين في الدنيا والاخرة). Дөньяда бәхет-сәгадәткә малик булу[2] фәкать тугры, дөрес фикерләр булучылык аркасында насыйп буладыр. مَن كَانَ يُرِيدُ الْعِزَّةَ فَلِلَّهِ الْعِزَّةُ جَمِيعًا ۚ إِلَيْهِ يَصْعَدُ الْكَلِمُ الطَّيِّبُ وَالْعَمَلُ الصَّالِحُ يَرْفَعُهُ ۚ وَالَّذِينَ يَمْكُرُونَ السَّيِّئَاتِ لَهُمْ عَذَابٌ شَدِيدٌ ۖ وَمَكْرُ أُولَٰئِكَ هُوَ يَبُورُ («Фатыр», 10) «Бер кеше үзенең дәрәҗәсен күтәрергә теләсә, барлык дәрәҗәләр -Аллаһ әмерендәдер. Сүздә тугры, хыянәтсез адәм файдалы гамәл кылсын, менә шул сыйфатлар дәрәҗәне күтәрәдер», - димәктер. Ягъни الصِّرَاطَ الْمُسْتَقِيمَ гә тапшырылу өчен тугрылык, тугры сүзле булу һәм файдалы гамәл кирәк буладыр. Дөнья йортында адәм балалары тугрылык الصِّرَاطَ الْمُسْتَقِيمَ саесында һәрбер олуглыкларга, яхшылыкларга ирешәдер. Дөньяда булган һәрбер тугры гамәл ахирәт көне өчен бәхет-сәгадаттер, чөнки وَلَا تَنسَ نَصِيبَكَ مِنَ الدُّنْيَا ۖ وَأَحْسِن كَمَا أَحْسَنَ اللَّهُ إِلَيْكَ («Әл-Кысас», 77) «Аллаһ Тәбарәкә вә Тәгаләнең бәндәләргә күрсәткән хәсәнәте югарыда сөйләнде. Аның һичбер хисабы, саны юктыр. Әр-Рәхман бабында бу тугрыда сөйләнде. Мөэминнәр الصِّرَاطَ الْمُسْتَقِيمَ не теләгәч, аны Аллаһтан сорагач, башка бәндәләргә фәкать яхшылык итү тиешледер. Киләчәктәге аять الصِّرَاطَ الْمُسْتَقِيمَ ни идекне белдерәдер.

صِرَاطَ الَّذِينَ أَنْعَمْتَ [сырател-ләзина әнгамтә]

«И Аллаһ, үзеңнең рәхмәтеңә сыйдырган, үзең хөрмәт иткән бәндәләреңнең юлына күндер», - дигән сүз буладыр. Бу аять мәрхәмәт сахибе булган Аллаһ бәндәләренә биргән бөек хокукыдыр. Әгәр дә адәм балалары, мөэминнәр Аллаһ хозурында үзләрен тугры тота белсәләр, Аллаһның хөрмәт иткән, нигъмәтләгән, олугълаган бәндәләре, нәбиләре, пәйгамбәрләре, садыйклары, шәһитләре берлән берәбер булуларын белдерәдер. فَأُولَٰئِكَ مَعَ الَّذِينَ أَنْعَمَ اللَّهُ عَلَيْهِم مِّنَ النَّبِيِّينَ وَالصِّدِّيقِينَ وَالشُّهَدَاءِ وَالصَّالِحِينَ ۚ وَحَسُنَ أُولَٰئِكَ رَفِيقًا («ән-Ниса», 69) «Аллаһны чын танып, тугры юлда булган мөэминнәр, йәүме кыяматтә Аллаһ хөрмәт иткән нәбиләре, садыйклар-салихләре, шәһитләре берлән бергә булырлар. Алар берлән бер юлда, бер урында булу - нинди һуш эштер», - димәктер. Ягъни хакыйкый мөэминлек сыйфаты бәндәләрне пәйгамбәрләр, әүлияләр дәрәҗәсенә күтәрәдер.

Ошбуның өчен Аллаһтан шул юлга кертелүне сораулар телдән генә булырга тиеш түгелдер. Бәлки, ихлас күңел берлән гамәли рәвештә соралырга

1. Хошугъ – Аллаһтан курку хисе.

2. Малик булу – ия булу.

тиешледер. Ягъни һәрбер эшне Аллаһ боерганча алып баручы һәм Аллаһ тыйган эшләрдән тыелучылар бу бөек нигъмәткә тоташадыр. Пәйгамбәрләрнең сыйфаты, гамәл-гыйбадәтләре, әхлак вә әдәпләре, йөреш-торышлары, башка адәм балалары берлән мөгамәлә итүләре, ата-анага, гаиләгә миһербан, шәфкатьле булулары, гомумән, барлык бәни бәшәргә[1] мәрхәмәтле булулары һәм үзләренең бу гүзәл сыйфатларын киләчәк буыннарга да үрнәк итеп калдыра алулары. Ничә мең гасырлар узса да, аларны һаман яд итәрлек дәрәҗәдә булып, бүгенге көндә дә ислам диненең алар юлыннан бара алуы – зур мәрхәмәттер. اهْدِنَا الصِّرَاطَ الْمُسْتَقِيمَ -дога мәэсүралардандыр[2]. Аллаһ Тәбарәкә бу кеби бөек догаларны кабул итәдер. Коръән Кәримдә булган барлык дога, аятьләрнең асыл мәгънәсе اهْدِنَا الصِّرَاطَ الْمُسْتَقِيمَ дер.

غَيْرِ الْمَغْضُوبِ عَلَيْهِمْ [гайрил-мәгъдүби галәйһим]

«И Аллаһ, шундый бәндәләр юлыннан сакла, алар синең газабыңа, ачуга тоташтылар», - димәктер. Адәм балалары арасында Аллаһының ачуына, газабына тоташкан бәндәләр шулардыр.

Ислам дине бөтен нигезләре, кануннары, әмер-нәһиләре берлән адәм балаларын беренче класслар, адәмчелек дөньясына файдалы кеше итеп тәрбия итәдер. Башка мәхлукатларга, адәм балаларына кул берләнме, тел берләнме, көч берләнме, зарар тидерүдән үзен саклый алган бәндәләр генә Аллаһка, сөекле Аллаһның мәрхәмәтенә, нигъмәтенә муафыйк[3] кешеләр хисаб ителәдер. Бу сыйфат Аллаһының ачуына тоташтырадыр. Мөселман булган кеше, әлбәттә, Аллаһка сөекле бәндә булырга тиешледер. Ошбуның өчен, барлык изге теләкләргә ирешү өчен, ошбу догалар берлән укылып, гамәли рәвештә кылынырга тиешледер. Коръән Кәрим эчендә Аллаһ Тәбарәкәнең барлык хәрәм ителеп күрсәтелгән эшләрдән әгәр дә син тыела алмасаң, Аллаһының ачысына, газабына тоташтырадыр.

Мисал өчен, иң куркыныч, бөтен бозыклыкның анасы булган хәмерне эчү – хәрәмдер. Хәмер эчкән кешедә миһербан да юктыр, шәфкать тә юктыр, иман нуры да юктыр. Изгелекне кылудан мәнегъ итә[4], туктатадыр. Тагать-гыйбадәтеннән мәхрүм итәдер. Фәкать бөтен булган бозыклыкны, пычраклыкны кылуга җитәклидер. Бәндәләргә һәртөрле бозык, куркыныч сыйфатларга җитәкчелек

1. Бәни бәшәр – кешеләр.

2. Мәэсүра – күчерелеп килгән.

3. Муафыйк – яраклы.

4. Мәнегъ итү – тыю.

итәр өчен, Аллаһ Тәбарәкә аны хәрәм иткәндер.

Ата-аналарны рәнҗетү, аларның кадер-хөрмәтен китәрү - ислам динендә хәрәмдер. Гайбәт сөйләү, сүз йөртү, ялганга шаһәдәт бирү, кешегә юк бәла-боһтан ялган яла ягу, башкалар хакында сүи занда[1] булу, ягъни ул шулайдыр, болайдыр дип хөкем итүләр - хәрәмдер. Бу сыйфатлар барчасы да дөньяда вакытта адәм баласын аеруча югалтадыр. Йәүме кыямәт Аллаһының иң каты газабына тоташтырадыр. Аллаһының газабына юлыгачактыр. Коръән Кәримдәге барлык нәһи-мөнкәрләр[2] ошбу аятькә кереп бетәдер, ягъни غَيْرِ الْمَغْضُوبِ عَلَيْهِمْ аятенә керәдер. «И Аллаһ, безләргә син ачу тотма, без бәндәләрең кимчелекләре, гөнаһлары бардыр, ошбуның өчен син безнең кимчелекләребезне гафу итеп, үзеңең ачуыңнан ерак кыл,» - дигән сүз буладыр.

Дөрес, Аллаһ Тәбарәкә бәндәләргә бер вакытта да ачу тотмыйдыр. إِنَّ اللَّهَ لَا يَظْلِمُ النَّاسَ شَيْئًا («Юныс», 44) «Ул Аллаһ Тәбарәкә, дөреслектә, бәндәләргә бервакытта да золымлык итмидер». Бу һәм бөек догаларның кабул булуына ишарәдер, ягъни Аллаһтан сорый белсәң, сәбәбенә керешсәң, Аллаһ Тәбарәкә - ачу тотмаучы һәм гафу итүчедер.

Ислам дине бәндәләргә бервакытта да, бер хәлдә чик куймыйдыр, ягъни бәндә үз ихтыяры берлән кабул итә, үз ихтыяры берлән инкяр итә. Мөэмин булу эшендә дә бәндәләр ирекледер: لَا إِكْرَاهَ فِي الدِّينِ («Әл-Бакара», 256) Әмма мөэмин исемен күтәреп, калбеннән монафикъ булуны Аллаһ Тәбарәкә вә Тәгалә сөймидер. Менә шундый икейөзле кешеләргә Аллаһының ачуы гаять катыдыр. Мондый икейөзле кешеләр хакында Коръәне Кәрим болай ди: إِنَّ الَّذِينَ يَشْتَرُونَ بِعَهْدِ اللَّهِ وَأَيْمَانِهِمْ ثَمَنًا قَلِيلًا أُولَئِكَ لَا خَلَاقَ لَهُمْ فِي الْآخِرَةِ وَلَا يُكَلِّمُهُمُ اللَّهُ وَلَا يَنظُرُ إِلَيْهِمْ يَوْمَ الْقِيَامَةِ وَلَا يُزَكِّيهِمْ وَلَهُمْ عَذَابٌ أَلِيمٌ («Али Гыймран», 77): «Шундый мөэминнәр үзләренең иманнарын, гаһәдләрне дөнья малына алыштырдылар. Менә болар өчен ахирәттә өлеш юктыр. Аллаһ Тәбарәкә болар берлән сөйләшмәс тә һәм йәүме кыямәттә аларга бакмас та. Аллаһ Тәбарәкә аларны гөнаһларыннан багламас та, алар өчен рәнҗетүче газап йөкләнәчәктер», - димәктер. Аллаһ Тәбарәкә вә Тәгалә бәндәләргә вәгазь-нәсыйхәт әйтеп, бәндәләрне йәүме кыямәт хәвефеннән саклау өчен, бу аятьне индерде. Әгәр бәндәләр ошбуны аңлап, тугры юлга керә алсалар, бу - «И Аллаһ, ачуыңнан сакла» дигән догаларның кабул булуыдыр.

وَلَا الضَّالِّينَ [вә ләд-даалиин]

---

1. Сүи зан – начар уй.

2. Нәһи-мөнкәр – начар эшне эшләмәскә кушу һәм инкарь итү.

«И Аллаһ, син мине залялəттə[1] калучылар юлыннан сакла», - дигəн сүз буладыр. Коръəне Кəримдəге аятьлəр далəлəттə булучы бəндəлəрнең нинди икəнлеге хакында ачык рəвештə бəян итəдер: كَمَا بَدَأَكُمْ تَعُودُونَ ﴿٢٩﴾ فَرِيقًا هَدَىٰ وَفَرِيقًا حَقَّ عَلَيْهِمُ الضَّلَالَةُ ۗ إِنَّهُمُ اتَّخَذُوا الشَّيَاطِينَ أَوْلِيَاءَ مِن دُونِ اللَّهِ وَيَحْسَبُونَ أَنَّهُم مُّهْتَدُونَ ﴿٣٠﴾ («Əл-Əграф», 29-30) «Адəм балаларыннан əүвəлге халыкның яратылышы берлəн Аллаһка кайтуын Аллаһ телидер.» Ошбуның өчен كَمَا بَدَأَكُمْ تَعُودُونَ, ягъни ничек хəлык кылынган булсан, шулай кайтырга тиешлесең, димəктер. Лəкин адəм балаларының бер фиркасы тугры юлга, ягъни Аллаһ юлына китеп, бер фиркасы далəлəт юлына китте. Менə шул начар юлга – далəлəт юлына китүчелəр шайтанга иярделəр, шайтанны дус тоттылар. Аллаһтан баш тарттылар. Алар ул шайтан аларны тугрылыкка күндерер дип хисап иттелəр. Ул далəлəт юлындагы бəндəлəр - Аллаһтан ераклаштылар. Хакыйкатьне күрүдəн сукыр булдылар. Хакыйкатьне ишетүдəн саңгырау булдылар. Яман, ярамас юлга китүчелек гаять куркынычтыр.

Мөхəммəд Габдүһ тəфисерендə əйтəдер: و كل فريق يموت علي ما عش عليه و يبعث علي ما مات عليه 8нче жилд, 379 нчы сəхифə: «һəрбер фирка үлəдер. Ничек дөнья көтсə, шул юл берлəн кыямəт көнендə кубарыладыр. Нинди юлда үлгəн булса, шул юл берлəн.»

Адəм балаларының начар юлга китүлəренең сəбəбе шулар: бəндə бозыклыкны кыла-кыла, шуңа хəрəслəнə[2], шул гадəткə керə. Шуның өчен ул начарлыкны арттыра гына барадыр. Аның шул юлга керүенə сəбəп аның фикер начарлыкларында. Ул аны шул хакыйкать дип зан итəдер[3]. Һəм шул занны дөрес дип таный һəм шуны арттыра гына барадыр. Коръəн Кəрим бу тугрыда: «وَإِن تُطِعْ أَكْثَرَ مَن فِي الْأَرْضِ يُضِلُّوكَ عَن سَبِيلِ اللَّهِ ۚ إِن يَتَّبِعُونَ إِلَّا الظَّنَّ وَإِنْ هُمْ إِلَّا يَخْرُصُونَ («Əл-Əнгам», 116)», - ди. «Адəм баласының калбенə бер мəртəбə бозыклык керсə, ул үсə генə бара. Бəндəлəр шуңа хəрəслəнə, ягъни шуны чынлык санап, чын күңелдəн шулайдыр дип зан итə, ошбуның өчен Аллаһтан, далəлəттəн сакла дип, дога кылынадыр.

Адəм балаларының һичкеме үзлəрен изə җəннəт əһеле диюгə хакы юктыр. Аллаһтан җəннəт əһеле кылсын дип, дога кылырга һəм Аллаһының боерганнарын дөрес итеп үтəргə, тыйганнарыннан тыелырга тиешледер. Менə мондый

1. Залялəт – азганлык, начар юлга керү.

2. Хəрəслəну – күнегү.

3. Зан итү – уйлау.

булганда, Аллаһ тәбәрәк вә тәгалә ижтиһадың[1] аркасында жәннәт берлән мәшрәф итәчәктер. وَمَا أُبَرِّئُ نَفْسِي ۚ إِنَّ النَّفْسَ لَأَمَّارَةٌ بِالسُّوءِ إِلَّا مَا رَحِمَ رَبِّي («Йосыф», 53) «Йосыф пәйгамбәремез: «Үземнең нәфсем изге дип әйтә алмыйм, чөнки нәфес бозык юлга бик тиз иярәдер. Мәгәр шул кешеләр бозык юлга иярмәсләр, кайсыдыр ки Аллаһының мәрхәмәтен, рәхмәтен өмет итеп, Аллаһ боерганча гамәлләрне кылдылар», - дигән.

Ошбуның өчен дөньяга килгән һичбер адәм баласының «мин - изге» диюгә хакы юктыр һәм башкаларны да хөкем итүгә хакы юктыр. Бәндәнең изгелеге, явызлыгы Аллаһ хозурында мәгълүмдер, ләкин изгеләр гадәте - изгелек кылучы дип, хөкем кылу мөмкиндер һәм Аллаһтан: «Йә Рабби, син үзең сөйгән изге бәндәләрең җөмләсеннән кылсаң иде» ,- дип ялварырга һәм сорарга һәр кайсымыз бурычлыдыр. Иншә Аллаһ Аллаһ – тәбәрәк изге догаларыбызны кабул итүче, үзе кабул кылып, үзенең сөйгән бәндәсе кылсын. Амин.

Әл-хафиз кәләмуллаһ вәл-хаҗҗел-харәмәйн Габделбари Низаметдин Гайса әл-Уфави, асыл ватаны әл-Әзи әт-Төмәни.

1. Ижтихад – тырышлык.

## «Бакарә – Сыер» сүрәсе

Бу сүрә ике йөз сиксән алты аять булып Мәдинәдә иңгән. Моның «Бакарә-сыер» сүрәсе булып әйтелүенә сәбәп - сыер турында гаять мөһим кыйсса булуы. Яһүдиләр турында фәкать сыер вакыйгасы бик олуг урын тотадыр.

الم ﴿١﴾ ذَٰلِكَ الْكِتَابُ لَا رَيْبَ فِيهِ هُدًى لِّلْمُتَّقِينَ ﴿٢﴾

Моның максаты: бер нәрсәнең дөреслеген тасдыйк итәр[1] өчен, әлбәттә, кыйсем ант ләзем. Ошбуның өчен Аллаһ Коръәне Кәримнең Аллаһдан куркучылар өчен генә тугры юлга күндерүче китап идегене тасдыйк итеп, кыйсым кыладыр. Димәк, Аллаһтан курыкмаучы, Аллаһны тәгъриф итмәүчеләр өчен Коръән юл күрсәтүче түгел, чөнки алдагы аять ачык рәвештә мөттәкыйннәр2, Аллаһтан куркучыларны кем идегене белдерәдер.

الَّذِينَ يُؤْمِنُونَ بِالْغَيْبِ وَيُقِيمُونَ الصَّلَاةَ وَمِمَّا رَزَقْنَاهُمْ يُنفِقُونَ ﴿٣﴾

Аллаһтан куркучыларның сыйфаты шундыйдыр: алар Аллаһның барлыгына гаибән[3] ышаналар, аларга күренеп тору шарт түгелдер. Алар Аллаһының әхлакый-әдәби тәрбия өчен кушылганын, гамәлләреннән намаз-гыйбадәтне үтиләр. Намазның әхлакый-әдәби тәрбия өчен кушылуы турында истикъбаль[4] аять булып үтәр. Моның соңында Аллаһ аларны тәрбия итү өчен биргән нигъмәтләр-ризыклардан башкаларга, фәкыйрь вә ятимнәргә садыйкән кылырлар. Садакаларның фәкыйрьләр хакы идеге турында киләчәктә аять килер.

وَالَّذِينَ يُؤْمِنُونَ بِمَا أُنزِلَ إِلَيْكَ وَمَا أُنزِلَ مِن قَبْلِكَ وَبِالْآخِرَةِ هُمْ يُوقِنُونَ ﴿٤﴾

Алар дәхи шундыйлардыр, ягъни Аллаһтан куркучыларның сыйфатыннан берсе: Аллаһтан иңдерелгән китапка - Коръәне Кәримгә ышаналар. Коръән Аллаһ тарафыннан иңдерелгән китап идегенә ачыклыйдыр. Шулай ук үзләреннән элгәреләргә иңгән китапларга иман китерәләр, ышаналар. Вә, шулай ук, ахирәт көненең булуына чынлап ышанырлар.

أُولَٰئِكَ عَلَىٰ هُدًى مِّن رَّبِّهِمْ ۖ وَأُولَٰئِكَ هُمُ الْمُفْلِحُونَ ﴿٥﴾

Менә шулар инде тәрбияче Аллаһ күрсәткән туры юлдагы кешеләр. Менә шулар инде фәлах[5] табучы, котылучылар, ягъни намаз вә иттифакъ – бу нәфесне җиңә торган, әхлакый-әдәби тәрбия бирә торган гамәлләр. Болар өчен,

1. Тасдыйк итү – раслау.

2. Мөттәкыйн – Аллаһтан куркучы.

3. Гаибән – яшерен.

4. Истикъбаль – киләчәк.

5. Фәлах – уңыш.

Аллаһының китабына ышану ләзем табыладыр һәм Аллаһ хозурында ахирәттә җавап бирүгә ышану ләзем табыладыр. Шуның өчен, Аллаһ Җәллә Җәләлә бу гамәлләр бәндәләрнең калебләрен, әгъзаларын, малларын пакьли торган гамәл булганы өчен, Коръән Кәримдә фәлах табучылар идегене белдереп әйтәдер.

إِنَّ الَّذِينَ كَفَرُوا سَوَاءٌ عَلَيْهِمْ أَأَنذَرْتَهُمْ أَمْ لَمْ تُنذِرْهُمْ لَا يُؤْمِنُونَ ﴿٦﴾

Аллаһ Тәбарәкә вә Тәгалә Аллаһны тәгъриф кылмаучыларны кирәк син аларны куркыт, кирәк куркытма, алар бит ышаначак түгелләр идегене ачык белдерә. Менә моннан аңларга кирәк: Аллаһка ышанмаучы, Аллаһны танымаучы икенче бертөрле фикердә, икенче бертөрле юл тоткан булып, аларга Коръән хөкеме яки кыямәт берлән куркытып, дингә кертү булмаячаклыкны белдерә димәк. Ислам дине ихтыярый бер дин булып, фәкать Коръәннең хөкеме ышанучылар өчен генәдер. Ислам диненең ихтыярый дин идегенә, ислам динендә көчләү юклыгы хакында аятьләр бар. Аллаһ Тәбарәкә вә Тәгалә ышанмаучылар хакында, аларның калебләре башка нәрсә берлән капланганы өчен, болай ди:

خَتَمَ اللَّهُ عَلَىٰ قُلُوبِهِمْ وَعَلَىٰ سَمْعِهِمْ ۖ وَعَلَىٰ أَبْصَارِهِمْ غِشَاوَةٌ ۖ وَلَهُمْ عَذَابٌ عَظِيمٌ ﴿٧﴾

Аллаһ бит аларның калебләрен каплады, ягъни алар икенче фикергә күчтеләр, шуның өчен алар хаклыкны ишетмәсләр, хаклыкны күрмәсләр. Күңелләренә пичәт басылган, күзләрен караңгылык каплаган, болар турында Аллаһның газабыннан башка һичнәрсә булачак түгел дип белдерүдән максат. Аллаһка ышанмаучыларга сөйлисе, аларны үгетлисе юк һәм алар аны тыңламыйлар да, аңларга теләмиләр дә дип әйтәдер. Бу да ислам диненең ирекле идегенә зур дәлилдер.

وَ مِنَ النَّاسِ مَن يَقُولُ آمَنَّا بِاللَّهِ وَبِالْيَوْمِ الْآخِرِ وَمَا هُم بِمُؤْمِنِينَ ﴿٨﴾

Менә бу аять монафикълар хакында, икейөзлеләр хакында, аларны мөэмин дип әйтү юклыгы хакында да. Шундый кешеләр: «Без Аллаһка һәм ахирәткә иман китердек, ышандык», - диерләр, әмма гамәлдә булмый, телдә генә булганнарга мөэмин диелми. Аллаһ тарафыннан куелган һәрбер эш гамәли булу ләзем. Гамәл булмау мөэминлек сыйфаты түгел. Гакыл үлчәүгә бер фабрикада бер детальне ясамый торып, ясадым дип булмый. Шуның кебек ышангач, бөтен эш гамәли булуы ләзем.

Мондый кешеләр хакында Аллаһ ачык белдерәдер:

يُخَادِعُونَ اللَّهَ وَالَّذِينَ آمَنُوا وَمَا يَخْدَعُونَ إِلَّا أَنفُسَهُمْ وَمَا يَشْعُرُونَ ﴿٩﴾

Һаман да: «Мин – мөэмин», – дип гамәл кылмаучылар турында бу бәндәләр Аллаһны алдыйбыз дип беләләр, ләкин алар Аллаһны алдый алмыйлар, үзләрен-

үзләре алдыйлар. Аллаһ - бар нәрсәне белүче зат. Ләкин адәм баласы үзенең алдануын үзе белми, аңламыйдыр. Әгәр Аллаһка ышансак, кыяматкә ышансак, телдән генә ышанып, Аллаһ кушканча гамәл кылмау, Аллаһ белми калды дип уйлау, бу Аллаһка ширкәт була. Ә Аллаһка ширкәт кылучылар Аллаһның газабына тоташадыр. Менә шуның өчен Аллаһы Тәбарәкә, мондый халыклар хакында ачык аңлату өчен, болай ди:

فِي قُلُوبِهِم مَّرَضٌ فَزَادَهُمُ اللَّهُ مَرَضًا ۖ وَلَهُمْ عَذَابٌ أَلِيمٌ بِمَا كَانُوا يَكْذِبُونَ ﴿١٠﴾

Андый бәндәләр калебләре чирле бәндәләр булып, Аллаһ ул чирләрен арттыра гына, аларга Аллаһының рәнҗетүче газабы булачак, чөнки алар ялганчылар булдылар. Ягъни мин иманлы дип, гамәл итмәү халыкны, кешеләрне алдау була. Аллаһны алдап булмый, менә шуның өчен аларга газап каты һәм әрнеткеч булачак.

وَإِذَا قِيلَ لَهُمْ لَا تُفْسِدُوا فِي الْأَرْضِ قَالُوا إِنَّمَا نَحْنُ مُصْلِحُونَ ﴿١١﴾

Әгәр шул халыкны алдаучыларга: «Нигә соң сез җир йөзендә бозыклык кыласыз, үзегез без мөэмин дисез?» - дип әйтелсә, алар җавап бирерләр: «Юк, без бозыклык кылмыймыз, без тынычлык, татулык телибез». Менә бу аять [= күренеш] хәзерге тормышта бик күп, чөнки дингә ышанучыларның һәрберсе нинди генә дин тотмасын: «Без динле», - дип, халыкны ышандырып, халык арасында дошманлык, бәхетсезлек тудырырга тырышалар, адәм балаларын бер җинес, бер диндә булган халыкларга каршы котыртып, береннән-берене үтерәләр, моңа тарихлар шаһиттер. Аллаһ боларга җавап итеп, аларның кем идегене ачык белдерәдер:

أَلَا إِنَّهُمْ هُمُ الْمُفْسِدُونَ وَلَٰكِن لَّا يَشْعُرُونَ ﴿١٢﴾

«Хәтерегездә нык тотыгыз, и адәм балалары, без динле дип, халыкны һәлакәт юлына, сугыш юлына котыртучылар, динне корал ясап кулланучылар. Алар бозыклык кылучылар, котычкыч халык, ләкин алар аны аңламыйлар яки аңларга теләмиләр», - дип белдерәдер.

وَإِذَا قِيلَ لَهُمْ آمِنُوا كَمَا آمَنَ النَّاسُ قَالُوا أَنُؤْمِنُ كَمَا آمَنَ السُّفَهَاءُ ۗ أَلَا إِنَّهُمْ هُمُ السُّفَهَاءُ
وَلَٰكِن لَّا يَعْلَمُونَ ﴿١٣﴾

Әгәр дә кешеләргә иман килгән кебек иман китерегез диелсә, алар әйтерләр: «Без сезнең надан юлдан чыккан кешеләр кебек иман китерәчәкмезме соң?» Ләкин алар үзләре надан булганнарын үзләре белмиләр. Бернәрсәнең хакыйкатен белми торып, төрле тарафтан уйлап карамый торып, кеше сөйли дип, яки тәкәбберлек кылып, ышанмау наданлык хисап ителәдер. Аллаһ тара-

фыннан һәрбер нәрсәнең халкатын тикшереп, кичә-көндезләрнең, юлдан? планеталарның хикмәте илаһи берлән һәрвакыт бер урында, бер формада булулары, табигатьнең һичвакытта да ялгышмавы - бу үзе бер зур галәмәттер. Менә мондый кешеләрнең наданлыгы шуннан ачык мәгълүмдер. Алдагы аять моны изах итәдер:

وَإِذَا لَقُوا الَّذِينَ آمَنُوا قَالُوا آمَنَّا وَإِذَا خَلَوْا إِلَىٰ شَيَاطِينِهِمْ قَالُوا إِنَّا مَعَكُمْ إِنَّمَا نَحْنُ مُسْتَهْزِئُونَ ﴿١٤﴾

Кайчан алар иман китерүчеләргә очрасалар: «Без иман китерүче», - диярләр. Кайчан үзләренең котыртучыларына юлыксалар: «Без сезнең белән, без бит тик аларны истиһза кылабыз[1], мәсхәрә кылабыз гына», - диерләр. Ләкин Аллаһның моңа ачык җавабы бар:

اللَّهُ يَسْتَهْزِئُ بِهِمْ وَيَمُدُّهُمْ فِي طُغْيَانِهِمْ يَعْمَهُونَ ﴿١٥﴾

«Аллаһ аларны мәсхәр кылыр һәм алар үз дәләләтләрендә калдырылыр. Хакыйкатьне, тугрылыкны таба алмаслар. Моннан максат: калебләр бер кире күргәч, яхшылыкка аңлавы иҗтиһад итми, шуның өчен алар тугрылыктан ерак булып, мәсхәрә кылынырлар», - димәктер.

Аларның нинди кеше идеген алдагы аять ачып бирә:

أُولَٰئِكَ الَّذِينَ اشْتَرَوُا الضَّلَالَةَ بِالْهُدَىٰ فَمَا رَبِحَت تِّجَارَتُهُمْ وَمَا كَانُوا مُهْتَدِينَ ﴿١٦﴾

«Менә мондый кешеләр тугрылыкны бозыклык берлән алыштыручылар, тугрылыкны начарлыкка дөнья өчен сатучылар». Моннан максат нәрсә, тугрылык нәрсә, бозыклык нәрсә идегене белмәүчеләр яки белергә теләмәүчеләр хакында бу аять иңгән. Ләкин аларның бу эшләре аларга һич файда китермидер. Алар тугры юлга күнәчәк түгелдер. Дәхи алар турында мондый пример (мисал) килергә мөмкин дип Аллаһ әйтә:

مَثَلُهُمْ كَمَثَلِ الَّذِي اسْتَوْقَدَ نَارًا فَلَمَّا أَضَاءَتْ مَا حَوْلَهُ ذَهَبَ اللَّهُ بِنُورِهِمْ وَتَرَكَهُمْ فِي ظُلُمَاتٍ لَّا يُبْصِرُونَ ﴿١٧﴾

Аларның охшашлары шулай дип Аллаһ белдерә: «Ул утны кабызды. Инде тирә-якны яктыртам дигәндә, Аллаһ ул утны сүндерде дә, бернәрсә күрмәс булып калдылар». Ягъни күз ут яктысыннан соң күрмәс булып китә. Шул рәвешле, хакыйкатьтән ераклаттылучылар хакыйкатьне күрмәс хәлгә киләләр дигән сүздер. Алар хакында тәкрар Аллаһ әйтәдер:

1. Истиһза – хурлау, мыскыллау.

صُمٌّ بُكْمٌ عُمْيٌ فَهُمْ لَا يَرْجِعُونَ ﴿١٨﴾

«Алар инде саңгыраулар, телсезләр, сукырлар, шуның өчен алар кайтачак түгелләр». Ягъни хакыйкатьне тыңламый да, сөйләми дә, күрми дә, хакыйкатькә кайтырга теләми дә димәктер.

Бу аять ачык аңлатадыр: хакыйкатьне күрергә теләмәүчеләрнең күзләре сукыр да, ишетергә теләмәүчеләрнең колаклары саңгыраудыр, хакыйкатьне сөйләргә теләмәүчеләр телсез берлән бәрабәрдер. Бу сыйфатлар булган кешеләр – Аллаһка кайтырга теләмәүчеләр.

أَوْ كَصَيِّبٍ مِّنَ السَّمَاءِ فِيهِ ظُلُمَاتٌ وَرَعْدٌ وَبَرْقٌ يَجْعَلُونَ أَصَابِعَهُمْ فِي آذَانِهِم مِّنَ الصَّوَاعِقِ حَذَرَ الْمَوْتِ ۚ وَاللَّهُ مُحِيطٌ بِالْكَافِرِينَ ﴿١٩﴾

Аллаһ мисал итәдер: күктән төшкән яңгыр астында калган кешеләр кебек, ул яңгырда караңгылыклар, күк күкрәүләр, яшен яшнәүләре бар. Алар үлемнән куркып, яшеннән саклану өчен, колакларына бармакларын тыгалар, ләкин Аллаһ карышучыларны һәр ягыннан беләм һәм күзәтәдер.

Аллаһның күктән иңгән Коръәне - ул мисле яңгыр рәвешле мәрхәмәттер. Яңгыр - һәр галәмгә мәрхәмәттер, бәрәкәттер. Ул Коръән эчендә шатлык, һәм кайгылар булуны бәян итә торган аятьләр күптер. Менә шуларны ишетмәү өчен, үз юлыннан адашып, бармакларын колакларына тыгалар, ишетмәскә тырышалар. Ләкин эш бит аларда түгел, син ышансаң, ышанмасаң да, Аллаһка кайтачаксын, дип тәнбиһтер.[1] Бу аять тасдыйкъ өчен Коръәндә аятьләр күптер. ثُمَّ إِلَيْهِ تُرْجَعُونَ кеби аятьләрдер.

يَكَادُ الْبَرْقُ يَخْطَفُ أَبْصَارَهُمْ ۖ كُلَّمَا أَضَاءَ لَهُم مَّشَوْا فِيهِ وَإِذَا أَظْلَمَ عَلَيْهِمْ قَامُوا ۚ وَلَوْ شَاءَ اللَّهُ لَذَهَبَ بِسَمْعِهِمْ وَأَبْصَارِهِمْ ۚ إِنَّ اللَّهَ عَلَىٰ كُلِّ شَيْءٍ قَدِيرٌ ﴿٢٠﴾

«Яшен янса, аларның күзләрен чыгара яза, шул яшен аларны яктырткан саен, алар шул башлыктан файдаланып йөриләр, әгәр дә яшен караңгыласа, алар туктап калалар. Әгәр дә эшләре өчен Аллаһ теләсә иде, аларның күзләрен вә колакларын юк итәр иде. Аллаһның бит һәрнәрсәгә көче житә». Монда максат: алар Коръән нурын күрәләр һәм күзләре чыга яза һәм шул Коръән нуры берлән файдаланалар. Әгәр Коръән иңми торса, туктап калалар. Моннан максат: ислам дине никадәр ихтыярлы. Гәрчә чыгучы булса да, ихтыяр кылалар. Бәндә үзе аңлап, эш алып баруга ихтыярлыдыр.

---

1. Тәнбиһ – кисәтү.

﴿يَا أَيُّهَا النَّاسُ اعْبُدُوا رَبَّكُمُ الَّذِي خَلَقَكُمْ وَالَّذِينَ مِن قَبْلِكُمْ لَعَلَّكُمْ تَتَّقُونَ ﴿٢١﴾

Бу урында Аллаһ бөтен адәм балаларына әйтәдер: «И бәндәләр, сез Аллаһка гыйбадәт итегез! Үзегезнең бәндә икәнлегезне белдерегез! Ул бит сезне бар итүче һәм сездән элеккеләрен дә бар итүче! Шул вакытта гына чын Аллаһның бәндәсе булуыгыз өметледер». Моннан максат: шулар чын диннәр итеп таныла шул кеше үзе тәрбия итүчене танып, аңа үзенең кол-габд идегене белдерә алса. Бу аятьтән аңларга мөмкин: бу хәяттән башка бер хәяттә булып узган идек, чөнки сездән элекке адәмнәрне дә яратучы Аллаһ ул. Бу да Аллаһының бакый бер зат идегене аңлатадыр. Моны тасдыйк өчен: كُلُّ مَنْ عَلَيْهَا فَانٍ وَيَبْقَى وَجْهُ رَبِّكَ ذُو الْجَلَالِ وَالْإِكْرَامِ («Әр-Рәхман», 26-27) Моның соңында Аллаһның сыйфатын, көчен белдерү өчен, түбәндәге аять берлән ачып бирә:

الَّذِي جَعَلَ لَكُمُ الْأَرْضَ فِرَاشًا وَالسَّمَاءَ بِنَاءً وَأَنزَلَ مِنَ السَّمَاءِ مَاءً فَأَخْرَجَ بِهِ مِنَ الثَّمَرَاتِ رِزْقًا لَّكُمْ ۖ فَلَا تَجْعَلُوا لِلَّهِ أَندَادًا وَأَنتُمْ تَعْلَمُونَ ﴿٢٢﴾

Ул Аллаһ сезләр өчен җирне уңайлы түшәде һәм өстегездә чиксез, бер дә җимерелми торган күкне төзеде. Ул күктән сулар төшеп, шул сулар берлән сезне туйдыру өчен, инде сез ул Аллаһка һичнәрсәне тиңдәш ясамагыз, сез аның охшаш юклыгын яхшы беләсез. Бу урында шуны аңларга кирәк: җир бәндәләргә файдалану өчен уңайлы итеп яратылды. Җирдән адәм балалары туенадыр, киенәдер, башка мәнфәгатьле нәрсәләрен дә шуннан аладыр. Әмма бәндәләрнең ризыгы өчен Аллаһның күгеннән төшкән яңгыры җитәдер. Ләкин Аллаһка охшаш һичнәрсә юктыр. Булуы мөмкин түгелдер. Дөрес, «Искуственный (ясалма) яңгыр ясый алалар бит», - дигән фикергә килү мөмкин,. Ул бит беркадәр участкага гына җитә, әмма яңгыр бөтен җир йөзенә җитәрлек буладыр. Хәтта шул яңгыр тиешле матдәләрне бирәдер һәм җир өстендәге үсемлекләр генә түгел, бәлки һәртөрле җирдән чыккан байлыкларга да яңгырның файдасы бардыр. Ягъни яңгырда бар яктан туярырлык матдәләр бардыр. Димәк, тиңдәш һич мөмкин түгел.

وَإِن كُنتُمْ فِي رَيْبٍ مِّمَّا نَزَّلْنَا عَلَىٰ عَبْدِنَا فَأْتُوا بِسُورَةٍ مِّن مِّثْلِهِ وَادْعُوا شُهَدَاءَكُم مِّن دُونِ اللَّهِ إِن كُنتُمْ صَادِقِينَ ﴿٢٣﴾

Аллаһ Тәбарәкә вә Тәгалә бу аять берлән шуны белдерәдер: әгәр дә сезләр Мөхәммәдпәйгамбәргә иңдерелгән Корьәнгә шик тотсагыз, үзегез шуңа охшаган берәр сүрә китерегез, шулай ук, Аллаһтан башка ярдәмчеләрегезне дә бу эшкә ярдәмгә чакырыгыз. Әгәр дә сез сүзләрегездә туры икәнсез, эшләп карагыз. Моннан максат шулдыр: Корьән бәндәләрне һәрнәрсәне эшләргә

ихтыяр итәдер. Хәтта хикмәт фәлсәфәсенең чиге булмаган Коръән Кәримне дә эшләп карагыз, дип ирек бирәдер. Коръәнгә охшаш китерү мөмкин түгел, чөнки Коръән Кәримдә күрсәтелгән дәлилләр, аларга һич бәндәнең көче җитми, хәятта практически (гамәли) бернәрсә эшләнсә дә, гасырлар узу белән, ул алышына барадыр. Әммә Коръән хөкме берлән күрсәтелде: Аллаһының кануннары һич алышынмаган һәм алышынашачак та түгел. Мисал өчен, миллион еллар күк йөзе хәлык ителгән, миллион еллар кояш хәрәкәт итә, кичә-көндезләр булып тора, һичкем алыштыра алмый. Дөрес, караңгы төнне искуственно (ясалма рәвештә) көндез ясап була, ләкин менә көндезге кояш нурын тоташ итеп, я бар җирдә дә төн ясап булмый. Нинди булса, төнен берлән бер участокны ничә минутларга каплап булса да, билгеле сәгать каплап торып булмый. Ходай тәкъдире берлән куелган кичә мәгълүм сәгать караңгы булып тора торган һәм торачак. Менә шуның өчен аять: لَا تَبْدِيلَ لِخَلْقِ اللَّهِ («Әр-Рум», 30).

فَإِن لَّمْ تَفْعَلُوا وَلَن تَفْعَلُوا فَاتَّقُوا النَّارَ الَّتِي وَقُودُهَا النَّاسُ وَالْحِجَارَةُ أُعِدَّتْ لِلْكَافِرِينَ ﴿٢٤﴾

Әгәр дә сез моны эшли алмасагыз һәм эшли дә алмыйсыз, ул вакытта сез Аллаһка карышучы буласыз да, Аллаһның каты газабына тоташачаксыз. Ул газап ут газабы булып, аның ягулыгы – кешеләр һәм ташлардыр, сез моннан сакланыгыз дип, тәнбиһ кыладыр. Моннан максат: Аллаһының куркытып, дингә кертүе өчен түгелдер, бәлки уйлату тәнбиһ өчендер. Адәм баласы җир йөзенең бәгъзе бер кыйсемнәренә бертөрле канун-закон куя алса да, бөтен җир йөзенә бертөрле закон кую мөмкин түгел. Аллаһның кануны - Коръән сөйләгән һәрбер нәрсә бөтен җир йөзенә, җиргә һәм күктә һәр планеталарга муафыйктыр, ягъни Аллаһ кануны бөтен хәяткә бер формада куелгандыр. Моны булдыру һичкемнең кулыннан килмидер. Көч тә җитмидер, мал ягыннан һич мөмкин түгелдер. Әммә Аллаһ кануннары һичбер акча да кирәкми, эшләп торырга кеше дә кирәкми, электр дә кирәкми. Ул корылган Аллаһтан әмер булганга кадәр дәвам итәдер, һичкем боза алмый, шуның өчен тәнбиһтер.

Аллаһ Тәгалә: «Ул утның ягулыгы адәмнәр һәм ташлар», - дип әйтә. Инде сорау туа: адәмнәр каршы өчен газап кылынса, шул ташларны өчен газап ителә.

Җавап моннан максат: Аллаһ кануны бозып, үзгә, Аллаһлык дәгъвасы кылган рәвешле башка эш эшләсәң, әлбәттә, үзең дә һәлак буласың, бәндәләрне дә һәлак итәсең. Бәндәләрнең хәятендә тик файдалы булган ташларны да һәлак итәсен. Димәк, Аллаһлык дәгъвасы кылучылык бөтен хәятне газабка

мөстәхикъ[1] итәдер. Моңа мисал өчен фиргәвен кыйсасы дәлилдер.

وَبَشِّرِ الَّذِينَ آمَنُوا وَعَمِلُوا الصَّالِحَاتِ أَنَّ لَهُمْ جَنَّاتٍ تَجْرِي مِن تَحْتِهَا الْأَنْهَارُ ۖ كُلَّمَا رُزِقُوا مِنْهَا مِن ثَمَرَةٍ رِّزْقًا ۙ قَالُوا هَٰذَا الَّذِي رُزِقْنَا مِن قَبْلُ ۖ وَأُتُوا بِهِ مُتَشَابِهًا ۖ وَلَهُمْ فِيهَا أَزْوَاجٌ مُّطَهَّرَةٌ ۖ وَهُمْ فِيهَا خَالِدُونَ ﴿٢٥﴾

Менә бу аять инде Аллаһ хөкеменә ышанучылар өчен нәрсә булуны ачык белдерәдер. Мөхәммәд галәйһис-сәламгә Аллаһ: «Син Аллаһка ышанып, Коръән хөкеме берлән гамәл итүчеләргә сөенеч бир, алар өчен бит киләчәк хәят - мәңгелек хәят; араларыннан елгалар агып тора торган, төрле җимешләр үсеп тора торган бакчалар һәм пакъ булган хатыннар бардыр. Алар анда мәңге калачаклар», - дип сөенеч бирүгә әмер итәдер. Вакыйгада, Коръәннең бөтен хөкемнәре гамәлгә куелса, бу инде Коръәнгә ышану була. Бу вакытта адәм балалары һичкемгә зарар итми, бәлки һәрвакытта адәм балаларына мәнфәгатьле эшләр генә эшли. Димәк, адәм баласының үз вакытындагы кыяматтә гакыл җитмәслек рәхәт бакчалары булачактыр һәм бу хәят мәңгелек. Киләчәк буыннарга да үрнәк булып, аларның хәяте дә мул, һәркемгә җитешкән хәят булачак идеген белдерә. Бу урында араларында елгалар агып торыр, җимешләре җиткән рәхәт бакчалары мисал өчен күрсәтелгәндер. Ләкин Аллаһның мәңгелек йортындагы рәхәт бакчалары адәм баласының гакылы җитәрлек булырга тиеш түгел. Бу турыда Пәйгамбәремез дә гакыллар аны аңлап бетерә ала торган көч җитәргән түгел дип тасдыйк иткәндер.

إِنَّ اللَّهَ لَا يَسْتَحْيِي أَن يَضْرِبَ مَثَلًا مَّا بَعُوضَةً فَمَا فَوْقَهَا ۚ فَأَمَّا الَّذِينَ آمَنُوا فَيَعْلَمُونَ أَنَّهُ الْحَقُّ مِن رَّبِّهِمْ ۖ وَأَمَّا الَّذِينَ كَفَرُوا فَيَقُولُونَ مَاذَا أَرَادَ اللَّهُ بِهَٰذَا مَثَلًا ۘ يُضِلُّ بِهِ كَثِيرًا وَيَهْدِي بِهِ كَثِيرًا ۚ وَمَا يُضِلُّ بِهِ إِلَّا الْفَاسِقِينَ ﴿٢٦﴾

Аллаһ бит һич тартынмый, кечкенә җебенме яки аннан зурмы мисал өчен китерә, ләкин Аллаһка ышанучылар нинди генә нәрсә булмасын, Аллаһтан идегенә ышаналар. Әмма Аллаһка карышучылар: «Соң Аллаһ бу нәрсәне мисал итеп китерүдә нәрсә тели икән?» - дип әйтәләр. Күпләр начар юлга кителәр вә күпләр тугры юлга кителәр. Һәрбер кечкенә нәрсәгә игътибар итүләре ләзем, чөнки Аллаһның бөтен аятьләрендә нинди дә булса бер зур хикмәт бардыр. Бу турыда 23нче аятьнең шәрхендә бераз язылган иде. Шул кеше, кайсыдыр ки бернәрсәне тикшерми торып инкяр итә, менә шуның өчен һәрнәрсәне тикшерү ихтыяры булган бер кешедер.

1. Мөстәхикъ – лаеклы.

Менә бу аять даләләт итүчеләр кемнәр икәнен күрсәтә:

**الَّذِينَ يَنقُضُونَ عَهْدَ اللَّهِ مِن بَعْدِ مِيثَاقِهِ وَيَقْطَعُونَ مَا أَمَرَاللَّهُ بِهِ أَن يُوصَلَ وَيُفْسِدُونَ فِي الْأَرْضِ ۚ أُولَٰئِكَ هُمُ الْخَاسِرُونَ ﴿٢٧﴾**

Менә болар – шундый кешеләр, ягъни фасикълар, Аллаһ биргән гаһедләрен боздылар. Менә шул игътибарсыз караулары берлән Аллаһының күп әмерләрен җиренә җиткерүдән тукталалар. Җир йөзендә бозыклык кылалар. Менә болар инде кайгы-хәсрәттә булучылар.

Моннан максат шулдыр: Аллаһның кәламен тикшерми торып, игътибар итми торып, мәнгы итү - дөрес эш түгел, бу - Аллаһка биргән вәгъдәгә хыянәт буладыр. Гомумән, бөтен хәяттә булган нәрсәләрне тикшерми торып, мәнгы итмәү, хәяткә хыянәт буладыр. Хәяткә хыянәт адәм баласыны рисва итәдер. Менә шуның өчен Аллаһ: **هُمُ الْخَاسِرُونَ** , - дип тәнбиһ кыладыр. Хәяттә бөтен нәрсә тикшерергә тиеш, тикшерелгән соңында гына гамәлгә куелырга тиеш. Әгәр дә Коръәннең бөтен хөкемнәрне чын игътибар берлән тикшерелсә иде, ул канун - бу хәят өчен дә, киләчәк хәят өчен дә иң уңайлы канундыр.

Менә тагын Аллаһ бәндәләргә ачык рәвештә аңлату өчен аятьне китерә:

**كَيْفَ تَكْفُرُونَ بِاللَّهِ وَكُنتُمْ أَمْوَاتًا فَأَحْيَاكُمْ ۖ ثُمَّ يُمِيتُكُمْ ثُمَّ يُحْيِيكُمْ ثُمَّ إِلَيْهِ تُرْجَعُونَ ﴿٢٨﴾**

# Коръән тәфсире (Икенче варианты)

Коръән дигән сүз «икъра»дан алынган беренче сүз, Коръән «икъра» берлән, ягъни укырга кушу берлән боерылган. Рәсүл тарафыннан укылып нәшер ителгән сүрә.

Коръән барлыгы 23 ел буена Рәсүлемезгә бирелгән, дини сөальләргә җавап әйтелеп иңелгәндер. Ошбуның өчен Коръәннең мәгънәсен бер сүзгә бер сүз перевод (тәрҗемә) итеп кенә аңлап булмый, аннан соң кайбер аятьләр берничә төрле мәсьәләдән тора. Менә шуның өчен Коръәннең аятенә шәрех-толкование яки аңлатма кертелергә тиеш була.

Беренче сүрә - «Фатиха», ачкыч мәгънәсендә дә була. Ләкин бу урында – бәндәнең чын күңеленнән догасыдыр. Кыскача мәгънәсе тулысы берлән сүз аңлата. Коръән бирәүгә дә көчләп өйрәтүгә, аңлатуга мохтаҗ түгел. Ул үзенең дөрес эчтәлеге берлән үзеннән-үзе адәм балалары өчен кирәк бер канун, кирәк ышанасын, кирәк ышанмасын. Адәм баласы гакыл иясе булган шул юл берлән гамәл итә.

Димәк, адәм баласы дөньяда башка адәмнәргә файдалы булган эшләр эшләргә, зарарлы булганнарыннан тыелырга тиеш. Бу динле-динсез булуга карамый. Бәлки адәмнең адәмчелек сыйфатыдыр. Менә болар бар да Коръәндә бардыр. Динле кеше: «Аллаһ шулай кушкан», - дип саклана, ә дингә ышанмаучылар үзенең саф вөҗданына ышанадыр.

«Фатиха» сүрәсенең мәгънәсе. Адәм балалары, хайваннар, барлык җирдә вә күктә булган хәят планеталар, бөтен җир вә күкнең бер канун берлән саклануы – галәмнең тәрбиячесе Аллаһның бөек сыйфатыдыр.

Менә шул сыйфатны, канунны бозмый саклый алуы өчен, Аллаһка хәмд-мактау белдереләдер. Бөтен хәят мактау белдерәдер. Ягъни аларның бер дә нарушать итми (бозмыйча), һәркайсы үз керәсендә яшәве - үзе хәмдтер, мактаудыр (бу турыда киләчәк аятьләрдә белдерелер).

Әр-рәхмән әр-рәхим сыйфаты. Аллаһ бәндәләргә мәрхәмәтледер, ягъни дөнья йөзендәге мәрхәмәт ул инде бөтен галәмнең адәм баласына файдалы булып яралтылуы һәм адәм баласының хәяттә булган бөтен мәхлукатларга көче житәрлек, ягъни бөтен мәхлукатны үзенә яшь итәрерлек булуы Аллаһның мәрхәмәт сыйфатыдыр. Бәндәнең бөтен мәхлукатларга хуҗа була алуы хакында алдагы аятьләрдә тәкрар ачык итеп язылыр.

Әр-рәхим сыйфаты. Бусы Аллаһның йомышак табигатьле булуы, ягъни адәм баласы дөнья хәятендә хыянәт итеп, кануннарны бозса да, шундый вакытта үч алмавы, җәза кылмавы, бәндә үзе аңлар әле, төзәлер әле дип, җәзаны

кичектерү сыйфатыдыр. Дөрес диндә булган кеше кыяматкә, ахирәткә ышанадыр.

Шул көндә хөкем итүче Аллаһның сыйфатыдыр. Шуның өчен мөэмин: «Син шул көннең хуҗасы, малик буласың», - дип, Аллаһка ялварырга тиеш була. Үзенең бәндәчелеген белдерергә тиеш була. Менә шуның өчен мөэминнен: «Мин син кушканнарны тотам, сиңа бәндәчелек белдерәм. Әгәр мин канунны өзеп, бер гөнаһ кылсам, син дә, үтенәм, миңа ярдәм ит, кичер», - дию була.

«Кичер, калдырма, тугры булган юлга, үзең күрсәткән юлга, адәм балаларына файдалы юлга күндер. Ул юл - шундый юл: син бу тугры юл берлән үзенең ачуыңнан ерак кылып, тәрбия иттең, коточкыч сыйфатлардан сакладың, йә Рабби! Син безләрне дә шулай сакла», - дигән сүз буладыр. Шуның өчен бу бөек дога артыннан «әмин» диелсә, «Йә Рабби, кабул кыл!» - дигән сүз буладыр.

## 2нче сүрәсе – «Сыер» сүрәсе.

Бу сүрәгә бик күп шәригать кануннары керәдер. Һәр тәнбиһләр[1] - исламның әсасы[2]: иман, намаз, руза, зәкәт, хаҗ, никах, талак, метрика – шуларны изах итү өчен тарихлар. Гомумән, солых, татулык, дәүләт, иттифаклык һәм башка бик күп гыйлем: анатомия, астрономия, физика гыйлеме, байларга тиеш булган чыгымнар, налог кеби, ул фәкать башкаларга ярдәм йөзеннән булу кеби эшләрегездер.

Корьәндә шушы «Сыер» сүрәсенең башында мәгънәсе булмаган сүзләр дә куелгандыр. Барлыгы 24 сүздер. Моның сәбәбе – һәр эштә адәм баласы ант иткән кеби бу Корьәннең эченә кергәндер. «Аллаһ берлән ант итеп әйтәм», - дигән сүздер. Әлиф-ләм-мим.

1. Әмер – сүзнең баштагы аятен шулай аңларга кирәк.

2. «Бу Корьәннең әдәм балаларын тугры юлга күндерүче Китап икәнлегенә шик юктыр», - дип, «Аллаһ берлән ант итәм», - дигән сүздер.

3. **ٱلَّذِينَ يُؤْمِنُونَ بِٱلْغَيْبِ** Туры юлга күндерүчеләр, алар шулардыр – гайб юлга, күзгә күренмәгән Аллаһка ышанып, ул кушкан намазларны укырлар, үзләрендә булган ярылыктан фәкыйрьләргә иттифак кылырлар.

4. Моның соңында ул тугры юлга күнгән бәндәләр үзләренә тапшырылган китап Корьәнгә һәм аннан алда иңгән китапларга ышанырлар.

---

1. Тәнбиһ – кисетү.

2. Әсас – нигез.

5. Һәм ахирәт көннең булуына чын күңеленнән ышаналар. Менә бу сыйфатлы кешеләр Аллаһның тугры юлга күндерелгән бәндәсе булыр. Алар - үзләренең теләкләренә ирешүчеләрдер.

6. Ышанмаган, иман итмәгән кешеләр, аларны куркытсаң да, куркытмасаң да, алар ышанмыйлар.

7. Чөнки аларның колаклары ишетми, калебләре бикләнгән, күзләре хакыйкатьне күрүдән сукырлашкан. Боларга Аллаһның газабы - каты юлдыр (тәнбиһтер).

8. Тагын адәмнәрнең шундыйлары да бар: без Аллаһка да ышанабыз, ахирәткә дә ышанабыз, ләкин алар ышанучылар түгелдер.

9. Болар: «Аллаһны алдыйбыз», - дип уйлыйлар. Юк, ул Аллаһны алдый алмыйлар. Алар үзләрен-үзләре алдыйлар. Шуны аңламыйлар.

10. Чөнки аларның калебләре авырудыр, ягъни аңламыйдыр, Аллаһ ул авыруны арттырыр һәм аларга Аллаһның ахирәт газабы булачактыр.

11. Шул ялган теләгәннәре өчен.

12. Әгәр аларга: «Сез дөньяда бозыклык кылмагыз», - дип әйтсәң, алар: «Юк, бозыклык кылмыйбыз, без төзәтәбез», - дип әйтерләр.

13. Юк, алай түгел, алар начарлык кылалар, ләкин үзләре аңламыйлар.

14. Әгәр: «Халык иман китергән кеби сез дә иман китерегез», - дип әйтсәң, алар: «Ахмак халыклар кебек иман китерикме?» - дип әйтерләр. Юк, алар үзләре - ахмаклардыр, ләкин алар аны белмиләр.

15. Монафикълар, икейөзле кешеләр мөэминнәрне очратсалар: «Без сезнең дингә ышанабыз», - диярләр. Мөэминнәр булмаса, алар: «Без сезнең берлән ул мөэминнәрне мәсхәрә кылабыз», - диеп әйтерләр.

Алар әгәр иман китергән кешеләргә очрасалар: «Без иман китердек», - диләр. Әгәр үзләренең шайтаннарына аулак урында очрасалар: «Без сезнең белән, без аларны мәсхәрә кылабыз гына», - диләр.

Аларны Аллаһ мәсхәрә кыладыр һәм Аллаһ аларның чиктән ашуларына юл куя.

Менә шулар инде туры бару урынына адашуны сайлучылар. Аларның бу сәүдәләре файда китерә алмады һәм алар туры юлга төшә дә алмадылар.

16. Аларның охшашлары шул кеше кебидер: ул ут кабызды, тирә-якларын яктырткач, Аллаһ Тәбарәкә ул утның нурын сүндерде, караңгылыкка калдырды. Алар - хакыйкатьне күрмәүчеләрдер.

17. Алар - саңгыраулар, телсезләр, сукырлардыр. Шуның өчен алар хакыйкатькә кайтачак түгелләрдер.

18. Яки аларның охшашы күктән яуган яңгыр астында калган кебектер. Ул яңгырда караңгылыклар, яшен яшьнәүләр бардыр. Алар үлемнән куркып, яшеннән сакланып, колакларына бармакларын тыгалар. Аллаһ Тәбарәкә катгый белә торып, күреп, инкяр итүчеләрне әйләнеп алгандыр, мохитләрен белүчедер.

19. Ул яшен аларның күзләрен чыгара яза, әгәр дә шул яшен яктыртса, алар шул яктылыкта йөриләр. Әгәр аларга караңгылык булса, туктыйлар. Әгәр Аллаһ теләсә иде, аларның колакларын, күзләрен юк итәр иде. Аллаһның бар нәрсәгә көче җитүчедер.

20. Әй, адәмнәр, сезләр һәм сезләрдән элек булганнар тәрбияче Аллаһка гыйбадәт итегез! Мөттәкыйннәрдән булырсыз.

21. Ул Аллаһ шулдыр ки: сезгә җирне түшәлгән рәвештә кылды. Күкне түшәм рәвешле кылды һәм күкләрдән су төшерәдер. Шул су берлән сезләргә азык итеп төрле җимешләр чыгарадыр. Шулай булгач, Аллаһка тиңдәш ясамагыз. Аллаһның тиңдәше юклыгын беләсез.

22. Әгәр дә шулар безнең калбебездщ Мөхәммәдкә (саллә Аллаһу галәйһи вә сәлләм) иңдерелгән нәрсәдә шик булса, шуның кебек бер сүз китерегез. Аллаһтан башка ярдәмчеләрегезне дә ярдәмгә чакырыгыз. Әгәр дә фикерегездә тугры икәнсез, эшләп карагыз.

23. Әгәр дә моны эшли алмасагыз, эшли алачак та түгелсез. Шулай булгач, уттан сакланыгыз (җәһәннәм утыннан), аның ягулыгы адәмнәр һәм ташлар булыр. Бу урын белә торып күз күреп инкарь итүчеләр өчен хәзерләнде.

24. Иман китергән һәм дә адәм балаларына файдалы гамәл итүчеләр өчен Аллаһ Тәбарәкә вә Тәгалә асларыннан елгалар агып тора торган бакчалар барлыгын белдерәдер. Ул нигъмәтләр аларга бер-беренә ошаган хәлдә китерелер. Алар өчен анда пакъ булган хатыннар (әзвәҗ мотаһһәрдән максаты) бардыр. Алар анда мәңге калырлар.

25. Аллаһ Тәбарәкә вә Тәгалә мисал китерүдән тартынмый. Кирәк кечектә

булсын, кирәк зур булсын, белдереп кенә булсын, тасдыйкъ өчен мисал китерәдер. Шунда бәндәләр Аллаһка иман китерделәр, алар һәрнәрсәнең Аллаһтан икәнен беләләр. Әмма иман китермәгән бәндәләр: «Бу мисал китерү берлән Аллаһ нәрсә тели икән?» - диләр. Бу китергән мисаллар берлән күпләр юлдан язалар вә күпләр һидаять юлына күнәләр. Юлдан язучылар - алар фасыйклардыр.

26. Фасыйклар шулардыр, кайсыдыр ки Аллаһка биргән вәгъдәләрен боздылар. Аллаһның әмерләрен туктаттылар, җир йөзендә бозыклык кылдылар. Боларга хәсрәттән башка һичнәрсә юктыр.

27. Ник соң сез Аллаһны инкяр итәсез? Сезләр үлек идегез, Аллаһ сезләрне торгызды, дөньяга чыгарды. Моның соңында үләрсез, янә Аллаһ торгызыр (монысы кабердән күтәрелү хакында). Бу тугрыда бар да кабердән куялмас (чөнки тән адаша). Киләчәктә сөйләнер. Моның соңында Аллаһ хозурына кайтарылырсыз.

28. Ул Аллаһ сезләр өчен җирдә булган бар нәрсәне хәлык итте, яралтты. Моның соңында күкне һәм анда җиде планетаны сузды, ул Аллаһ - бар нәрсәне белүчедер.

29. Аллаһ Тәбарәкә фәрештәләренә: «Мин җир йөзендә хәлифә кылдым», - дип әйтте. Фәрештәләр: «Син хәлык кыласыңмы? Ул бит бозыклык кылыр, кан түгүче булыр. Менә без синең зикереңдә, тәсбихеңдә сине яклауда хезмәт итәбез», - дип әйттеләр. Аллаһ: «Мин - үзем белүче, сезләр бу турыда белүче түгел» дип җавап бирде.

30. Аллаһ Тәбарәкә вә Тәгалә адәмгә бөтен нәрсәләрнең исемнәрен өйрәтте, аннан соң аларны фәрештәләр карамагына куйды. «Менә шуларның исемнәрен әйтегез миңа, әгәр дә сезләр фикерегездә тугры булсагыз», - диде.

31. Фәрештәләр әйттеләр: «Без сине бөтен кимчелекләрдә яклыймыз, син белдергән нәрсәләрдән башка һичнәрсә белмибез. Әй Аллаһ, син бөтен нәрсәләрне хөкемен берлән белүчедер.»

32. «Әй адәм! Боларга син боларның исемнәрен аңлат», - диде. Ул аларга исемнәрне аңлаткач, ул әйтте: «Мин сезгә әйтмәдемме, мин күктә вә җирдәге гайб булган нәрсәләрне беләмен һәм сез ачык рәвештә кылган һәм яшерен нәрсәләрне дә беләм димәдемме?»

33. Менә шуннан соң фәрештәләргә: «Адәм баласына сәҗдә кылыгыз.

Баш иегез», - дип әйтте һәм фәрештәләр баш иделәр, мәгәр Иблис баш имәде, тәкәбберлек итте, инкяр итүчеләрдән булды.

34. Шулвакытта без адәм баласына: «Син үзең һәм хатының шушы җәннәттә торыгыз, андагы нигъмәтләрдән, җимешләрдән ниләр телисез, шуларны ашагыз, - дип әйттек. - Ләкин менә бу җимешләргә тотынмагыз, залимнәрдән булырсыз.»

35. Менә шулвакытта шайтан аларны котыртты, аларны җәннәттән, рәхәттан чыгарды. Без Адәмгә: «Хәзер инде сез берегезгә-берегез дошман булган хәлдә җиргә төшегез, анда сез билгеләнгән вакытка кадәр торырсыз», - дип әйттек.

36. Шулвакыт Адәм Аллаһтан сүзләр өйрәнеп алды да, тәүбә итте. Ул Аллаһ – миһербанлыдыр, тәүбәләрне кабул итүчедер.

37. Аллаһ Тәбарәкә әйтте: «Бөтенегез дә төшенегез, белегез: әгәр сезләргә Миннән туры юл күрсәтелсә һәм минем юлга каерылсалар, аларга һич куркыныч юктыр, көенеч тә юктыр.»

38. Безнең аятьләребезгә каршы төшкән һәм аларны ялганга тоткан бәндәләр - ут әһелләре. Алар шунда мәңге калырлар.

39. Әй Исраил балалары, Минем биргән нигъмәтләрне исегезгә төшерегез һәм дә Миңа биргән вәгъдәгезне тотыгыз! Мин дә сезгә биргән вәгъдәне үтәрмен һәм Миннән генә куркыгыз!

40. Сездә булган нәрсәләрне раслаган хәлдә, Мин иңдергән нәрсәгә иман китерегез һәм аңа башлап каршылык итүче булмагыз. Аллаһның аятьләрен аз акчага алыштырмагыз һәм Миннән генә сакланыгыз.

41. Тугрылык берлән ялганны бутамагыз һәм, үзегез белә торып, тугрылыкны яшермәгез.

42. Намаз үтәгез, зәкәт бирегез, рокугъ кылучылар берлән бергә рокугъ кылыгыз.

43. Үзегез оныта торып, адәмнәрне яхшылыкка димлисез, үзегез бит Китап укыйсыз, аңламыйсызмы моны?!

44. Бөтен эшләрегездә түземле һәм намазны ярдәмче итегез. Намаз ул – олуг гамәлдер, авырдыр, ләкин хошугъ-ходугъ ияләренә агыр түгелдер.

Хошүгъ-ходугъ, шулар Тәрбиячеләренең хозурына кайтачаклары. Уйлап гамәл итүчеләргә генә аз түгелдер.

# Госман нөсхәсе

Бисмилләһир-рахмән ир-рахим.

Коръән Кәрим – Аллаһ тарафыннан Рәсүлемез Мөхәммәд Мостафа саллә-Аллаһу галәйһи вә сәлләмгә иңдерелгән китаптыр.

Рәсүлемез аны һич үзгәртмичә, өйрәтеп калдыргандыр. Бу тугрыда Рәсүлемезгә Аллаһ Җәллә Җәлалә хитаб итәдер (һәм бу хитаб бөтен мөселманга гамьдер). استعذ بالله يَا أَيُّهَا الرَّسُولُ بَلِّغْ مَا أُنزِلَ إِلَيْكَ مِن رَّبِّكَ ۖ وَإِن لَّمْ تَفْعَلْ فَمَا بَلَّغْتَ رِسَالَتَهُ («әл-Мәидә», 67) Ләкин таблигъ итү аятьне уку һәм язу берлән буладыр. Язарга боерган аятьләр күптер. Мисал өчен, беренче вәхи: قْرَأْ بِاسْمِ رَبِّكَ الَّذِي خَلَقَ ﴿١﴾ خَلَقَ الْإِنسَانَ مِنْ عَلَقٍ ﴿٢﴾ اقْرَأْ وَرَبُّكَ الْأَكْرَمُ ﴿٣﴾ الَّذِي عَلَّمَ بِالْقَلَمِ ﴿٤﴾ عَلَّمَ الْإِنسَانَ مَا لَمْ يَعْلَمْ («Икъра», 1-5). Беренче вәхидә үк укысаң да, язуны белдерде, укыганнан соң каләм берлән язуны белдерде. Икенче قَالَ عِلْمُهَا عِندَ رَبِّي فِي كِتَابٍ ۖ لَّا يَضِلُّ رَبِّي وَلَا يَنسَى ("Таһә", 52) Моннан һәрнәрсәне хифз итү өчен язу ләзем идегене аңларга кирәк, чөнки мәгълүм: Аллаһ Җәллә Җәлалә үзе онытмаса да, язуны белдерде. Дәхи لَمْ يَكُنِ الَّذِينَ كَفَرُوا مِنْ أَهْلِ الْكِتَابِ وَالْمُشْرِكِينَ مُنفَكِّينَ حَتَّىٰ تَأْتِيَهُمُ الْبَيِّنَةُ ﴿١﴾ رَسُولٌ مِّنَ اللَّهِ يَتْلُو صُحُفًا مُّطَهَّرَةً ﴿٢﴾ فِيهَا كُتُبٌ قَيِّمَةٌ («Бәйийнәт», 1-3). Бу аятьтән мәгълүмдер ки, Коръән үзе саф кәгазьләрдә, дөрес язу берлән язылырга тиеш. Ягъни сәхифәләрнең пакь булуы – хатасызлыктыр. Язуның каим булуы дөреслектән гыйбарәттер.

Дәхи дә لَا أُقْسِمُ بِمَوَاقِعِ النُّجُومِ ﴿٧٥﴾ وَإِنَّهُ لَقَسَمٌ لَّوْ تَعْلَمُونَ عَظِيمٌ إِنَّهُ لَقُرْآنٌ كَرِيمٌ فِي كِتَابٍ مَّكْنُونٍ ﴿٧٧﴾ («Вакыйга», 75-78). Бу аятьтән мәгълүмдер, Коръән Кәрим хаталардан саф булган һәм кәгазьләргә язылган булуы. Әгәр хата язылган булса иде, Коръәннең кәримлек сыйфаты булмас иде һәм язылган китапта да мәмнүнлек булмас иде.

Дәхи وَإِنَّهُ لَكِتَابٌ عَزِيزٌ ﴿٤١﴾ لَّا يَأْتِيهِ الْبَاطِلُ مِن بَيْنِ يَدَيْهِ وَلَا مِنْ خَلْفِهِ ۖ تَنزِيلٌ مِّنْ حَكِيمٍ حَمِيدٍ ﴿٤٢﴾ («Фүссыйләт», 41-42). Менә бу урындагы لكتاب عزيز Коръәннең язылган язуында хата юклыкны белдерә. Хәдисләрдә дә бу сүзләр күптер. Хәзрәт рәсүлуллаһ Гомәр бине Хәрәм исемле бер сәхабәсен Йеменгә вәли итеп җибәргәндә, язылган бер Коръән биреп җибәргәне мәгълүмдер. Менә шул биреп җибәрелгән Коръән кәгазендә لا يمسك الا طاهرا сүзе язылган иде. Шулай булгач, Коръәннең языла баруы гасыр сәгадәттә Аллаһ тарафыннан боерылган һәм язылып ятканы ачык мәгълүмдер. Сәхабәләрдә язу зоһүре ислам заманында Мәккәдә язу гаять мәгъруф иде, хәтта ул вакытларда хатыннардан да байтак кына яза белүче хатыннар бар иде. Хәдисләрнең риваятенә күрә, хәзрәте Гомәрнең кыз карындашы Гомәрнең ислам дине кабул иткәненә

кадәр, “Таһә” сүрәсен язып, йортында укый торган булган. Ирләрдән яза белүчеләр хисапсыз күп иде. Менә шуларның арасында иң мәшһүр булганнары: Әбү Бәкер, Гомәр, Госман, Гали, Зөбәер, Гамир бине әл-Кәйсә, Мөнзәллә бине Бәйгъ, Мөгайрә бине Шөгъбә, Габдуллаһ бине Рәүхә, Халид бине Вәлид, Халид бине Сәгыйт, Мөгавия, Зәйд бине Сабит, Талһа, Госман бине Сабит, Әйән бине Сәгыйт, Язид бине Ибн Суфьян, Хатыйб бине Гомра, Галә бине әл-Хызри, Әбү Сәлимә бине әл-Шәһит, Габдуллаһ бине Сәгыйт, Җәһим бине Әлсаләт кебиләр язуда зур шөһрәт иткәннәр. Һиҗрәт соңында сәхабәләр язу хакында нык игътибар иткәннәр, хәтта яшь балаларына да язу өйрәткәннәр. Әнәс бине Мәлик, Ибн Гомәр, Ибн Гомра, Бин Габбас кеби яшь балалар барчасы да яза белү берлән шөһрәт тапканнар. Сәхабәләр арасында да яза белүчеләр бар иде. Мәшһүр мөхәддисләр хәдис фәннәрендә мөтәхәссәд Коръән Кәримнең өч мәртәбә җыйналуын белдерәләр. Бере – пәйгамбәр заманында күңелгә ятлау юлы берлән яки язарга яраклы нәрсәләргә язылып, бау юлы берлән, икенчесе – хәзрәт Гомәр заманында, өченчесе – хәзрәт Госман заманында (әл-Иткан, ж.1, с. 59).

Ятлау юлы мәгълүм, әмма язу юлы килгән бер вәхи аять вә сүрәләр шул вакытта язу гадәт булган нәрсәләргә Рәсүл Аллаһның укуы берлән үз хозурындагы вәхи язучы хәят тарафыннан язылып, соңыннан шул язу Рәсүлемезнең үзенә тыңлатты. Менә шушы язылган нәрсәләр хәзрәт Әбү Бәкер заманында барчасы бер урынга җыйналып, китап рәвешенә китерелде. Хәзрәт Госман заманында язуларның рәсемнәре төзетелеп, менә шушы китап хәленә китерелгәннән, күп нөсхәләре күчерелде. Хакыйкать шушы өч түбәннән әүвәлге икесе генә җыйнау булып, өченчесе – күчерүдер. Ошбуның өчен хәзрәт Әбү Бәкер җамигъ әл-Коръән булып, хәзрәт Госман нашир әл-Коръән буладыр. Хәзрәт Госман заманында Коръән язарга төзелгән хәят һәркайсы хафиз әл-Коръән иде. Ләкин хәзрәт Госман күңелгә бертөрле дә шик кермәсен өчен, хәзрәт Хәфсә кулында сакланган хәзрәт Әбү Бәкер җыйнаган Коръәнне китерткән иде.

Хәзрәт Госман тарафыннан язылып, төрле өлкәләргә таралган Коръәннәрнең кайсы урыннарда саклану турында төрле мәгълүмат күрелмәде.

Бөек тарихчы Ризаэддин бине Фәхреддин биредә ошбуны яза: “Чит илләрдә йөреп, ислам әсәрләре сакланган китапханәләрне зиярәт итеп, тикшерү булмады һәм үзебезнең гомер иткән шәһәрләрдә бу мәсъәләләрне нечкәләп тикшерү һәм бер нәтиҗә чыгару хакында таянычлы материаллар табылмау сәясендә бу урында язылган хәбәрләр – бәгъзе бер урыннарда күренеп калган хәбәрләрдер. Хәзрәт Госман тарафыннан өлкәләргә җибәрелгән

мөсхәфләрдән[1] берсе Кордоба шәһәрендә, мәчеттә иде. Халык арасында мөсхәф Госмани дип мәшһүр булган. Нөсхә Әндәлүси халкы арасында бик игътибарлы санала иде. Мүхдүн сәлаләсеннән булган Гали әл-Мөгътазад бине Идрис бу мөсхәфне 645 һ., 1248 м. тарихында Кордоба мәчетеннән алып талисманга күчерде. Талисман хәзинәсендә сакланган бу мөсхәф бик хөрмәтле диләр. Аны сакчылар куеп сакладылар. Бу Коръәндә хәзрәт Госман шәһит булгандагы кан бар иде дисәләр дә, бу шөбһәледер ( نفخ الطيب 1ж., 283-288 с.).

Икенче, Шамига җибәрелгән Коръән 658 һ., 259 м. тарихында Дәмәшк шәһәрендә Бөнвәмия мәчетендә иде. Ибн Батүттә җамигъ өмүр хозурында михраб турысында зур бүлмәдә саклана. Бу Шамигә җибәрелгән Коръән һәр җомгада ачылып, халык зиярәт кыла иде. Хәтта үз араларында низагъ, дәгъва булган булса, шул мөсхәф хозурында бетереп бәхилләшеп чыгалар иде (تحفة النظار 1 ж., 54 с.).

Өченче. Мәккәгә җибәрелгән мөсхәф һиҗрәттән 64нче елда Кәгъбатуллаһ янганда яндырылган. Бәгъзе берләр бу нөсхә Шамигә күчерелде диләр. 627 һ. тарихында Дәмәшк шәһәрендә (Коббәт әл-яһүд, Коббәт әт-Тираб исемле урында) дип дәгъва итәләр ( نفع الطيب 1 ж., 282 с.).

Дүртенче. Бүген дә Мисырда Каһирәдә Хәдив китапханәсендә саклана торган вә тирегә язылган мөсхәф. Буны хәзрәт Госман шәһит ителгәндәге мөсхәф дип зан кылалар[2]. Бу мөсхәф Габбасиләрдән әл-Мөктадир хәлифә хәзинәсеннән алынып, Мисырда Гомәр бине әл-Гасый мәчетенә китерелгән, аннан алынып, хәдив китапханәсенә куелган. Бәгъзеләр моны хәзрәте Госман тарафыннан Мисырга җибәрелгән мөсхәф диләр. ( تاريخ اداب اللغة العربية 1ж.)

Бишенче. Мисырдагы мөсхәф 727 һиҗри тарихында Басра шәһәрендә зиярәт итүче ибн Батуттада әмир әл-мөэминин Гали бине Ибн Талиб исемендәге җамигъдә хәзрәте Госман укып утырган вакытта шәһит ителгән – шәриф кан әсәре (فَسَيَكْفِيكَهُمُ اللَّهُ وَهُوَ السَّمِيعُ الْعَلِيمُ) дигән кәгазьдә диләр ( تحفة النظار 1ж., 112 с.).

Алтынчы. Мәдинәдә булган мөсхәф, һиҗрәттән 74нче елда вафат булган Сәлләмә бинт әл-Угугъ хәдисендә мәгълүм ( صحيح البخاري ج 1 127 с.) һәм Сәхих Мөслимдә бу мөсхәф өчен махсус урын булганлыгы аңлана. (مسلم 1ж., 144 с.) Йөз яшенә ирешкән, 210 һиҗри тарихында вафат булган Әбү Гөбәйдәнең һәм 902нче һиҗри Мәдинәдә вафат булган Сәхәвинең хәзрәте Госман мөсхәфне

1. Мосхәф – аерым кәгазь битләреннән җыелган, кушылган; нөсхә.

2. Зан кылу – уйлау, санау.

күргәнлеге риваять ителәдер. (تفسير روح المعاني 7ж., 22 с.)

Төркия мөхәррриләреннән Әюб Басрый хәзрәте: “Госманның хатты Куфи берлән язган вә алтын берлән зиннәтләнгән зур кулдагы мөсхәфне алтын берлән чигелгән җаймәгә төреп сакланадыр”, - дип тасдыйк итә. (مرآت مدينة 59 с.)

Бу мөсхәфлар мөсхәфе Госман йөрсә дә, хәзрәте Госман үз кулы берлән язган мөсхәф булмыйча, бәлки хәзрәте Госман заманында хәят тарафыннан язылган мөсхәфләрдер. Коръән язучы хәятләргә Рәсүлемез хәдис язарга рөхсәт иткәннең сәбәбе: мөсхәфне хәдис берлән бутаудан курыккан. (صحيح مسلم 2ж., 292 с.)

/4б/ Мөсхәф бәгъзе бер риваятьләргә әүвәлдәге Забур, Инҗил, Тәүрат формасында төрелгән нәрсәләргә язылган. Бу вакытта “картас” яки “вәрәкә” дип исем бирелгән мөсхәф хәленә китерү ягъни мөсхәф дип исем бирелүдән максат: чәенкер нәрсәләргә тиреләргә языла башлагач, бирелгән исемдер.

Хәзрәте Әбү Бәкер заманында мөсхәф китап хәленә китерелгән һәм сүрәләр, аятьләр һәркайсы Рәсүл Аллаһ тәртип берлән, үзләре укыган формада язылган. Җәмгесе 114 сүрә булып, Пәйгамбәребездән 114 китап калган дип тәкъдим ителә.

Әл-хасыйль, Адәмнән башлап Мөхәммәдпәйгамбәргә кадәр килгән китаплар 110 сәхифә булып килгән 4 зур китап: Тәурат, Забур, Инҗил, Коръән.

Буны тасдыйкъ өчен Коръәндә аять إِنَّ هَٰذَا لَفِي الصُّحُفِ الْأُولَىٰ (18) صُحُفِ إِبْرَاهِيمَ وَمُوسَىٰ (19) («Әл-Әгъләә”, 18-19). Менә шул аятьләр иңгән вакытта, киң рәвештә аңлатыр өчен, толкование (тәфсир) формасында Мөхәммәд пәйгамбәр сөйләгән сүзләр хәдис диелеп йөртеләдер.

Коръән мөсхәфне дөрес аңлау өчен, әлбәттә, хәдис белү ләзем була. Хәдис белмәгән кеше Коръәнне дөрес тәрҗемә итә алмыйдыр. Мөсхәфне язган вакытта, җиде Коръән хәфиз кариләр булган, шуның өчен Коръән кураъ сәбгә берлән языладыр. Югарыда, һиҗрәттән соң 64нче елда Мәккәдә бер нөсхәсе янды дип, әйтелгән иде. Шулай булгач, мөсхәфе Госман, ягъни Госманның үз кулы берлән язылган мөсхәф үзе бармы яки, булмаса, югалганмы? Күбесенең мәгълүматына караганда, мөсхәфе Госман югалды дип фараз ителә.

Ләкин мөсхәфе Госман үзе югалса да, аның хәяте тарафыннан язылган Коръәннәр барлыгы турында дөрес дәлилләр бар. Мәсәлән, хәят әгъзасы булган Зәйд бине Сабит дүрт мөсхәф язганлыгы риваять ителә. Хәзрәте Госман бу мөсхәфләрне дүрт шәһәргә җибәрә. Шулвакытта үз ихтыярларында язучылар да булган. Шул мөсхәф җибәрелгән шәһәр имамнары да тик ятмаганнар.

Үзләренә кирәк кадәр язганнар. Тарихта моңа мисаллар күптер. Мәсәлән, хәзрәте Гали берлән Могавия гаскәрләре алдына 500 мөсхәф күтәреп чыкканы мәгълүмдер. Димәк дүрт-биш ел эчендә бер мохсафтән бу кадәр мөсхәф күчерелгән булгач, әлбәттә, башкалар да язганнар.

Мәсьәлә шунда: бәгъзе бер тарихларда Коръән мөсхәфнең размеры язылган (мөсхәфе Госман дигән китапта Шебунин[1] 53х67 сантиметр дип яза). /56/ Ләкин асыл хәят язган мөсхәфнең зурлыгы һәркайсы берәбердер.

Инде Совет илендә Ташкент музейханәсендә сакланган мөсхәф госмани. Бу мөсхәф, әлбәттә, язучы хәят тарафыннан хәзрәт Госман кулы астында язылган мөсхәфләрнең берседер. Рәсүлемездән соң сәхабәләр ике мәртәбә мөсхәф язганнары мәгълүмдер. Хәтта хәзрәт Әбү Бәкер заманында Мәдинәнең әтрафында сәхабәләрнең хисабы юк иде. Мөхәммәд пәйгамбәрнең وداع حجندا бәхәсләшү хәҗендә ун меңнән артык сәхабә катнашканы риваять ителгәндер.

Хәтта хәзрәте Гали кул астында иң маһир алты-җиде сәхабә мөсхәф язуга тәгаен ителгән иде. Шулардан баштан ахырга кадәр мөсхәф язучы Зәйд бине Сабит идеге мәгълүмдер (баб мәдинәт әл-голүм) булган Гали, Убәй бине Кәгаб һәм башкалар мөсхәф язганнар. Шул мөсхәфләрдән берсе Мәдинәдә калып, калганнары Күфә, Шам, Басрә, Йәмән, Мәккә, Мәшриф шәһәрләренә таралгандыр. Хәзрәте Госман Зәйд бине Сабиттан үзенә бер мөсхәф яздырган. Менә шул Коръән әһле гыйлем кашында әл-имам исемендәге мөсхәф. Менә шул хәзердәге Ташкент музейханәсендәге мөсхәф.

Бу мөсхәф 310 һиҗри, 920 милади ел тарихларында Багдад шәһәреннән, ислам дине өйрәтер өчен, Төркестан аркылы җибәрелгән вәкилләр белән хәлиф әл-Мокътәдир билләһ тарафыннан һидия тарикы берлән җибәрелеп, шул Төркестанда кыр астында өй вәкилләр бер елга кадәр калып, Коръәне Кәрим вакытлы шул урында калдырыла, чөнки барачак сәфәр Болгар төрекләре әле ул вакыт ислам динендә булмыйлар. Шул сәбәптән калдырган була.

Шәһре Болгарда ислам дине кертелгәннән соң, ул мөсхәф, Төркестан губернатор заманында, Сәмәрканд мәчетендә ачык рәвештә хосусый шул Ташкент басылган өстәл тормасында урында куелып тора.

Бу мөсхәф Сәмәркандтә кулдан-кулга ягъни буыннан-буынга күчеп, 92 миладидан 1867 миладига кадәр Сәмәркандта тора, ләкин саклау җәһәтеннән игътибар ителми. Тәбрикән хөрмәт йорттан олуг китап итеп, дини китап итеп, гаять алынып килә.

Бу мәсхәфне хәзрәте Шиһабеддин әл-Мәрҗани 27 яшьләрендә Сәмәркандта

1. [А. Ф. Шебунин, «Куфический Коран С.-Петербургской публичной библиотеки» // Записки Восточного отделения Русского археологического общества. СПб., 1891, т. 6, с. 89-133].

1845 еллар милади тарихында, 1260 һиҗри тарихында күргәнен белдерә һәм соңгы вакытларында Петербург китапханәсендә тәкрар күренелде.

Икенче Татарстанның Утыз-Имән авылының Габдеррәхим хәзрәтләре Урта Азиядә Сәмәркандта мөсхәф Госманны очрап, бозылган җирләрен бераз төзәтеп, ямавы турында әйтә. Нәзарәтнең бер кечкенә вәрәкәсендә кем тарафыннан язылган мәгълүм түгел, хәзер дә саклана. Вәрәканың икенче ягында мөфти Габдессәлам турында язылуга караганда, 1825-1840 елларда язылганы аңлана.

Әл-хасыйл, бу Коръәннең Сәмәркандтан алынуы хакында шул ук вәрәкадә язылган. Христиан динендә бер мәшһүр Гофман дигән кеше, кайдандыр хәзрәте Госман мөсхәфен күреп, бер зур әсәре гатика идекне аңлап, ... торганны күреп, бер йөз сумга сатып алып, Петербург китапханәсенә куярга сәбәп булды дип язылган. Язуның кем тарафыннан һәм кайсы елда язылганы мәгълүм түгел. Шул ук Нәзарәт милкендә Шиюнин дигән бер кеше тарафыннан язылган бер китапта китапның исеме куфа мәсхәфе исемле, 1891 елда язылган.

Анда шулай яза: публичный библиотекада бик иске булса кирәк Коръән бар. Бу библиотекага подарок (бүләк) итеп китерелгән. Төркестанның генерал-губернаторы Гуфман (!) тарафыннан 1869 ел 24 октябрь Сәмәрканд мәчетеннән Петербургка китерелгән. Бу мөсхәф Министр просвещения исеменә тиешле документлар берлән җибәрелә. Документка ике дини голама тасдыйк итү буенча язылган дип документ копиясен куя. Документка Сәмәркандтагы хаҗи Әхрар мәчетендә Коръән булуы хакында хәбәр булгач, ул Коръәнне аннан алу чарасына керешәләр. Шул Коръән хакында: «Коръән хаҗи Әхрар мәчетендә торса да, ул Бохара әмиренең /66/ милке дип таныйбыз», - диләр. Һәм бу мөсхәфнең һичбер төрле кирәге табылмый. "Менә борынрак халык зиярәттән йөрсә дә, хәзер дә әмирдән башка кеше зиярәт кылмый", - дип табалар[1] һәм бу мөсхәфне һичкем укый белми. Бу мөсхәф күп йөз еллар ята, һичкем файдаланмый.

Шуларны игътибар итеп, генерал-майор Абрамов мәчеткә 100 сум биреп алып китте. Шуның берлән андагы духовенство риза булып кала: "Мин хисап кылам, бу көтебханәдә торса, галимнәр файдаланыр",- дип яза. Шуның өчен тиешле духовенство берлән сөйләшүне ягъни тиешле кешеләре (мелла Габделҗәлил һәм мөфти ярдәмчесе мелла) берлән сүзләре буенча төзелгән материаллар берлән сезнең карамакка җибәрәм.

1. Коръән шаһ хөкүмәте тарафыннан мөселман халкында ирек бирмәү нияте берлән көчләп алдау юлы берлән алынган. Бер-ике мәшһүр булмаган шул мөсхәф янында тамак туйдыручы кешеләргә 100 сум биреп Коръән көчләп алынган, Бохара әмиренең балинкасы (?) берлән. Моннан соң төзелгән материаллар төпле түгел. Шул саклаучы ике кеше сүзе буенча төзелгән.

Монда күрсәтү буенча, ул ничек монда килеп элеккән турында язылган тиешле һәм мәгълүматлы кешеләр тарафыннан сөйләгән сүз түгел:

1. Мөсхәф 920 елларда килеп кала, димәк 800 еллар буена надан шул мөсхәфне сатучы шуннан үз гомеренә тамак туйдыручы Габделҗәмилнең каян дөрес хәбәр бирүе мөмкин. Бу - турыдан-туры ялган.

2. Шебунин мөсхәфнең килеп калуы хакында болай дип яза, бу турыда китаптан каралыр: 3 сәхифә, 2 нче бүлек. Бу һәм дөрес түгел, чөнки мөсхәф хөрмәтле китап ителеп 800 еллар саклангaн. Бер хәлиф, үзенең сәламәтлеген алып калыр өчен, мөсхәфне кадерсез итә. Өшкерү юлы – ишаннар юлы. Ул дөрес түгел. Хәлиф булган кеше чын мөселман хәлифәсе булса, мондый кадерле әсәр кадимәгә бу кадәр хөрмәтсезлек күрсәтми. Димәк, булу мөмкин, 800 ел эчендә мондый хәлдә узгандыр. Мөсхәфнең Русиягә килүенә 920 елларда мөсхәф барлыгын белеп, китапханәгә алалар 1867 елларда. Димәк мең еллар эчендә әллә нинди эшләр булуы мөмкин. Кыскасы, мөсхәф госмани булган төрекләре ислам динен кабул итү вакытында, Ибн Фадлан вәкилләре 920 елларда Туркестанга китереп, вакытлы калдыралар һәм шул мөсхәф шунда ишаннар-мөридләр кулына һәм үзен хәлиф әйтүче Нәкышбандиләр кулына төшеп тиешле урынга

3. Мөсхәф Госмани ишаныбыз һәм мөселман духовенствосына төшеп, 800 еллар әрәм булып яткан, бер ташландык хәленә килгән вакытта нинди план берлән булса да ишаныбыздан алып югалудан коткаручы Гофман булган. Минемчә мөселманнар бу хезмәт өчен Гофманга рәхмәт белдерергә тиеш.

4. Тапкыр югалу юлына дучар булган рәхмәт Габдерәхман Рәсүлевка Мөсхәф Госманинең 17 вәракасы Сәмәркандта югалганы мәгълүм. Бу инде китапханәгә төшкәнгә кадәр, чөнки китапханәгә куйганда барлык 353 вәрака язылган булса, Уфага кайткач төзелгән актта 353 вәрака күрсәтелә. Коръәннең зурлыгы: буе бер аршин булып, киңлеге өч вершок була, ягъни 53/ 63 сантиметр. Бу мөсхәфнең Уфага китерелүе дә шул Болгар төркиләре, ягъни Идел-Урал буе мөселманнары милке булганлыктан. Бу турыда күп еллар хәрәкәт була, ягъни мөсхәф Госмани турында күп сүзләр-мәҗлесләр була, ләкин шаһ хөкүмәте Туркестан мөселманнары бүләк иткән дип (бу турыда Шиюнин турыдан-туры бүләк дип яза) рөхсәт итмиләр.

Кайчан Октябрь инкыйлабы шаһ хөкүмәтен йөзтүбән китергәч һәм бәрабәр

хосусый мөселман гаскәре төзелгәч, мөфти Галимҗан әл-Баруди һәм Нәзарәтнең бөтен әгъзалары Народный комиссариатка 1917 елда мөрәҗәгать итәләр. Бу эшләр башында – мөселманнар гаскәре Шура Комитет башында Әхмәт Салихов, Усман Токумбаев һәм мөхтәсиб Исхаков (Петербург имамы була ул вакытта). 1917 елның декабрь аенда халык комиссариаты рәисе Владимир Ильич Ленин Коръәнне бирергә карар итә. 1918 ел 8 гыйнварында Петербургтан телеграм була. Коръән хәзер мөселман гаскәре кулында һәм каравыл берлән саклана. Уфага озату турында телеграм бирелде дип языла. 1918 ел 19 гыйнварында адмирал Исхак Ибраһимов һәм Галләм Максудовлар җитәкчелегендә 29 гаскәр берлән хосусый вагоннарда Уфага кайтаралар. Уфада зур хәзерлек берлән барлык Нәзарәт хезмәткәрләре, шәһәр мәхәллә имамнары, мәдрәсәи Галия, мәдрәсәи Госмания, мәдрәсәи Хөсәйниянең мөдәррисләре һәм талибләре катнашалар. Уфа шәһәренең мөселманнары катнашалар. Бу көнне зур бәйрәм итеп демонстрация ясап, тәкбир әйтеп каршы алалар.

Күп еллар ихтыярлары булмаган мөселманнар бүген революциянең хөрмәтле булган тигезлек-азатлык нигезендә һәм куркусыз вокзалда поезд килгәннән кычкырып тәкьбир берлән каршы алалар. Шулвакыт мәйдандагы миллионлаган мөселманнар алдында мөфти Галимҗан әл-Баруди зур чыгыш ясый. Дәүләтебезнең бөтен милләтләргә тигез хокук бирүе, дәүләтебездә диннәр арасында аерма юклыгы һәм дин тотуда һәркем ирекле булуы, дәүләтебезнең бөтен җир йөзендә тынычлык татулык-дуслык, бердәмлек өчен иҗтиһад итүе турында сөйли һәм мөсхәф Госманинең мөселманнар кулына кайтуын игълан итә. Хәзер дә араларда хөкүмәтебезнең ярышына зарар китерергә тырышучыларның барлыгыны белдерә һәм һәрбер мәхәллә имамнарына совет дәүләтенең дөрес юлдан баруы турында халыкара вәгазьләр сөйләргә дәүләтебезнең ярышына каршы хәрәкәтчеләргә катгый чаралар күрергә дип сөйли. Һәм бу мөрәҗәгать һәрбер мәхәллә имамнарына таратыла. "Әд-дин вәл-әдәб" журналы монда язылган.

Мөсхәф Госмани вокзалдан Диния Нәзарәтенә кадәр күтәреп алып килүендә юл буенда барлык урамнарда тәкьбир берлән кызыл әләм берлән истикъбаль иттеләр, олуг азатлык бәйрәме ясалды. Безгә дә бу тантаналы бәйрәмгә катнашу насыйп булды. Ул вакыт мин Коръән хифз кылган идем, Галиягә укырга кайткан идем.

Мөсхәфнең һәрбер вәракасы каралып комиссия тарафыннан акт төзелеп, Туркестанда вакытында күп кенә вәракаларының югалганы белдерелде. Мөсхәф 353 вәрака итеп тасдыйкъ ителде. Бу турыда акт бар иде, ләкин хәзердә юк.

Соңгы дәвердә 1923 ел Мәркәз Диния Нәзарәтенең голамалар берлә

иттикяф мәҗлесе булдырып, бу мөсхәфне Әфган Гыйрак аркылы Гарәбстанга кайтарырга дигән карар чыгарыла. Комиссия төзеп, поезд белән Ташкентка озатырга карар ителә. Комиссиягә 4 кеше тәгаен ителә. Хәтеремдә калганнардан берсе Гатаулла Ермиев булырга кирәк, икенчесе Госман Сөләйман углы һәм башкалар. Бу һәять Куйбышев аркылы мөсхәфне алып китергә булалар. Коръәнне озатуга сәбәп шул булды: 1923 елда Әфганстанның Аманиллаһ хан Совет дәүләтебезгә килеп, Мәркәз Диния Нәзарәтенең мөфтиләре-казыйлары берлән очрашып, Аманиллаһ хан Совет дәүләтендә мөселманнарның ирекле булуы һәм бөтен халыкны тигез каравы, бөтен милләт, сыйныф тигез хокуклы булуы хакында һәм безнең хөкүмәт берлән чын якын дус булуны белдереп чыгыш ясый. Бу чыгыш Астраханда һәм Уфа мәчетендә ясала. Безгә бу мәҗлескә катнашырга туры килде, чөнки мин яшь кенә бер Коръән хафиз идем һәм мәҗлес ачканда без тиләвәт Коръән кылдык, әлхәмдүлиллаһ. Моннан соңгы вакытларда мин Нәзарәттән ерак бер карияда имам тордым. Бу турыда нинди әхвәлләр булу турында хәбәрем юк, ләкин шул мөсхәф Госмани Ташкентка барганда агырлана һәм файда булганнан белүче булмый кала. Фәкать шуны мөфти Габдерәхман Рәсүли сөйләде: Кайчан Мәркәз Нәзарәт дүрткә бүленеп Ташкент Нәзарәте тәшкил ителеп, Ишан Бабахан хәзрәтләре Урта Азия вә Казакстан мөфтисе итеп тәгаен ителә. Менә шул вакытта шушы мөсхәф Госманине үзбәк таифәсеннән берәү Нәзарәткә тапшыра.

Габдерәхман Рәсүл бу мөсхәф Госмани – югалган мөсхәф, моны мөселманнар кадер итә алмады дип, 1947 елда Ташкент музей-ханәсенә тапшыра. Бу – Габдерәхман Рәсүлинең сөйләгән сүзе. Хөҗҗәт күрмәдем, хәзер дә күрелми, чөнки Диния Нәзарәтенең хозурыннан мин 1956 елда киттем. Шушы 20 ел эчендә Нәзарәтнең кыйммәтле хөҗҗәтләре тәмам югалып беткән.

Минем бу мөсхәф Госмани турында язуымның бәгъзе берләре – үзем ишетерәк иткәнлектән, хәтердә калганнардан, бәгъзе берләре төрле гәҗит-журналлардан карап һәм бәгъзе бер тарих китапларыннан карап язылды. Бигрәк тә бөек тарихчыбыз мөфти Ризаэддин Фәхреддиневнең мәгълүматларыннан алынды. Ләкин мин тасдыйкъ итәм, бу – дөрес һәм тарихи булып калырга тиешле хәзердә мөсхәф Госмани Ташкент музей-ханәсендә бик хөрмәт берлән саклана. 1976 елда барып күрү насыйп булды.

Хәзердә Диния Нәзарәте хозурында саклана торган бер вәрака мөсхәф хакында ошбу мәгълүматны бирәм.

1947 елларда мин, имамны алыштыру өчен, Диния нәзарәте тарафыннан командировать ителдем. Имам итеп Мортазинны алып бардым. Бу вакытта мөфти Габдерәхман Рәсүлев иде. Эстәрлетамакта җомга укытып, Мортазинны

имам итеп тәгаен иттем.

Җомгадан чыкканда, бер хатын һәм бер ир, салман булса кирәк: “Хәзрәт, менә сезгә бер кечкенә әманәт тапшырам. Бу - безгә нәселдән сакланып килгән нәрсә. Хәзердә безнең моны саклар кешебез юк”, - дип, кәгазьгә ураган картас (?) өрелеп формада бер нәрсә тапшырды. Мин аны, ачып та карамый, алып кайтып, мөфти Габдерәхман Рәсүлигә тапшырдым. Ул аны өстәлгә алып куя, ул да карамый. Көннәрдән бер көнне мөфти Габдерәхман Рәсүлев: “Бу кайткан кыйммәтле нәрсә - мөсхәф Госманинең бер вәракасы. Туркестан һәм Сәмәркандта вакытта аның 17 вәракасы урланган, шуннан берсе булырга тиеш”, - дип белдерде. Моннан соң бу турыда бер дә сүз булмады. Мөфти Габдерәхман Рәсүли 1951 елларда вафат булып, Шакир Хыялетдинов сайлана, ләкин бу вәрака турында мин дә сорамадым, мөфтиләр дә әйтмәде. Мин 1956 нчы ел Ленинград шәһәренә тәгаен ителәм, бу турыда тәмам онытылып киткән. Тик шул гына, Ленинград шәһәреннән халык арасында 4 данә мөсхәф Госманинең копиясен Диния Нәзарәтенә җибәрдем. Хәзердә аларның берсе дә юк. Бер төрле дә хөҗҗәт тә юк.

1975 елда бу хезмәткә безне тәгаен кылалар, ягъни мөфти итеп сайлыйлар. 1976 ел башларында, китаплар актарып утырганда, Диния Нәзарәтендә мөфтинең эш бүлмәсендә шкаф тартмасыннан шушы мин Эстәрлетамактан алып кайткан мөсхәф Госмани вәракасы табыла. Һичкем тимәгән, хәтта караучы да булмаган, игътибарсыз яткан.

Мин аны игътибар берлән алып (бу турыда, мөсхәф Госмани турында язып ята идем), алтын белән капланган хосусый рам эшләтеп, ике кат пыяла арасына рамга салып, хосусый шкафка куеп, өстен пәрдә берлән капладым. Чит ил делегатлары килгәндә, ачып күрсәтеп торам. Хәзердә мөсхәф Госманинең бу вәракасы хөрмәт берлән саклана.

Инде бу вәрака мөсхәф Госмани икәнлегенә һәм нинди юл берлән Эстәрлетамакка килеп керүе хакында беркадәр мәгълүмат:

Татарстанның Чистай өязе Утыз Имән авылының Габдерәхим яки Мөхәммәд Рәхим хәзрәткә Узбекистанда (Сәмәркандтамы, Туркестандамы) бу мөсхәф Госмани очрап, бераз урыннарына ремонт ясый. Бу турыда Диния Нәзарәтендә бер кечкенә кәгазьгә язылган мәгълүмат табылды. Гәрчә кем тарафыннан язылган һәм кайчан язылганы мәгълүм булмаса да, 1825 елларга туры килә (чөнки Габдесәлам мөфти вакытында язылган туры килә). Мөсхәфнең вәракасы Габдерәхим яки Мөхәммәд Рәхим хәзрәт ремонтлаган. Бу Габдерәхим хәзрәт Бохара-Сәмәрканд һәм Афганистанда күп еллар гомер сөргән, 1835 елда вафат була. Шушы мөсхәфнең вәракасына язылган язудан тасдыйкъ итергә була.

Вәракада язылган язу: Бәлдәи фахирә Казанда (тәрҗемә: Олуг шәрәфле Казан шәһәрендә) Исхак бай Юныс углы. Мөхәммәд Рәхим әфәнденең зәүҗәсенең вәлидәсе (атасы). Тәрҗемә: ягъни Исхак бай Габдерәхим хатынының атасы Габдесәлам мөфтинең кызы булганлыгы җиһәтеннән тәварисән вакәгъ булмыштыр. Сәййидинә Госман Зуннурәйн (разый Аллаһ ганһү) хәзрәтләренең мөбарәк куллары берлән кәгазе кеби энҗе тере (?) үзәренә язды. Корьән Кәримнең вәракасы дип язылган. Ләкин Ризаэддин Фәхреддинов "Асар"да болай белдерә: 1835 елларда Татарстан Минзәлә өязе Утар авылының Шаһи Әхмәт әс-Симатинең шәкертләреннән Ибраһим мелла (атасының исеме мәгълүм түгел) Сәмәркандта заһидлек сөргән, үзен изге итеп таныткан. Бу инде мөсхәф Госмани тирәсендә күп буталган. Шул бервакыт: "Менә хәзрәте Госман бөтен өммәт өчен мөсхәф яздырса да, бүгендә фәкать Сәмәрканд сартлары (үзбәкләре) файдалана. Шуны үз милләтебез арасына китермәк мөмкин булмасмы?" - дигән. Арадан бер кеше: "Мөсхәф Госмани вакыфтыр, аны урынында тоту хәерле. Син бу мөсхәфне кирпич сарайларына ба ия йөрдең, мин күрдем", - дип җавап биргән. Шулвакыт бу Ибраһим мелла: "Сөбхәналлаһ, син монда утырып күргәнсең, мин бит мөсхәфне ярын да алмадым, берничә вәракасын алдым", - дип әйткән. Ибраһим мелланың Бохарадан Әстәрлебашка кайткач, бу вәракаларны билгеле кешеләргә күрсәткәне мәгълүм. Нигъмәтуллаһ Биктимер хәзрәтләре моны күреп үзенә тапшырырга кушкан. Моннан соң Ибраһим мелла Әстәрлетамакка килеп, Габделхак исемендәге бер сатучыга сатмакчы булган. Билгеле хәзрәтләрдән Шәрәфетдин Зәйнетдин бу эшне мәслихәт күрмәгәч, бай Габделхак сатып алудан кире кайткан. Шушы Габделхак байның бер хезмәтчесе Рәхмәтуллаһ исемендә сатып ала. Бер данәсен үзендә калдырып, калганнарын Уфага Габдессәлам мөфтигә сатып биргәндер. Әстәрлетамакта калганы исән булып, бәгъзе вакыт зиярәт итүләре белдерелә. Мөфти Габдесәлам сатып алганы углы Габдерәүфкә калгандыр. 1872 елларда сатылып, Казанга күчерәләр, диләр. Бүген дә бәгъзе берәүләр кулында ятадыр.

Корьән саклана: Ләйлә Мостафина, телефон 298797. Казан, Искра 9 -12.

Бу инде шул Сәмәркандтагы, аннан соң Петербург китапханәсендә 50 еллар яткан, моның соңында Уфада 5 ел яткан, хәзердә Ташкент музейханәсендә хөрмәт ителеп сакланган мөсхәф Госманинең бер вәракасы. Размеры 53х63 булып тирегә язылган. Нәкъ шул вәраканы бүләк итүче тарафыннан югарыда язылган сүзләр һәм хат Куфи гарәп хәрефе берлән язылган сүзләр арттырылган. Корьәннең "әл-Мөэмин" сүрәсендә 116-118 аятьләр язылган раслап.

Хәзердә Дины Нәзарәтендә рәис мөфти әл-хаҗел-хәрәмәйн вәл-хафиз Кәләмуллаһ Габделбари Низаметдин Исаев.

1980 ел, февраль.

# Ислам дине: иман, игътикад, намаз һәм фәлсәфәсе

Бисмилләһир-рәхманир-рәхим.

Ислам дине адәм балаларын үз ихтыярлары берлән хәерле эшләргә күндерүче, илаһи бер канун (закон) булып, Аллаһ Тәбарәкә вә Тәгалә тарафыннан пәйгамбәремез Мөхәммәд Мостафа салләл-Аллаһи галәйһи вә сәлләм аркылы җир йөзендәге халыкларга ирештерелде һәм шуны кабул итүне адәм балаларына тәклиф ителде.

Бу илаһи канун – инсаннарның хәлләрен төзәтүгә, дөнья хәяте вә мәгыйшәт низамнарын, гомер итү тәртипләрен сакларга вә ахирәттә мәңгелек сәгадәткә ирешүгә сәбәп булган һәм дә гакылга муафыйк төзелгән дәстүрләрдән гыйбарәттер.

Ошбу илаһи канун саесында инсаннар үзләренең дөньяга килүләренең сере нидә вә дөньяда булган мөддәттә вә хәлифәләрендә нинди эшләрдән гыйбарәт икәнлеген күрергә һәм белергә тиешледер.

Менә бу илаһи канунны кабул итүчеләр «мөэмин» һәм канун буенча гамәл итүчеләр «мөслим» диеп аталалардыр.

Дин җәһатеннән башка адәмнәрдән аерылалар. Шәригать кануннарына ышану үзе иман буладыр.

Мөэмин булуның ачык заһири шигары «Лә иләһә иллә-Лаһ, Мөхәммәд әр-рәсүл Аллаһ» сүзе буладыр. Ошбу канун буенча гамәл итүчеләр мөслим буладыр. Ошбу сыйфатлы бәндәләр, ягъни заһир иман белән гамәл итүчеләр мөслим булучылар. Бер-беренә карындаш һәм фикердәш булырга тиешледер. Бер-беренә зарар китерүдән имин булып, агырлык (=авырлык) вакытларында бере-беренә ярдәмендә булырга тиешледер. قال رسول الله صلى الله عليه و سلم (المسلم من سلم المسلمون من لسانه و يده) بخارى

Мөселман үзе рәвешле мөселманның теленнән һәм кулыннан һәрвакыт сәламәт, имин булырга тиешледер. المؤمن كالبنيان يشدُّ بعضه بعضا (مسلم) Мөэминнәр бере-бере берлән, барыбер, туганнардыр. Ошбуның өчен үз араларыгызда ислах килешегезне, кәрдәшлегезне саклагыз. Бу турыда Аллаһтан нык сакланыгыз, шул вакытта гына фәлах табарсыз, ягъни теләгән теләкләрегезгә ирешерсез.

Ислам дине - җисмәни вә рухани дин булганлыктан, дөнья тереклегендә ифрат берлән бергә җәмгъ иткән диндер. Коръән Кәримдә бу турыда: لَا تنسَ

نَصِيبَكَ مِنَ الدُّنْيَا ۖ وَأَحْسِن كَمَا أَحْسَنَ اللَّهُ إِلَيْكَ («әл-Кысас», 77) – диелә. Ягъни «Син шул дөнья көтү эшләрендә ахирәтлек өчен кирәк нәрсәләрне онытма», ягъни ахирәт кирәклеген шул дөнья эшенә баглангандыр. Ошбуны булдырыр өчен, ягъни ахирәт кирәклеген хәзерләү өчен وَأَحْسِن كَمَا أَحْسَنَ اللَّهُ إِلَيْكَ, ягъни бәндәләргә, гомумән, барча мәхлукатларга күркәм табигатьле була... Аллаһ Тәбарәкә синең гөнаһ кылуына каршы булуына карамастан, сиңа мәрхәмәт ният, күркәм мөгамәләдә тора димәктер.

Рәсүл әл-икрамнең хәдисләрендә الدنيا مزرعة الاخرة дип, «Дөньяны ахирәт өчен хәзерләп торган урын – игенлек зәргать», - димештер Әхмәд бине Хәмбәл.

Ислам дине - үзенең барлык биналары берлән мөхәккәм, мөкәммәл бер гали диндер.

Ислам биналары биш булып, бу биналар һәркайсы адәм балаларын адәмчелек нигезендә тәрбияләү өчен боерылып, канун илаһи итеп кертелгәндер. Бу турыда хосусый, изахи рәвештә киләчәктә сөйләнер, иншә Аллаһ.

Ислам дине ялгыз вәхдәният, ялгыз гакыйдәдән генә гыйбарәт булмыйча, бәлки шул вәхдәният гакыйдәләрнең дөньядагы шәхсият вәһһинәт берлән катнашуы ләземдер. һәм бу катнашулар гаять әсаслыдыр. Шуның өчен ислам диненең гаясы, теләге ошбу нәрсәләрдән гыйбарәттер:

1. Аллаһка бәндәчелекне белдерү (اعْبُدُوا رَبَّكُمُ)

2. Итагать кылу (أَطِيعُوا اللَّهَ)

3. Гаделлектән аерылмау (إِنَّ اللَّهَ يَأْمُرُ بِالْعَدْلِ وَالْإِحْسَانِ)

4. Адәмчелек хокукын саклау (وَ لَقَدْ كَرَّمْنا بَنِي آدَمَ)

5. Гомумән сөлхе мөслимәтне саклау (يَا أَيُّهَا الَّذِينَ آمَنُوا ادْخُلُوا فِي السِّلْمِ كَافَّةً)

6. Адәм балаларының үз араларында булган хокукларын, тигезлекләрен саклау. Ир вә хатын, сыйфат төсен аермау. Барчасын бәрабәр күрү (إِنَّ أَكْرَمَكُمْ عِنْدَ اللَّهِ أَتْقَاكُم).

7. Мөхтәлиф, ягъни ыруглар – кабиләләр һәм төрле мәмләкәтләр, өлкәләрдә яшәүче инсаннар арасына өлфәт мәхәббәт урнаштыру, барчасын берләштерү (وَاعْتَصِمُوا بِحَبْلِ اللَّهِ جَمِيعًا وَلَا تَفَرَّقُوا).

1нче аять кәриманең мәгънәсе اعْبُدُوا رَبَّكُمُ Аллаһ Тәгаләгә бәндәчелекне белдерү боерылган. Аллаһка бәндәчелекне белдерү Коръәне Кәрим буенча гамәл кылганда гына табыладыр. Хыянәт итмәү, ялган сөйләмәү, сүз йөртмәү, гайбәт сөйләмәү, башка адәм балаларына зарар итмәү кеби изге гамәлләр.

Аллаһны – Аллаһ, Рабб итеп тану, бәндәчелекне белдерү буладыр.

Икенче: Аллаһка итагать кылу - мәгълүм ки, Коръән буенча гамәлдер. Кушканнарны тоту, тыйганнарыннан тыелу – бәндәләрне яхшылыкка димләү, яман сыйфатларыннан туктау кеби гамәлләрдер.

Өченче: гадәләттән аерылмау берлән боерылгандыр. Гадәләт – адәм баласының үз- үзенә дөрес тәрбия итүе, әгъзаларын һәртөрле агыр (авыр), ярамас йөкләрдән саклавы, сәламәтлекне хифз сихәтне ригая кылуы; гаилә тәрбия итү эшләрендә гадәләт, ата-аналарга ихтирам эшләрендә гадәләт, адәм балалары арасында мөгамәләдә гадәләт, Аллаһ тарафыннан куелган кануннарда гадәләт кебиләр.

Дүртенче: адәмчелек хокукын саклау, Аллаһ тарафыннан хөрмәтле булган зат адәм баласының хөрмәтне ригая кылу. Һич бертөрле юл берлән адәмнең хөрмәтен китәрмәү, һәрвакытта ярдәмдә булу. Сәламәтлекне саклауда, динне саклауда кебиләр. Шәригать мөкаддәсемез дә адәм балаларының җәсәде (=тәне) үлгәннән соң да хөрмәтлидер. Ошбуның өчен мәет булган хәлдә дә хөрмәт итү, тәрбияләп, дәфен итү, хәтта артыннан яхшы сыйфаты берлән генә яд итү, яман гадәтләрен, сыйфатларын яд итмәү кебиләр.

Бишенче: гомумән, солых татулыкны саклау берлән әмер ителгән. Ислам динендә адәм балалары арасында татулык, тынычлык саклау юлында һәрбер мөэмин-мөселман бурычлыдыр. Һәрбер мөэминнең өстендә фарыз гамәлдер.

Тынычлык саклау хезмәтләре мөэминнәргә хәтта берәмләп йөкләтелгәндер. Бәлки һәр сәгать, һәр минут тынычлык саклау юлында хезмәт өстемезгә нык вә нык йөкләтелгәндер. Югарыдагы аять (ادْخُلُوا فِي السِّلْمِ كَافَّةً) булган кеби, мөэминнәргә үз араларында, һәр очраган саен: «Мин сиңа тынычлык теләүче, син миннән тыныч бул», - дип әйтү фарыз ителгәндер. «Әс-сәламү галәйкүм» боерылгандыр (وَتُسَلِّمُوا عَلَى أَهْلِهَا).

Дүртенче: адәм балаларына үз араларында булган хокукларның тигезлеген саклау боерылгандыр. Аятьнең мәзмүзе: «Сез барчагыз да бәрабәрсез. Тик сезнең араларда артыклык Аллаһ хозурында булу мөмкин. Ул да булса, Аллаһтан нык сакланып, Аллаһның газабыннан куркып, тугры юл берлән баручылар артыклык табачактыр дип, ир вә хатын, бай вә фәкыйрь, нинди мөлкәт, нинди сыйфат, нинди төсле булуга карамастан, Аллаһ Тәбарәкә вә Тәгалә хозурында һәркем бәрабәр булып йәүмә кыямәт, дөнья хәятендә тугры, саф, әхлаклы, истикамәтле булучылар гына артык булыр», - дип белдерәдер. Бу исә аерым күрү, артыклык булмыйдыр. Бәлки хезмәт бәрабәренә тугрылык, тәхәммөлле, сабыр булу бәрабәренә мөкәфәтьтер.

Җиденче: бәндәләрне Аллаһ Тәбарәкә вә Тәгалә берләшүгә дәгъват итәдер.

Бу исә ислам диненә дәгъват булмыйдыр. Бәлки ислам диненең әсасы булган тынычлык, татулык, тугрылык, адәм балаларын җәбәр-золым итүдән саклану, чын инсаниятә игътибар итү өчен дәгъват итүдер. ادْعُ إِلَىٰ سَبِيلِ رَبِّكَ بِالْحِكْمَةِ وَالْمَوْعِظَةِ الْحَسَنَةِ («Нәхл», 125). Бу югарыда сөйләнгән мәддәләрне ислам дине шушы ике сыйфатка бүләдер:

1. Аллаһны ихлас күңел берлән берләү, олуглау һәм пакьләү.

2. Әхлакны түзәтү.

Ислам дине – чиге булмаган фазыйләтләреннән өлеш алуга, тугры юл берлән барганда, гакылларга сыймаслык дәрәҗәләргә күтәрелергә, адәм балаларын чакыра торган дин сәмавидер, дин әл-һәйдтер. Бу эшләрнең юлы, сәбәбе итеп дөрес гыйлем тәхси итү, гакылларын, фикерләрен дөрес эшләтү, тик тотмау дип боерылгандыр.

إِنَّ فِي خَلْقِ السَّمَاوَاتِ وَالْأَرْضِ وَاخْتِلَافِ فَاعْتَبِرُوا يَا أُولِي الْأَبْصَارِ («әл-Хәшер», 2), اللَّيْلِ وَالنَّهَارِ لَآيَاتٍ لِأُولِي الْأَلْبَابِ («әл-Әгъраф», 191) ягъни гакыл сахибләренә игътибар итү берлән боерылгандыр. Тик гакылларын дөрес, тугры йөртә, эшләтә белү ләземдер. Ислам динендә адәм балаларының гакылы җитми торган, фикерләр ирешү мөмкин булмаган серләр юктыр. Аның барлык кагыйдәләре ачыктыр, һәркемгә мәгълүмдер. Аның тарафыннан боерылган әмерләр көч җитмәслек түгел вә күп вакытлар үткәрергә ихтыяҗ булырлык дәрәҗәдә дә түгелдер. Адәм балаларына мосыйбәт,[1] кайгы килгән вакытларда, һичбер ярдәмче булмаган вакытларда, кайда гына йөрелергә да белмәгән вакытларда, бу дин – бәндәләр өчен олугъ бер ышаныч, таянычтыр.

Ошбуның тәэсире берлән үзебезне тынычландыра, тәслия кыла. Шуның өчен дә бу дин хакында фитрый дин, табигый дин дип хөкем кылучылар шул фикерләрендә һич шөбһәсез калырга тиешледер.

Ислам дине – фитрый диндер.

كل مولود يولد على فطرة хәдис Мөслим. فِطْرَتَ اللَّهِ الَّتِي فَطَرَ النَّاسَ عَلَيْهَا («әл-Әгъраф», 177): «Аллаһ Тәбарәкә җәмигъ бәшәрне фитрый дин берлән мәшрәф кылды». Ислам дине тарафыннан иршәд ителгән, күрсәтелгән мәүзүгъләрнең беренче дәрәҗәдә әһәмиятле булганнары:

1. Бу кайнатның хәкиме, кадыйре булган бер сөенече бардыр. Ягъни бу дөнья төзелешенең яшәешенә, дөрес тугры дәвам итүенә бер хөкем итүче, көче җитүче бер зат бардыр. Ул затка һичбер дөнья нәрсәләре охшамый. һәм үзе дә дөнья нәрсәләренә охшамаган, һәрнәрсәне күреп

1. Мосыйбәт – кайгы, бәла.

вә белеп идарә итәдер. Әмма ул затның үзене маңгай күзе берлән күрү мөмкин түгелдер, тик гакыл, фикер күзләре генә күрәдер.

2. Дөньядагы бөтен мәхлукатнең вөҗүдә чыгулары, хасыйл булулары габәс, буш түгелдер. Бәлки һәркайсы гая касде берлән яратылгандыр. Әмма шул җөмләдән адәм балалары тел берлән генә бәян ителә алмаслык дәрәҗәдә гали булган кәмаләт хасыйл итү өчен мәхлүк булганнар. Шушы кәмаләтне кәсәб итү адәм балаларының мөкаддәс вазыйфалары һәм илаһи бөек әмердер.

3. **فَامْشُوا فِي مَنَاكِبِهَا وَكُلُوا مِن رِّزْقِهِ** («Мөлек», 15) Ягъни җирнең иң авыр урыннарында булса да, үзеңә тиешле ризыклыкны кәсәб ләземдер.

4. Инсанның рухы мәңгелеккә яратылган өчен бетми, югалмыйдыр.

5. Аллаһ Тәгалә, фәрештәләре вә адәм балаларының үз араларыннан үзләре өчен җибәрелгән рәсүлләре – илчеләре вә шул рәсүлләр аркылы җибәрелгән китаплары бардыр. Ошбулар барчасы да хак, барчасы да адәм балаларына әхлакый, әдәби тәрбия өчен канун иләһидыр. **إِنَّ هَٰذَا الْقُرْآنَ يَهْدِي لِلَّتِي هِيَ أَقْوَمُ** («Исраил», 9), **ذَٰلِكَ الْكِتَابُ لَا رَيْبَ ۛ فِيهِ ۛ هُدًى لِّلْمُتَّقِينَ** («әл-Бакарә», 2). Бу кеби аятьләр бик күптер.

А) Дөреслектә, бу Коръән Кәрим - адәмнәрне һидаятькә, тугры юлга күндерер өчен канун иләһидыр.

Б) Бу Коръән Кәримнең Аллаһтан курка илүчеләрне тугры юлга күндерүендә шик юктыр.

6. Бу дөньяда булган барлык эшләр Аллаһ Тәгаләнең теләве берлән буладыр. Вә теләве берлән бетәдер. **كُن فَيَكُونُ** («Ясин», 86) **كُلُّ مَنْ عَلَيْهَا فَانٍ وَيَبْقَىٰ وَجْهُ رَبِّكَ ذُو الْجَلَالِ وَالْإِكْرَامِ** («Әбнә», 26)

7. Илаһ үзе бетмидер һәм тәбдил дә ителмидер. Илаһ – мәңгедер.

8. Бу дөньядан башка да фида, мәңгелек бер галәм бардыр. Ул галәмнең әхвәле бу көндә шәригать мөкаддәсемез Рәсүле Икрам тарафыннан бирелгән хәбәрләр берлән җөмләсе мәгълүмдер.

9. Ислам диненә ябышу, иярү һәм аны тотуда һәркем үзе мөстәкыйль, ирекле булып, берәр сәбәпче булуның яки васыйтә булуның яки васыять юлы берлән булуның хаҗәте юктыр. **لَا إِكْرَاهَ فِي الدِّينِ** [(«әл-Бакарә», 256) һәм] **فَمَن شَاءَ فَلْيُؤْمِن وَمَن شَاءَ فَلْيَكْفُرْ** [«әл-Каһеф», 29] аять мөкаддәсләре

дәлилдер. Ислам динендә бер тулы да истибдәд вә хикмәт юктыр, ягъни изгелек сыйфаты берлән ярдәм бирү яки могъҗиза күрсәтү берлән дингә дәгъват итү дә юктыр. Ошбуның өчен һәрбер адәм баласының, хәтта шул җөмләдән рәсүлләр-нәбиләрнең дә, Аллаһ исеменнән гөнаһларын гафу итүне вә Аллаһның ризалыгына тоташуы яки Аллаһтан кайту кеби эшләрне булдыра алабыз диюгә хаклары юктыр. Бер мөселманның дин мәртәбәсе никадәр олугъ булса да, үзенә караганда бик түбән күрелгән кешегә нисбәт булган хакы гына бардыр. Мәсәлән, үгет-нәсыйхәт итү, тугры юлга димләү, яманлыклардан тыю кебиләр генә. كُنتُمْ خَيْرَ أُمَّةٍ أُخْرِجَتْ لِلنَّاسِ تَأْمُرُونَ بِالْمَعْرُوفِ وَتَنْهَوْنَ عَنِ الْمُنكَرِ («Али Гыйммран», 111). Ягъни сезнең үз араларыгызда хәбәрдар булган адәмнәр булуы ләземдер. Яхшылыкка димләүче, яманлыклардан тыючылар булуы ләзем димәктер.

Үгет-нәсыйхәт сәбәбеннән динне яхшы аңлау артадыр. Мөселманның фикере киңәядер. Начар вә ачулы фикерләрдән саклanадыр. Башка инсаннар вә милләтләр берлән өлфәтләре артадыр. Рухи тәрбия аладыр, мөмкин кадәр холыкны төзәтәдер. Бу исә ислам диненең әмре һәм әсасе. Гадәләт булып нәтиҗәсе сәгадәттер. فَأُولَٰئِكَ هُمُ الْمُفْلِحُونَ [«әл-Әгъраф», 8].

Дөньяда хөкем сөргән җинаятьләрне, адәм балалары арасында булган золымнарны, җәфаларны, тигезсезлекләреннән килгән фетнә вә бәлаләрне киметү, бетерү юллары күптөрле булу мөмкин, әмма шул күп юлларның тугрысы һәм мәшәкатьсез җиңел булганы – ислам динедер.

Ислам динен кабул итү берлән вә аның хөкемнәрен йөкләү сәбәпле, адәм баласы үзенең хакына аз гына да зарар китерми, дөньясы бозылмый. Әмма ахирәте төзелә, тормыш көтү көрәшләрендә була торган зур кайгыларын басарлык юанычалар табыла. Нәфесен пакьли, гали фикерләргә вә гали эшләргә киң юллар ача. Гакылны канәгатьләндерә торган нәрсә матдият түгелдер, бәлки мәгънәвияттер. Ягъни кайгылы вакытларында матди җиһәтеннән никадәр тәэмин ителсә дә, бәндә канәгать итә алмыйдыр. Һаман яшәвенә кайгырадыр. Әмма дингә ышану, Аллаһка ышану, мәгънәви булу җиһәтеннән “Аллаһка тапшырдым, үзең хәерле кылсана», - дию белән канәгатьләнәдер, рәхәт табыладыр. Ошбуның өчен гакылны канәгатьләндерүчән мәддият булмый, мәгънәвият буладыр. Ислам дине адәм балаларына һәм гомуми мәгъшияткә зарар китерми һәм бәрабәр иминлекне, гомумиятлекне бозмый торган һәрбер эшкә, һәрбер мәзһәбкә хөррият бирә. Нинди кавемнән, нинди милләттән булсалар да, үзенә сыгынучыларның рәхәт яшәүләрен тәэмин итә, дусларына һәм рәсми дошманнарына да галиҗәнаблек ысулы берлән мөгамәлә кыладыр.

Аять فَاعْفُ عَنْهُمْ وَاسْتَغْفِرْ لَهُمْ وَشَاوِرْهُمْ فِي الْأَمْرِ ۖ فَإِذَا عَزَمْتَ فَتَوَكَّلْ عَلَى اللَّهِ («Али Гыймран», 109), ягъни дошманлык итүчеләрне гафу итүгә әмер итә. Дошманлык итүчеләргә дә Аллаһтан истигъфар эстәргә әмер итәдер һәм алар берлән һәрбер эштә мәшавәрә кылуны боерадыр. Бу – ислам диненең галиҗәнаблек сыйфатыдыр. Хөкем вакытларында һәр ике тарафны теләсә кем булуына карамастан тигез тота вә хаклыкта янад (?) итеп хөкем төзидер.

وَإِذَا حَكَمْتُم بَيْنَ النَّاسِ أَن تَحْكُمُوا بِالْعَدْلِ («ән-Ниса», 58), ягъни «Адәм балалары арасында хөкем-суд вакытларында гадәләт берлән хөкем итү – катгый әмердер». Әһле исламне берлек вә карәндәшлеккә дәгъват итәдер. Җәмәгать хәлендә яшәүләрен гомумән халык берлән тынычлыкта вә рәхәт гомер сөрүләрен телидер. Ошбуның өчен бәдави гарәпләр арасында заһир булган бу дин гадәттән тыш тизлек берлән таралды, гомумиләште. Мәзлүм, изелгән сыйныфларның бердән бер баш орачак, күңел юатачак урталары булды. Адәм балалары арасында бертөрле дә корал көче күтәрелми, бик җиңел таралуы, вә җиңел аңлануы да һәм аз вакыт эчендә гомумиләшүендә төрле сыйныфларны үзенә җәләп итүендә бу дингә охшаган мәзһәб, дин, мисак /96/ күренмәде вә тарихларда язылмады.

Ошбу юллар берлән гамәл кылу өчен ягъни ошбу ислам кануннарын канун-закон итеп тоту өчен, исламның әсасы, әхлакы, әдәбе, дин тәрбия өчен булган биналарына чын игътибар ләзем буладыр.

Моңа кадәр ислам кануннарын өйрәтүдә яки ислам кануннары берлән гамәл кылуда бик күп житешсезлекләр булгандыр. Бәлки күп кенә мөэминнәр хәтта имамнар да үзләре белми, аңламый, шул аңламау аркасында дини эшләрен алып баруда бик зур агырлыклар булып, бик җиңел юл берлән табыла торган саваплардан мәхрүм калганнардыр. Хәтта бу куркыныч сыйфат ислам диннен инкарь итү хәленә китергәндер.

Ошбу урында язылачак «Ислам дине» исемендәге вәгазь китабымыз – ислам диненең әсасы, нигезе булган гамәлләрнең нидән гыйбарәт икәнен һәм шул әхлакый-әдәби тәрбия өчен Аллаһ Тәбарәкә вә тәгалә тарафыннан йөкләтелгән дини гамәлләр ничек үтәлергә тиешле, нинди хәлдә дөнья мәгъшиятенә ...се һәм әҗер вә савабы күп булырга мөмкинлеген нинди гамәл-гыйбадәтләрнең Аллаһ Тәбарәкә вә тәгаләгә сөекле һәм шул гамәл-гыйбадәтләрне кай вакытта һәм ничек үтәсәң мәнфәгатьле, нәтиҗәле гамәл булачагsy аңлатуны үз эченә алачак. Һәм берничә җомгаларга таратылырлык вәгазь булачактыр. Кыскача әйткәндә, бу урында язылган берлән генә чикләнми, бәлки бу язмаларның вәгазь өчен мәтен дәрәҗәсендә тотылып, изахи рәвештә алынып язылуы ләземдер.

һәрбер дини вәгазьләр фәкать рәсми мәчетләрдә минбәрләрдә сөйләнергә тиешле булганлыктан беренче бүлек мәчетләргә килүдән, йөрүдән максат ни булырга тиешлеге хакында әйтелеп, 21нче битеннән башланыр.

Мәчетләргә намаз уку, вәгазь тыңлау нияте берлән килгән вакытларда, никадәр бөек әҗерләр булачагы хакында мөбарәк Рәсүлемезнең мөкаддәс булган сүзләреннән сәхих булган берничә хәдисне күчерәбез:

**و عن ابى ماجه - من غدا الى المسجد لا يريد الا ان يتعلم خيراً و يعلمه كان له كأجره معتمر تام العمرة**

**من راح الى المسجد لا يريد الا ان يتعلم خيراً او يعلمه فله اجر حاج تام**

راح иртә килү мәгънәсендә.

Бу урында җәнаб Рәсүл Аллаһ саллә Аллаһ галәйһи вә сәлләм мәчетләргә килүдән максат фәкать хәер аять өйрәнү өчен булган тәкъдирдә һәм шул яхшы сыйфатларны, гадәтләрне үзеңнән соңгыларга гадәт итеп калдырган тәкъдирдә, камил булган гомрә, хаҗ савабы барлыгын белдерәдер. Кыскача әйткәндә, мәчетләргә килү әҗер вә савап өмет итеп, ислам диненең әхлакый-әдәби тәрбиясен алу өчен, булган вәгазьләрне игътибар берлән тыңлау һәм шул вәгазь буенча гамәл итүгә гадәтләнү өчен булырга тиешледер.

Би-гакәс, мәчетләргә килеп урам юлларында җыелып- җыелып гайбәт сөйләү өчен булса, бу вакытта әҗер вә савап урынына гөнаһлар язылып, узган вакытларда кылган изге гамәл-гыйбадәтләрнең дә әҗерләре бетәчәктер. Калебләр караладыр. Иманның нуры да сүнү ихтималы бардыр. Тәмам һәлак булу ихтимал зурдыр. Ни рәвешле мөбарәк рәсүлемез хәдисләрендә **ان الحسد تأكل الحسنات كما تأكل النار الخطم** диелмештер, ягъни: «Явыз гамәлләр начар гадәтләр изгелекләр эшен бетерәдер. Нитәк (ни рәвешле – ред.) ун утыз(ны) бетергән кеби», - димештер (Бохари). Менә бу кеби мөэминнәр өчен хәвефле булган гадәтләрен өйрәнгәч, ташлый алмаган кешеләр дә аз түгелдер.

Мәчетләргә килүдән максат вәгазь насыйхәт тыңларга булмыйча, әҗер вә савап өмет итү булмыйча, бәлки берәр сүз ишетеп булмасмы, берәрсенең гайбәтенә кереп булмасмы дигән ният берлән киленәдер. Ошбуның өчен, мөхтәрәм әһле мөслимин, бу кеби хәвефле, куркыныч, кабахәт сыйфатлардан тукталырга Коръән Кәрим катгый әмер итәдер. Мәчетләр диварында түгел, бәлки каю урында да мөэминнәр өчен гайбәт сөйләү, сүз йөртү – хәвефле гадәттер. Бу кеби явыз сыйфатлардан бер-беребезне тыю берлән Аллаһ Тәбарәкә әмер иткәндер. **وَ يَنهى عَنِ الفَحشآءِ وَ المُنكَرِ وَ البَغى** Бу әмерләрне хәтердән чыгарырга тиешле түгелдер. Шулвакытта гына иманнарыбыз саф

булып, киләчәк буыннар өчен дә үрнәк-нәмүнә булачактыр.

Бу ярамас сыйфатларның булуының сәбәбе шулдыр. Мәгълүмдер ки, الشَّيْطَانَ إِنَّهُ لَكُمْ عَدُوٌّ مُبِينٌ ягъни «дөреслектә шайтан - адәм баласының иң куркыныч заһири дошманыдыр». Менә шул шайтан коткысына ияреп адәм балалары намаз укып та, гайре изге гамәлләрне кылып та шул хөрмәтле изгелекләрне юкка чыгарадыр.

Гайбәт сөйли, башкаларның суи занында (начар уй – ред.) була һәм үзенә тапшырылмаган эшләрен хөкем итә. Мәгълүмдер ки, шәригатьнең хөкемнәрен обсуждать итүгә (тикшерергә – ред.) һичкемнең хакы юктыр. Ул - иләһи канундыр. Шәригать кануннарын обсуждать итми, бәлки күбрәк белгән кешеләрдән сорау берлән боерылгандыр. فَاسْأَلُواْ أَهْلَ الذِّكْرِ إِن كُنتُمْ لاَ تَعْلَمُونَ («Нәхел», 42).

Ислам шәригатендә сорашу өчен бер дә белүче кеше таба алмаган тәкъдирдә, пакь Коръән Кәримне аңламаган тәкъдирдә шәригатебезнең аңлау өчен иң җиңел юллары бардыр. Ислам диненең үлчәү-вәзен дүрт нәрсә тәмәссек итәдер, таянадыр: китап, сөннәт, иҗмаи өммәт, кыяс. Китаптан максуд Коръән Кәримдер. Сөннәтеннән максуд мөбарәк Рәсүлемезнең сәхих булган хәдисләредер. Иҗмаи өммәт булса, Рәсүлемездән соңгы әсхабе кирамнәр, голамаи кирамнәремездер, иттифагыдыр. Юлларның берсен дә белмәгән тәкъдирдә гакылга салып үлчәп карау кыяс кылудыр, ягъни синең дини гамәл, дини бер эшеңнең а) башка адәм балаларына, гомумән мәхлукатларга бертөрле дә зарары булмасын, бәлки файдалары өчен булсын; б) шул гамәлең, эшең үзенең хәятеңә һәм мәгъшыятеңә зарар китерерлек булмасын, гомумән, Аллаһ Тәбарәкә риза була торган гамәл булсын; в) шул гамәлең итагать итә торган мөгамәләгә ... дәвамына зарар итми торган булсын.

Менә шул юлны тотып, гамәл итү ләзем буладыр. Ошбуның гыйбадәт, вәгазь-нәсыйхәт өчен килүе берлән боерылгандыр. Изгелек эстәү – яхшылык өйрәнү өчендер. Вә шулай ук, шул өйрәнгән изге гамәлләрен мәчетләргә килә алмаучылары ислам диненә ихласы булган бәндәләргә ирештерү өчен килергә боерылгандыр.

Ислам дине өйрәнә торган урыннар – мәчетләрдер, мөбарәк Рәсүлемезнең мөкаддәс булган минбәрләредер. Ошбуның өчен ислам мәбналәре (нигезлщнгщн – ред.) мөкаддәс урынарында дин өйрәтү эшләре, вәгазь-нәсыйхәт фәкать Коръән Кәрим, сахих булган хәдисләргә игътимад[1] ителеп сөйләнергә тиешледер. Шәригать кануннарын бозмаска, арттырмаска, алыштырмаска яки киметмәскә, үз файдаңа тугры китермәскә, сөйләмәскә һәм башкаларның

1. Игътимад – ышану.

хәтерләрен табырга тырышып йөргәләмәскә тиешледер.

Нитәк Җәнабе Хак Пәйгамбәремезгә әмер итеп бу һәм барлык вәгазьләргә да әмер катгыйдыр.يَا أَيُّهَا الرَّسُولُ بَلِّغْ مَا أُنزِلَ إِلَيْكَ مِن رَّبِّكَ ۖ وَإِن لَّمْ تَفْعَلْ فَمَا بَلَّغْتَ رِسَالَتَهُ («Мәидә», 67 аять). Мәзмүне: ягъни Аллаһ Тәбарәкә вә Тәгалә рәсүлемез Мөхәммәд Мостафа салләл Аллаһ галәйһи вә сәлләм әмер иткән кеби, һәрбер дин эшләреннән рәхбәрлек итүчеләргә әмер итәдер. Аллаһ тарафыннан нинәрсә өйрәтелгән булса, шуның берлә гамәл итүгә. Әгәр Аллаһ тарафыннан күрсәтелмәгән булса, ул шәригать булмыйдыр. Бу кеби эшләрдән катгый мәнгы (тыю – ред.) итәдер. Ошбу аяте кәримә әмре фида буенча шәригать эшләренең, Коръән Кәрим боерганча, Рәсүле Икрам күрсәтеп биргәнчә булуы катгыйдыр.

Бундый хәлдә, әлбәттә, өйрәтүчеләргә, тыңлаучыларга да вә тотучыларга да тәмам хаж савабы булачактыр, ягъни кабул булган хаж савабы булачактыр.

Бу тәртиптә динебезне алып бару, ислам диненең пакемездә булып явәшенә һәм җәмәгать арасында үрнәк-нәмунә булып, үз алдына артуына сәбәп булачактыр. Ошбуның өчен җәнаб Рәсүл хәдисләрендә әйтелә: من سن في الإسلام سنة حسنة كان له أجرها وأجر من عمل بها من بعده لا ينقص ذلك من أجورهم شيئاً (Мөслим, 2 нче ж., 256 с.) Ягъни кем дә булса ислам диненең эшләрендә күркәм булган гамәл өйрәтеп калдырса, әгәр шул изге гамәл берлән үзеннән соң гамәл кылсалар, өйрәтүчегә дә шул әҗәр киметми язылыр. Әгәр дә бу дини эшләрдә Коръәне Кәримгә вә хәдисе нәбәвиягә әсасланып (нигезләнеп – ред.) үзебездән соңгыларга калдыра алсак, гаять зур бәхетлеләрдән булыр идек. Яхшылыкны хәер бәянны өйрәтүдә бертөрле дә агырлык (=авырлык) булачак түгелдер. Нинди генә дини хәерле эш булмасын, гыйлем эстәү буладыр.

Талиб әл-гыйлемгә фәрештәләр дә ярдәм итәдер. /14б/ Гыйлем эстәүченең мәгшыятендә бәрәкәт хасыйл буладыр. Бундый бәндәләрнең Аллаһ Тәбарәкә вә Тәгалә ризыгын арттырадыр.

Нитәк, җәнаб Рәсүл хәдисләрендә و من غدا يطلب العلم صلت عليه الملائكته و يُبارك له في معشيته و لم ينقص من يرزقه و كان مبارك عليه (Сөнән Әби Дәүд). Мәзмүнә: әгәр дә бер бәндә гыйлем эстәү юлына керешсә, аңа фәрештәләр ярдәм итәдер. Көнкүрешендә бәрәкәт хасил буладыр. Ризыгы һичвакытта да кимемәс, барлык эшләре мөбарәк булыр. Ошбуның өчен һәрбер гыйлем эстәүче кеше гыйлем эстәүдә һич хәвефсез гомерен сарыф итүгә тиешледер. һәрбер гыйлемлек алу яхшылыкка өйрәнү, вәгазь нәсыйхәт тыңлау, вакытларны әрәм /15а/ итү, исраф итү булмыйдыр. Бәлки Аллаһ Тәбарәкә вә тәгалә гомерләргә бәрәкәт бирәдер. Ризыкларның бәрәкәтле булуына, киң булуына Аллаһның рәхмәт фәрештәләре ярдәм бирәчәктер.

Аллаһ Тәбарәкә вә Тәгалә кирәк нинди генә юл берлән булмасын, белмәгәннәрне белү өчен ижтиһад итүчеләрнең дәрәҗәләрен фәрештәләр дәрәҗәсенә күтәрү берлән вәгъдә итәдер. يَرْفَعِ اللَّهُ الَّذِينَ آمَنُوا مِنكُمْ وَالَّذِينَ أُوتُوا الْعِلْمَ («әл-Мөҗәдәлә», 11). Бу - вәгазь тыңлаучылар өчен канун иләһидыр. Ошбуның өчен мәчет-җәмигъларыбызда җомга көннәрендә җомга вәгазьләрен хөрмәт итеп, ганимәт белеп, ихлас күңел берлән тыңларга һәм хөрмәтле сәгатьләрне адәм балалары үзенең бәндәчелек берлән булган кимчелекләреннән мәгъфирәт ярлыкау эстәп, бер генә минут та бушка уздырмаска тиешледер. Бәлки азмы-күпме шәригать хөкемнәрен өйрәтүгә ижтиһад итүгә тиешледер. Бу сыйфатлар белгәннәребез өчен тәкрарлау, хәтергә китерү булып, белмәгәннәребезгә өйрәтү булачактыр.

Вәгазь-нәсыйхәтне тыңламасак, вәгазь-нәсыйхәткә игътибар итмәсәк, изге гамәлләрдән әҗер вә саваплы гамәлләрдән үзең мәхрүм калган кеби, киләчәк буыннарны да мәхрүм итү буладыр. Вә шулай ук хәерле вакытларны исраф итү, бушка әрәм итү булачактыр, олугъ гөнаһтыр. لَا تُسْرِفُوا ۚ إِنَّهُ لَا يُحِبُّ الْمُسْرِفِينَ («әл-Әгъраф», 31).

Мөхтәрәм әһле мөслимин. Араларыбызда ислам дине исеменнән йөртелгән китапларның хисабы, сакны юктыр. Бәлки хәзер вакытта гарәп хәрефе берлән язылган китаплар күрсәк, дини китап дип йөртеләдер. Вә шулай ук, хәзер вакытта араларыбызда элекке дини мәктәпнең иң түбән сыйныфларын күргән, бераз гына төрки таныган халыклар үзләрен зур белемле галим хисап кылып, менә шулар теләсә кем тарафыннан татар телендә язылган бидгать-хорафат, һәртөрле шәригать мөкаддәсемезгә зарарлы гадәтләр берлән тултырылган китапларны, дини китап исеменнән, халык арасына таратып яталар. Гомумән, бу кеби ислам дине өчен куркыныч эшләр – ислам динен авырайтып, былчыратып, язылган китаплар дин исеменнән халыкның фикерен чуалтып, саташтырып йөрүләр күбәеп китте.

Әгәр дә шул мөселманнарны саташтыручыларга ислам динен дөрес итеп өйрәтергә теләсәң, тыңламый, «Син үзең надан, берни дә белмисең», - дип, үзен зур галим хисап итеп, сүз яраштырырга керешә. Ике бозауга кибәк аерып бирүгә көче җитмәгән, башы берлән: «Син ул - надан», - дип, халык арасына провокация тарата. Бу эше берлән ул сине былчырата да алмый, синең гыйлемгә зарар да китерә алмый, бәлки бу сыйфатлар хөкүмәтебезнең һәрбер дин эшләрендә халыклар тотарга ирекле дигән канунга каршы хәрәкәт була. Ягъни хөкүмәтебез һәм дине мөкаддәсемез – хорафат, бидгать ислам дине исеменнән кертелгән һәрбер фанатический эшләрен бетерә, ошбу хөкүмәт

динне бетерә дип күрсәтүче була. Ислам динендә бәхәсләшергә, сүз ярыштырырга һичберәүнең хакы юктыр, чөнки ул - илаһи канундыр. Әгәр дә ул дөрес юл берлән алып барылса, Аллаһның Кәламе Коръән Кәрим вә Нәбийнә мөхтәрәмемезнең мөкаддәс булган сәхих хәдисләре аңлаган кешеләргә, аңларга теләгән кешеләргә сафсата сатарга һич юл куячак түгелдер. Ислам дине бәндәләрне адаштырмыйдыр, бәлки ул үзе мәңге адашмаслык маяк итеп куелгандыр. Тик шуңа ныклы тотынырга кирәктер. Менә шуның өчен Аллаһ Җәллә Җәлалә аңлашмаган хәлдә: «Сез Коръәне Кәримнән карагыз, Рәсүлемезнең сәхих булган хәдисләреннән карагыз», - дип боергандыр. فَإِن تَنَازَعْتُمْ فِي شَيْءٍ فَرُدُّوهُ إِلَى اللَّهِ وَالرَّسُولِ إِن كُنتُمْ تُؤْمِنُونَ بِاللَّهِ وَالْيَوْمِ الْآخِرِالخ («ән-Ниса», 59), ягъни әгәр сезнең араларыгызда дини мәсъәләдә аңлашылмау була калса, сез Коръән Кәримгә һәм хәдисе Рәсүлгә мөрәҗәгать итегез, әгәр дә сез Аллаһка һәм кыямәтнең булуына иман китерүче булсагыз.

Мәзкүр аяте кәримә дин мәсъәләләрен кешеләрнең үз фикерләренә карата эшләргә кушмыйдыр, бәлки Аллаһтан һәм кыямәт көненнән куркып, боерылганча хәл итергә боерадыр.

## Коръәне Кәрим күрсәткәнчә планеталар хакында кыскача мәгълүмат.

Иң беренче, Аллаһ Рабб әл-галәмин барлык адәм балаларын, динле яки динсез булуына карамастан, нинди дин тотуына да карамастан, һәркемне Аллаһның җирдә вә күктә булган, күренгән һәм күренмәгән байлыкларын эзләргә, табарга, мәнфәгатьләнергә ирекле кылгандыр. Коръән Кәрим бу тугрыда ошбуны ачык рәвештә белдерәдер. «Локман», 20: Әстәгыйзү би-Ләһ: أَلَمْ تَرَوْا أَنَّ اللَّهَ سَخَّرَ لَكُم مَّا فِي السَّمَاوَاتِ وَمَا فِي الْأَرْضِ وَأَسْبَغَ عَلَيْكُمْ نِعَمَهُ ظَاهِرَةً وَبَاطِنَةً ۗ وَمِنَ النَّاسِ مَن يُجَادِلُ فِي اللَّهِ بِغَيْرِعِلْمٍ وَلَا هُدًى وَلَا كِتَابٍ مُّنِيرٍ Ягъни: И сез, күрмисезме, Аллаһ Тәбарәкә вә Тәгалә сезне бит мәсхәр кылды, ягъни ирекле кылды. Аллаһның күкләрдә булган вә җирләрдә булган яшерен вә эшләре, байлыкларыннан файдаланырга адәм балалары белеме, гыйлеме булмаса да, кулында бертөрле дә ачык дәлиле булмаса да, Аллаһ турында мөҗәдәлә кыланыр дип уйлатадыр. Шулай булгач, һәр кеше ирекледер Аллаһның яшерен байлыкларын табарга һәм файдаланырга. Хәзер заманда 20 нче гасырның соңгы елларында Аллаһның яшерен байлыкларыннан хисапсыз файдалана башладылар. Хәзерге вакытта, әлбәттә, җирдәге байлыклардан файдалана башладылар. Коръән Кәрим: سَخَّرَ لَكُم مَّا فِي السَّمَاوَاتِ وَمَا فِي الْأَرْضِ - диеп беренче буларак күктәге байлыкларны хәтергә китерәдер. Коръән Кәрим бөтен

булган нәрсәләрне ачып җибәрде. Монда 1400 ел мөкаддәм башланган, ләкин ул Адәм пәйгамбәрдән үк башланган булмаган. Шул сәбәптән Коръән бәгланып, куелып: «Әй, бер дини китап кына», - дип игътибарсыз калдырылган. Коръән Кәримнең серләрен мөселманнар ача алмаган, ачарга ирек бирелмәгән. Ләкин башка динсез яки башка бер диндә булучыларга ачыла барган һәм хәзер дә ачыла барадыр. ИншәАллаһ, истикъбаль Коръән Кәрим дине һәм көчле булган фәнни китап мәйданга чыгачактыр, чөнки аны мәйданга куя баучылар ирекледер. Тик аны дөрес аңлау кирәк һәм ул Коръән Кәримгә шәрехләү киң рәвештә язылырга тиешледер. Коръән бер дә үзгәртелергә тиеш түгелдер.

Ислам дине, гомумән, ислам кануны булган Кәламуллаһ Коръән Кәрим дини һәм фәнни китаптыр. Коръәндә һәрбер научный эшләр һәм башка кануннар кыскача гына белдерелгән. Тик Коръән дини китап ителеп игътибарсыз калдырылган.

Хәзер дә һәрбер научный эшләрнең көннән-көн ачыла баруы – Коръән Кәримнең ачыла баруыдыр. Гасырлар уза-уза аңа игътибар булуы – чын өметтәдер. Коръәннең хөкме әйтәдер. ИншәАллаһ, бу турыда җәнаб Рабб әлгаләмин إِنَّا نَحْنُ نَزَّلْنَا الذِّكْرَ وَإِنَّا لَهُ لَحَافِظُونَ дип белдергәндер. Бу мәкаләмдә фәнни галимнәр алдында бик нечкә, төшенүе агыр (=авыр) булган, галәмнең яратылуы һәм шул җирдә тереклекнең килеп чыгуы хакында язам.

Болар һәркайсы – Коръән Кәримнән алынган аятьләр берлән тасдыйкъ ителгән хәерләрдер һәм остазымыз Зияәтдин әл-Камали хәзрәтләренең асыл фикерләреннәндер. Коръәне Кәримдә хас 156 аять, моннан башка да күптер.

Ислам халыкларының галәм яралтылуы хакында ачык һәм бер фикердә булулары ләземдер. Ләкин бәгъзе бер, бәлки, күпчелек ислам диненә һөҗүм итү ниятендә булган монархистларның яки наданлыклары сәбәбеннән, яки ислам диненә катгый дошманлыклары сәбәбеннән, ислам дине өстенә, гомумән, галәм яралтылуы хакында мәгълүмат бирү дигән булып, төрле ялган ифтиралар берлә тулы төрле китаплар язып таратып, ислам дине хакында бер дә булмаган хата фикерләр язалар, халыкны эздән яздыралар. Коръәннең ачык хакыйкатен яшерү, ислам диненең киләчәктә дәвам итүенә, начар һәм куркыныч эзләр калдырды. Менә хәзер көн дә аларның хаталары, ифтиралары дин исеменнән ислам галәме арасында көч алып китте. Бу инде дингә каршы сөйләүчеләр өчен, атеизм өчен көчле корал һәм зур материал ителеп файдаланыладыр. Бигрәк тә куркынычы – милләт телендә һәм башка телләрдә, без аңлаган телләрдә ислам дине хакында хакыйкатьне ачарлык һичбер төрле китап таратылмыйдыр. Бәлки ислам балаларына надан әби-бабайлары ышанып килгән хорафат-бидгать, фанатически, ислам диненең иң дошманы булган

сүзләр берлә, миссионерлар тарафыннан эш алып барыладыр. Димәк, ислам динен хөкүмәт тарафыннан беркем дә бетермидер. Бәлки динне бетерүче әнә шул надан әбиләр йә бабайлар, чөнки алар хакыйкатьне белми, ялган-хата күрсәтелгән китап берлән эш йөртәләр. Бу бик куркыныч. Аллаһ үзе сакласын! Европа язучылары, шул миссионерлар тарафыннан дин итеп күрсәткән төрле әкиятләр, Коръәндә бер дә булмаган төпсез хыяллар - халык арасында әнә шул ялган төпсез хикәяләрне ислам дине исеменнән йөртәләр.

Мисал өчен, гомумән, Коръән переводлары да күбесе куркыныч, ислам диненең катгый дошманнарыдыр. Бигрәк куркыныч: хәзерге вакытта балалар рус хәрефе белән русча гына укый беләләр. Шулай булгач, Саблуков тарафыннан русча тәрҗемә ителгән Коръәнне укып, шуннан мәгълүмат алган кеше ничек итеп ислам диненең хакыйкатен дөрес аңлап дөрес хөкем итә алсын?! Саблуковның переводы баштан азагына кадәр меңләрчә хата, бозык, ислам диненә пычраклык белән тутырылган. Шулай ук, Казимирский переводы да – хата, ифтира, истихзадыр. Инде Крачковский переводы булса, дөрес, ул - гарәп телен чын белүче, ләкин Коръәнне тәрҗемә итү өчен тел белү генә җитмидер. Тел белү берлән генә Аллаһның хөкемен дөрес аңлап булмыйдыр. Коръәнне дөрес аңлау өчен ислам динен тәмам белүче булу ләземдер. Коръәннең һәрбер аятенә, бәлки һәрбер сүзенә киң рәвештә комментарий язарга кирәк, чөнки шул ук бер аятьтә бер темада сөйләп барылса, шул аятькә бер сүз берлән башка бер мәгълүмат кертелеп киткәндер. Мәгълүмдер ки, Коръән аять-аять иңгән һәм шул аятьләрне пәйгамбәремез Мөхәммәд саллә Аллаһ галәйһи вә сәлләм укып биргән, ләкин шул вакытта киңрәк аңлау өчен сөәльләр бирелгән. Шул сөәльләргә Рәсүлемез җавап биргән, төшендергәндер. Менә шул мөбарәк Рәсүлемезнең төшендерү өчен биргән җаваплары аңлатулар хәдис булып калган, шәрехләү булган. Ошбуның өчен көтеб ситтәдә булган ягъни Бохари, Мөслим, ибне Маҗә, ибне Тәймиййә, Мөватта, Тирмизи сани кеби бөек китаплардагы хәдисләр – Коръәнне дөрес аңлау өчен тулы комментарийдыр. Бу кеби бөек хәдисләрнең һичберсе Коръәннең хилафына куелмагандыр. Бу тугрыда мисаллар күптер. Һәркайсы аерым язарга зәгыйфьлек, картлык зарар итәдер. Хәерле булсын.

Асыл фикеремә күчәм. Менә шул Коръәннең хата һәм дошманлык фикере берлән, Коръәнне эздән чыгару нияте берлән язылган переводлардан карап, ислам дине исемендә күп кенә китаплар чыгарылып таратылган, шулай итеп бөтен җир йөзенә ислам дине исеменнән яңлыш (=ялгыш) фикерләр таратылгандыр. Бу турыда җирлек галимнәремезнең ислам кылу өчен һәм ихтыярлары булмагандыр, чөнки корал көч шул ислам диннең дошманнары кулында

булгандыр.

Мәгълүмдер, һәрнәрсәнең хакыйкатен ачу өчен корал кирәктер. Корал берлән хакыйкать ачыладыр. Әмма яшьләремезнең тик рус телендә генә укый белүләре, ягъни шул хакыйкатьне ача торган корал рус телендә генә булып шул Саблуков переводы аларга Коръән хакыйкатен ачу өчен коралдыр. Әлбәттә, шул дөрес дип ышаналар. Аллаһ хәерле кылсын. Шул дөрес язылмаган хата, ифтира берлән язылган русча китапларга рәддия язарга ирек булмаган. Ә миссионерлар, «әгәр дә шул переводлар-брошюралар дөрес булмагач нигә рәддия язмыйсыз», дип, бөтен хаталарны ислам дине өстенә, ислам галимнәре өстенә аударганнар.

Инде галәм яралтылуы хакында халык арасында төпсез хикәяләр, асылсыз кыйссалар күп йөридер. Бу төпсез хикәяләрне кайбер тәфсир итүчеләребез Коръән тәфсиренә кертеп җибәргәннәр. Гомумән «әл-Фәваид» тәфсире кеби һәм башка күп кенә тәфсирләрдә дә тулып ята. Ә укучылар бу ялган төпсез әкиятне Коръән тәфсире шулай әйткән дип, дин исеменнән гамәлгә куйганнар һәм бу көндә гамәлгә куеп баралар. Ислам дине исеменнән таратылган бидгать-хорафатларны күрә торып, сөкүт (эндәшми – ред.) калу – ислам динендә олуг җинаятьтер.

## Ислам динендә галәм

Ислам динендә галәм дип, ялгыз Аллаһтан башка булган бөтен барлыкка, бөтен кайнатка әйтеләдер. Бу икегә бүленәдер: галәм әл-өмүр, галәм әл-халк. Галәм әл-өмүр дип фәрештәләр фәүте, энергрия кеби саф булган галәмнәргә әйтеләдер. Галәм әл-хәлк дип маддә һәм җисемнәрдән төзелгән галәмгә әйтеләдер. Йолдызлар, кояш, ай, җирләр кебиләргә әйтеләрдер. Бунын бу рәвешле булуы хакында Аллаһ Тәбарәкә Коръән Кәримдә «әл-Әгъраф» сүрәсендәге 54нче аятьтә белдерәдер. Әстәгыйзү биллаһ: إِنَّ رَبَّكُمُ اللَّهُ الَّذِي خَلَقَ السَّمَاوَاتِ وَالْأَرْضَ فِي سِتَّةِ أَيَّامٍ ثُمَّ اسْتَوَىٰ عَلَى الْعَرْشِ يُغْشِي اللَّيْلَ النَّهَارَ يَطْلُبُهُ حَثِيثًا وَالشَّمْسَ وَالْقَمَرَ وَالنُّجُومَ مُسَخَّرَاتٍ بِأَمْرِهِ ۗ أَلَا لَهُ الْخَلْقُ وَالْأَمْرُ ۗ تَبَارَكَ اللَّهُ رَبُّ الْعَالَمِينَ

Бу аятьтән аңлашыладыр: бөтен галәм әл-өмүр һәм галәм әл-халк. Мөбарәк Рәсүлемездән җанны нәрсә дип сораугa Аллаһ Рабб әл-галәмин: قُلِ الرُّوحُ مِنْ أَمْرِ رَبِّي, ягъни «Бәгъзе җан – галәм әл-өмүрдән», - дип җавап биргән. Бу хакта хосусый язармын, насыйп булса. Ләкин галәм әл-халк, якын галәм, ерак галәм дип бүленәдер. Менә шул якын галәмгә «дөнья» дип әйтеләдер, чөнки дөнья сүзе دنو дән алынган, «якын булмак» мәгънәсендәдер. Ягъни дөнья дигән сүз

якын галәм булыр, галәм әл-махлукаттыр. Дөнья – кояш һәм башка планеталар ай өстендә яшәдегемез җир вә җирдәге мәгъдәннәр[1], үсемлекләр вә хайваннардан гыйбарәттер. Ошбулар әс-сәма әд-дөнья дип исемләнәдер. Аллаһ Тәбарәкә вә Тәгалә Коръән Кәримдә җирне зикер иткән кеби аның тирәсендә җиде планетаны да зикер итәдер, мәсәлән «Бакарә» сүрәсендәге 22-23нче аятьләрдә җирдәге әсәрләрне сөйләгәндә, فَسَوَّاهُنَّ سَبْعَ سَمَاوَاتٍ дип җиде планетаны да зикер итәдер.

الَّذِي جَعَلَ لَكُمُ الأَرْضَ فِرَاشاً وَالسَّمَاء بِنَاء وَأَنزَلَ مِنَ السَّمَاءِ مَاءً فَأَخْرَجَ بِهِ مِنَ الثَّمَرَاتِ رِزْقاً لَّكُمْ فَلاَ تَجْعَلُواْ لِلّهِ أَندَاداً وَأَنتُمْ تَعْلَمُونَ [«әл-Бакарә», 22] дәхи: هُوَ الَّذِي خَلَقَ لَكُمْ مَا فِي الْأَرْضِ جَمِيعًا ثُمَّ اسْتَوَى إِلَى السَّمَاءِ فَسَوَّاهُنَّ سَبْعَ سَمَاوَاتٍ وَهُوَ بِكُلِّ شَيْءٍ عَلِيمٌ [«әл-Бакарә», 29] җирдә тереклек һәм шул тереклектә максуд барлыкны белдерә һәм خَلَقَ سَبْعَ سَمَاوَاتٍ طِبَاقًا дип җиде планетаны аңлатадыр.

تُسَبِّحُ لَهُ السَّمَاوَاتُ السَّبْعُ وَالْأَرْضُ وَمَنْ فِيهِنَّ дип җирне җиде сәярләр берлән бергә зикер итәдер. «Мөлек» сүрәсендәге 3нче аятьтә سَبْعَ سَمَاوَاتٍ дип әйтеп китүе һәм, шулай ук, 5нче аятьтә وَلَقَدْ زَيَّنَّا السَّمَاءَ الدُّنْيَا сәма, дөнья дип исемләгәндер. Ягъни Коръән назарында кояш мәзмунда булган планеталарның җирдән башкасын сәма әд-дөнья дип кыскача гына белдерәдер. Шул якын булган, ягъни якын галәм Коръән назарынча ничәдер. Шул дөньяның җиде планетасы бар. Мона дәлил - «әл-Бакарә» сүрәсе, 29: فَسَوَّاهُنَّ سَبْعَ سَمَاوَاتٍ ягъни Аллаһ тәгалә югарыда җиде планета барын белдергәндер һәм бу планеталарның һәр кайсының орбиталары бардыр. Һәркайсы кояш тирәсендә үз орбитасында әйләнәдер.

Коръән назарында «Мөэминин» сүрәсендәге 17нче аять وَلَقَدْ خَلَقْنَا فَوْقَكُمْ سَبْعَ طَرَائِقَ ягъни «Сезнең өстегездә һәрбер планетаның – җиде планетаның – үз өчен җикләнгән орбитасы бардыр. Ошбу планеталарның нык мөхәккәм булуы хакында Аллаһ Тәбарәкә Коръән Кәримдә «Нәба» сүрәсендәге 12нче аятьтә әйтә: وَبَنَيْنَا فَوْقَكُمْ سَبْعًا شِدَادًا.

## Җир үзе планетаданмы?

Җирнең хәрәкәт итү күп аятьләр белән белдерелгәндер. Җир 8 нче планетадан хисап ителәдер. Моңа дәлил ягъни җирнең 8 нче планета булуына дәлил تُسَبِّحُ لَهُ السَّمَاوَاتُ السَّبْعُ وَالْأَرْضُ («Бәни Исраил», 43). Шулай булгач, җирне

---

1. Мәгъдән – 1. Чишмә, чыганак. 2. Руда.

7 нче планета итеп сану мөмкин түгел, чөнки Аллаһ Тәбарәкә вә тәгалә җиде планета хакында сәма дип ягъни күктә булган планеталарны гына мәгълүм итә. Җир безнең аяк астыбыздадыр, ягъни сәма әд-дөнья дип әйтеләдер. Бу инде җирдән башка күктәге планеталар хакында булып, ягъни күктәге якын булган җиде планета турында буладыр. Инде бер мәсьәлә бу бик күп сөйләнәчәк, ягъни күк дип тәрҗемә итәбез. Шул сәманы күк дип итү дөресме? Коръәндәге сәманы күк дип тәрҗемә итү дөрес түгел. Бу – һава, бушлык яки планеталарның орбитасы, кояш яктылыгы белән зәңгәр төстә күренә. Шуңа бабаларымыз күк дип исем биргән булмаса, сәма күк түгелдер.

Планеталарның исемнәре Коръән буенча бармыйдыр.

Аятьләр планеталарны җиде дип әйтә дә, ләкин исемнәрен санап күрсәткән урыны юктыр. Моның сәбәбе шулдыр: Коръән - илаһи булган бер бөек китаптыр. Адәмнең тормышта шул турыда үзара низаг-дәгъва итешмәүләргә игътибар ителгәндер. Коръән – һидаят китабыдыр, астрономия түгелдер. Юлдызларга исем бирү җәмгыять бәшәр хакыйктыр. Алар хокукыйдыр.

## Планеталарның кыскача тарихчасы

Бу турыда хәзерге галимнәр нык беләдер, хәтта югарырак мәктәпләрдә укучы балалар да беләдер. Монда планеталарның тарихчасын кыскача язудан максат. Коръән Кәрим ачык һәм киң бу турыда хәбәр биргән булса да, шул турыда фикер йөртүчеләр булса да, Коръәне Кәримне игътибарсыз калдырганнар. [...]

Инде югарыда сөйләнеп узган бәгъзе бер планеталарның әхвәле хакында фән галимнәре менә хәзер төрле корал көчләре белән, телескоплар аркылы хакыйкатьне ачадыр, әмма гаҗәп бер хәл, обсерватория булмаган, бер төрле дә телескоп кораллары булмаган бер гасырда, Гарәбстан чүлләрендә укый-яза белмәгән ятим үскән Мөхәммәдгаләйһиссәламнең башы белән бу хакыйкатьләрне кәшеф иткән итүләре! Һич шөбһәсез бу эшләргә битараф караучы гыйлем әһелләре вәхи илаһи белән кәшеф ителмеш хакыйкать Коръән – Аллаһ сүзедер, дип әйтүгә мәҗбүр булачактыр. Коръән Кәрим һичкем тарафыннан төзелгән юк, Коръән Кәрим – илаһи бер китап, ул дини һәм научный китаптыр. Коръән Кәрим әхлакый, әдәби, дини, иҗтимагый, Коръән Кәримнең һәрбер аяте дә игътибар ителсә, гаять мөһим, бөтен хәятемездә җир вә күкләрдә булган бөтен нәрсәне файдаланырга өйрәтүче илаһи канундыр.

Җиде планета суган кабыгы кеби кат-кат ясалганмы? Бу турыда Коръән Кәримнең белдерүе ничектер? Коръән Кәримдә җиде планета хакында берничә аять бардыр. Бу турыда язган да идем. «әл-Мөлек», 3: سَبْعَ سَمَوَاتٍ طِبَاقاً , «Нух»,

15: أَلَمْ تَرَوْا كَيْفَ خَلَقَ اللَّهُ سَبْعَ سَمَاوَاتٍ طِبَاقًا кебиләр. Ошбу аятьтә Корьәнне бәгъзе бер тәфсир итүчеләр «күкләр җиде кат булып, суган кабыгы кеби, берсе икенчесенә капланган» дип изах биргәннәр. Имамнарның да күбесе шулай аңлыйлар, ләкин тәфсирләрдәге бу изахлар вә кыйссалар һичберсе Корьән Кәримдә юктыр, бәлки бу буш сүзләр Корьән аңлатуга бинаән катгый хилафтыр. Бу турыда дөресен аңлау һәркемгә тиешледер.

1. Гасыр сәгадәттә طباق нинди мәгънәдә файдаланган?

2. Корьәндә үзе طباق сүзе тәфсир ителгәнме?

3. Пәйгамбәребез طباق сүзен тәфсир иткәнме?

4. Планеталар хакында Корьән Кәримнең аңлатуы ничек?

Әгәр шушы дүрт мәсьәлә дөрес тикшерелсә, Корьән Кәримнең ачык белдерүе, ислам диненең саф карашы гамәлгә куелачактыр.

طباق сүзенә тарихи караш. Мәрхүм остаз Зыяэтдин әл-Кәмали хәзрәтләре бу турыда һәртөрле лөгать китаплары карап, ягъни Ибн әл-Әсирнең نهايه, Суютының الدر المنثور , Исфаһанинең مفردات قاموس, عريب القرآن вә башка тарих әл-лүгател-гарәбия طباق مطابقة сүзләрне тикшереп түбәндәгеләрне таптым дип дәрес биргән иде: күпчелек, җәмәгать, төркем мәгънәсендә جائنا طبق من الناس кеби. Дәхи дә ерак вә озак урыннарга да әйтеләдер توصل الاطباق و تقطع الارحام хәдисендәге сүз буенча. Тарих, хәл, үзгәреш мәгънәсендә. Гомәр б. әл-Гасның (كنت على اطباق ثلاث) «Өчтөрле тарихи хәлләрдә булдым» бер хәлдән икенче хәлгә күчү мәгънәсендә. لَتَرْكَبُنَّ طَبَقًا عَنْ طَبَقٍ («әл-Иншикак», 19) – моннан башка да төрле мәгънәләрдә киләдер.

Кыскача тәрҗемә Корьән Кәримнең хикмәтле сүзләре гасыр сәгадәттән вакытындагыча тәрҗемә ителер. Соңгы вакытлардагы ясалмыш сүзләр белән тәрҗемә мөтләкән (=бөтенләй) дөрес түгелдер. Дөрес тәрҗемә иткәндә ягъни гасыр сәгадәт вакытында кулланмыш тәрҗемәгә игътибарән طَبَقًا вә طَبَقٍ Корьәндәге (سَبْعَ سَمَوَاتٍ طِبَاقًا) Аллаһ берсе-берсенә уратыр, каплар хәлдәге югарыдагы планеталарны җиде итеп хәлык кылды. Яки: һәрбер җиде планета үзенең орбитасы белән үзен каплар хәлдә хәлык кылынды.

كُلٌّ فِي فَلَكٍ يَسْبَحُونَ («ән-Әнбия, 33»): Аллаһ Тәбарәкә вә тәгалә җиде планетаны җәмәгать, төркем хәлдә хәлык кылды, яки югарыдагы җиде планетала

бере артыннан бере хәлык кылынды.

Әл-хасыйл, югарыда язылмыш طباق сүзенең Коръән аятьләре, хәдисләре белән белдерелгән дөрес һәм гасыр сәгадәт вакытындагы мәгънәсе игътибар ителер һәм һәркайсы тугры киләдер. Планеталар Аллаһ тарафыннан үзенә муафыйк мәнзәлләр һәм чикләр куелганлыгын Коръән Кәрим тасдыйкъ итәдер. Чыннан да, планеталарның кояшка караганда үзенең мәнзәле бардыр һәм чикләре бардыр (كُلٌّ فِي فَلَكٍ يَسْبَحُونَ). Димәк, һәркайсының үзләренең зурлыкларына карата мәнзәлләре бардыр. Нинди генә юл белән тәрҗемә ителсә дә, һич аерма юктыр. һәркайсы үз урынында муафыйктер. Коръән Кәрим طباق сүзне изахы тәрҗемә иткәндер: «әл-Мөлек» сүрәсе خَلَقَ سَبْعَ سَمَاوَاتٍ طِبَاقًا аяте артында ук изахы рәвештә مَّا تَرَى فِي خَلْقِ الرَّحْمَنِ مِن تَفَاوُتٍ فَارْجِعِ الْبَصَرَ هَلْ تَرَى مِن فُطُورٍ. ثُمَّ ارْجِعِ الْبَصَرَ كَرَّتَيْنِ يَنقَلِبْ إِلَيْكَ الْبَصَرُ خَاسِأً وَهُوَ حَسِيرٌ: «Аллаһның хилкатендә һич тәфәүт күрмәссең, кимчелек һәм күрмәссең. Күзеңне күтәребрәк, югарырак кара, шунда берәр фотур ярык кеби кимчелек күрәсеңме? Дәхи дә күккә кара, күзләрең Ходаның хикмәтен күреп өметсез булып кайтыр». Ягъни Аллаһ Тәбарәкә вә тәгалә планеталарны сыйныгы вә куюлышларында, аларның тәкъдирләрендә, хәрәкәтләрендә, тәртипләрендә, кечкенәләрен дә һәм зурларын да берсе икенчесенә табигъ булган хәлдә яратты.

Вә шул җөмләдән кояш вә ай турында ачык мәгълүм итеп, «Нух» сүрәсендәге 16 аять килә: وَجَعَلَ الْقَمَرَ فِيهِنَّ نُورًا وَجَعَلَ الشَّمْسَ سِرَاجًا шул планеталар арасында нур итеп, яктыртучы итеп, юл күрсәтүче чираг итеп, кояшны Ходай кылды.

## Планеталар бер җыентык булдыლармы?

Чөнки طباق җәмгыять мәгънәсендә алынса, бер җыентык, төркем булу ихтималы күздә тотыладыр. «әл-Әнбия», 30: أَوَلَمْ يرَ الَّذِينَ كَفَرُوا أَنَّ السَّمَاوَاتِ وَالْأَرْضَ كَانَتَا رَتْقًا فَفَتَقْنَاهُمَا: Әй Аллаһны инкяр итүчеләр, кәферләр! Белмиләрме, тәхкыйк, югарыдагы планеталар бер җыентык булдылар һәм җирдә бер оешкан хәлдә булсалар, ягъни оешкан хәлдә бер дәвер гомер иткән булсалар, шул оешкан хәлдән аерылып барлыкка килмешләрдер. Бу инде Коръән белән ачык мәгълүм ителгәндер. Ягъни планеталар Коръән нәзарендә планеталар оешкан бер зур көррә булса, кодрәт илаһия белән бере артыннан бере нәбүвәт белән барлыкка килгәннәрдер. Аллаһ Тәбарәкә вә тәгалә җир вә күктәге булган һәм алар арасында булган һәрбер планеталарны ялган бушлык өчен хәлык кылмагандыр. «әл-Әнбия», 16: وَمَا خَلَقْنَا السَّمَاءَ وَالْأَرْضَ وَمَا بَيْنَهُمَا لَاعِبِينَ дип ачык

тасдыйк итәдер.

## Планеталар купол кеби каты нәрсә өстендә йөриләрме? Ислам дине ничек карый?

Коръән Кәримдә «әр-Рәгыд», 2: اللَّهُ الَّذِي رَفَعَ السَّمَاوَاتِ بِغَيْرِ عَمَدٍ تَرَوْنَهَا: Аллаһ Тәбарәкә югарыдагы планеталарны, күзгә күренгәнчә, һичбер тараксыз күтәрде. Димәк, планеталар һичбер нәрсәгә тимәстән ачык хәлдә дәвам итүне аңлатадыр. Янәдә бу турыда киңрәк мәгълүмат өчен «әл-Мәләикә», 41: إِنَّ اللَّهَ يُمْسِكُ السَّمَاوَاتِ وَالْأَرْضَ أَن تَزُولَا ۚ وَلَئِن زَالَتَا إِنْ أَمْسَكَهُمَا مِنْ أَحَدٍ مِّن بَعْدِهِ: «Аллаһ Тәбарәкә югарыдагы планеталарны һәм җирне бере-беренә тимәслек, заил булмаслык итеп тотадыр. Әгәр дә бере-берсенә тисә, заил булса, Аллаһтан башка моны һич тотучы, һичбер көч юктыр». Моннан мәгълүмдер, җир һәм планеталарның бере-беренә тими зарар тимәслек хәлык кылынганы. Димәк, планеталар һичбер купол кеби нәрсәгә беркетелми, һәркайсы бере-беренә зарар китермәслек орбиталарда йөзәдер.

كُلٌّ فِي فَلَكٍ يَسْبَحُونَ бу турыда мөбарәк Рәсүлебезнең мигъраҗ хакындагы хәдисендә мәгълүмдер.

Планеталарга ислам диненең карашы.

1. Планеталар барчасы бер асылдан яратылмыш.
2. Планетелар бер оешкан хәлдә булып, соңра нәүбәт белән береннән-бере аерылган, җиде булып яратылгандыр.
3. Гасырлар үтү белән бәгъзе әхвәлләре алмашынсын, хәзерге хәлләрендә хәрәкәт итмәктәдер.
4. Яралтылышта һәм куялмыш тәртибендә һәм билгеләнгән чикләрендә бере-беренә охшаган хәлдә яратылмыштыр.
5. Һәркайсы үзенең куелган чигендә хәрәкәт итәдер.
6. Җир – сигезенче планета булып хәрәкәт итәдер.
7. Купол төзеп куелган дигән фикерләр ялган, төпсез бер ифтирадыр. Моны ислам динендә булган һәрбер кешегә игътибар белән карау тиешледер.

Хакыйкый Коръәндә булган Аллаһның сүзе дөрес куелгандыр, ләкин Коръән переводларына карап хөрмәтле Кәлямулланы пычратуга һичкемнең хакы юктыр. Тикшерергә, хакыйкатьне эзләргә һәрбер галим бурычлыдыр.

Тикшерми торып ябып кую җинаятьтер. Коръән Кәрим гаять мөһим, киң серле илаһи кәламдер. Тарихы бөек булган тарихи китаптыр.

Планеталарның югарыга куелу хакында тарихи белдеру:

Коръән Кәрим вәхи булып иңә башлаганда ике агым бар иде: фәнни агым вә дини агым. Фәнни агымга караганда күк ялтыравыклы (шикак) бер җисем бер купол бар, планеталар шул купол өстендә хәрәкәт итәдер, дигән фикерләр 14нче гасырларга кадәр дәвам итте. [...]

Бу турыда Коръән Кәрим «Та һа» сүрәсендә 31-35нче аятьләрдә «Җир белән күк андый нәрсәләр дә түгел, планеталар тараксыз яшиләр» дип бөтен дөньяга игълан итте. Бөтен акыллы кешеләргә хакыйкать шул вакытта ук мәйданга чыккан иде. Менә шуны хәзер фән гыйлеме төрле кораллар аркылы тасдыйкъ итте. «Сәҗдә», 4-5: اللَّهُ الَّذِي خَلَقَ السَّمَاوَاتِ وَالْأَرْضَ وَمَا بَيْنَهُمَا فِي سِتَّةِ أَيَّامٍ ثُمَّ اسْتَوَىٰ عَلَى الْعَرْشِ ۖ مَا لَكُم مِّن دُونِهِ مِن وَلِيٍّ وَلَا شَفِيعٍ ۚ أَفَلَا تَتَذَكَّرُونَ ﴿٤﴾ يُدَبِّرُ الْأَمْرَ مِنَ السَّمَاءِ إِلَى الْأَرْضِ ثُمَّ يَعْرُجُ إِلَيْهِ فِي يَوْمٍ كَانَ مِقْدَارُهُ أَلْفَ سَنَةٍ مِّمَّا تَعُدُّونَ Бу урында Аллаһ хозурындагы көннәр берсе мең көннәр хисап кылынадыр. Моннан аңларга кирәк, күкләрнең хәлык кылуына ничә миллион еллар булганны. Коръән Кәрим һәм кояш вә айның да тараксыз хәрәкәт итүен ачык мәгълүм итәдер. «Ясин», 38: وَالشَّمْسُ تَجْرِي لِمُسْتَقَرٍّ لَّهَا ذَٰلِكَ تَقْدِيرُ الْعَزِيزِ الْعَلِيمِ*وَالْقَمَرَ قَدَّرْنَاهُ مَنَازِلَ حَتَّىٰ عَادَ كَالْعُرْجُونِ الْقَدِيمِ Ни-кадәр ачык һәм аңларлык хөрмәтле аятьләр! Тик күзне бу дини китап дип йоммаска кирәк, акыл күзләре ачык булса, хакыйкатьне күрми калмас, иншәАллаһ.

Фән агымнарына караганда, планеталар оешкан хәлдә булганнар, моның соңында тәртип белән планеталар хасыйл булган дигән сүзләр Коръән иңгәнгә кадәр юк иде. Бу фикерләр 18нче гасырда гына кабул ителде. Коръән Кәрим моны أَنَّ السَّمَاوَاتِ وَالْأَرْضَ كَانَتَا رَتْقًا فَفَتَقْنَاهُمَا дигән сүз белән игълан итте. Димәк, Коръән иңгәннән 1100 еллар соң гына фән кабул итте. Вә шулай ук Коръән Кәрим иңгән заманда планеталар да алмашыну, үзгәрү кануны буенча хәрәкәт итү белән бу хәлгә планета хәленә килеп ирешуне бер төрле дә әсас тәгълим юк иде. [...]

سَبْعَ سَمَوَاتٍ طِبَاقاً дигән аятьнең Саблуков тәрҗемәсе: «Тот, кто сотворил семь небес поставив одна над другими сводами». Бигрәк истихза белән тәрҗемә иткән, шул тәрҗемәне татарчага тәрҗемә итсәк: «Теге, кем яратты җиде күкләрне бере өстенә берсен куполларга куйды».

Хакыйкый тәрҗемә: «Ул Аллаһ җиде планетаны бере-беренә өртеп яратты» ягъни һәркайсы планета бере-береннән өртелгән, һәркайсының чикләнгән

орбитасы барлыгын белдерде.

## Җир хакында Коръәннең нәзары

Җир нәрсәдән вөҗүдкә килмештер. Коръән Кәримнең мәгълүмат бирүенә күрә, җир шул ук югарыда булган хәлдән вөҗүдкә килмештер, ягъни һаман шул оешкан хәлдән аерылып вөҗүдкә килмештер. Моңа дәлил Коръән Кәрим «әл-Әнбия», 30: أَوَلَمْ يرَ الَّذِينَ كَفَرُوا أَنَّ السَّمَاوَاتِ وَالْأَرْضَ كَانَتَا رَتْقًا فَفَتَقْنَاهُمَا Җир югарыдагы хәлдән аерылганнан соң ни хәлдә булды? Югарыда сөйләнгәнчә, җир югарыдагы булган урыннан аерылган бер җөзьедер, ягъни бер кисәктер. Коръән белән тасдыйкъты́р. [...]

Коръән Кәрим нәзарында җирнең югары урыннан аерылу вакытына кадәр, ут хәлендә булуы ошбу аять белән тасдыйк ителәдер. «әр-Рәхман», 15: وَخَلَقَ الْجَانَّ مِن مَّارِجٍ مِّن نَّارٍ Аллаһ Тәбарәкә вә Тәгалә җанны ут җөмләсеннән булган утынсыз ялкыннан башлап яратты. Бу сыйфатта Коръән Кәримнең галәме инсан яратылышы күп кенә сүрәләрдә белдерелгәндер. Вә шуның белән бәрәбәр галәме инсанда булган җирдә җан исемендә акыллы мәхлукатлар яратылуыны ачып бирәдер (مِن مَّارِجٍ).

«әл-Хәҗәр», 27: وَالْجَانَّ خَلَقْنَاهُ مِن قَبْلُ مِن نَّارِ السَّمُومِ, ягъни «Инсаннан алда агулы ут дәверендә башлап җанны яраттык». Шулук «әл-Хәҗәр», 26: وَلَقَدْ خَلَقْنَا الْإِنسَانَ مِن صَلْصَالٍ مِّنْ حَمَإٍ مَّسْنُونٍ Җирнең туфрак өзелү гөлен дәверендә инсанны яратканны мәгълүм иткән соңында, 27нче аять белән, галәм инсаннан әүвәл, җирнең агулы ут булган дәвереннән алда, җанның яралтылуы хакында хәбәр бирәдер. Шушы ике аять җирдә булган хилкать[1] булуына бинаән җирнең ут дәвере соңында ун чыгып торуы аңлашыладыр. Коръән Кәрим шуның өчен беренчесен مَّارِجٍ, икенчесен نَّارِ السَّمُومِ дип исемлидер. Бу аятьнең изахына бинаән, адәм туфрактан яралтылмагандыр, бәлки, җирнең туфрак хәленә килгән вакытында яралтылгандыр, ягъни җир файдаланырлык булгач адәм яралтылгандыр. Шушы җирнең ут дәвереннән соң кабык булуы башланадыр. Коръән нәзарында җиргә кабык булуы җиргә ерак булган югарылыкта салкын җир башланып, шул салкынлык җирнең тышкы катламын кабыкны хасыйл иткәндер. «Нур», 43: وَيُنَزِّلُ مِنَ السَّمَاءِ مِن جِبَالٍ فِيهَا مِن بَرَدٍ Аллаһ индерәдер: «Югарылыкта булган таулардан болытлардан боз таулары хасил буладыр».

1. Хилкать – яралтылыш.

Моның изахы: Аллаһ Җәллә Җәләлә бу аятьнең әүвәлендә أَلَمْ تَرَ أَنَّ اللَّهَ يُزْجِي سَحَابًا ثُمَّ يُؤَلِّفُ بَيْنَهُ ثُمَّ يَجْعَلُهُ رُكَامًا فَتَرَى الْوَدْقَ يَخْرُجُ مِنْ خِلَالِهِ дип болытларны нинди юл белән хасил булуын, яңгыр болытлары кайсы дәрәҗәдә вә нинди хәлдә булуны һәм, яңгыр болытлары ни кадәр югары күтәрелсә, боз хасил булуны белдерәдер. Димәк, югарыга җирдән ни-кадәр ерак китсә, шул-кадәр салкынлык каты буладыр. Димәк, җирнең салкынлык белән кабыклары ката башламый торып, җирдә тереклек башламагандыр.

Җирдә катламнар хасил булуы: әлбәттә, бер юлы кабык хасил булмаган, бәлки йомшаклык белән катламнар түшәлә башлагандыр. Бу турыда Коръән аятьләре күптер һәм төрле хәлдә бәян итәдер. «әл-Бакарә», 22: الَّذِي جَعَلَ لَكُمُ الْأَرْضَ فِرَاشًا, ягъни «Җирне сезгә файдаланырга муафыйк итеп түшәдек». «әл-Бакарә», 21: يَا أَيُّهَا النَّاسُ اعْبُدُوا رَبَّكُمُ. Моннан аңларга кирәк, җир адәмнәргә файдаланырлык хәлгә килгәч اعْبُدُوا رَبَّكُمُ дип итагать итүгә боергандыр. «әз-Зәррият», 48: وَالْأَرْضَ فَرَشْنَاهَا فَنِعْمَ الْمَاهِدُونَ. «Та һа», 53: الَّذِي جَعَلَ لَكُمُ الْأَرْضَ مَهْدًا. Ул Аллаһ шундый заттыр: җирне, сезнең файдагыз өчен, мәнфәгатьле итеп төшерде. «Нух», 19: وَاللَّهُ جَعَلَ لَكُمُ الْأَرْضَ بِسَاطًا, ягъни «Җирне, сезнең мәнфәгатегез өчен ярарлык хәлдә, түшәк хәленә китердек». Димәк, җирдә кабык хасил булып, адәм балаларының файдасына ярарлык булган хәлдә тереклек башланмыштыр.

## Җирнең селкетүе, калтыравы

Коръән Кәрим нәзарында, җирдә катламнар түшәлмеш вакытында ук калтырау, селкенү кеби дәверләр уздыргандыр. Моңа дәлил, «ән-Нәхел», 15: وَأَلْقَىٰ فِي الْأَرْضِ رَوَاسِيَ أَن تَمِيدَ بِكُمْ, ягъни «Җирнең өстенә зур таулар куйдык, тетрәмәсен өчен». «ән-Нәба», 6-7:

أَلَمْ نَجْعَلِ الْأَرْضَ مِهَادًا ﴿٦﴾ وَالْجِبَالَ أَوْتَادًا﴿٧﴾

Бу турыда аятьләр чиксез күптер.

Җир югары булган чиремнән аерылгач, бер ут хәлендә булуы сөйләнде. Инде җирдә салкынлык хасил булгач, җирдә эсселек бетүе, ягъни ут хәленнән тышкы ягы капланды, кабык хасил булды. Җирнең тарафларыннан ихата итеп, төрле диңгезләр җиргә керә башлады. Шул диңгез сулары кайнар хәлгә килеп, югары күтәрелә башлады. Коръәннең وَالسَّمَآءِ ذَاتِ الرَّجْعِ канунынча, тәкрар җиргә төшеп, дәрьяләр хасил буладыр. Шул сулар җиргә үтеп, җир эчендәге утка якынлашып, шул җирнең капкаларына чыгып, зилзилә хасил буладыр.

Моңа шәһит – Коръән аятьләре:

**إِذَا زُلْزِلَتِ الْأَرْضُ زِلْزَالَهَا ﴿١﴾ وَأَخْرَجَتِ الْأَرْضُ أَثْقَالَهَا ﴿٢﴾ وَقَالَ الْإِنسَانُ مَا لَهَا ﴿٣﴾**

Коръән нәзарында җирдә зилзилә булуга манигъ, ягъни зилзилә һәрвакыт булып торудан саклау өчен, Аллаһ Тәбарәкә хосусый Коръән аяте буенча (**رَوَاسِيَ**) дип ителә. Бу **رَوَاسِيَ** икегә бүленәдер: җирнең тыш кабыгына мөхәккәм беркетелгән, ныгытылган мәддәләр. Моңа дәлил Коръәндә гаять күптер. Җөмләдән «әр-Рәгыд», 3: **وَهُوَ الَّذِي مَدَّ الْأَرْضَ وَجَعَلَ فِيهَا رَوَاسِيَ وَأَنْهَارًا** «Ул җир өстенә таулар, чишмәләр төзеде».

# [Ислам динендә хатын-кыз]

Хатын-кызларга багышланган аятьләр Коръәне Кәримдә гаять күптер. 130 аять хассәтән булып, моннан башка да төрле әмре мәгъруф вә тәнһа мөнкәр булган аятьләрнең хөкеме гамь булып, Аллаһның әмере бәни адәм дип, килгән хөкемнәр ир вә хатынга бәрабәр булып, аерым хатыннар хакында, алар берлән мөгамәлә хакында аятьләр күптер. Язылачак мәкаләм хатыннарга багышланган аятьләрдән булып, һәр сүрә вә аять ачык күрсәтелеп язылыр, иншәАллаһ.

Моны язудан максатым: Коръәне Кәримнең тәрҗемәләре гаять чуалчык. Бәлки күп хата-актардан гыйбарәт булып, халык арасында шулар шәригать хөкеме булып яшәп килгән, хәзер дә бигрәк халык дин турында мәгълүматы булмагач, суга батарга якын булган кешенең саламга тотынып караганы кеби, шул ярамый торган гадәтне шәригать дип гамәл кылмактадыр. Ләкин бу эшләр гаять куркыныч, мөкаддәс динебезнең башыннан истиһза буладыр. Бәрабер аятьләргә таянырга көчле материал буладыр.

Бәлки минем бу Коръән аятьне игътибар итеп, хосусый хатыннарга багланган аятьләрне изах (=аңлатма) кылдым, бәлки истикъбаль игътибар ителеп, Коръән Кәримнең бу хикмәтләр китап иттекне аңлаучылар булыр һәм гамәлгә куелыр. Коръән Кәримнең тагы да бер мөһим мәсъәләсен аңларлар дип өмет итәм, чөнки җәнаб Рабб әл-галәмин و لتعلمن نباة بعده حين аятьне җирдә юкка индермәгәндер дигән зур таянычларга таянып, ошбу мәкаләмне язарга шоругъ[1] иттем. Җәнаб Рабб әл-галәмин дә رب يسر ولا تعسر وسهل علينا يا رب و تمم بالخير дигән догаларда калам. Аллаһ Тәбарәкә вә Тәгаләнең бу догаларымны кабул итүенә нык ышанам, әлхәмдүли-Лаһ.

Әл-хафиз Каләмуллаһ әл-хаж әл-хәрәмәйн сабикъ әл-мөфти әл-ислам Эчке Русия һәм Сибирия мөселманнарының Дinduния Нәзарәтендә хезмәт күрсәткән бер шәех дип игътибар ителде. Габделбари хәзрәт бине Низаметдин әл-Гайсави Исаев. 1983 ел.

Әгүзү би-Ллаһи мин әш-шәйтан әр-рәҗим. Бисмил-Лаһир-рәхманир-рахим.

Беренче бүлек. Хатын-кызлар ирләр берлән бәрабәр булып, бөтен әмре мәгърүфләр: «Йә бәни адәм!», - дип килгәннәр.

Аллаһның рәхмәт-мәрхәмәте бәрабәр килгәндер вә шулай ук Аллаһның җәза хөкме дә бәрабәрдер. Аллаһ Рабб әл-галәмин يا أيها الناس дип әмер

1. Шоругъ итү – башлау.

итәдер. Бу хөкем – ир вә хатынга, бөтен бәни бәшәргә әмердер.

Әстәгыйзу би-Аллаһ, сүрә «әл-Бакарә», 21: يَا أَيُّهَا النَّاسُ اعْبُدُوا رَبَّكُمُ الَّذِي خَلَقَكُمْ وَالَّذِينَ مِن قَبْلِكُمْ لَعَلَّكُمْ تَتَّقُونَ «Бәндәчелекне белдерү - бөтенебезгә гамьдер. Әй Адәм балалары, Аллаһка гына гыйбадәт кылыгыз! Ул Аллаһ сезләрне хәлык кылучыдыр һәм сездән алдагыларын да хәлык кылучыдыр. Тәхкыйкъ, мөттәкыйннәр җөмләсеннән булырсыз, ягъни газаптан котылучы булырсыз диməктер. Адәм баласын бу аять кәримә уйглатадыр, тәфәккер кылуга дәгъват итәдер. Адәм баласы үзенең яратылышын тәфәккер кылып һәм бу сыйфатлар, дөнья хәлык кылынганнан башлап ничә миллион еллар узса да, һичбер алышынмый, яңартылмый – дәвам итәдер. Бу бер ялгыз Аллаһ көчедер. Аллаһның кодрәтедер. Ошбуның өчен үзен Аллаһның бәндәсе, габде итеп тану ләзем табыладыр. Гакыл дөрес йөртелгәндә, бу үз-үзеннән Аллаһка түбәнчелекне белдерүне мәҗбүр итәдер.

Лә Иләһә иллә Аллаһ каләме тайибәсен чын күңеленнән әйтүгә ләзем итәдер. Һәр гакыл сахибе ихтыярсыз Аллаһны тәгъриф кылу өчен үз хәлыкәтен тану ләземдер. من عرف نفسه فقد عرفه ربه

Дәхи дә «Бакарә» сүрәсенең 35нче аяте бу инде ир вә хатынга бәрабер хөкем иттекне ачыктан-ачык белдерәдер: و قلنا يا آدام اسكن انت و زوجك الجنة و كلا منها رغداً حيث شيئتما و لا تقربا هذه الشجرة فتكون من الظالمين Аллаһ: «Әй Адәм», - дип әмер итәдер, ягъни бу урындагы адәмгә хас әмер итүе аңлатадыр. الرجال قوامون علي النساء аятьнең ачык рәвештә قوامون علي النساء ягъни ирләргә беренче әмер булып, хатыннарга – табигътыр.

Безләр адәмгә: «Үзең һәм хатының җәннәттә торыгызлар, күңелегез теләгән һәрнәрсәне ашагызлар, ләкин Аллаһ сезләргә әйтәдер һәм сезләрне уйлатадыр, тәнбиһ итәдер: «Ошбу агачка якын килмәгез, үзләрегезгә золымлык кылучы булырсызлар», – дип әйттек. Моннан максат: әгәр дә адәм баласы Аллаһ кушмаган нәрсәгә тотынмаса, һичбер мәшәкатькә эләкмәс иде, һәрвакыт җәннәттә калыр иде, мәшәкать чикмәс иде. Ягъни адәм баласының нәфсен тыя алмавы – үз-үзенә золымлык итү буладыр. Ягъни ир вә хатын нәфескә хуҗа була алмаса, үз-үзенә зарар итәдер. Хөкем – гамьдер. Моның соңында, ягъни Аллаһның боерганы тотмау, гөнаһ кылу булгач, әлбәттә, бу гөнаһтан котылу юлын эзләү ләзем буладыр. Аллаһка ялвару, дога кылу, сорау – ир вә хатынга бәрабәр буладыр. Бу һәм Ходаның ир вә хатынга тигез каравыдыр.

«Бәкарә» сүрәсе 128нче аять: رَبَّنَا وَاجْعَلْنَا مُسْلِمَيْنِ لَكَ وَمِن ذُرِّيَّتِنَا أُمَّةً مُّسْلِمَةً لَّكَ وَأَرِنَا مَنَاسِكَنَا وَتُبْ عَلَيْنَا ۖ إِنَّكَ أَنتَ التَّوَّابُ الرَّحِيمُ «Әй безнең Раббымыз Аллаһ, Син

безләрне үзеңә буйсынучы мөселманнардан кыл һәм бездән соңгы нәселләребезне дә мөселманнардан кыл. Безләргә өйрәт, торачак урыннарыбызны безнең, һөнәргә кайтачакмыз, шуның өчен гөнаһларыбыздан тәүбә итәмез. Син - тәүбәләрне кабул итүче, гөнаһларымызны кичерүче бөек мәрхәмәт ияседер». Бу урында да ир вә хатынга дога һәм тәүбәләр гамьдер. Бу кеби әмерләрдә гаять Аллаһның хөкеме ир вә хатынга бәрабәр күктер. Бәгъзе бер хөкеме гамь аятьләрне күрсәтеп китәм. Намаз, зәкәт, руза, гомумән, бәни әл-ислам булган таләпләр гамьдер. اقيمو الصلوة و اتو الزكوة و اركعوا مع الراكعين فاسجلوا و سبحوا ليلا طويلا فاذكروا لله ذكرا كثيرا و عبدو ربكم و اتكحوا кеби вә шулай ук җәһәннәмгә хөкем җәннәткә хөкем дә гамьдер.

و اسبق الذين كفروا الي جهنم زمره و سبق الذين استوا الي الجنة زمره кеби аятьләр, мисаллар күптер.

Ислам нигезләрендә җәмгыять булып яшәү әмер ителгәндер. Җәмгыять булу өчен ир вә хатын булу шарттыр. Ошбуның өчен, Аллаһ тарафыннан никах әмер ителгәндер. Никахлану өчен бертөрле диндә булу ләзем куелгандыр, чөнки никах дөнья көтү өчен, эшләр күбәйтү өчен саф, пакь булган, үз женестә шик булган хәлдә, ир диндә булган хәлдә боерылгандыр. Әгәр дә ислам динендәге адәмнәр ислам динендәге кеше берлән никахланса, бу инде шәригать канунына әсасләнеп, гаһд вәгъдә булып, бу турыда нәсел-кардәшлеккә нык игътибар иteләдер, ягъни мәхрәм кардәш, намәхрәм кардәшкә игътибар ителәдер. Бу инде киләчәк буыннарда саф, хәләл булган нәселеннән булып, адәмчелек саклауга, нәсел саклануга хезмәт итәдер.

Һәрбер саф бәрабәр, хыянәтсез сакланган никах Аллаһ хозурында изге гамәлләрдән булып, йәүме кыямәт Аллаһ хозурында гөнаһтан пакь ир вә хатын бер-беренә ярдәмче-шәфәгатьче булачактыр. Нитак, җәнаб Рабб әл-галәмин: ادخلوا الجنة و انتم و ازدنكم تحبون , - дип, шатлык белдерәдер. Ошбуның өчен никахта зур игътибар, зур эшләр бардыр.

Аллаһ Җәллә Җәләләдә ошбуның өчен «Тур» сүрәсендә, 32нче аятьтә و انكحوا الايمي نمكم و الصالحين من عبادكم و امائكم ان يكونوا فقراء يعنيهم الله من فضلا و الله واسع عليم Сезләр ирсез хатыннардан тугры булган, Аллаһка гыйбадәт кылучы хатыннарга вә шулай ук ... салихән булганнарына габидән булганнарына никахланыгыз, фәкыйрь булсагыз, бай булырсыз. Аллаһның фазыйләте берлән бай булырсыз. Аллаһның киң байлыгы насыйп булыр. Аллаһ һәрнәрсәне

дә белүчедер. Бу урындагы байлык мал җиһәтеннән булган кеби, иман игътикад гыйбадәт байлыгы да игътибар ителгәндер. Салихән-габидән хатын яки ир һәрвакытта яхшылыкка, тугрылыкка тартадыр. Ошбуның өчен Аллаһ Тәбарәкә вә Тәгалә ислам галәмне башка дин әһелен никахланудан вәгазь-нәсыйхәт юлы берлән мәнгы итәдер. Түбәндәге аятьтә ул ачык белдерелгән:

«Бакарә», 221: وَلَا تَنْكِحُوا الْمُشْرِكَاتِ حَتَّىٰ يُؤْمِنَّ ۚ وَلَأَمَةٌ مُؤْمِنَةٌ خَيْرٌ مِنْ مُشْرِكَةٍ وَلَوْ أَعْجَبَتْكُمْ ۗ وَلَا تُنْكِحُوا الْمُشْرِكِينَ حَتَّىٰ يُؤْمِنُوا ۚ وَلَعَبْدٌ مُؤْمِنٌ خَيْرٌ مِنْ مُشْرِكٍ وَلَوْ أَعْجَبَكُمْ ۗ أُولَٰئِكَ يَدْعُونَ إِلَى النَّارِ ۖ وَاللَّهُ يَدْعُو إِلَى الْجَنَّةِ وَالْمَغْفِرَةِ بِإِذْنِهِ ۖ وَيُبَيِّنُ آيَاتِهِ لِلنَّاسِ لَعَلَّهُمْ يَتَذَكَّرُونَ ягъни Аллаһ Раббел-галәмин бу аяте кәримә берлән башка дин әһеленә никахланудан саклануга боерадыр һәм бу аяте кәримәне үгет-нәсыйхәт иткәндер: «Сезләр, әй ирләр, башка дин әһеленә никахланмагыз, хәтта хакыйкый мөэмин булмый торып, сезне алар кызыктырса да, хәтерегездән чыкмасын, бер кол, хезмәтче булып йөрүче мөэмин хатын алардан артыграктыр. Шулай ук, әй хатыннар, сезләр дә башка дин әһеленә тормышка чыкмагыз, алар ислам динен кабул итми торып, гарчә сезне матурлык, байлык берлән кызыктырсалар да, хәтерегезгә нык алыгыз бер мөэмин булган фәкыйрьгә тормышка чыгуыгыз хәерледер. Алар сезне утка тартырлар, җәһәннәмгә җитәкләрләр. Аллаһ бит сезләрне җәннәткә чакыра, Аллаһ сезне гафу итергә чакыра. Бу аятьне Аллаһ Тәбарәкә вә Тәгалә бөтен адәм балаларына бәян итә, белдерәдер: «Бәлки сезләр үзләрегез аңлап, Аллаһның үгет-нәсыйхәтен тыңларсыз», - димәктер.

Хатыннарга бер генә никахлану ләзем табыладыр. Аллаһ Җәллә Җәлалә Коръән Кәримдә «Ниса» сүрәсендәге 3нче аятьтә ачып бирәдер: وَإِنْ خِفْتُمْ أَلَّا تُقْسِطُوا فِي الْيَتَامَىٰ فَانْكِحُوا مَا طَابَ لَكُمْ مِنَ النِّسَاءِ مَثْنَىٰ وَثُلَاثَ وَرُبَاعَ ۖ فَإِنْ خِفْتُمْ أَلَّا تَعْدِلُوا فَوَاحِدَةً أَوْ مَا مَلَكَتْ أَيْمَانُكُمْ ۚ ذَٰلِكَ أَدْنَىٰ أَلَّا تَعُولُوا Әгәр дә ятимнәр арасында гадәләт итә алмасагыз, сез хатыннардан хуш булганы берне, икене, өчне, дүртне никахланыгыз. Әгәр гадәләт итүгә көчегез җитмәсә, берне никахланыгыз. Бер хатынга да гадәләт итә алмасагыз, кизекне никахланыгыз. Бу инде бер хатын берлән чикләнергә әмердер. Бу урында дүрт хатын алуга әмер юктыр, чөнки Аллаһ Тәбарәкә вә Тәгалә хатыннар арасында гадәләт булмаячакны беләдер. Кием, торак, тамак бәрабәр булса да, хатыннарны һичкем тигез ярату булмас, бәлки яшьрәк хатынны ныграк ярату булып, гадәләт югаладыр. Шуның өчен бер берлән чикләнүгә әмер ителгәндер.

Ислам шаригате хатыннарда була торган вакытлы сырхаулар хакында ачыктан-ачык хатыннарны игътибар итәдер. Аятьләр ул сырхауларның мөддәтләрен күрсәтәдер һәм мондый хәлдә ирләргә катгый мангы итәдер.

«Бакарә», 222: وَيَسْأَلُونَكَ عَنِ الْمَحِيضِ ۖ قُلْ هُوَ أَذًى فَاعْتَزِلُوا النِّسَاءَ فِي الْمَحِيضِ ۖ وَلَا تَقْرَبُوهُنَّ حَتَّىٰ يَطْهُرْنَ ۖ فَإِذَا تَطَهَّرْنَ فَأْتُوهُنَّ مِنْ حَيْثُ أَمَرَكُمُ اللَّهُ ۚ إِنَّ اللَّهَ يُحِبُّ التَّوَّابِينَ وَيُحِبُّ الْمُتَطَهِّرِينَ Ягъни хәез вакытында, хатыннарның авыр хәлдә булуларына игътибар итеп, бу аятьне иңдергәндер: «Хатыннар хәез турында синнән сорасалар, и Мөхәммәд, син аларга мәгълүм аять аңлат. Ул – хатыннарда була торган бер авырудыр. Сез инде, хатыннарыгыз мондый хәлдә вакытта, якынлык кылмагыз, хәтта пакьләнми торып. Инде пакьләнсәләр, Аллаһ кушкан буенча якынлык итегез. Аллаһ бит тәүбә итүчеләрне, пакьләнүчеләрне сөядер». Пакьләнгәннән соң, хатыннар белән катнашу шәригатьтә рөхсәт ителәдер.

«Бакарә», 223: نِسَاؤُكُمْ حَرْثٌ لَّكُمْ فَأْتُوا حَرْثَكُمْ أَنَّىٰ شِئْتُمْ ۖ وَقَدِّمُوا لِأَنفُسِكُمْ ۚ وَاتَّقُوا اللَّهَ وَاعْلَمُوا أَنَّكُم مُّلَاقُوهُ ۗ وَبَشِّرِ الْمُؤْمِنِينَ «Хатыннарыгыз – сезнең мисле иген игә торган урыныгыздыр. Теләсәгез ничек файдаланыгыз, ләкин нәфесне артык җибәрмәгез. Башка урынны файдаланудан сакланыгыз. Аллаһтан куркучы булыгыз. Хәтерегездән чыгармагыз: Аллаһка юлыгачакбыз. «Мөэминнәргә сөенеч бир», – дип Аллаһ әмер итте. Бу һәм хатыннар белән яхшы мөгамәләдә булу, аларны рәнҗетмәүгә әмердер. Күрем вакытында, бәгъзе берәүләр башка урынны булса да файдаланудан саклану өчен, катгый әмердер. Аллаһ Тәбарәкә, ир белән хатын бертигез булып, хатыннар белән уйнау ярамаганны аңлатадыр, чөнки кыямәт көн сорау булачактыр».

«Ән-Ниса» сүрәсе беренче аять белдерәдер: يَا أَيُّهَا النَّاسُ اتَّقُوا رَبَّكُمُ الَّذِي خَلَقَكُم مِّن نَّفْسٍ وَاحِدَةٍ وَخَلَقَ مِنْهَا زَوْجَهَا وَبَثَّ مِنْهُمَا رِجَالًا كَثِيرًا وَنِسَاءً ۚ وَاتَّقُوا اللَّهَ الَّذِي تَسَاءَلُونَ بِهِ وَالْأَرْحَامَ ۚ إِنَّ اللَّهَ كَانَ عَلَيْكُمْ رَقِيبًا «И адәмнәр, бу хөкем бөтен бәни бәшәргә хастыр. Аллаһтан нык сакланыгыз. Ул Аллаһ шундый Аллаһтыр, сезләрне бер нәфестән барлыкка китерде һәм шул нәфесләрдә хатыннарны хәлык кылды. Бу ике җенестән, ир белән хатыннан, ирләрне күбрәк кылды. Ул Аллаһтан нык куркыгыз, ул Аллаһ һәрбер нәрсәне исеме белән сорар. Сезләр дә кардәшләрегезне дә ригая кылыгыз. Ул Аллаһ – һәрбер гамәлләрдә тикшерүчедер».

Талак бабында. «Бакарә», 226: لِّلَّذِينَ يُؤْلُونَ مِن نِّسَائِهِمْ تَرَبُّصُ أَرْبَعَةِ أَشْهُرٍ ۖ فَإِن فَاءُوا فَإِنَّ اللَّهَ غَفُورٌ رَّحِيمٌ «Шундый бәндәләр хатыннары белән җимагъ (якынлык) кылмаска ант итәдер. Мондый хәлдә дүрт ай сабыр итәргә тиештер. Моннан соң җимагъ кылырга мөмкин, ләкин кәффарәт[1] ләземдер».

1. Кәффарәт – гөнаһтан арыну.

«Бакарә», 227: وَإِنْ عَزَمُوا الطَّلَاقَ فَإِنَّ اللَّهَ سَمِيعٌ عَلِيمٌ «Шул ямин (ант итү – ред.) афәт вакытында дүрт ай эчендә, җимагъ кылмый, талак теләсәгез, дүрт ай үтү белән, хатын аерылган буладыр».

«Бакарә», 228: وَالْمُطَلَّقَاتُ يَتَرَبَّصْنَ بِأَنفُسِهِنَّ ثَلَاثَةَ قُرُوءٍ ۚ وَلَا يَحِلُّ لَهُنَّ أَن يَكْتُمْنَ مَا خَلَقَ اللَّهُ فِي أَرْحَامِهِنَّ إِن كُنَّ يُؤْمِنَّ بِاللَّهِ وَالْيَوْمِ الْآخِرِ ۚ وَبُعُولَتُهُنَّ أَحَقُّ بِرَدِّهِنَّ فِي ذَٰلِكَ إِنْ أَرَادُوا إِصْلَاحًا ۚ وَلَهُنَّ مِثْلُ الَّذِي عَلَيْهِنَّ بِالْمَعْرُوفِ ۚ وَلِلرِّجَالِ عَلَيْهِنَّ دَرَجَةٌ ۗ وَاللَّهُ عَزِيزٌ حَكِيمٌ «Талак кылынмыш хатыннар, пакь булган хәлдә, шул талак соңында өч хифз булганны көтәләр, гадәти өч хифыздыр. Ләкин эчендә бала булса, баланы яшерү хәләл түгелдер, ягъни дөрес түгелдер. Әгәр Аллаһка, ахирәткә ышансалар, ягъни хифыз күрә торып яки йөкле эчендә баласы булуын яшерергә тиеш түгелдер. Ул хатынның үз ирләре, шушы өч хифыз арасында кайтып, җимагъ кылырга тиешле. Әгәр дә яңадан яхшы тереклек кылуны теләсәләр. Хатыннарның ирләре өстендә хакы бардыр, ирләрнең хатыннарда булган хакы кеби. Әлбәттә, Аллаһ әмер кылган рәвештә. Димәк, ир белән хатынның шәригатьчә гомер итүләре ләземдер. Әмма дәрәҗә җәһәтеннән ирнең дәрәҗәсе хатыннарныкыннан артыктыр. Аллаһ һәр эшне мәслихәтчә кылуга кушадыр».

«Бакарә», 229: الطَّلَاقُ مَرَّتَانِ ۖ فَإِمْسَاكٌ بِمَعْرُوفٍ أَوْ تَسْرِيحٌ بِإِحْسَانٍ ۗ وَلَا يَحِلُّ لَكُمْ أَن تَأْخُذُوا مِمَّا آتَيْتُمُوهُنَّ شَيْئًا إِلَّا أَن يَخَافَا أَلَّا يُقِيمَا حُدُودَ اللَّهِ ۖ فَإِنْ خِفْتُمْ أَلَّا يُقِيمَا حُدُودَ اللَّهِ فَلَا جُنَاحَ عَلَيْهِمَا فِيمَا افْتَدَتْ بِهِ ۗ تِلْكَ حُدُودُ اللَّهِ فَلَا تَعْتَدُوهَا ۚ وَمَن يَتَعَدَّ حُدُودَ اللَّهِ فَأُولَٰئِكَ هُمُ الظَّالِمُونَ Бу – Ходайның билгеләнгән чигедер. Аннан узу залимлек буладыр. Тәрҗемә: «Шул гыйддәт эчендә кайтып җимагъ кылмак. Дөрес булган талак – ике талактыр. Талак ражигый. Әмма өченче талак соңында кайту дөрес түгелдер. Димәк, ике талак соңында кайтса, шәригать буенча хатынны асрау тиешледер. Яки булмаса, ул хатынны изгелек кылмак белән җибәрергә тиештер. Шул вакыт эчендә гыйддәте тулганчы, шәригать буенча хатынга ләзем булган хакларны ир түләргә тиештер. Талак кылганыгыз өчен. Ул хатынга биргән мәһәрләрегездән һичнәрсә алу – ирләргә дөрес түгелдер, чөнки ул нәрсәләр – хатын хакы, ирләргә хәрәмдер. Әгәр ир белән хатын Аллаһның кушканнары җиренә җиткерә алмаудан курыксалар, ягъни ир белән хатын арасы төзек булмаса, хатынның аерыласы килсә, боларның мондый хәлдә һәр икесенә дә гөнаһ юктыр, ягъни хатын, үзен талак кылдыру өчен, иренә ирнең биргән малыннан шул мәһәрдән кыйсмән яки бөтенләй бирсә, хатын биргәнне алган өчен ире гөнаһлы түгелдер. Менә бу рәвешле хатынның иргә мал биреп аерылуы хәлге хәлегъ талак диеләдер. Бу инде Аллаһның хөкемнәренең чигедер. Бу чикләрдән үтмәгез! Әгәр берәү Аллаһның чигеннән узса, Аллаһның

әмеренә хилафлык кылса, бу – залимлектер».

Монда, ир аермаганда, хатын «үзем аерылдым» дисә, моның хөкеме язылыр.

«Бакарә», 230: فَإِن طَلَّقَهَا فَلَا تَحِلُّ لَهُ مِن بَعْدُ حَتَّىٰ تَنكِحَ زَوْجًا غَيْرَهُ ۗ فَإِن طَلَّقَهَا فَلَا جُنَاحَ عَلَيْهِمَا أَن يَتَرَاجَعَا إِن ظَنَّا أَن يُقِيمَا حُدُودَ اللَّهِ ۗ وَتِلْكَ حُدُودُ اللَّهِ يُبَيِّنُهَا لِقَوْمٍ يَعْلَمُونَ «Әгәр хатынны өч мәртәбә талак кылса, бу өч талак соңында ул хатын әүвәлге иренә хәрәм буладыр. Гыйддәт тулган соңында, икенче бер иргә никахланып, барып җимагъ кылганга кадәр ул икенче ир ул хатынны талак кылса, гыйддәт тулган соңында әүвәлге иренә кире баруда гөнаһ юктыр. Әгәр дә Аллаһның әмерен җиренә җиткерә алсалар, ошбу хөкем – Аллаһның шәригатендә чик белеп, гамәл кылучылар өчен».

«Бакарә», 231: وَإِذَا طَلَّقْتُمُ النِّسَاءَ فَبَلَغْنَ أَجَلَهُنَّ فَأَمْسِكُوهُنَّ بِمَعْرُوفٍ أَوْ سَرِّحُوهُنَّ بِمَعْرُوفٍ ۚ وَلَا تُمْسِكُوهُنَّ ضِرَارًا لِّتَعْتَدُوا ۚ وَمَن يَفْعَلْ ذَٰلِكَ فَقَدْ ظَلَمَ نَفْسَهُ ۚ وَلَا تَتَّخِذُوا آيَاتِ اللَّهِ هُزُوًا ۚ وَاذْكُرُوا نِعْمَتَ اللَّهِ عَلَيْكُمْ وَمَا أَنزَلَ عَلَيْكُم مِّنَ الْكِتَابِ وَالْحِكْمَةِ يَعِظُكُم بِهِ ۚ وَاتَّقُوا اللَّهَ وَاعْلَمُوا أَنَّ اللَّهَ بِكُلِّ شَيْءٍ عَلِيمٌ «Һәркайчан хатыннарыгызны талак кылсагыз, гыйддәтләре үтәргә якын булса, ул вакытта хатыннарыгызны шәригатьчә тотыгыз, ягъни катнашмагыз да, яхшы торыгыз яки шәригатьчә аларга ихтыяр бирегез, ягъни, гыйддәтләре үткәнчә, якын килмәгез. Инде кайтасыз икән, яхшы ният белән, тереклек кылу нияте белән кайтыгыз. Әмма хатыннарның гыйддәтләрен озайту нияте белән җимагъ кылгач, тагы талак кылсагыз, бу дөрес түгелдер. Әгәр мондый эш эшләсәгез, үзегезгә золымлык итүче буласыз һәм ахирәттә җәзасын күрәчәксез. Коръән хөкемнәрен җиңелгә санамагыз, Аллаһ сезгә биргән нигъмәтләрне хәтерегездә тотыгыз һәм сезгә иңдерелгән китап - Коръәнне яныгызда тотыгыз! Ул Коръәннең эчендә булган хөкемнәрне хәтерегездән чыгармагыз! Аллаһ ул Коръән белән вәгазь итәдер. Аллаһтан куркыгыз, Аллаһның хөкемнәренә хилафлык кылмагыз! Аллаһ Тәбарәкә һәрнәрсәне белүчедер».

«Бакарә», 232: وَإِذَا طَلَّقْتُمُ النِّسَاءَ فَبَلَغْنَ أَجَلَهُنَّ فَلَا تَعْضُلُوهُنَّ أَن يَنكِحْنَ أَزْوَاجَهُنَّ إِذَا تَرَاضَوْا بَيْنَهُم بِالْمَعْرُوفِ ۗ ذَٰلِكَ يُوعَظُ بِهِ مَن كَانَ مِنكُمْ يُؤْمِنُ بِاللَّهِ وَالْيَوْمِ الْآخِرِ ۗ ذَٰلِكُمْ أَزْكَىٰ لَكُمْ وَأَطْهَرُ ۗ وَاللَّهُ يَعْلَمُ وَأَنتُمْ لَا تَعْلَمُونَ «Кайчан хатыннарыгызны талак кылсагыз һәм аларның гыйддәтләре узса, ул хатыннарны әүвәлге иренә никахланудан мәнгы итмәгез, әгәр ир белән хатын шәригатьчә никахланырга риза булсалар. Менә шушы хөкем һәм шул хөкем белән боерылыр. Әгәр дә Аллаһка, ахирәт көненә иман китерсәгез, бу – Коръән хөкемедер. Аның белән гамәл итү сезнең өчен файдалыдыр, дәхи бозыклыктан пакьлектер. Аллаһ сез белмәгән файдалы эшне белдерәдер. Аллаһ ничек боерса, шуның белән гамәл

кылыгыз».

233нче аять бала тәрбия итүдә талакка баглангандыр. Бу аять махсус бала имезү турында: وَالْوَالِدَاتُ يُرْضِعْنَ أَوْلَادَهُنَّ حَوْلَيْنِ كَامِلَيْنِ ۖ لِمَنْ أَرَادَ أَن يُتِمَّ الرَّضَاعَةَ ۚ وَعَلَى الْمَوْلُودِ لَهُ رِزْقُهُنَّ وَكِسْوَتُهُنَّ بِالْمَعْرُوفِ ۚ لَا تُكَلَّفُ نَفْسٌ إِلَّا وُسْعَهَا ۚ لَا تُضَارَّ وَالِدَةٌ بِوَلَدِهَا وَلَا مَوْلُودٌ لَّهُ بِوَلَدِهِ ۚ وَعَلَى الْوَارِثِ مِثْلُ ذَٰلِكَ ۗ فَإِنْ أَرَادَا فِصَالًا عَن تَرَاضٍ مِّنْهُمَا وَتَشَاوُرٍ فَلَا جُنَاحَ عَلَيْهِمَا ۗ وَإِنْ أَرَدتُّمْ أَن تَسْتَرْضِعُوا أَوْلَادَكُمْ فَلَا جُنَاحَ عَلَيْكُمْ إِذَا سَلَّمْتُم مَّا آتَيْتُم بِالْمَعْرُوفِ ۗ وَاتَّقُوا اللَّهَ وَاعْلَمُوا أَنَّ اللَّهَ بِمَا تَعْمَلُونَ بَصِيرٌ «Балаларның ике ел имезүен камил итүне теләгән, бала тәрбияләгән аналарның ашавы һәм киемнәре – ата өстендәдер. Шәригатьчә, көче житкәнчә бала имезүчене тәрбия итәр. Һичкемгә көче житмәгән эш йөкләтелмидер. Әгәр дә ана баласын зарарлаудан курыкса, ана үзе разый була һәм үзенә дә зарар килмәслек булса, үзе тәрбия итәр, имезер. Әгәр бала башка хатыннан имсә, бу вакытта үз анасы: «Мин имезмимен», - димәсе. Әгәр анасы да үлсә, бу вакытта анның урынына калган вариска да зарар килерлек булмасын. Әгәр ата да, ана да баланы имезмәскә теләсәләр, һәр икесе риза булып, киңәш белән баланы аерсалар, аларга гөнаһ юктыр. Әгәр теләсәгез, баланы ят хатынга биреп имезүдә зарар юктыр, гөнаһ та юктыр, имезгән хакны шәригатьчә түләсәләр. Аллаһтан нык сакланыгыз. Аллаһ һәрбер эшләгән эшне үтә күрүчедер. Талак кылынган хатынның баласын анасы, теләсә, имезә, теләмәсә, имезми, гөнаһ юктыр».

234 аять: وَالَّذِينَ يُتَوَفَّوْنَ مِنكُمْ وَيَذَرُونَ أَزْوَاجًا يَتَرَبَّصْنَ بِأَنفُسِهِنَّ أَرْبَعَةَ أَشْهُرٍ وَعَشْرًا ۖ فَإِذَا بَلَغْنَ أَجَلَهُنَّ فَلَا جُنَاحَ عَلَيْكُمْ فِيمَا فَعَلْنَ فِي أَنفُسِهِنَّ بِالْمَعْرُوفِ ۗ وَاللَّهُ بِمَا تَعْمَلُونَ خَبِيرٌ «Сезләрдән бәгъзе берәүләрегез вафат булып, хатыннары калса, ул хатыннар дүрт ай, ун көн гыйддәтләрне көтәрләр. Гыйддәт – дүрт ай, ун көндер. Кайчан гыйддәтләре үтсә, бу вакытта кодалауда гөнаһ булмас, ул хатыннарга шәригать кушканча бизәнеп йөрүдә гөнаһ юктыр. Аллаһ сезнең һәр эшегездән хәбәрдардыр».

235нче аять: لَا جُنَاحَ عَلَيْكُمْ فِيمَا عَرَّضْتُم بِهِ مِنْ خِطْبَةِ النِّسَاءِ أَوْ أَكْنَنتُمْ فِي أَنفُسِكُمْ ۚ عَلِمَ اللَّهُ أَنَّكُمْ سَتَذْكُرُونَهُنَّ وَلَٰكِن لَّا تُوَاعِدُوهُنَّ سِرًّا إِلَّا أَن تَقُولُوا قَوْلًا مَّعْرُوفًا ۚ وَلَا تَعْزِمُوا عُقْدَةَ النِّكَاحِ حَتَّىٰ يَبْلُغَ الْكِتَابُ أَجَلَهُ ۚ وَاعْلَمُوا أَنَّ اللَّهَ يَعْلَمُ مَا فِي أَنفُسِكُمْ فَاحْذَرُوهُ ۚ وَاعْلَمُوا أَنَّ اللَّهَ غَفُورٌ حَلِيمٌ «Әгәр дә гыйддәт саклый торган хатынга яучы жибәрү турында белдерелсә, яхшылык белән, бу вакытта гөнаһ юктыр. Ул хатынга яучы жибәрергә уйласагыз да, гөнаһ юктыр. Сезнең яучы жибәрергә хәзер булганыгызны Аллаһ беләдер. Ләкин гыйддәт эчендә яучы жибәрүдән сакланыгыз. Шулай ук, ул гыйддәт эчендә булган хатын белән яшерен вәгъдә куеш-

магыз, ягъни никахлану өчен яки катнашу өчен, ягъни никах кылышмагыз, никахка кызыктырмагыз һәм кызыктырырдай сүз дә сөйләмәгез. Никах кылуны касд кылмагыз. Гыйддәт үткәнгә кадәр. Белегез, Аллаһ Сөбханә вә Тәгалә сезнең күңелдә булган уйларны беләдер. Аллаһ йомшак сыйфатлы, гафу итүчедер. Мондый хәлдә дә талак кылу булу ихтимал тотылып, Аллаһ Тәбарәкә ошбу кануннарны бәян итә».

236нчы аять: لَّا جُنَاحَ عَلَيْكُمْ إِن طَلَّقْتُمُ النِّسَاءَ مَا لَمْ تَمَسُّوهُنَّ أَوْ تَفْرِضُوا لَهُنَّ فَرِيضَةً ۚ وَمَتِّعُوهُنَّ عَلَى الْمُوسِعِ قَدَرُهُ وَعَلَى الْمُقْتِرِ قَدَرُهُ مَتَاعًا بِالْمَعْرُوفِ ۖ حَقًّا عَلَى الْمُحْسِنِينَ «Хатыннарны талак кылсагыз да, никах вакытында мәһәр билгеләнгән булмаса да, сезгә гөнаһ булмас. Ул хатынга бераз нәрсә бирегез. Моңа мәтагъ (متاع) дип әйтелер. Бай кеше булса, байлыкка карап мәтагъ бирү тиештер. Фәкыйрь кеше көче җиткән кадәр мәтагъ бирергә тиештер. Ягъни шул талак кылынмыш хатынны шәригать буенча файдаланырлык итү тиештер. Изге мөэминнәргә мәтагъ бирү важибтер. Бу якынлык кылмый, талак кылынса, хатынның бәһасен күтәрүдер. Хосусый хөрмәт итүдер, рәнҗүдән саклanудыр».

237нче аять إِن طَلَّقْتُمُوهُنَّ مِن قَبْلِ أَن تَمَسُّوهُنَّ وَقَدْ فَرَضْتُمْ لَهُنَّ فَرِيضَةً فَنِصْفُ مَا فَرَضْتُمْ إِلَّا أَن يَعْفُونَ أَوْ يَعْفُوَ الَّذِي بِيَدِهِ عُقْدَةُ النِّكَاحِ ۚ وَأَن تَعْفُوا أَقْرَبُ لِلتَّقْوَىٰ ۚ وَلَا تَنسَوُا الْفَضْلَ بَيْنَكُمْ ۚ إِنَّ اللَّهَ بِمَا تَعْمَلُونَ بَصِيرٌ «Әгәр һич катнашмый, хатыннарны талак кылсагыз, никах вакытында мәһәр билгеләнгән булса, мондый хәлдә аталган билгеләнгән мәһәрнең яртысы хатынга түләнер, әгәр дә хатын калган ярты мәһәрне гафу итсә. Ләкин гафу итешүегез тәкъвалырактыр, изге гамәлдер. Бер-берегезгә үзара мәрхәмәтле булыгыз. Аллаһ бит, ни эшләсәгез дә, белүчедер».

240нчы аять тол калган хатыннар хакында: وَالَّذِينَ يُتَوَفَّوْنَ مِنكُمْ وَيَذَرُونَ أَزْوَاجًا وَصِيَّةً لِّأَزْوَاجِهِم مَّتَاعًا إِلَى الْحَوْلِ غَيْرَ إِخْرَاجٍ ۚ فَإِنْ خَرَجْنَ فَلَا جُنَاحَ عَلَيْكُمْ فِي مَا فَعَلْنَ فِي أَنفُسِهِنَّ مِن مَّعْرُوفٍ ۗ وَاللَّهُ عَزِيزٌ حَكِيمٌ «Сездән бәгъзеләрегез үлсә, хатыннары калса, ул кеше сәламәт вакытында васыять итәргә тиешледер бер елга җитәрлек нәфәка кебек нәрсәгезне. Мәетнең варислары ул хатынны квартирдан чыгармасыннар. Әгәр ул хатын үз ихтыяры белән чыкса, ул хатыннарның үзләре теләп чыккан өчен, бу вакытта варисларга гөнаһ булмас. Шәригать эшләрендә Аллаһка муафыйк гамәл итегез».

Тагын мәһәр турында. «Ән-Ниса», 4нче аять: وَآتُوا النِّسَاءَ صَدُقَاتِهِنَّ نِحْلَةً ۚ فَإِن طِبْنَ لَكُمْ عَن شَيْءٍ مِّنْهُ نَفْسًا فَكُلُوهُ هَنِيئًا مَّرِيئًا «И вәлиләр, ягъни мәһәрне өстенә алган кешеләр, хатыннарыгызга мәһәрне үз ихтыярыгыз белән бирегез. Әгәр хатыннар күңелләреннән разый булып, мәһәрләреннән дә сезгә бирәр нәрсә

бирсәләр, ул нәрсәне ашагыз, ахыры хәерле булыр, шифа булыр». هَنِيئًا مَّرِيئًا дән максат – хатын биргән малдан бал сатып алып, шул балны яңгыр суы белән юып эчсәң, шифа булыр.

«Ән-Ниса», 127нче аять: وَيَسْتَفْتُونَكَ فِي النِّسَاءِ ۖ قُلِ اللَّهُ يُفْتِيكُمْ فِيهِنَّ وَمَا يُتْلَىٰ عَلَيْكُمْ فِي الْكِتَابِ فِي يَتَامَى النِّسَاءِ اللَّاتِي لَا تُؤْتُونَهُنَّ مَا كُتِبَ لَهُنَّ وَتَرْغَبُونَ أَن تَنكِحُوهُنَّ وَالْمُسْتَضْعَفِينَ مِنَ الْوِلْدَانِ وَأَن تَقُومُوا لِلْيَتَامَىٰ بِالْقِسْطِ ۚ وَمَا تَفْعَلُوا مِنْ خَيْرٍ فَإِنَّ اللَّهَ كَانَ بِهِ عَلِيمًا «И Мөхәммәт, синнән хатыннарның мирасы хакында сорарлар. Син аларга әйт: «Аллаһы Тәгалә хатыннарның мирасы хакында фәтва бирәдер. Һәм Коръәндә укылмыш аятьләр фәтва бирәдер. Хатыннарның ятиме турында: шундый хатыннар сез аларга фарыз өлешләрен бирмисез, ул хатыннарны никахланудан гарыз кыласыз.[1] Диндә зәгыйфь балалар турында: аларга мирастан башка да хакларын бирү белән Коръән боерадыр».

Коръән Кәримдә аерым «Талак» сүрәсе бардыр. Моның күбрәк хөкеме Пәйгамбәргә хастыр, ләкин бәгъзе бер хөкемнәре гамм[2] да буладыр. Пәйгамбәргә – хитаб, мөэминнәргә – әмердер. «Талак» сүрәсе, 1нче аять: يَا أَيُّهَا النَّبِيُّ إِذَا طَلَّقْتُمُ النِّسَاءَ فَطَلِّقُوهُنَّ لِعِدَّتِهِنَّ وَأَحْصُوا الْعِدَّةَ ۖ وَاتَّقُوا اللَّهَ رَبَّكُمْ ۖ لَا تُخْرِجُوهُنَّ مِن بُيُوتِهِنَّ وَلَا يَخْرُجْنَ إِلَّا أَن يَأْتِينَ بِفَاحِشَةٍ مُّبَيِّنَةٍ ۚ وَتِلْكَ حُدُودُ اللَّهِ ۚ وَمَن يَتَعَدَّ حُدُودَ اللَّهِ فَقَدْ ظَلَمَ نَفْسَهُ ۚ لَا تَدْرِي لَعَلَّ اللَّهَ يُحْدِثُ بَعْدَ ذَٰلِكَ أَمْرًا Менә бу аять гаммдер: «И пәйгамбәр, әгәр хатыннарыгызны талак кылсагыз, әгәр дә аңа иҗмагъ кылмаган вакытта талак кылсагыз яки гыйддәтләре эчендә талак кылсагыз, шул гыйддәт вакытында туйдыру һәм йортында торгызу хакында тавыш чыкмасын. Аллаһтан куркыгыз! Аллаһның әмерләрен бу турыда гамәлгә куегыз. Ул хатыннарны тора торган йортыннан чыгармагыз! Ул хатыннар үзләре дә чыкмасыннар. Гыйддәтләре тулганчы шул өйдә торсыннар. Әгәр ул хатыннар ачык рәвештә шәригатькә ярамас эш эшләсә, ягъни шул гыйддәт эчендә зарар китерсә яки зина кылсалар, ул вакытта шул гөнаһына җәза кылу өчен, сугу өчен чыгарылыр».

Талак хакында шушы күрсәтелгәннәр – Аллаһ хөкеменең чигедер. Бер кеше бу чиктән узса, бу инде үз-үзенә зөлмәт кылучы буладыр. Һичкем белмидер, Аллаһ Тәбарәкә вә Тәгалә шул гыйддәт эчендә ирнең күңеленә мәхәббәт төшеп, бәлки хатынына кайтыр. Ул хатыннарны кысмагыз, рәнҗетмәгез. Аларның тора торган җирләрен тарайтып, аларны чыгарга мәҗбүр итмәгез! Аларны

1. Гарыз кылу – каршы тору, юл куймау.

2. Гамм – гади халык.

ашатыгыз, киемнәр бирегез, хәтта бала тудырганга кадәр. Әгәр ул хатыннар шул торган баласын имезсә, имезгән өчен хакны түләп барыгыз. Бер-берегез белән шәригатьчә булган киңәшне кабул кылыгыз (ягъни талак кылынган хатын булса да), аерган хатын тудырган баланы имезергә авырса яки имезергә разый булмаса, бу вакытта ир, бала имезү өчен, икенче, сөт анасы яллар. Бай кеше байлыгы кадәр талак кылынган хатынына бала имезгән өчен иркен, киңрәк иттифак итсен. Фәкыйрь кеше, көче җиткәнчә, инфак итәр.[1] Аллаһы Тәгалә һәрнәрсә өчен чик куйды.

4нче аять: وَاللَّائِي يَئِسْنَ مِنَ الْمَحِيضِ مِن نِّسَائِكُمْ إِنِ ارْتَبْتُمْ فَعِدَّتُهُنَّ ثَلَاثَةُ أَشْهُرٍ وَاللَّائِي لَمْ يَحِضْنَ ۚ وَأُولَاتُ الْأَحْمَالِ أَجَلُهُنَّ أَن يَضَعْنَ حَمْلَهُنَّ ۚ وَمَن يَتَّقِ اللَّهَ يَجْعَل لَّهُ مِنْ أَمْرِهِ يُسْرًا «Картлык сәбәпле күрем күрүдән туктаган хатыннар сезләр аның хакында шик тотсагыз яки яшь булып та күрем күрми торган кызларны ирләр аерса, гыйддәтләре өч айдыр. Йөкле, корсаклы хатыннарның мөддәтләре – бала тудырганчыдыр. Бер хатын Аллаһтан курыкса, булган баланы, ягъни корсакка узганын яшермәсә, аның бар эшендә Аллаһ җиңеллек бирәдер.

5нче аять: ذَٰلِكَ أَمْرُ اللَّهِ أَنزَلَهُ إِلَيْكُمْ ۚ وَمَن يَتَّقِ اللَّهَ يُكَفِّرْ عَنْهُ سَيِّئَاتِهِ وَيُعْظِمْ لَهُ أَجْرًا «Бу – Аллаһның хөкемедер. Аллаһ ул хөкемне сезләр өчен иңдерде. Бер кеше, Аллаһтан куркып, талак хакындагы хөкемнәрне гамәлгә ирештерсә, Аллаһ аның гөнаһларын каплар һәм аның савабын күбәйтер».

Никахны боза торган эшләр хакында Коръән аятьләре:

«Ән-Ниса», 34: الرِّجَالُ قَوَّامُونَ عَلَى النِّسَاءِ بِمَا فَضَّلَ اللَّهُ بَعْضَهُمْ عَلَىٰ بَعْضٍ وَبِمَا أَنفَقُوا مِنْ أَمْوَالِهِمْ ۚ فَالصَّالِحَاتُ قَانِتَاتٌ حَافِظَاتٌ لِّلْغَيْبِ بِمَا حَفِظَ اللَّهُ ۚ وَاللَّاتِي تَخَافُونَ نُشُوزَهُنَّ فَعِظُوهُنَّ وَاهْجُرُوهُنَّ فِي الْمَضَاجِعِ وَاضْرِبُوهُنَّ ۖ فَإِنْ أَطَعْنَكُمْ فَلَا تَبْغُوا عَلَيْهِنَّ سَبِيلًا ۗ إِنَّ اللَّهَ كَانَ عَلِيًّا كَبِيرًا «Ирләр хатыннарга әдәп өйрәтү өчен өстендер, каимдер. Аллаһ бәгъзеләрне бәгъзеләрдән артык кылды. Ирләр хатыннарга караганда акыллырактыр. Изге хатыннар шундый хатыннардыр, Аллаһка һәм ирләренә итагать итәләр, ирләре яннарында булмаганда да, үзләрен һәм малларын саклыйлар. Нитәк, Аллаһ аларны үзе саклыйдыр. Шундый хатыннар, ул хатыннарның яшерен гөнаһларын белсәгез, аларга Аллаһның газабын сөйләп үгет-нәсыйхәт итегез. Әгәр дә алар үгет-нәсыйхәтне тыңламасалар, аларның янында ятмагыз. Әгәр дә тыңламасалар, үгет-нәсыйхәткә игътибар итмәсәләр, сугыгыз, ләкин җәрәхәт кылырдай сукмагыз. Гөнаһларыннан тәүбә итеп, сезгә итагать кылсалар, әүвәлге гөнаһлары белән шелтәләмәгез. Аллаһ – олугтыр, гөнаһларны

1. Инфак итү – тотып бетерү, сарыф итү.

кичерүчедер».

35нче аять: وَإِنْ خِفْتُمْ شِقَاقَ بَيْنِهِمَا فَابْعَثُوا حَكَمًا مِّنْ أَهْلِهِ وَحَكَمًا مِّنْ أَهْلِهَا إِن يُرِيدَا إِصْلَاحًا يُوَفِّقِ اللَّهُ بَيْنَهُمَا ۗ إِنَّ اللَّهَ كَانَ عَلِيمًا خَبِيرًا «Әгәр дә ир белән хатын арасында низаг чыгудан курыксагыз, ирнең якыннарыннан бер кешене хаким итеп җибәрегез, хатын тарафыннан да берне хаким җибәрегез. Әгәр дә бу ике кеше ислах теләсәләр, ир белән хатын арасына Аллаһ иттифак салыр. Дөреслектә ул Аллаһ – белүчедер, һәр эштә хәбәре бардыр».

75нче аять, бу аять фәкать хатыннарны коткару өчен әмердер. Бу һәм хатыннарны ригаядер, хатыннарга хөрмәттер: وَمَا لَكُمْ لَا تُقَاتِلُونَ فِي سَبِيلِ اللَّهِ وَالْمُسْتَضْعَفِينَ مِنَ الرِّجَالِ وَالنِّسَاءِ وَالْوِلْدَانِ الَّذِينَ يَقُولُونَ رَبَّنَا أَخْرِجْنَا مِنْ هَٰذِهِ الْقَرْيَةِ الظَّالِمِ أَهْلُهَا وَاجْعَل لَّنَا مِن لَّدُنكَ وَلِيًّا وَاجْعَل لَّنَا مِن لَّدُنكَ نَصِيرًا «И мөэминнәр, сезгә ни булды? Ник Аллаһ юлында сугыш кылмыйсыз, Мәккәдә калган зәгыйфь ирләр-хатыннар вә балаларны кәферләрдән коткармыйсыз? Ул зәгыйфьләрегез: «Бөтен халыкны безгә золым итә торган кариядән безне чыгар, йә Рабб, син безгә рәхмәтең белән вәли кыл, рәхмәтең белән насарат бир», - дип дога кыладыр.

«Исра», 32: وَلَا تَقْرَبُوا الزِّنَىٰ ۖ إِنَّهُ كَانَ فَاحِشَةً وَسَاءَ سَبِيلًا «Бозыклыкка, ягъни зинага якын бармагыз, ул – бик фахишәлек һәм юлларның иң бозыгыдыр».

«Әл-Мөэминун», 5-6: وَالَّذِينَ هُمْ لِفُرُوجِهِمْ حَافِظُونَ ﴿٥﴾ إِلَّا عَلَىٰ أَزْوَاجِهِمْ أَوْ مَا مَلَكَتْ أَيْمَانُهُمْ فَإِنَّهُمْ غَيْرُ مَلُومِينَ ﴿٦﴾ «Тагын шундый адәмнәр гаурәт урыннарын саклarлар. Мәгәр үз хатыннары алдында, никахланмыш кешеләре алдында һәм үзләре мөлекләгән кәнизәкләре алдында сакламасалар, моның өчен җәза кылынмаслар».

«Ән-Нур», 2: الزَّانِيَةُ وَالزَّانِي فَاجْلِدُوا كُلَّ وَاحِدٍ مِّنْهُمَا مِائَةَ جَلْدَةٍ ۖ وَلَا تَأْخُذْكُم بِهِمَا رَأْفَةٌ فِي دِينِ اللَّهِ إِن كُنتُمْ تُؤْمِنُونَ بِاللَّهِ وَالْيَوْمِ الْآخِرِ ۖ وَلْيَشْهَدْ عَذَابَهُمَا طَائِفَةٌ مِّنَ الْمُؤْمِنِينَ «Зина кылучы хатын, зина кылучы ир, әгәр өйләнмәгән булсалар, һәр икесенә йөзәр камчы сугарга кирәк, суккан вакытта мәрхәмәт-шәфкатьле булу кирәкмидер. Әгәр дә сез Аллаһка, кыямәт көнгә иман китерсәгез, бу – дини хөкемдер. Аларны сукканда кеше алдында сугарга тиешледер».

«Ән-Нур», 3: الزَّانِي لَا يَنكِحُ إِلَّا زَانِيَةً أَوْ مُشْرِكَةً وَالزَّانِيَةُ لَا يَنكِحُهَا إِلَّا زَانٍ أَوْ مُشْرِكٌ ۚ وَحُرِّمَ ذَٰلِكَ عَلَى الْمُؤْمِنِينَ «Зина кылучы ир зина кылучы хатынга никахланыр яки мөшрикәгә никахланыр. Шулай ук, зина кылучы хатын зина кылучы иргә яки мөшрикккә никахланыр. Болар – мөэминнәргә хәрәмдер».

4нче аять: وَالَّذِينَ يَرْمُونَ الْمُحْصَنَاتِ ثُمَّ لَمْ يَأْتُوا بِأَرْبَعَةِ شُهَدَاءَ فَاجْلِدُوهُمْ ثَمَانِينَ

جَلْدَةً وَلَا تَقْبَلُوا لَهُمْ شَهَادَةً أَبَدًا ۚ وَأُولَٰئِكَ هُمُ الْفَاسِقُونَ «Бер кеше пакь кешене зиначы дип атаса, дүрт шәһит тота алмаса, шул кешегә сиксән камчы сугарга боерылган. Ялган шаһадәт бирүченең шаһадәте кабул ителми, бәлки бу ялган кешеләрне фасикъ диеләдер».

5нче аять: إِلَّا الَّذِينَ تَابُوا مِن بَعْدِ ذَٰلِكَ وَأَصْلَحُوا فَإِنَّ اللَّهَ غَفُورٌ رَّحِيمٌ «Әгәр дә шул ялган шаһадәтләреннән тәүбә итсәләр, яхшылык кылсалар, Аллаһ гафу итәдер».

6нчы аять: وَالَّذِينَ يَرْمُونَ أَزْوَاجَهُمْ وَلَمْ يَكُن لَّهُمْ شُهَدَاءُ إِلَّا أَنفُسُهُمْ فَشَهَادَةُ أَحَدِهِمْ أَرْبَعُ شَهَادَاتٍ بِاللَّهِ ۙ إِنَّهُ لَمِنَ الصَّادِقِينَ «Шундый ир хатынын зиначы дип әйтсә, шаһидләр булмаса, бу сүзне әйткәндә үзе генә булса, аларның һәрберсе дүрт мәртәбә шаһадәт бирергә тиеш, бишенче шаһадәтендә ир әйтер: «Аллаһ белән ант, ул ир хатынны зиначы дип дөрес сүкте», - дип, бишенче шаһадәттә ул ир: «Аллаһның ләгънәте, зиначы дип әйтүчегә булсын», - дип әйтер.

7нче аять: وَالْخَامِسَةُ أَنَّ لَعْنَتَ اللَّهِ عَلَيْهِ إِن كَانَ مِنَ الْكَاذِبِينَ «Бишенче шаһадәттә ул ир әйтер: «Аллаһның ләгънәте зиначы дип сүгүчегә булсын, әгәр дә ул сүзендә ялганчылардан булса».

8нче аять: وَيَدْرَأُ عَنْهَا الْعَذَابَ أَن تَشْهَدَ أَرْبَعَ شَهَادَاتٍ بِاللَّهِ ۙ إِنَّهُ لَمِنَ الْكَاذِبِينَ «Бу хәлдә хатынга тиешле хәддләр сугалар, бетерәләр дә хатынга дүрт мәртәбә шаһадәт бирү тиешле буладыр: «Аллаһ белән ант итәмен, ирем мине зиначылар дип сүккәндә, ялганчылардан», - дип.

9нчы аять: وَالْخَامِسَةَ أَنَّ غَضَبَ اللَّهِ عَلَيْهَا إِن كَانَ مِنَ الصَّادِقِينَ «Хатын бишенче шаһадәтен дә бирәү ләзем табылып, Аллаһның ачуы ул хатынга булсын, әгәр ул иремне зиначы дип сүгүе дөрес булса».

10нчы аять: وَلَوْلَا فَضْلُ اللَّهِ عَلَيْكُمْ وَرَحْمَتُهُ وَأَنَّ اللَّهَ تَوَّابٌ حَكِيمٌ «Әгәр сезләргә Аллаһының фазыйләте булмаса иде, сезгә җәзаны ашыктырыр иде. Аллаһ – хикмәт иясе, тәүбәләрне кабул итүчедер».

12нче аять: لَّوْلَا إِذْ سَمِعْتُمُوهُ ظَنَّ الْمُؤْمِنُونَ وَالْمُؤْمِنَاتُ بِأَنفُسِهِمْ خَيْرًا وَقَالُوا هَٰذَا إِفْكٌ مُّبِينٌ «Бу мондый хәл арада күп хәзер дә Аллаһ Раббел-галәмин әйтәдер: «Сез ул начар хәбәрне ишеткәндә, нигә хөсне занн кылмадыгыз? Мөэмин ирләр, мөэмин хатыннар, бер-беренә хөсне зан кылган кебек, бу хәбәрне нигә ялган дип әйтмәдегез?» Димәк, бераү турында начар хәбәр ишеткәч: «Ә, ул шулайдыр», - дип, начарлыкны көчәйтергә кирәкми, бәлки чын мөэмин, чын мөэминәләргә: «Бу хәбәр дөрес түгел, ялган», - дию ләзем, әгәр дә шул начар хәбәрне тасдыйкъ итәрлек шаһитлар булмаса.

13нче аять моны тасдыйк итә: لَّوْلَا جَاءُوا عَلَيْهِ بِأَرْبَعَةِ شُهَدَاءَ ۚ فَإِذْ لَمْ يَأْتُوا بِالشُّهَدَاءِ فَأُولَٰئِكَ عِندَ اللَّهِ هُمُ الْكَاذِبُونَ «Ул яман фикердә булып сүгүчеләр дүрт шәһит китерсәләр иде. Әгәр алар дүрт шәһит китерә алмасалар, алар – Аллаһ хозурында ялганчылардыр». 24нче аять бу ялганчылар хакында ачып бирә: يَوْمَ تَشْهَدُ عَلَيْهِمْ أَلْسِنَتُهُمْ وَأَيْدِيهِمْ وَأَرْجُلُهُم بِمَا كَانُوا يَعْمَلُونَ «Ул ялган белән сүгүчеләрнең кыямәт көндә зарарына, дөньяда кылган явыз гамәлләре өчен, телләре, куллары, аяклары шаһәдәт бирер ».

25нче аять يَوْمَئِذٍ يُوَفِّيهِمُ اللَّهُ دِينَهُمُ الْحَقَّ وَيَعْلَمُونَ أَنَّ اللَّهَ هُوَ الْحَقُّ الْمُبِينُ «Аллаһы Тәгалә аларга тиешле җәзаларны бирер. Шунда белерләр үзләренең җәзаларын. Ул Аллаһның сыйфаты, ачык һәм тугрыдыр».

26нчы аять: الْخَبِيثَاتُ لِلْخَبِيثِينَ وَالْخَبِيثُونَ لِلْخَبِيثَاتِ ۖ وَالطَّيِّبَاتُ لِلطَّيِّبِينَ وَالطَّيِّبُونَ لِلطَّيِّبَاتِ ۚ أُولَٰئِكَ مُبَرَّءُونَ مِمَّا يَقُولُونَ ۖ لَهُم مَّغْفِرَةٌ وَرِزْقٌ كَرِيمٌ «Хатыннарның яман сүзләре – яман адәмнәр өчендер. Яхшы сүзле хатыннар яхшы адәмнәр өчен. Яхшы хатыннар алар сөйләгән яман сүзләрдән пакьтер. Алар өчен Аллаһның ярлыкавыдыр һәм киң ризыклардыр».

27нче аять: يَا أَيُّهَا الَّذِينَ آمَنُوا لَا تَدْخُلُوا بُيُوتًا غَيْرَ بُيُوتِكُمْ حَتَّىٰ تَسْتَأْنِسُوا وَتُسَلِّمُوا عَلَىٰ أَهْلِهَا ۚ ذَٰلِكُمْ خَيْرٌ لَّكُمْ لَعَلَّكُمْ تَذَكَّرُونَ «И мөэминнәр, йортларга кермәгез, ягъни башка кешеләр йортына, мәгәр хәбәр биреп, бәгъдә йорты әһеленә сәлам биреп керегез. Бу – сезнең өчен хәерле вәгазьдер».

28нче аять ир кеше булмаган йортларга керергә рөхсәт ителмәгәндер: فَإِن لَّمْ تَجِدُوا فِيهَا أَحَدًا فَلَا تَدْخُلُوهَا حَتَّىٰ يُؤْذَنَ لَكُمْ ۖ وَإِن قِيلَ لَكُمُ ارْجِعُوا فَارْجِعُوا ۖ هُوَ أَزْكَىٰ لَكُمْ ۚ وَاللَّهُ بِمَا تَعْمَلُونَ عَلِيمٌ «Ул йортта бер кем дә булмаса, рөхсәт булмый торып кермәгез, әгәр: «Керегез!» - дисәләр, керегез. Бу сезнең пакьлегегез өчендер. Аллаһ – бөтен эшләрне дә белүчедер. Һәр эштән хәбәре бардыр».

31нче аять: وَقُل لِّلْمُؤْمِنَاتِ يَغْضُضْنَ مِنْ أَبْصَارِهِنَّ وَيَحْفَظْنَ فُرُوجَهُنَّ وَلَا يُبْدِينَ زِينَتَهُنَّ إِلَّا مَا ظَهَرَ مِنْهَا ۖ وَلْيَضْرِبْنَ بِخُمُرِهِنَّ عَلَىٰ جُيُوبِهِنَّ ۖ وَلَا يُبْدِينَ زِينَتَهُنَّ إِلَّا لِبُعُولَتِهِنَّ أَوْ آبَائِهِنَّ أَوْ آبَاءِ بُعُولَتِهِنَّ أَوْ أَبْنَائِهِنَّ أَوْ أَبْنَاءِ بُعُولَتِهِنَّ أَوْ إِخْوَانِهِنَّ أَوْ بَنِي إِخْوَانِهِنَّ أَوْ بَنِي أَخَوَاتِهِنَّ أَوْ نِسَائِهِنَّ أَوْ مَا مَلَكَتْ أَيْمَانُهُنَّ أَوِ التَّابِعِينَ غَيْرِ أُولِي الْإِرْبَةِ مِنَ الرِّجَالِ أَوِ الطِّفْلِ الَّذِينَ لَمْ يَظْهَرُوا عَلَىٰ عَوْرَاتِ النِّسَاءِ ۖ وَلَا يَضْرِبْنَ بِأَرْجُلِهِنَّ لِيُعْلَمَ مَا يُخْفِينَ مِن زِينَتِهِنَّ ۚ وَتُوبُوا إِلَى اللَّهِ جَمِيعًا أَيُّهَ الْمُؤْمِنُونَ لَعَلَّكُمْ تُفْلِحُونَ «Мөэмин хатыннарга әйт син, и Мөхәммәд: карарга дөрес булмаган нәрсәләрдән күзләрен йомсыннар, фәрҗләрен сакласыннар, кул белән йөздән башка зиннәт урыннарын ачмасыннар, мәгәр зиннәт

урыннарның ачык булган җирләрен ачсалар ярыйдыйр – йөз, кул, аяклар. Башларын, муеннарын, күкрәкләрен пәрдәләр белән капласыннар. Дәхи зиннәт урыннары ачык булуы мөмкин – ирләре алдында, аталары алдында, ирләрнең аталары алдында, үзләренең кардәшләре алдында, кардәшләренең балаларына кыз туганнарының балаларына, мөэмин хатыннарга, хатынның үз милкендә булган кол яки кәнизәкләренә. Кендек белән тезгә кадәр урында башка урынга сүләкләрнең каравы дөрес. Ашау өчен генә үзләрен ияргәннәр алдында да дөрес. Сабыйлар алдында. Болар да хатын туйгысы булмыйдыр. Хатыннар аякларны берен беренә куймасыннар. Яшергән зиннәт урыннары беленсен өчен. И мөэминнәр, Аллаһка тәүбә итегез, кайтыгыз, дөнья-ахирәт сәгадәткә ирешерсез».

32нче аять: وَأَنكِحُوا الْأَيَامَىٰ مِنكُمْ وَالصَّالِحِينَ مِنْ عِبَادِكُمْ وَإِمَائِكُمْ ۚ إِن يَكُونُوا فُقَرَاءَ يُغْنِهِمُ اللَّهُ مِن فَضْلِهِ ۗ وَاللَّهُ وَاسِعٌ عَلِيمٌ «Сез ирсез хатыннардан изге, тугры булган хатыннардан һәм коллар-кизәкләрдән фәкыйрь булмасагыз, бай булырсыз. Аллаһ кулында байлык киндер».

33 нче аять: وَلْيَسْتَعْفِفِ الَّذِينَ لَا يَجِدُونَ نِكَاحًا حَتَّىٰ يُغْنِيَهُمُ اللَّهُ مِن فَضْلِهِ ۗ وَالَّذِينَ يَبْتَغُونَ الْكِتَابَ مِمَّا مَلَكَتْ أَيْمَانُكُمْ فَكَاتِبُوهُمْ إِنْ عَلِمْتُمْ فِيهِمْ خَيْرًا ۖ وَآتُوهُم مِّن مَّالِ اللَّهِ الَّذِي آتَاكُمْ ۚ وَلَا تُكْرِهُوا فَتَيَاتِكُمْ عَلَى الْبِغَاءِ إِنْ أَرَدْنَ تَحَصُّنًا لِّتَبْتَغُوا عَرَضَ الْحَيَاةِ الدُّنْيَا ۚ وَمَن يُكْرِههُّنَّ فَإِنَّ اللَّهَ مِن بَعْدِ إِكْرَاهِهِنَّ غَفُورٌ رَّحِيمٌ «Шуннан кешеләрнең никахлану өчен мәһәр түләргә көчләре җитмәсә, алар зинадан пакь торсыннар, Аллаһның фазыйләте булып, бай булганга кадәр. Кулыгызда булган кол яки кәнизәкләр сезләрдән мәкатиблекне теләсәләр, сез аларга мәкатиб кылыгыз, әгәр белсәгез аларда яхшылык барын. Шул сезләргә мәкатиб булганнарга Аллаһ биргән малларыгыздан ярдәм итегез, җарияләрегезне зинага көчләмәгез, әгәр алар зинадан саклануны теләсәләр. Әгәр берегез аларны зинага көчләсәгез, дөрес Аллаһ Тәбарәкә аларны – көчләнеп зина итүчеләрне ярлыкаячактыр һәм мәрхәмәт итәчәктер».

58нче аять: أَيُّهَا الَّذِينَ آمَنُوا لِيَسْتَأْذِنكُمُ الَّذِينَ مَلَكَتْ أَيْمَانُكُمْ وَالَّذِينَ لَمْ يَبْلُغُوا الْحُلُمَ مِنكُمْ ثَلَاثَ مَرَّاتٍ ۚ مِّن قَبْلِ صَلَاةِ الْفَجْرِ وَحِينَ تَضَعُونَ ثِيَابَكُم مِّنَ الظَّهِيرَةِ وَمِن بَعْدِ صَلَاةِ الْعِشَاءِ ۚ ثَلَاثُ عَوْرَاتٍ لَّكُمْ ۚ لَيْسَ عَلَيْكُمْ وَلَا عَلَيْهِمْ جُنَاحٌ بَعْدَهُنَّ ۚ طَوَّافُونَ عَلَيْكُم بَعْضُكُمْ عَلَىٰ بَعْضٍ ۚ كَذَٰلِكَ يُبَيِّنُ اللَّهُ لَكُمُ الْآيَاتِ ۗ وَاللَّهُ عَلِيمٌ حَكِيمٌ «И иман китергән адәмнәр, сезнең кулыгызда булган колларыгыз-кәнизәкләрегез өч вакытта сезнең янга керергә рөхсәт сорасыннар. Шулай ук, балигъ булмаган балаларыгыз да, иртә намазыннан элек – бу вакыт урында өст ачык булуы мөмкиндер. Кием алыш-

тыру вакыты булу мөмкиндер. Тагын да көндез – көн яртысыннан, ягъни өйлә вакытыннан соң, бу вакыт – һәм йоклау вакытыдыр. Тагын ясигъ намазыннан соң. Менә бу өч вакытта гаурәт урыннары ачык булу мөмкин. Бу өч вакыттан башка вакытта сез үзегез дә һәм башкалар да күрергә мөмкиндер. Коллар-кәнизәкләр һәм сезне зиярәт итәргә килүчеләр дә керергә мөмкиндер. Ошбуның белән Аллаһ сезләргә ачык мәгълүмат бирәдер. Бу – Аллаһның бер бөек галәмәтедер. Аллаһ бит хикмәт иясе һәм белүчедер.

60нчы аять: وَالْقَوَاعِدُ مِنَ النِّسَاءِ اللَّاتِي لَا يَرْجُونَ نِكَاحًا فَلَيْسَ عَلَيْهِنَّ جُنَاحٌ أَن يَضَعْنَ ثِيَابَهُنَّ غَيْرَ مُتَبَرِّجَاتٍ بِزِينَةٍ ۖ وَأَن يَسْتَعْفِفْنَ خَيْرٌ لَّهُنَّ ۗ وَاللَّهُ سَمِيعٌ عَلِيمٌ «Хатыннардан – бала тапмый торган, хәез күрми торган карчыклар иргә баруны теләмиләр. Аларга ирләр алдында бәгъзе бер каплый торган киемнәрен салуда гөнаһ юктыр. Зиннәт урыннарын ачмаулары тиештер. Әгәр капламыш урыннарын ачмасалар, алар өчен хәерлерәктер. Аллаһ аларның хәлен белер, максатларын ишетер».

61нче аять. Бу аять сугыш вакытларында ни рәвештә яшәү мөмкинлеге хакындадыр. Аллаһ Тәбарәкә вә Тәгалә авыр вакытларда да ниханы саклау һәм хатыннарны химая итеп бу аятьне иңдергәндер. Бу төрле хәл булганда да кирәкле канундыр: لَّيْسَ عَلَى الْأَعْمَىٰ حَرَجٌ وَلَا عَلَى الْأَعْرَجِ حَرَجٌ وَلَا عَلَى الْمَرِيضِ حَرَجٌ وَلَا عَلَىٰ أَنفُسِكُمْ أَن تَأْكُلُوا مِن بُيُوتِكُمْ أَوْ بُيُوتِ آبَائِكُمْ أَوْ بُيُوتِ أُمَّهَاتِكُمْ أَوْ بُيُوتِ إِخْوَانِكُمْ أَوْ بُيُوتِ أَخَوَاتِكُمْ أَوْ بُيُوتِ أَعْمَامِكُمْ أَوْ بُيُوتِ عَمَّاتِكُمْ أَوْ بُيُوتِ أَخْوَالِكُمْ أَوْ بُيُوتِ خَالَاتِكُمْ أَوْ مَا مَلَكْتُم مَّفَاتِحَهُ أَوْ صَدِيقِكُمْ ۚ لَيْسَ عَلَيْكُمْ جُنَاحٌ أَن تَأْكُلُوا جَمِيعًا أَوْ أَشْتَاتًا ۚ فَإِذَا دَخَلْتُم بُيُوتًا فَسَلِّمُوا عَلَىٰ أَنفُسِكُمْ تَحِيَّةً مِّنْ عِندِ اللَّهِ مُبَارَكَةً طَيِّبَةً ۚ كَذَٰلِكَ يُبَيِّنُ اللَّهُ لَكُمُ الْآيَاتِ لَعَلَّكُمْ تَعْقِلُونَ «Сукырларга, аксакларга, башка авыруларга, дәхи үзегезгә сугышка чыкмаска мөмкин. Җыелышып яки аерым-аерым бу күрсәткән кешеләрнең хөҗрәсендә, үз йортларыгызда аталарыгыз-аналарыгызның үзегез белән бертуган ир кардәшләрегезнең вә кыз кардәшләрегезнең, ачкычларын сезгә ышанып калдырган якын дусларыгызның йортында – бу җирләрдә җыелып яки аерым ашауда гөнаһ юктыр. Әгәр ошбу өйләрнең берсенә керсәгез, аның әһеленә сәлам бирегез. Аллаһтан сезләргә сәлам булган кеби, йорт хуҗаларына иркенле тормыш булып, хуш булырлар. Аллаһ Тәбарәкә вә Тәгалә сезләргә бу аятьләр белән ачык мәгълүм итәдер. Бәлки гакылларыгыз белән уйларсыз дип тәнбиһ кыладыр». Ирләре сугышта булган хатыннар яки озак сәфәрләрдә булган хатыннар теләсә кая барып ашап, эчеп, кунып йөрергә тиешле түгелдер. Бу – Аллаһның хөкемедер. Бу хөкемне бозу – зур гөнаһтыр һәм бозыклыкка тартадыр. Яки ят җирләргә чыгып ашап, эчеп йөрү яки кунып

калу зарури булганда да бик нык чикләнгәндер. Әгәр шул канунны бозып, үз ихтыяр йөрсәң, бу инде синең бу тормышыңда да бәхетсезлеккә тартып, йәүм кыямәт каты җәзага дучар булачаксың, дип Аллаһ Җәллә Җәләләгә һәрбер мөэминә булган хатыннарны һәм ирләрне бәхетсезлеккә дучар булудан саклау өчен әйткәндер.

«Әш-Шөгарә», 166: وَتَذَرُونَ مَا خَلَقَ لَكُمْ رَبُّكُم مِّنْ أَزْوَاجِكُم ۚ بَلْ أَنتُمْ قَوْمٌ عَادُونَ «Сезләр куясыз Раббыгыз Аллаһ сезнең өчен хәлк кылган хатыннарны, бәлки сезләр моның белән хәләлдән хәрәмгә үтүче кәвемнәрдән буласыз».

«Әл-Әхзаб», 4: مَّا جَعَلَ اللَّهُ لِرَجُلٍ مِّن قَلْبَيْنِ فِي جَوْفِهِ ۚ وَمَا جَعَلَ أَزْوَاجَكُمُ اللَّائِي تُظَاهِرُونَ مِنْهُنَّ أُمَّهَاتِكُمْ ۚ وَمَا جَعَلَ أَدْعِيَاءَكُمْ أَبْنَاءَكُمْ ۚ ذَٰلِكُمْ قَوْلُكُم بِأَفْوَاهِكُمْ ۖ وَاللَّهُ يَقُولُ الْحَقَّ وَهُوَ يَهْدِي السَّبِيلَ «Аллаһ Тәбарәкә бер ир өчен ике калеб-йөрәк кылмады һәм, шулай ук, хатыннарыгыздан да ике хәлилә кылмады. Кайсыдырыгыз ул хатыннарыгызга: «Син минем анама охшагансың», - дип әйтсә, ул хатыннарыгызны Аллаһ сезгә ана кылмады. Шулай ук, угыллыкка алып угыл дигән балаларыгыз сезгә сәлбия угыл булмады. Бу тик сезнең сүзләрегез генәдер. Авызыгыз белән әйткән сүз генәдер. Аллаһы Тәгалә хак булган сүзне әйтәдер һәм ул хак юлга күндерәдер».

«Әл-Әхзаб», 28-30нчы аятьләр. Дөрес, бу аятьләр Мөхәммәд пәйгамбәргә хасс булса да, мөселманнар өчен гаммдер: يَا أَيُّهَا النَّبِيُّ قُل لِّأَزْوَاجِكَ إِن كُنتُنَّ تُرِدْنَ الْحَيَاةَ الدُّنْيَا وَزِينَتَهَا فَتَعَالَيْنَ أُمَتِّعْكُنَّ وَأُسَرِّحْكُنَّ سَرَاحًا جَمِيلًا «И Мөхәммәд, хатыннарыңа: «Әгәр сез дөнья тереклегенә сорар булсагыз, дөнья зиннәтен генә теләсәгез, мин сезгә мәтагъ бирермен (мәтаг, җимагъ әйтмәгән), хатынга бер кат кием биреп, тыныч, сезгә зарар итми талак кылырмын», - дип әйт. Ислам динендә хатыннарга мәрхәмәтле булуны боергандыр».

29: وَإِن كُنتُنَّ تُرِدْنَ اللَّهَ وَرَسُولَهُ وَالدَّارَ الْآخِرَةَ فَإِنَّ اللَّهَ أَعَدَّ لِلْمُحْسِنَاتِ مِنكُنَّ أَجْرًا عَظِيمًا «Әгәр Аллаһ ризасы һәм Пәйгамбәр ризасы, ахирәтне теләсәгез, Аллаһ Тәбарәкә Аллаһка һәм Пәйгамбәргә итагать итүче кешеләргә әҗерләр хәзерләде». Менә моннан нык аңларга кирәк: Аллаһ әмеренә, Пәйгамбәрнең сөннәтенә итагать үз-үзен шәригать буенча тотканда табыладыр? Ошбуның өчен ир белән хатын арасында шәригать хөкемнәрен тузан кадәр дә алмашу ярамыйдыр. Ул бәндәләрне кыяматтә булачак әҗерләрдән мәхрүм итәдер.

29нчы аять Пәйгамбәр хатыннарына хас аятьтер, ләкин хөкеме гаммдер: يَا نِسَاءَ النَّبِيِّ مَن يَأْتِ مِنكُنَّ بِفَاحِشَةٍ مُّبَيِّنَةٍ يُضَاعَفْ لَهَا الْعَذَابُ ضِعْفَيْنِ ۚ وَكَانَ ذَٰلِكَ عَلَى اللَّهِ يَسِيرًا «И Пәйгамбәр хатыннары, әгәр дә сезләрдән берегез Пәйгамбәрнең

кәефен җибәрерлек бозыклык кылсагыз, ул хатынга башка хатыннарга караганда ике өлеш газап булачактыр. Бу эшне эшләү Аллаһ өчен җиңелдер».

«Әл-Әхзәб», 31: وَمَن يَقْنُتْ مِنكُنَّ لِلَّهِ وَرَسُولِهِ وَتَعْمَلْ صَالِحًا نُّؤْتِهَا أَجْرَهَا مَرَّتَيْنِ وَأَعْتَدْنَا لَهَا رِزْقًا كَرِيمًا «И хатыннар, әгәр дә берегез Аллаһка вә Пәйгамбәргә изгелек кылсагыз, моның әҗер-савабы башка хатыннарга караганда ике өлеш бирелер һәм алар өчен җәннәттә хөрмәт аерым булыр». Бу һәм ислам милләтенә хезмәт итүчеләрнең хатыннары өчен хасстыр, әгәр тугры хезмәт кылучы булса».

32нче аять хас Пәйгамбәр хатыннары хакында булып, хөкеме һәр хатыннарга гаммдер: يَا نِسَاءَ النَّبِيِّ لَسْتُنَّ كَأَحَدٍ مِّنَ النِّسَاءِ ۚ إِنِ اتَّقَيْتُنَّ فَلَا تَخْضَعْنَ بِالْقَوْلِ فَيَطْمَعَ الَّذِي فِي قَلْبِهِ مَرَضٌ وَقُلْنَ قَوْلًا مَّعْرُوفًا «И Пәйгамбәр хатыннары, сез башка хатыннар кебек түгелсез. Әгәр сез һәртөрле гөнаһтан сакланып Аллаһка һәм Пәйгамбәренә итагать итсәгез, дәрәҗәгез артыр. Шулай булгач, ят ирләргә тавышыгызны нечкәртеп йомшак җавап бирмәгез, йомшак сөйләшмәгез, аларның калебендә шәһвәт кузгалып, алар сездән өмет итәрләр. Ул яман фикергә тартыр, һәм сезне кызыктыру фикерендә булып, куркыныч гөнаһка мөбтәлә булырсыз. Дөньяда рисвай булып, кыямәт көн Аллаһының рәхмәтеннән мәхрүм калырсыз», - дип тәнбиһ итәдер.

33нче аять хатыннарның нинди тәртиптә булу турындадыр: وَقَرْنَ فِي بُيُوتِكُنَّ وَلَا تَبَرَّجْنَ تَبَرُّجَ الْجَاهِلِيَّةِ الْأُولَىٰ ۖ وَأَقِمْنَ الصَّلَاةَ وَآتِينَ الزَّكَاةَ وَأَطِعْنَ اللَّهَ وَرَسُولَهُ ۚ إِنَّمَا يُرِيدُ اللَّهُ لِيُذْهِبَ عَنكُمُ الرِّجْسَ أَهْلَ الْبَيْتِ وَيُطَهِّرَكُمْ تَطْهِيرًا «Өйләрегездә генә торырга тырышыгыз. Әлекке кебек гаурәт урыннарыгызны ирләргә белдермәгез. Намазларыгызны укыгыз, зәкәтләрегезне бирегез. Аллаһка һәм Аның Пәйгамбәренә итагать кылыгыз. Аллаһ сездән гөнаһларыгызны бетерүне телидер. Сезләрне кимчелекләрдән пакьләүне телидер». Менә бу аять - бик кирәкле аять. Беренче, әгәр бу аять белән вәгазь ителгәнче мондый ярамас сыйфат булса, Аллаһ Тәбарәкә ул эшне кую белән гөнаһларны гафу итүне белдерәдер. Хатыннарга күбрәк өйләрендә генә тору әҗерле идегене белдерәдер. Чыгып йөрү бик кирәкле булмаганда, хатыннарга мәсләхәт түгелдер идегене белдерәдер. Моның соңында ят ирләргә гаурәт урыннарын белдерүдән сакланырга кушадыр. Хатыннар брюка кисә, кыска күлмәк кисә, әлбәттә, бөтен җире беленеп торадыр. Бу инде зур гөнаһтыр. Моның соңында түшләрен күтәреп күрсәтеп, тар-кыска кием белән йөрсә, бу да ирләрне кызыктыру өчен, булып зур гөнаһтандыр. Болар өчен каты җәза булачактыр.

34нче аять: وَقَرْنَ فِي بُيُوتِكُنَّ وَلَا تَبَرَّجْنَ تَبَرُّجَ الْجَاهِلِيَّةِ الْأُولَىٰ ۖ وَأَقِمْنَ الصَّلَاةَ وَآتِينَ الزَّكَاةَ وَأَطِعْنَ اللَّهَ وَرَسُولَهُ ۚ إِنَّمَا يُرِيدُ اللَّهُ لِيُذْهِبَ عَنكُمُ الرِّجْسَ أَهْلَ الْبَيْتِ وَيُطَهِّرَكُمْ تَطْهِيرًا

«Йортларыгызда һәрвакыт укылган аятьләрне яд итегез, Пәйгамбәрнең һәр эшен, сөннәтләрен яд итегез. Моннан максат – Аллаһның биргән нигъмәтләренә шөкер кылыгыз. Сәламәтлек нигъмәте, тынычлык нигъмәте, Аллаһны яд итү нигъмәте, ягъни мөэмин булу нигъмәте, үзеңне саф саклау нигъмәте, Аллаһның биргән аш нигъмәтләре башкача бөтен әгъзаларга сәламәтлек китерә торган ир вә хатыннар арасында була торган нигъмәтләр шуларга разый булып тору кебиләр. Аллаһ Тәбарәкә вә Тәгалә хуш булган заттыр. Хуш булуны сөядер һәм бөтен эшләрдән ул хәбәрдардыр, ягъни һәр эштән хәбәре бардыр».

35нче аять: إِنَّ الْمُسْلِمِينَ وَالْمُسْلِمَاتِ وَالْمُؤْمِنِينَ وَالْمُؤْمِنَاتِ وَالْقَانِتِينَ وَالْقَانِتَاتِ وَالصَّادِقِينَ وَالصَّادِقَاتِ وَالصَّابِرِينَ وَالصَّابِرَاتِ وَالْخَاشِعِينَ وَالْخَاشِعَاتِ وَالْمُتَصَدِّقِينَ وَالْمُتَصَدِّقَاتِ وَالصَّائِمِينَ وَالصَّائِمَاتِ وَالْحَافِظِينَ فُرُوجَهُمْ وَالْحَافِظَاتِ وَالذَّاكِرِينَ اللَّهَ كَثِيرًا وَالذَّاكِرَاتِ أَعَدَّ اللَّهُ لَهُم مَّغْفِرَةً وَأَجْرًا عَظِيمًا «Ир вә хатыннан Аллаһка мөслим булучылар, ягъни чын мөслим шулдыр ки: бөтен әмерләрне җиренә җиткерүчеләр. Ир вә хатыннан – Аллаһка, Аллаһның барлыгына иман китерүчеләр, ир вә хатыннардан – Аллаһның хөкемнәренә таянып гамәл кылучылар, ир вә хатыннан – гамәлдә, сүздә дөрес туры булучылар. Ир вә хатыннан – Аллаһның боерганын гамәл итүдә вә гөнаһтан саклануга сабыр итүчеләр. Ир вә хатыннан – чын калебләре белән Аллаһка хошуг вә ходугъ илән гамәл кылучылар. Ир вә хатыннан – малларыннан садака чыгаручылар. Ир вә хатыннан – руза тотучылар. Ир вә хатыннан – фәрҗләрне хәрәм эштән саклаучылар. Ир вә хатыннан – Аллаһны күп зикер итүчеләр. Мондый сыйфатлы бәндәләргә Аллаһ Тәбарәкә гөнаһларны кичерү белән вәгъдә итә һәм һәр кылган изгелекләре бәрабәренә бөек әҗерләр вәгъдә итте».

36нчы аять: وَمَا كَانَ لِمُؤْمِنٍ وَلَا مُؤْمِنَةٍ إِذَا قَضَى اللَّهُ وَرَسُولُهُ أَمْرًا أَن يَكُونَ لَهُمُ الْخِيَرَةُ مِنْ أَمْرِهِمْ ۗ وَمَن يَعْصِ اللَّهَ وَرَسُولَهُ فَقَدْ ضَلَّ ضَلَالًا مُّبِينًا «Мөэмин ир вә мөэминә хатынга үз белдегечә кылырга дөрес түгелдер, Аллаһ һәм Аллаһның рәсүле бер эш белән хөкем кылса, шуны үз ихтыярлары белән хөкем итү дөрес түгелдер. Бәлки Аллаһның рәсүленә кушканы буенча гамәл итү ләземдер. Кем булса да Аллаһка, аның рәсүленә гөнаһ кылса, тәхкыйк, ул кеше - ачык рәвештә золымлык кылучыдыр, ягъни һәрбер эшнең шәригать кануны буенча эшләнү ләземдер».

37нче аять: وَإِذْ تَقُولُ لِلَّذِي أَنْعَمَ اللَّهُ عَلَيْهِ وَأَنْعَمْتَ عَلَيْهِ أَمْسِكْ عَلَيْكَ زَوْجَكَ وَاتَّقِ اللَّهَ وَتُخْفِي فِي نَفْسِكَ مَا اللَّهُ مُبْدِيهِ وَتَخْشَى النَّاسَ وَاللَّهُ أَحَقُّ أَن تَخْشَاهُ ۖ فَلَمَّا قَضَىٰ زَيْدٌ مِّنْهَا وَطَرًا زَوَّجْنَاكَهَا لِكَيْ لَا يَكُونَ عَلَى الْمُؤْمِنِينَ حَرَجٌ فِي أَزْوَاجِ أَدْعِيَائِهِمْ إِذَا قَضَوْا مِنْهُنَّ وَطَرًا ۚ وَكَانَ أَمْرُ اللَّهِ مَفْعُولًا Бу аять Рәсүлемезнең азат иткән Зәйд исемле колы

хакында иңде, ләкин хөкем гаммдер: «Шулвакыт зикер ит, и Мөхәммәд, Аллаһы Тәгалә ул кешене ислам дине белән нигъмәтләде һәм ул Зәед синең колың иде. Син аны азат иттең. Бу – зур нигъмәттер. Хатыныңны үзгә хатын итеп тот. Аны талак кылудан, Аллаһтан курык. Нәфсеңдә бернәрсәне яшерсәң дә, Аллаһ аны ачык итәчәктер. Адәмнәрдән куркасың, Зәеднең хатынын алдыр дип, фәлән кешенең хатын алдыр дип, сөйләрләр дип куркасың. Ләкин һичкемнең сөйләвеннән курыкма, Аллаһтан курык. Зәед ул хатынны, Зәйнәпне, тиешле хәлдә талак кылгач, без ул хатынны сиңа никахландырдык. Мөэминнәргә мәшәкать булмасын өчен, угылыкка алган балаларының хатыннарына да (ягъни угылыкка алган улының хатынын) никахлану дөрес, ягъни салби түгелдер. Әгәр дә алар хатыннардан талак кылсалар, Аллаһ бернәрсәне булдырырга теләсә, әлбәттә, буладыр».

«Әл-Мөҗәдәлә», 2нче аять: الَّذِينَ يُظَاهِرُونَ مِنكُم مِّن نِّسَائِهِم مَّا هُنَّ أُمَّهَاتِهِمْ ۖ إِنْ أُمَّهَاتُهُمْ إِلَّا اللَّائِي وَلَدْنَهُمْ ۚ وَإِنَّهُمْ لَيَقُولُونَ مُنكَرًا مِّنَ الْقَوْلِ وَزُورًا ۚ وَإِنَّ اللَّهَ لَعَفُوٌّ غَفُورٌ «Шундый ирләр хатыннардан аналарына охшатырлар. Ул хатыннар, хакыйкатьтә аналарыгыз булмыйдыр. Сезнең аналарыгыз сезне тудыргандыр. Болай охшатып әйтү – шәригатьтә мөнкәр эштер. Дөрес, бу сүз белән хатын талак булмас. Аллаһ - гафу итүче, ярлыкаучыдыр».

3нче аять: وَالَّذِينَ يُظَاهِرُونَ مِن نِّسَائِهِمْ ثُمَّ يَعُودُونَ لِمَا قَالُوا فَتَحْرِيرُ رَقَبَةٍ مِّن قَبْلِ أَن يَتَمَاسَّا ۚ ذَٰلِكُمْ تُوعَظُونَ بِهِ ۚ وَاللَّهُ بِمَا تَعْمَلُونَ خَبِيرٌ «Сезләрдән хатыннарын аналарына охшаткан кешеләр шул сүзләреннән үкенеп кайтсалар, әгәр хатыннарына якынлык кылырга теләсәләр, бер кол азат итү шарттыр. Хатынына катнашмастан кол азат итү кәффарәт өчендер, вәгазь өчендер. Ул Аллаһ – кылганыгызны белүчедер».

4нче аять: فَمَن لَّمْ يَجِدْ فَصِيَامُ شَهْرَيْنِ مُتَتَابِعَيْنِ مِن قَبْلِ أَن يَتَمَاسَّا ۖ فَمَن لَّمْ يَسْتَطِعْ فَإِطْعَامُ سِتِّينَ مِسْكِينًا ۚ ذَٰلِكَ لِتُؤْمِنُوا بِاللَّهِ وَرَسُولِهِ ۚ وَتِلْكَ حُدُودُ اللَّهِ ۗ وَلِلْكَافِرِينَ عَذَابٌ أَلِيمٌ «Әгәр азат итүгә кол булмаса, тоташтан ике ай ураза тотарга тиештер хатынына катнашканга кадәр. Әгәр ике ай ураза тотарга көче җитмәсә, алтмыш факыйрьне ашату ләземдер. Бу хөкем – Аллаһка һәм Рәсүлгә иман китерүегез өчендер. Бу – Аллаһның билгеләгән чигедер».

«Әт-Тәхрим», 10нчы аять: ضَرَبَ اللَّهُ مَثَلًا لِّلَّذِينَ كَفَرُوا امْرَأَتَ نُوحٍ وَامْرَأَتَ لُوطٍ ۖ كَانَتَا تَحْتَ عَبْدَيْنِ مِنْ عِبَادِنَا صَالِحَيْنِ فَخَانَتَاهُمَا فَلَمْ يُغْنِيَا عَنْهُمَا مِنَ اللَّهِ شَيْئًا وَقِيلَ ادْخُلَا النَّارَ مَعَ الدَّاخِلِينَ «Аллаһ Тәбарәкә вә Тәгалә моны мисал өчен зикер кыладыр. Аллаһка карышкан кешеләр – Нух пәйгамбәр хатыны, Лут пәйгамбәр хатыны. Бу ике хатын кулларының астында иде, һәр икесе безнең изге кулларыбыздан

иде. Бу ике хатын – Нух һәм Лут пәйгамбәр хатыннары хыянәт кылдылар. Бу ике хатынга пәйгамбәрләре булган Нух һәм Лут һичнәрсә җибәрмәделәр. Ул хатыннарга: «Утка керүчеләр белән утка керегез!» - дип әйтелер». Моннан аңларга кирәк, ирләренә хыянәт иткән хатыннарга пәйгамбәрләр дә ярдәм бирә алмый. Димәк, иргә хыянәт итүчегә – җәһәннәмдер. Мисал өчен, фиргавен хатыны турында Корьән белдерәдер: «әт-Тәхрим», 11 нче аять: ضَرَبَ اللَّهُ مَثَلًا لِّلَّذِينَ آمَنُوا امْرَأَتَ فِرْعَوْنَ إِذْ قَالَتْ رَبِّ ابْنِ لِي عِندَكَ بَيْتًا فِي الْجَنَّةِ وَنَجِّنِي مِن فِرْعَوْنَ وَعَمَلِهِ وَنَجِّنِي مِنَ الْقَوْمِ الظَّالِمِينَ «Аллаһ иман китергән кешеләргә искә төшерү өчен фиргавен хатынының кыйсасын зикер итәдер. Ул, фиргавен хатыны әйтте: «И Аллаһ, үз хозырыңда оҗмах эчендә миңа бер йортны бина кылсаң, мине фиргавеннән һәм аның гамәленнән коткар, дәхи мине залим булган фиргавен кавеменнән коткар», - дип мөнәҗәт кылды». Димәк, хатыннарга ирләренең иман юлында түгеллеген белеп, риза булып тору ярамыйдыр. Аллаһтан котылуны соравы ләземдер. Бу гаять мөһим. Бәгъзе бер хатыннар, никахтан куркып, риза булып торалар. Дәхи дә «әл-Мәсәд» сүрәсендә Әбү Ләһәб хатыны иренең ислам diненә дошманлыгыны теләп, халык арасында ислам диненең зарарына сүз йөртүе өчен, җәһәннәмгә, утыннар йөкләгән хәлдә кертелер: وَامْرَأَتُهُ حَمَّالَةَ الْحَطَبِ. Моннан аңларга кирәк, иренең яманлыгына риза булган хатын да җәһәннәм белән газап кылыныр.

Моннан соң, хатыннарның мәкере нинди хәлгә калдыруы турында язылыр. Хосусән, Йосыф пәйгамбәр хакында, «Йосыф», 23 аять: وَرَاوَدَتْهُ الَّتِي هُوَ فِي بَيْتِهَا عَن نَّفْسِهِ وَغَلَّقَتِ الْأَبْوَابَ وَقَالَتْ هَيْتَ لَكَ ۚ قَالَ مَعَاذَ اللَّهِ ۖ إِنَّهُ رَبِّي أَحْسَنَ مَثْوَايَ ۖ إِنَّهُ لَا يُفْلِحُ الظَّالِمُونَ «Вәзир хатыны, ялынып, Йосыфтан максат теләде, ишекләрне бикләде һәм әйтте: «И Йосыф, никадәр матур киемнәр кидем, барчасы синең өчен». Йосыф әйтте: «Аллаһ сакласын бу эштән. Хуҗам мине хөрмәт итсә, мин ул эшне эшләсәм, залимнәрдән булам. Залимнәр газаптан котыла алмаслар».

«Йосыф», 24нче аять: وَلَقَدْ هَمَّتْ بِهِ ۖ وَهَمَّ بِهَا لَوْلَا أَن رَّأَىٰ بُرْهَانَ رَبِّهِ ۚ كَذَٰلِكَ لِنَصْرِفَ عَنْهُ السُّوءَ وَالْفَحْشَاءَ ۚ إِنَّهُ مِنْ عِبَادِنَا الْمُخْلَصِينَ «Шулвакыт Зөләйха Йосыфны үзенә якынлык кылырга касд итте. Йосыф та Зөләйхага касд кылды, ләкин үтәмәде. Йосыф, әгәр Аллаһтан дәлил күрмәсә иде, әлбәттә, үтәр иде. Йосыфка шундый дәлилләр күрсәтәбез, Йосыфтан яман фикерләрне бетерү өчендер, чөнки ул Йосыф Безнең чын халис, ихлас бәндәбездән иде».

«Йосыф», 25нче аять: وَاسْتَبَقَا الْبَابَ وَقَدَّتْ قَمِيصَهُ مِن دُبُرٍ وَأَلْفَيَا سَيِّدَهَا لَدَى الْبَابِ ۚ قَالَتْ مَا جَزَاءُ مَنْ أَرَادَ بِأَهْلِكَ سُوءًا إِلَّا أَن يُسْجَنَ أَوْ عَذَابٌ أَلِيمٌ «Һәр икесе ишеккә

йөгерделәр. Йосыф Зөләйхадан котылу өчен, ә Зөләйха Йосыфны тоту өчен. Зөләйха Йосыфның күлмәгенең артыннан тотты, күлмәк ертылды. Йөгереп ишек янына килгәч, Зөләйханың иренә очрадылар. Зөләйха иренә: «Инде синең хатыныңа яманлык, начарлык кылырга теләгән кешене хәбескә ябарга кирәк яки каты җәза кылырга кирәк», - диде».

«Йосыф», 26нчы аять: قَالَ هِيَ رَاوَدَتْنِي عَن نَّفْسِي ۚ وَشَهِدَ شَاهِدٌ مِّنْ أَهْلِهَا إِن كَانَ قَمِيصُهُ قُدَّ مِن قُبُلٍ فَصَدَقَتْ وَهُوَ مِنَ الْكَاذِبِينَ «Йосыф: «Зөләйха минем якынлык кылуны үзе теләде», - дип әйтте. Моны дөресләп, бер сабый бала шаһәдәт бирде: «Әгәр Йосыф күлмәге алдан ертылган булса, Зөләйха сүзе – дөрес, Йосыф сүзе ялган буладыр».

«Йосыф», 27нче аять: وَإِن كَانَ قَمِيصُهُ قُدَّ مِن دُبُرٍ فَكَذَبَتْ وَهُوَ مِنَ الصَّادِقِينَ «Әгәр Йосыфның күлмәге арттан ертылган булса, бу вакыт Зөләйханың сүзе – ялган, Йосыфныкы дөрес буладыр».

«Йосыф», 28нче аять: فَلَمَّا رَأَىٰ قَمِيصَهُ قُدَّ مِن دُبُرٍ قَالَ إِنَّهُ مِن كَيْدِكُنَّ ۖ إِنَّ كَيْدَكُنَّ عَظِيمٌ «Зөләйханың ире Йосыфның күлмәге арттан җыртылганын күргәч: «Әлбәттә, бу сүз - үзен пакьләү өчен корылган мәкердер», - диде».

«Йосыф», 29нчы аять: يُوسُفُ أَعْرِضْ عَنْ هَٰذَا ۚ وَاسْتَغْفِرِي لِذَنبِكِ ۖ إِنَّكِ كُنتِ مِنَ الْخَاطِئِينَ «И Йосыф, бу сүзләрне халыкка белдермә. Зөләйха, син гөнаһларыңнан истигъфар ит. Тәхкыйк, син хата кылучылардан булдың», - диде ире».

«Йосыф», 30нчы аять: وَقَالَ نِسْوَةٌ فِي الْمَدِينَةِ امْرَأَتُ الْعَزِيزِ تُرَاوِدُ فَتَاهَا عَن نَّفْسِهِ ۖ قَدْ شَغَفَهَا حُبًّا ۖ إِنَّا لَنَرَاهَا فِي ضَلَالٍ مُّبِينٍ «Мисырдагы хатыннардан бер таифәсе: «Газизнең хатыны үзенең колыннан җимагъ кылуны теләгән. Зөләйханың мәхәббәте чиктән ашкан. Без ул Зөләйханы ачык рәвештә бозыклык кылучы дип беләбез», - диделәр».

«Йосыф», 31нче аять: فَلَمَّا سَمِعَتْ بِمَكْرِهِنَّ أَرْسَلَتْ إِلَيْهِنَّ وَأَعْتَدَتْ لَهُنَّ مُتَّكَأً وَآتَتْ كُلَّ وَاحِدَةٍ مِّنْهُنَّ سِكِّينًا وَقَالَتِ اخْرُجْ عَلَيْهِنَّ ۖ فَلَمَّا رَأَيْنَهُ أَكْبَرْنَهُ وَقَطَّعْنَ أَيْدِيَهُنَّ وَقُلْنَ حَاشَ لِلَّهِ مَا هَٰذَا بَشَرًا إِنْ هَٰذَا إِلَّا مَلَكٌ كَرِيمٌ «Зөләйха ул хатыннарның сүзләрен ишеткәч, ул хатыннарны чакырды. Яхшы итеп тәгам хәзерләде. Аш алдыннан һәр хатынга пычак бирде. Шуннан соң Йосыфны хатыннар янына чыгарырга кушты. Ул хатыннар Йосыфны күрү белән хәйран калып аш дип кулларын кистеләр. «Аллаһны пакьлибез, бу адәм түгел, фәрештәдер», - диделәр».

«Йосыф», 32нче аять: قَالَتْ فَذَٰلِكُنَّ الَّذِي لُمْتُنَّنِي فِيهِ ۖ وَلَقَدْ رَاوَدتُّهُ عَن نَّفْسِهِ فَاسْتَعْصَمَ ۖ وَلَئِن لَّمْ يَفْعَلْ مَا آمُرُهُ لَيُسْجَنَنَّ وَلَيَكُونًا مِّنَ الصَّاغِرِينَ «Шулвакыт Зөләйха әйтте: «Сез

мине гаеп иткән кол шушыдыр». «Дөрес, мин аннан якынлык кылмакны теләдем, ләкин ул сакланды, кылмады», - диде. Соңра Зөләйха хатыннарга Йосыфны димләргә кушты һәм: «Әгәр мин әйткәнне кылмаса, әлбәттә, төрмәгә салып иң түбән кешеләрдән калдырам», - диде».

«Йосыф», 50нче аять: وَقَالَ الْمَلِكُ ائْتُونِي بِهِ ۖ فَلَمَّا جَاءَهُ الرَّسُولُ قَالَ ارْجِعْ إِلَىٰ رَبِّكَ فَاسْأَلْهُ مَا بَالُ النِّسْوَةِ اللَّاتِي قَطَّعْنَ أَيْدِيَهُنَّ ۚ إِنَّ رَبِّي بِكَيْدِهِنَّ عَلِيمٌ «Патша әйтте: «Ул Йосыфны төрмәдән чыгарып миңа китерегез». Йосыфны чакырырга кеше баргач: «Бар, патшаһка кайт һәм, мине күреп, кулларын кискән хатыннарның хәле ничек икәнен сора. Тәхкыйк, минем Раббым ул хатыннарның мәкерләрен беләдер».

«Йосыф», 51нче аять: قَالَ مَا خَطْبُكُنَّ إِذْ رَاوَدتُّنَّ يُوسُفَ عَن نَّفْسِهِ ۚ قُلْنَ حَاشَ لِلَّهِ مَا عَلِمْنَا عَلَيْهِ مِن سُوءٍ ۚ قَالَتِ امْرَأَتُ الْعَزِيزِ الْآنَ حَصْحَصَ الْحَقُّ أَنَا رَاوَدتُّهُ عَن نَّفْسِهِ وَإِنَّهُ لَمِنَ الصَّادِقِينَ «Патша янына китерелгәч: «Йосыфта гаеп бармы?» - диде. Хатыннар әйттеләр: «Аллаһтан куркабыз, ул Йосыфтан без бертөрле дә явызлык күрмәдек». Шуннан Зөләйха әйтте: «Тугрылык мәгълүм булды. Йосыфның якынлык кылуын мин теләдем. Йосыф хыянәт итүчеләрдән түгелдер, тугры кешедер».

«Йосыф», 52нче аять: ذَٰلِكَ لِيَعْلَمَ أَنِّي لَمْ أَخُنْهُ بِالْغَيْبِ وَأَنَّ اللَّهَ لَا يَهْدِي كَيْدَ الْخَائِنِينَ «Газиз өйдә юкта, хатынына хыянәт итмәгәнемне белсен өчен бу хәлне кылдым, Аллаһ Тәбарәкә ялганчыларны, хыянәтчеләрне тугры юлга күндермидер».

# Русия мөселманнары һәм мөфтиләр-казыйлар турында кыскача мәгълүмат (гыйнвар, 1979 ел)

Бу тарих берничә дәвергә бүленәдер:

1. Әчке Русиягә ислам дине кертелгәнгә кадәр.
2. Ислам дине кабул ителгәннән соң.
3. Башкорт халкының бунт күтәргәне соңында.
4. Октябрь инкыйлабыннан соңгы дәверләр.

Әчке Русиядә, мөселман дине кертелгәнгә кадәр булган әхвәлләреннән һәм ислам дине кертелгәннән соң булган дәверләрдә бертөрле дә ачык дәлил һәм шул вакытларда булып узган вакыйгалардан бертөрле дә хөҗҗәт калмаган. Гомумән, Иван Грозный дәверендә гарәп хәрефе берлән язылган ислам әсәрләре – бернәрсә дә калдырылмаган, һәлак ителгән. Шулай ук, шул заманның хәлифәләре дә бертөрле дә әсәр язуы калдырырга игътибарлары булмаган, вә ни өчендер ислам дине таратырга чыгучылар мөварихларның (тарихчыларның) имамнары да, мәсгудиләре дә бернәрсә язмый. Мәшһүр Ибн әл-Әсир дә бу турыда кыска гына әсәр язып калдырмый. Шулай булгач, Иван Грозныйны да гаепләп булмый. Ислам тарихчылары берлән нык хәбәрдар булган Мәсгуд яки Ибн әл-Әсирнең язмавына карап булмый. Ләкин Багдадтан килүче вәкилләр мәсҗедләр салдырды, мөфтиләр-казыйлар сайлады, ислам динен Идел-Урал буйларында аякка бастырды.

Идел-Урал буйларында мәзһәб башлыгы Имам Әгъзам Әбү Хәнифәнең урынлашып калырга шул вакытның галимнәре тәэсир итте. һәм шул Имам Әгъзам Әбү Хәнифәнең иранлы булуы да шимали төркләргә зур тәэсир биргәндер. Бу вакыйга 3-4 нче гасырларда буладыр. Бу шимали төркләрнең бер өлеше вак-вак авылларда торсалар да, киң далаларда күчеп йөрсәләр дә, җәй көннәрендә төньякларга (Урал-Идел буйларына) вә кыш көннәрендә җөнүб якларына күчәләр иде (Саратов, Әстерхан якларына). Бәгъзе бер өлешләре шәһәрләрдә торалар иде. Сату итәләр, кәрваннар йөртәләр иде. Бигрәк тә Иран мәмләкәте берлән катнашалар иде. Кытай, һинд, хәтта Аурупаның бәгъзе бер урыннарына баралар иде. Идел, Кама елгаларының сул тарафларында һәм шул елгаларга коя торган зур сулар буенда көн күрүче бу халык, күбесенчә, күчмә халәттә булып, кыш көннәрендә генә авылларга, агачтан ясалган землянкаларда җыелып торалар иде. Шәһәрләрдә җомга вә гает намазлары укылса да вә дини мәдрәсәләр булса да, дин эшләрен алып баруга казыйлар

вә мөфтиләр булса да, авыллардагы күчмә тирмәләрдә, чатырларда халыкларга юлбашчылык итүче абыз, ака исемендә үз араларында дин өйрәтүче вәгазьләр сөйләүче һәм үз араларында булган дәгъваларны хәл итүчеләр бар иде. Болар халыкның кайгы-шатлыкларын уртаклашалар иде. Димәк, халыкның бер кайгысы булса, барып юаталар иде. Вә шулай ук шатлыклары булса да, уртаклашалар иде. Әл-хәсыйл, бер гаилә булып яшиләр иде.

Ата-бабайларыбыз үз кавемнәребез арасында тәрҗемәи хәл, тарих китаплары, көндәлек мәгълүматлары язылган әсәрләр юк дәрәҗәсендә, калган бу урында язылган хәбәрләр күпчелеге әсас Нәзарәт вә мөфти-казыйларның тарих яки әсәрләре булмаганлыктан игътибарлы бабайлардан ишетеп килүгә, хәбәрләргә кайберләр иске китапларның читенә, китап тышларына язылган мәгълүматларга карап язып килде. Мисал өчен бер мондыйлар күп. Җөмләдән бер иске китапның катыркасына тышына ошбу язылган:

1. Бөре өязе (Бирск) Нурмөхәммәд исемле бер адәм 1196 һиҗридә (1776 ел милади тарихында) кул куйган бер кәгазендә (бу урында исемнәре белдерелгән мөфтиләрнең фәтвалары буенча хөкем ителде) дип язылган.

2. Иске бер «Җамигел-рөмүз» дигән китапның ахырында менә бу тарих язылган: **تم فی قریه التوریش و فی مدرسه ملا عبد الناصر بن شیخ ملا مراد باقی قاضیا الزمان ، مفتی الدروان فی یوم ۴ من شهر ربیع الاول ۱۱۹۵ هجری ۱۷۷۸ میلادی**

3. 1175 һиҗри 1761 милади тарихында вафат булган Оренбург шәһәренең Ибраһим ахунд. Пичатында «Ибраһим бине Түлек әл-мөфти» дип язылган. "Мөстәфадел-әхбар"да бу мәгълүмдер.

4. 1136 һиҗри 1727 милади тарихында вафат булган Мортаза әфәнде – Мортаза хафиз, Мортаза мөфти дип танылганлыгы мәгълүмдер.

5. Диния Нәзарәтенең китапханәсендә «Хөләсәтел-Кодури» ахырында ошбу рәвештә тарих язылган: **واقع الفراغ فی مدرسه ملا عبد الوهاب الاخوه المفتی البولغاری صاحبه و مالکه ندیر بن کل محمد ۱۱۲۷ فی برج تور** (милади 1715 нче дә буладыр).

Әгәр дә зан кылынса, бу бер бирелгән исем дип ул дөрес булмый. Галимголамә, мөфти, казый, әмир формасында булган исемнәре бу кешеләренә муафыйк аерым хезмәт бәрабәрендә генә, ягъни шул исемгә кодрәтеннән килерлек яки лаек булганда гына биреләдер. Бу исемнәр – тарихлар буенча, Уфа шәһәрендә Мәхкәмәи Шәргыя ачылмастан, мөкаддәм булган исемнәрдер.

# Ленинград шәһәре мәсҗед җамигенә ай кую бәйрәме

Бисмиллаһир-рәхманир-рәхим

1958 ел, июнь 20-сендә җомга көн.

1377 сәнә һиҗри зөлһиҗҗә 30, җомга көн, җомга намазыннан соң, Ленинград шәһәре мәсҗед җамигенә ай кую бәйрәме уздырылды.

Хөкүмәт тарафыннан рөхсәт алынган булса да, каю көндә, кайчан куелуы хакында алдан игълан ителмәде, ләкин җәмәгать җомгага килде, гаять күп булды. Җомгадан соң мөтәвәлият исеменнән Рәхим Агеев җәнәбләре ай кую турында бик гүзәл бер нотык ясап, бу гали минутлар моңа кадәр Ленинград мәсҗедендә булганы юк иде. Бу дәрәҗәләргә ирешүләр бөтен Совет дәүләтенең, бөтен адәм баласына бертигез каравы сәясендә насыйп булды.

Сез хөрмәтле мөселманнарның һиммәт, мөтәвәлиятнең шул һиммәтеңезне тиешле урыннарга файдалануы сәясендә, имам-хатыйб вә мөхтәсиб Габделбари хәзрәтнең мөбарәк Рәсүлемезнең минбәреннән Коръән Кәрим, хәдис рәсүлләрен чәчүе сәясендә насыйп булды. Бу бөек хезмәтләр тарихларга кереп калсын өчен, минем тәкъдимем шулар. Диния Нәзарәтенә бу мөкаддәс минутларның билгесе өчен тәшәккер телеграммалары бирелсен һәм соралсын иде. Безнең имам-хатыйб вә мөхтәсиб хәзрәтемезнең тагын да дәрәҗәсе арттырылсын, казый дәрәҗәсенә күтәрелсен дип дога итәр дә, күпчелек җәмәгать: «Күтәрелсен, күтәрелсен», - дигән һәвәсләр белдерделәр. Моның соңында имам-хатыйб тарафыннан бөек Советлар дәүләтенең бу мөкаддәс булган иҗазәт өчен рәһбәрләренә хәерле гомерләр биреп, адәм балаларына файдалы гомерләрне насыйп булсын дигән догалар әйтелде.

Моның соңында көмеш белән ялтыратылган ике метр озынлыкта булган айны алды тарафыннан – мәхәлләдә мөтәвәлият рәисе әл-хаҗел-хәрәмәйн Хәлим Госман углы Шаһмәхмүдев мөәзин һәм мәхәлләдә тәфтиш хәятенең рәисе Садыйк Сафиуллин җәнабләре күтәреп, аннан югары күтәрелгән тарафыннан – мәхәлләдә имам-хатыйб, әл-хаҗел-хәрәмәйн вәл-хафиз кәләмуллаһ Диния Нәзарәтенең тәфтиш хәятенең рәисе Габделбари хәзрәт ибн Низаметдин Исаев җәнабләре. Шулвакытта җәмәгать, торып, өч мәртәбә тәкъбир әйтте. Ай, мәсҗеднең тышкы тарафына чыгарылып, махсус хәзерләнгән урынга куелды. Моның соңында шул куелган урыннан коббага күтәрү өчен, түбәндәге затлар мөкыйн (تعين) әйтелде: рәис хаҗи Хәлим Госман углы Шаһмәхмүдев,

мөэзин Садыйк Сафиуллин, шәкертемездән Госман Фәхретдинов, мөтәвәлияттән Габдулла Биләлетдин, Рәхим Агеев, Хәсән Немшев, Йосыф Алпатов, Хәсән Мамин, Җиһаншаһ Терегулов, Хөсәен әфәнде Касыйми, Муфа әфәнде катнашып айны махсус хәзерләнгән аркан белән әкеренләп күндерә башладылар. Җыелган җәмәгать тәкрар тәкъбир әйтеп, ай тәмам күтәрелде.

Моның соңында инженер Постоков һәм Хәйрулла Алишиннар тарафыннан коббага мендерелеп, ай тәмам урынына утыртылып мөхәккәмләштерелде. Бу вакытта җәмәгать тәкрар тәкъбир әйтеп, зур шатлыклар изһар ителеп, олуг бәйрәм көне ителде. Җәмәгатьнең һәркайсы еглый-еглый, җәнаб Аллаһтан дәвамны сорап, догалар кылынды.

Имам вә мөхтәсиб Габделбари Исаев.

# Диния Нәзарәтенең 1959 ел чыгарган фәтвасе

Бисмиллаһир-рәхманир-рәхим

Шуралар җөмһүриятенең Европа бүлеге һәм Сибирия мөселманнары тарафыннан чыгарылган фәтва.

Мөхтәрәм мөселман кардәшләр!

Диния Нәзарәтенә карашлы казый вә имам-мөхтәсибләр тарафыннан алынган ышанычлы мәгълүматларга караганда, бәгъзе бер мәхәлләләр арасында яшерен рәвештә гайре рәсми муллалар вә шуларның иярүчеләре, суфыйлар, шәехләр, ишан вә мөридләренең ислам шәригатенә хилаф, ислам динендә булмаган хорафат, бидгатьләрне ихъя кылып, үзләренең кесәсенә калтайту, дөнья туплау максаты белән, фәлән изге вә фәлән ишан яки фәлән әүлия диеп, шуларның каберләрен зиярәт итү вә, шулар ризалыгы өчен, каберләр өстендә корбан чалу һәм шулардан ярдәм сорау кеби ислам шәригатенә тәмам илә хилаф, бидгать эшләрнең көчәеп киткәнлеге мәгълүм булды.

Ислам шәригатенең кушуы буенча хәле җиткән кешеләргә гомерендә бер мәртәбә хаҗ Кәгъбәтулланы таваф кылу фарыз ителеп, хәрәмәен шәрифне зиярәт кылу  мөэминнәргә мәшруг булган бөек гамәлдән саналадыр. Башка каберләрне зиярәт итү – кем генә кабере булмасын, аны мөкаддәс санап зиярәт итүе, аннан ярдәм теләү шәргы шәрифкә, мотлакан, хилаф вә бидгать эшләрдәндер.

Ислам динен бидгать-хорафаттан тазарту вә бәгъзе мөселманнарның күкрәгендә урнашкан бозык хата, игътикадне пакьләү максаты белән Коръән Кәрим вә Рәсүлемезнең хәдисенә сөялеп, түбәндәге мәгълүматларны сезгә белдерүне үземнең зур мөкаддәс бурыч саныймын.

Мөбарәк рәсүлемез хәдисендә **تركت فيكم أمرين لن تضلوا ما تمسكتم بهما كتاب الله وسنة رسوله** (Бохари), ягъни «Мин сезгә ике нәрсә калдырдым: берсе – Коръән Кәрим, икенче – Рәсүлемезнең сөннәте. Шушы ике нәрсә белән гамәл итсәгез, һичбер вакыт бозыклыкка төшмәссез», – диелә. Менә Рәсүлаллаһ (саллаЛаһу галәйһи вә сәлләм) шушы сүзләре белән безләрне һәрбер дини эшемездә Коръән Кәрим вә хәдис рәсүлгә таянып эш итәргә кушадыр. Дин исемендә эшләнә торган гамәлнең фарыз булучылыгы – Коръән белән, сөннәт булучылыгы рәсүлемезнең хәдисе белән сабит булучылыгы ләземдер. Аллаһтан: «Эшлә!» - дип әмер булмаса, Рәсүл икрам тарафыннан эшләнмәсә, яки өммәтләренә: «Эшләгез!» - дип әмер булмаса, мондый гамәлләрне эшләү, аннан савап өмет

итү – тәмам урынсыз, мәгънәсез эш булып каладыр. Нитәк, كل بدعة ضلالة وكل ضلالة (Җамигъ әс-сагыйр)في النار, ягъни һәрбер бидгать – заляләттер. Заляләт сахый уттадыр.

Яки Коръән Кәримдә, яки Рәсүлемезнең хәдисендә булмаган нәрсәләр – бидгатьтер. Бидгатьтән саналып, моның гаять бозык гамәл, ислам диненә хилаф иттегене Рәсүл икрам ачык итеп өммәтләренә моннан саклануны васыять итеп калдыргандыр. Ислам динендә булмаган эшне, халыкның күңелен нечкәртәм яки газап белән куркытам дип, үзлегеннән бер яңалыкны барлыкка китерүчеләргә, халыкның акылын томалаучыларга Рәсүл икрам болай ди: (Җамигъ әс-сагыйр) من احدث في امرنا هذا ما ليس منه فهو رد, «Ягъни бер адәм ислам диненә ислам динендә булмаган бернәрсәне дин исеменнән барлыкка китерсә, ул һич кабул булмас. Үзенә мәрдүд булыр». Нинди генә бидгать булсын, дини мәсьәләдә Коръән һәм хәдис рәсүлгә хилаф булса, һич кабул ителмәс.

Инде килик хәзергә кадәр һәм хәзерге мәдәният дәверендә ислам дине исеменнән эшләнеп яткан бидгать-хорафатлар һәм хәзерге көндә бәгъзе мөселманнар тарафыннан да шуларның эшләнеп торулары – без мөселманнар өчен гаять гөнаһлы вә йөзләребезне кызарта торган начар эшләрдер.

Мәсәлән: 1) әүлия яки ишан кабере диеп, каберләрен зиярәт итү һәм алардан ярдәм сорап һәм ярдәм өмет итеп, кабер янында куну, 2) каберләр янына барып, шуларны шатландырам дип, корбан чалу, мал бугазлау, шуннан савап өмет итү, 3) авырулар табибка мөрәҗәгать итми, бетү догалык яздыру яки талинкага яздырып эчүләр, 4) киләчәктә башыма нәрсә киләчәк иттегене белим әле диеп, фал ачтыру, комалак салдыру, карта ачтыру, чегән хатынна-рыннан учка тамырларга каратып, шуларга ышану.

Менә бу күрсәтелгән гадәтләргә ислам дине менә ничек карый: Аллаһ Сөбханәһү вә Тәгалә Коръән Кәримендә إِيَّاكَ نَعْبُدُ وَإِيَّاكَ نَسْتَعِينُ, ягъни «Сиңа гына гыйбадәт кылабыз вә Синнән генә ярдәм эстибез, тик гыйбадәт Аллаһ өчен гына булып, Аллаһтан башка һичбер кешедән ярдәм сорау истимдад эстәү катгыян дөрест түгелдер», - дип белдерә. Әүлияме, ишанмы, аларның каберләре янына барып, Аллаһны читкә куеп, ишаннан ярдәм сорау – бу инде куркыныч гамәл, Аллаһка ширек буладыр. Бу эштән бөтен көчләр белән ерак булу ләземдер, саклану ләземдер.

لا عقر في الإسلام (Җамигъ әс-сагыйр). Каберләрне зиярәт итү, янында куну, аннан ярдәм сорау һәм каберләр өстендә корбан чалу, бер адәмнең ут өстенә утырып киемнәрен яндыруы кабер өстендә утырып, кабер саклаудан хәерледер. Кабер өстендә корбан чалу – безнең татарлар, казахлар вә үзбәкләрдә шаиг-

ътер. Рәсүл (саллаЛлаһү галәйһи вә сәлләм) бу бидгать гамәлләрдән тыйган булса да, бәгъзе бер ит ашасы теләгән, мал, садака җыясы килгән муллалар бу бидгать гамәлләрне көчләндереп җибәреп, саф мөселманнарның игътикадына нык урнаштырып, Рәсүл икрамның мөбарәк сөннәтен аяк астына салып таптаганнар. Кабер иясе кем генә булмасын, җир астында ятып кешегә ярдәм итү түгел, бәлки үзе Аллаһның ярдәменә мохтаҗдыр, وَإِيَّاكَ نَسْتَعِينُ әйтүчедер. Кабердә җир астындагы кешедән ярдәм сорау – таштан юкә сую кабиләтеннәндер.

Янә рәсүлемезнең хәдисендә لعن الله من لعن والديه ، لعن الله من ذبح لغير الله (Җамигъ әс-сагыйр), ягъни: «Ата-анасыны ләгънәт иткән кеше һәм, Аллаһ ризалыгыннан башка, корбан бугазлаган кешеләргә Аллаһ ләгънәт кылыр димештер».

Рәсүлемез хәдисендә داووا مرضاكم «Авыруларыгызны докторларга күрсәтеп дәвалагыз», - димештер (Җамигъ әс-сәгыйр).

Янә рәсүлемез булмаган беркадәр сүзләр белән өшкерү, төкерү, ирләремез сөйсен дип, талинкаларга яздырып, эчертү кеби гамәлләр – Аллаһка ширкәттер. Мөселманнарга моннан сак булу ләземдер.

Фал ачтыру, карта ачтыру вә чегәннәрдән учтагы тамырлардан каратучылар Рәсүлемез: «Фал, ягъни багучы, фал актыручы, алдан хәбәр бирүче, шул хәбәр белән гамәл итүче, сихерче һәм сихер кылучы минем өммәтемнән түгелдер», - димештер, чөнки бу эшләр – дөнья туплау өчен корылган оятсыз фәхишләрнең пычрак эшедер. Ислам динен башкаларга пычрак итеп күрсәтүдер.

Мөхтәрәм мөселманнар! Әле булса арабызда ташланмаган бидгать-хорафатларның, шаригатькә хилаф кабәхәт гадәт булуы мәгълүмегездер. Нинди тараикъ белән булса да, акылыбыз белән уйлап, мондый кабахәт бидгать-хорафатларны арабыздан чыгарып ташлау, тәмам бетерү – мөкаддәс булган мөселманлык бурычыбыздыр.

Мөхтәрәм казыйлар, мөхтәсибләр, имам-хатыйблар, شر الناس شرار العلماء فى الناس (Җамигъ әс-сагыйр) «Адәмнәрнең явызы – адәмнәр эчендәге галимнәрнең явызыдыр», - дигән. Адәмнәр арасында галимнәрнең явызы димәкнең мәгънәсе: ислам диненең хакыйкатьтән, дөреслектән дөньяви мәнфәгатьне уйлап, хорафат белән халыкның мөбәйянен агулаучылар хакында әйткән сүз. Бинаән галәйһи, сез мөхтәрәм зават кирамнар ошбу мөрәҗәгатьнамәне җомгада һәм гаеттә халыкка укып, бидгать хорафаттан ислам динен пакьләү хакында иҗтиһад итүегез – дини вөҗдан, бурычыгыздыр.

# Хатлар

## Мөфти Шакир Хыялетдин белән хат язышу

Диния нәзарәтенда рәис мөфти хәзрәтләренә
Ленинград шәһәре мәсҗед җамигендә имам-хатыйб мөхтәсыйб Габделбари ибн Низаметдин Исаевтан
Гариза

Мин сезләргә кыскача гына причиналарымны белдереп үтәм.

Мин сезнең фәрманыгызга бинаән Ленинград шәһәренә 1956 ел 2 май көнендә килеп, сезгә мәгълүм булган, тәртипсез, җимерелгән мәсҗед җамигъдә хезмәт башладым. Бәлки имамлык хезмәте генә түгел, ремонт, восстановить итү эшләрен үзем алып бардым.

Ләкин беренче көннән башлап ук совет вәкиле, уполномоченный иптәш Васильев тарафыннан катгый каршылык күрә башладым. Беренче килү белән бер айга регистрация ясады, аннан алты айга ясап, һәр ел ике мәртәбә регистрациядән уздырып тора, бу аның безгә ышанмаганыннан килә. Булмаса, минем Совет дәүләтенә бер тиенлек хыянәтем юк, бәлки, вакыты белән, кызганмый, Ватан өчен канымны да түккән бер гражданмын, кирәк булсак – бу көндә хәзер без.

Менә хәзер дүртенче ел бертуктаусыз безгә дошманлык итүче кешеләрне котыртып (Богдановларны), безнең өстән жалоба биреп, шуларның жалобасына бинаән Горфинотдел халыкны тәшвишкә салып, шәһәр буена йорт саен кереп, тикшерү алып бара.

Уполномоченный Васильев иптәш ошбу ел май бәйрәме алдыннан мәхәллә идарәсенә килеп мөтәвәлиятнең протокол книгаларын карап мөтәвәлият алдында «Богданов егермәлектән чыкканы юк, аны беркемнең чыгарырга хакы юк, бу егермәлек протоколы дөрес түгел», - дип, ачыктан-ачык заявить итеп киткән.

Ошбу ел мәхәллә идарәсендә рәис булып торган Хәлим Шахмәмедов майның 20 сендә: «Рәислектән һәм мөтәвәллияттән мине бушатыгыз», - дип, мәхәллә идарәсенә гариза бирә. Беренче июльдә мәхәллә идарәсе мәҗлес ясап, Хәлим Шахмәмедовка бер ай отпуска бирә, хезмәттән бушату турындагы гаризасы, отпускадан кайткач, мәхәллә идарәсе мәҗлесе булганда, каралыр. Шуңа кадәр мөтәвәлли казначей Габделкоддус Рәхимовны рәис тәгаен итүгә карар итә. Хәлим Шахмәмедов отпускада ике ай йөреп кайта, кайткач та, мәхәллә идарәсе мәҗлесе ясалмый, хәзердә дүрт ай Габделкоддус Рәхимов

мәхәлләне бик тыныч гүзәл алып бара. Инде Хәлим Шахмәмедов уполномоченныйга: «Мине чыгардылар», - дип, жалоба бирлән бара. Уполномоченный (бусы Шахмәмедов сүзе): «Мин сине поддерживать итәрмен, сине беркем төшерә алмый. Монда мөфтинең дә хакы юк, имамның да хакы юк, шулай ук мөтәвәлиятнең дә хакы юк. Сине может только егермәлек төшерергә», - дип җибәрә, гәрчә гаризасы булса да. 19 октябрь уполномоченный мине Хәлим Шахмәмедов белән киңәшкә чакыра. Мин бара алмый калам, беренчедән, мин чирле, аяклар белән ятам, икенчедән, Хәлим Шахмәмедовны мөтәвәллият һәм халык рәис итеп танымыйлар. Ул хәзер дүрт айдан бирле хезмәт итми, үз теләге белән чыккан кеше. Мин: «Әгәр хуҗалык эше булса, мөтәвәллият әгъзалары белән чакыр, дини мәсьәлә булса, үземне генә чакыр», - дип, телефон белән җавап бирдем.

Шулвакытта уполномоченный: «Мин – совет вәкиле, мин чакырганда, синең килми калырга хакың юк, мин ничек тотарга белермен, син – минем кулда. Менә мин сине быел, карышканың өчен, регистрациядән уздырмыйм, ә Хәлим Шахмәмедовны беркем төшерә алмый, только может егермәлек төшерергә. Мин синең белән больше сөйләшмим», - дип, трубканы куя.

Мин сезгә үтенәм, әгәр бу мәсьәлә турында мин гаепле булсам, нигә мине хөкүмәт хезмәткәрләренә зарарлы итеп, Ленинград мәсҗедендә хезмәттә тотасыз? Әгәр дә үч алу өчен хезмәт ителә торган булса, тикшерелеп, чарасы күрелү тиеш. Мин дини хезмәтемдә ислам диненең кушканны дөрес саклаган кеби, Совет дәүләтенең гражданлык правосына да хыянәт итүне теләмим һәм, гражданлык правосын гали бер сыйфат итеп танып, кулымнан килгән кадәр ачык тугры хезмәтемне кызганмыйм.

Ошбуның өчен илтимас кылам, безгә берәр кечкенәрәк урын бирүегезне, бәлки без бу кеби урынны үти алырлык көчебез юктыр. Бигрәк тә асыл Ватанымызга кайтаруыгызны.

Габделбари Исаев. 19 октябрь 1959 ел[1].

1. Бу хат Габбас хәзрәт Бибарсовның шәхси архивында, махсус “Дела покойного муфтия Шакира Хиалетдинова” дип исемләнгән махсус папка эчендә саклана.

## Мөфти Шакир Хыялетдиновка һәм Уполномоченныйга рәсми хат

Совет җөмһүриятенең Аурупа кыйсме һәм Сибирия мөселманнарының бөек совет дәүләте тарафыннан танылып тасдыйк ителгән, Конституция кануны буенча динле совет гражданнарының дини хезмәтләрен үтәү өчен, руханилар хәзерләп бирүгә киң хокукы булган Диния Нәзарәте рәисе мөфти хәзрәтләренә һәм президиум әгъзаларына

вә шулай ук Диния Нәзарәте алдында Башкортостан җөмһүриятенең дини эшләрне караучы вәкил-уполномоченныйга

Бүген Ленинград шәһәре тарихи мәсҗед җамигендә имам-хатыйб советлар җөмһүриятенең Ауропа кыйсме һәм Сибирия мөселманнарының Диния Нәзарәтенда тәфтиш комиссиясе рәисе мөхтәсиб Габделбари Низаметдин углы Исаевтан шикаять һәм сораулар:

1. Без динчеләр мөселман динен тәгъриф итәбез һәм Коръән Кәрим буенча дәүләтнең яшәвенә тузан кадәр зарар китерми торган рәвештә шәригать эшләрен үтәп барабыз. Менә шул шәригать хөкүмен әҗра итү өчен Коръән Кәрим безгә, мөселманнарга, әмер итә, кушадыр: استعذ بالله أَطِيعُوا اللَّهَ وَأَطِيعُوا الرَّسُولَ وَأُوْلِي الْأَمْرِ مِنْكُمْ. Моның мәгънәсе һәркемгә ачыктыр. Әгәр мәхәлләдә мәхәллә идарәсе булып та, хөкүмәт тарафыннан танылмаган һәм тасдыйкъ ителмәгән Диния Нәзарәтенә яки мәхәллә имамына итагать итмәсә, бу шәригатькә кыйтган хилаф. Шулай ук, дәүләт таныган, тасдыйкъ иткән кешене танымау дәүләткә һәм хилаф, итагать итмәү була. Мондый хәлдә мәхәллә идарәсе имамга итагать итмәгәч, ни өчен соң динчеләр эченнән сайлана? Мәхәлләдәге бөтен общественный нәрсәләр имләк, хөкүмәт имләге хисап ителгәннән соң, аны ответственный саклау өчен, кем булса да ярый, кыскача, мәхәллә идарәсе исемендә булмый, комендант исемендә була. Дәүләт тарафыннан тәгаен ителгән, ыстажы хисап ителә торган кеше булырга тугры килә. Мәхәллә - дини идарә, аны идарә итүче имам башка кеше булу ләзем түгел, шәрган хилаф. Нитәк, Диния Нәзарәтенә идарә итүче мөфти аның әгъзалары, мәхәллә дини идарә идарә итүче имам аның әгъзалары булырга тиеш. Бу тугры шәрган дөрес була. Нитәк, Рәсүлаллаһ (салла Аллаһү галәйһи вә сәлләм) үзләре идарә итте, тиешле хезмәтләрне сәхабәләренә бүлеп бирде. Шәргән мәхәллә идарәсенең хаҗәте юк һәм мөселманнарның дини эшләрне әҗра итү өчен биргән хәер-садакаларында, имамнарга Диния Нәзарәтенә итагать итмәүче мөтәвәлиятнең һич хакы юк шәргән, аларга вазыйфа бирү мөселманнарга хыянәт була. Дини мөтәвәли Диния Нәзарәте тарафыннан шул эшне идарә итү өчен вәли-вәкиле

ителгән кеше дигән сүз була. Ни өчен бөек дини идарә Дания Нәзарәте бу хакта дәүләт хозурында иттифак итми, ни өчен ачык фәтва бирми?

2. Имамнар Диния Нәзарәте тарафыннан тәгаен ителә. Диния Нәзарәтен тәгъриф итмәгән, Диния Нәзарәте тарафыннан дин эшләрен әҗра итү өчен куелган имамны, «Синең мәхәлләдә катнашың юк», - диюче бәгъзе бер мөтәвәлият исемендәге личность тоткан кешеләргә, Диния Нәзарәт имам катгый бирмәскә тиеш. Нәзарәтнең бу эштә хокукы алынмаган булырга тиеш. Итагатьсез урыннарга имам тәгаен итү шәргән дөрес түгел, чөнки имам тәгаен ителә ислам динен тәгъриф итеп итагать итүче кавемнәргә. أُوْلِي الْأَمْر гә итагатьсезлек ислам динен тәгъриф итү хисап ителми, мондый урыннарга имам тәгаенләү шәргән дөрес түгел. Дөрес, җәмәгать имамны тәгъриф итә, хөрмәт тә итә, Диния Нәзарәтен тәгъриф итә, мәхәлләне һәм Диния Нәзарәтенең кирәкләренә сарыф итү өчен, үзенең хезмәт итеп тапкан малыннан садака итә. Инде мәхәллә идарәсе шул җәмәгать тарафыннан сайланган мөселман булгач, ни өчен Нәзарәтне, имамны тәгъриф итми, Диния Нәзарәтенә ярдәм итүдән баш тарта. Димәк, хыянәт итә, إِنَّ اللّهَ يَأْمُرُكُمْ أَن تُؤدُّواْ الأَمَانَاتِ إِلَى أَهْلِهَا аять кәримәсен гамәлдән чыгара, катгый хыянәт итә. Бу һәм шәргән зур хыянәт, Диния Нәзарәте ни өчен, дәүләт белән иттифак итеп, бу шәргән хыянәткә чара күрми? Ни өчен итагатьсез мөтәваллияттән имамнарны алмый? Яки мондый мөтәвәллиятне алып ташламый яки алып ташларга хокукы юк? Бу һәм шәргән хыянәт.

Әгәр халык сайлаган булса, рөхсәт ителсен, җәмәгать алдына мөтәвәллиятнең итагатьсезлеген куюга, шул сәгать, шул минут алып ташыйлар. Моңа һич шөбһә юк һәм бу эш шәригать диеп таныла.

3. Диния Нәзарәте тарафыннан тәгаен ителгән имамнарга мәхәллә идарәсе тарафыннан вазыйфа тәгаен ителә. Шул вазыйфаны имамнар мөселманнар тарафыннан башка шул мәҗлестә хәзер булган кешеләр белән беррәттән биргән хәер-садакаларыннан алалар. Мәхәллә идарәсе исемендәге кешеләр шул имамнар бер тиенләп җыйган хәер-садакаларны көтеп яталар. Әгәр үзенең вазыйфасын тәэмин итәрлек акча хәерләрен китерә алмаса: «Имамнарны агырлыйсыз, хыянәт итәсез», - дип гайбәт сөйли, җәфа итә. Житешмәгән вазыйфасын түләми, җәбер итә, истиһза-мәсхәрә кыла. Имамнарны гүя борынгы капиталислар замандагы кол дәрәҗәсендә йөртә. Рәсүл әкрамнең العلماء ورثة الانبياء дигән мөкаддәс хәдисен тәмам аяк аска таптап, галимнәрне мөтәвәлият колы итү була. Имамнарны галимнәр түгел дияргә берәүнең дә хакы юк, Диния Нәзарәте теләде кемгә шаһәдәтнамә таратмый, бәлки бик игътибар белән кемне кай урынга кую хакында хисапны бик дөрес йөртә. Шулай булгач,

имамнар ورثة الانبياء булып, ورثة الانبياء не кол итү وَأَطِيعُوا الرَّسُولَ аятенә хилаф булып, бу һәм шәргән вә гакыйлән зур хыянәт, зур җинаять була. Дипия Нәзарәте ни өчен бу турыда дәүләт белән иттифак итеп, шәрган чара күрми?

Имамнар шул күрсәткән вазыйфа буенча декларация бирә һәм шуңа бинаән 50 процент вазыйфасын налог итеп хөкүмәткә кайтара. Моңа карамастан, мәхәллә идарәсе исемендәге берничә кеше имамнарга: «Житәрлек акча китермәдең, урладың», - дип вазыйфасын тулы рәвештә бирми, җәфа итә. Имамнарның бу турыда шикаять – жалобасы һич урында кабул ителми. Бу һәм мөтәвәллият тарафыннан зур җәфа-газап итү була һәм гражданлык правасына кемдер хуҗа була, чөнки хөкүмәтебезнең бер генә урында да берәүне, кем булуына карамастан, нинди милләт булуына карамастан, икенче берәүгә кол итүгә рөхсәт биргәне юк. Бүгенге көндә бу мәсьәлә безнең бөек советлар дәүләтендә авангард булып бара, бүгенге көндә капиталистар кулында коллыкта яшәүче Азия, Африка халыклары да безнең бөек илебездән үрнәк-нәмүнә алып азатлык дигән бөек лозунгны гамәлгә куеп колониядан, коллыктан котылып яталар. Адәм баласының кем булуына карамастан хөрмәт хокукы югалырга тиеш түгел, Коръән وَ لَقَدْ كَرَّمْنا بَنِي آدَمَ диеп хөрмәт иткән, Аллаһ хөрмәт иткән адәм баласының һичбер урында хөрмәте югалырга тиеш түгел.

Без, Советлар дәүләтенең хөрмәте өчен малларыбызны, каннарыбызны, балаларыбызны кызганмый, шул юлда фидакарьлек күрсәтүче бөек Совет дәүләтенең гражданы, бүгенге көндә илебезнең бөек теләге коммунизм төзүгә һәм илебезнең тыныч яшәвенә төрле юллар белән ярдәм итүче руханилар, җәмәгатьтән аерым түгел; без шул Совет дәүләтенең җәмәгате, руханиләр бигрәк тә динче халыкларга якын булу белән, җәмәгать – мәхәлләнең барышы, Диния Нәзарәтенең барышы мәхәлләдә имамнар, казый вә мөфтиләрнең әхвәлен бездән сорый. Ни өчен мәхәллә идарәсе исемендәге берничә кеше безне һәм Нәзарәтне чит күрә? Бу дөресме? Дөрес булмаса, Диния Нәзарәте бу турыда нәрсә уйлый?

4. Мәхәлләгә садака җыйнау, әсбаб җыйнау, бу - Аллаһ тарафыннан мөэминнәргә боерылган әмер, мөэминнең бурычы. Коръән белән ничә төрле әмер ителгән: وَ مِمَّا رَزَقْناهُمْ يُنْفِقُونَ; وَأَنفِقُواْ فِي سَبِيلِ اللّهِ; وَأَنْفِقُوا مِنْ مَا رَزَقْنَاكُمْ; وَآتُوا حَقَّهُ يَوْمَ حَصَادِهِ ;قَدْ أَفْلَحَ مَنْ تَزَكَّى рәвешле аятьләр белән мөэминнәрне мөттәкыйн дәрәҗәсенә күтәрә. Әл-хасыйл, бу турыда аятьләр күп. Бу хакта ачык мәгълүм. Шулай булгач, бу дини эш, дини мәраси: имамны тәгъриф итмәгән, Нәзарәт әмеренә итагать итмәүчеләрнең бу садакада нинди хаклары бар? Имамнан рөхсәтсез бер тиен тоту катгый шәригатькә хилаф.

Мәхәллә идарәсе булган тәкъдирдә дә, шул имамның тырышлыгы белән

совет гражданнарының динне тәгъриф кылганнары тарафыннан тупланган садакалар һәм имләкләрен закон буенча сакларга хокуклары булса да, распоряжаться итүгә хокуклары юк. Бу шәргән һәм гакыйлән хилаф. Әгәр бу маллар белән распоряжаться итсә, ул вакытта ул кеше динле булырга тиеш. Ә динле кеше имамга һәм Нәзарәткә буйсынуы Коръән белән йөкләтелгән ( أَطِيعُوا اللَّهَ وَأَطِيعُوا الرَّسُولَ وَأُولِي الْأَمْرِ مِنْكُمْ).

Итагать итмәгәндә, бу эшне теләсә кемгә ответственный итеп сакларга бирергә мөмкин, әмма мәхәллә идарәсенең хаҗәте юк. Аларны тоту садаканы исраф була, ислам динендә исраф-хәрәмдер.

Мәхәллә идарәсенең исеме мөтәвәлият булгач, дини рөхбәрләр тарафыннан шул имләк малларга викәләт бирелгән кеше дигән сүз була, ягъни дини вәкил мәгънәсендә була.

Ягъни мөтәвәллият халкының гыйбадәт итүе өчен мәсҗедне җылыту, чистарту, благоустроить итүче кеше, алар дини рөхбәр түгел һәм хаклары да юк.

Без – бөек советлар хөкүмәтендә яшәүче руханиләр. Советлар дәүләтенең конституция законында каралган, совет гражданнары динле булырга мөмкин дигән пункты буенча, дингә ышанучы гражданнарның сораулары буенча дини теләкләрен әҗра итеп барабыз, шәригатебездә булмаган, дәүләтебезгә зарарлы бидгать, гореф-гадәт вә хорафатлар белән катгый көрщшәбез, дәүләтебезгә хыянәт – шәригатебездә иң олуг гөнаһ дип андый ярамас эшләр вә сүзләрдән ерак булуга димлибез. Ватан сөю, халык арасында тынычлык саклау ислам диненең төп бурычыннан идегене гамәли рәвештә динчеләргә күрсәтәбез. Бу мөкаддәс хезмәтне үтәүгә бөтен көчләребез белән иҗтиһад итәбез.

Халык теләге буенча якты иректе юллар салып баручы җир йөзендә алдынгы эз тәэмин булып фундаментальный корылган хөкүмәтебез бер совет гражданнары булган хәзердә дини рөһбәрлек итүчеләрне читкә какмавына ышанабыз.

Тик бу турыда Диния Нәзарәт тарафыннан дин киңәшмәләргә ачык мәгълүмат бирелүе тиешледер.

Ошбуның өчен Диния Нәзарәтенщ илтимас итәбез, бер Нәзарәтнең голәмалар мәҗлесе булдыруны дәүләт хозурында куеп, мөфти хәзрәтләренең мөфтилек мәнсәбенә үтүгә ун ел тулу уңае белән рөхсәт алуны ???.

Ленинград җамигендә имам-хатыйб, Диния Нәзарәтендщ тәфтиш хәяте рәисе әл-хаҗел-хәрәмәйн вәл-хафизел-кәләмуллаһ, мөхтәсиб Габделбари ибн Низаметдин Исаев.<br>9 гыйнвар, 1961.

## Мөфти Шакир Хыялетдиновтан җавап

Гайре рәсми хосусый хат.

Мөхтәрәм Габделбари хәзрәт!

Ган сахихел-калб сәлам сөннәтел-ислам ли-ард ирсал итеп әс-сәламү галәйкүм вә рәхмәтүллаһи вә бәрәкәтүһ. Март 28 нче тарихлы хатыгыз тапшырылды. Дөньяда хәтергә килмәгән нәрсәләр төшкә керә дигән шикелле, хәтергә килмәгән сүзләрне ишетергә дә туры килә икән. Синең язганнар хыялларың вакыйгга муафыйк булса, җавап кайтарып мәшәкать чикмәс идем. Язганнарың күбесе хакыйкатьтән бик ерак булу сәбәпле, бәгъзе сүзләреңне ачу белән түгел, самимият белән тәсхихка лөзүм бар.

1. «Мин үземне сезнең алдыгызда акларга теләгәнем юк һәм теләмим дә», – дисез. Сөбхәналлаһ, бу сүзне язудан мөкаддәм сез минем карамагымда кара булып танылуыгыз кирәк бит, бу бит әле ихтималдан чит нәрсә, моны язарга нәрсә мәҗбүр итте белмим. الَّذِينَ يَسْتَمِعُونَ الْقَوْلَ فَيَتَّبِعُونَ أَحْسَنَهُ аятьне бер генә хәтергә китерү кирәк иде.

2. «Хакыйкатьне яшерергә теләгем юк, хакыйкать һәрвакыт өскә чыга», - дисез. Бу сүзегез гаять кыйммәтле сүз, ләкин хакыйкать кай тарафта, әүвәл әле моны белергә кирәк, бу шикле мәсьәлә, әмма хакыйкатьне син-мин түгел, әллә нинди зур кешеләр дә яшерә алмыйдыр.

3. Бәгъзе хәсәдләр тарафыннан әдәпсез имзасыз хатлар язылган икән, аны Аллаһка тапшырам. Мәктүб хуҗасын белмәгәч, һичкемгә рәнҗергә хакым юк.

4. Ленинградка имам итеп куюдан шәхси мәнфәгатьне уйлап түгел, синең имам булып торудан миңа һич зарар юк, башкаларның имам булып хезмәт итүдән һәмишщ хосусый үзем өчен файдасы юк, имам тәгаен итүдә хосусый мәнфәгать күздә тотылмыйдыр. «Имамлыктан чыгару белән куркытмагыз», - дисез. Әстәгъфируллаһ! Имамлыктан сезне төшереп ташлау минем хакым түгелдер. Царь хөкүмәт заманы түгел, бәлки демократия әсасенә корылган Совет дәүләтендә яшибез, бу берәү – халык кулында, бездә түгел, Габделбари әфәнде. Түгел яшь булып сез, карт булып без дә андый-мондый курка торган куян йөрәк түгел, имзасыз хат язучыларның ифтирачыларның, әлбәттә, дөньяда яхуд йәүме кыяммәттә пәрдәсе ачылыр.

5. Түгел сез уйлаган аксакал ике арага фетнә салу, аннан зуррак аксакаллар да, иншәАллаһ, вәсвәсә кыла алмаслар. Тырышалар икән, иҗтиһадлары тәмам габәс булачак. Габделбари хәзрәт! һәр ачулануда истигъфа бирергә ашыкмагыз, бу мәктүбегез истигъфа сорап язган алтынчы хатыгыз, ләкин

ачуланып язган саен сезнең истигъфаны кабул итсәк, нинди хәерле нәтиҗә бирер икән, белмим.

Камар хәзрәт белән Фатхуллинның җинаяте хакында зикер итеп, Камарның кыямәте якын булуны яд иткәнсез, кылган хыянәтләре булып дәүләт тарафыннан җәза күрә икән, һич кайгым юк. الي جهنم زمرا. Дөрест, ул кешенең безгә дә катнашы булды. Түгел андый дәүләтнең гаделия мәхкәмәсенә даир эшләргә катнашу, гайре рәсми дини оешмалар белән дә мөнәсәбәт тотмыйбыз, чөнки дәүләт кануны шулай һәм шулай булырга тиеш.

Әлхәмдүлиллаһ, карт булсак та, моны гына аңларлык башыбыз бар.

Бу хаҗга җибәрү мәсьәләсе гуя минем ихтыярымда кебек: «Камарны хаҗга җибәрегез», - дип, көлке миңа монда бер сүз язасыз. Хаҗга җибәрү – ул Аллаһның кемгә насыйп итүендә, икенче, дәүләтебез ихтыярында. Ихтимал, Аллаһ сезгә насыйп итәр, бу хакта да ашыгыбрак язган تفويض كل الامور الي الله саф иман булырга тиеш.

Габделбари хәзрәт! Сезне үземә якын күреп, ачуның, ашыгып хат язуның файдасыз икәнен хәтерегезгә салып, الصبر من الرحمن و العجلة من الشيطان و, لمن صبر و غفر ان ذالك لمن عزم الامور гыйбарәләрен хәтерегезгә китереп, юкка ачуланып яшь имамыбызның сәламәтлегенә зарар килмәсен дип, хәер-хаваһлык белән яздым.

Башка адәм тарафыннан язылган булса, аңар җавап язам дип, карт башымны зәхмәт чиктермәс идем.

و الباقى عند التلاقى

Җөмләгезгә сәлам белән, хафиз кәләмуллаһ вәл-хаҗел-хәрәмәйн
Шакир бине Шәйхелислам Хыялетдин.
1961 ел, 5 апрель.

Бисмиллаһир-рәхманир-рәхим

Остаз мөхтәрәм әл-хажел-хәрәмәйн вәл-хафиз кәләмуллаһ мөфти хәзрәтләре җәнабегезгә Хак сөбханә вә тәгаләдән хәерле сәламәтлек, хәерле гомер теләп догаи хәерияләрегезне риҗа итеп,

Әс-сәламү галәйкүм вә рәхмәтуллаһи вә бәрәкәтүһтер.

Мә бәгдә, абыстай җәнаб галияләрегә һәркәзә хәерле сәламәтлек, хәерле гомер теләп сәламнәр күндерәбез. Мә бәгъд, мөхтәрәм казый хәзрәтләренә һәм абыстайга безләрдән чок сәлам белән хәерле сәламәтлек, хәерле гомерләр теләп калдык.

Мөхтәрәм хәзрәт, үзебез, әһле бәйтебез бу көндә, әлхәмдулиллаһ, шәриф Рамазанны үтеп барабыз. Сез олугларны да ул тарафта сәламәт булгайлар иде дигән догаларда калдык. Әхвәлләребез бу көндә шулайдыр: уполномоченный 2 февраль безне, рәис Идрисовны һәм Богдановны, чакырып, дини мәрасимнәрне үтәргә рөхсәт итте, ләкин «Әгәр берәр төрле нарушение булса, катгый мәнгы итәчәкбез», - дип, каты угроз белдерде.

Мәсәлән, имамның ашка, никахка, исемгә барулары полный регистрация ясалсын, ягъни ашка чакыручы килеп, мәхәлләгә яздырырга тиеш, булмаса – имамның барырга хокук юк. Мәчеттә имамнан башка кеше Коръән укымасын, гомумән, Госман Фәхретдиновны катгый мәмнүгъ итүгә, имамга мөтәвәллият үзләре теләп ярдәмче куярга – моннан мөкаддәм: «Шул мөтәвәллияткә шуны белдергән имам һәркөн җыеп кайткан хәерен мәчеткә кертә барсын, аннан ведомость белән акча-жалование бирегез, хәерләренә полный контроль куегыз», – дигән.

Ул инде имамның хәеренә контроль куя әле, мин үзем дә белмим кем күпме хәер биргәнне. Ну шулай булса да, Миңле Әхмәт белән Богдановның фикере буенча, эш алып бара. Аларны хуҗа итеп йөртә, халык теләге һич игътибар ителми.

Менә шул җәй көне сезгә килеп тапшырган халыкның протоколы тәгаен кылынган егермәлекләрне утвердить итми, Миңле-Әхмәт, Богдановларын үзе назначать итеп, утвердить итеп, үз эчләреннән мөтәвәлли сайлатып, халыкның теләген аяк аска таптады. «Хәзер инде имам яки наиб яки мөэззин булсын, боларны мин теләгеннәрне генә утвердить иттем. Имам кую – халык эше, мөфтинең монда хакы юк», – дип, хәзер дә шул Богдановлар белән Миңле Әхмәтне халык итеп йөртеп, шулар теләгәнне халык теләге дип, гамәлгә куеп бара.

Инде безгә нәрсә эшләргә, халыкның бер дә теләге йөртелми микән? 56 нчы елда егермәлек мәҗлесе белән бер мәртәбә чыгарылган, 60 нчы елда

тәкрар халык чыгарып ташлаган Богдановларны ул үзлегеннән тәгаен итүгә хокук бар микәнни? Дәхи дә дини мәрасимнәрне мөфти фәтвасыннан башка теләсә нишләтеп йөртүгә хокук бар микәнни? Имамнарны, мөэзиннәрне тәгаен итүдә мөфтинең рөхсәтеннән башка регистрация ясауга хокук бар микәнни? Мин аңламыйм, бу мөтәвәллиятне чынландырып бетерә: «Мөфтинең бер тинлек эше юк, бер тиен акча җыеп җибәргәгез аңа. Ул - Уфага хуҗа», - дигән сүзләр белән шул мөтәвәллиләр һәм тәфтиш комиссияләре Нәзарәтне һич игътибар итмиләр. Мин аңламыйм, бу ни юлдыр инде. Мондый хәлдә ничек имам булып торырга кирәк, кайчан синең дини эшләреңдә мөфти хуҗа түгел, уполномоченный һәм мөтәвәллият хуҗа.

Мәчетләрдә башкалардан Корьән укыту мәмнүгъ булу турында сезгә безнең өстән шикаять булыр, бу иттифак белән эшләнгән эш, белеп торыгыз.

Мөхтәрәм хәзрәт, сез бу турыда берәр нәрсә уйлыйсызмы? Берәр чара күрергә хокукыгыз бармы? Бездә булса, бер тинлек хокук юк, хәзердә шундый хәлдә яшибез.

Игътибар итүгезне үтенеп, мәгълүмегез Габделбари Исаев.
1962 ел, 8 февраль

Советлар җөмһүриятенең Европа бүлеге һәм Сибирия
мөселманнарының Диния Нәзарәтендә мөфти әл-хаҗел-хәрәмәйн вәл-
хафиз кәләмуллаһ мөфти әл-ислам хәзрәтләренә

## Белдерү мәктүбе

Мин - Ленинград областендә мөхтәсиб, Ленинград җамигендә имам-хатыйб әл-хаҗел-хәрәмәйн вәл-хафиз кәләмүллаһ Габделбари ибн Низаметдин Исаев түбәндәгеләрне сезләргә белдерүне бөек бурычымнан хисап итеп белдерәм һәм ошбу тугрыда ашыгыч хәлдә фәтвагызны көтеп калам.

Ленинград мәхәлләсе мәгълүмегез, мәчет җамигъ бөек, зур булса да, даирәсендә мөселманнар ул кадәр күп түгелдер, шулай булса да, дингә ихласлары тамм булу сәясендә һәртөрле юл белән бөтен хәер, садакаларны мәчет җәмигъ кассасына туплап, мәчетнең расходларны каплап килә алалар иде.

Җамигънең еллык вәридәт һәм мәсарифе яңа акча белән 40 меңнәр тәшкил итәдер. Ошбу вәридәттә имамның җыелган хәер-садакалары да хисап ителеп мәхәллә кассасына кертелә бара иде.

Инде 28 нче октябрь көнендә уполномоченный мәхәлләдә рәис мөтәвәллият һәм тәфтиш комиссияләре белән берлектә чакырып яңа закон игълан итте. Ул закон 22 пунктан игътибарән, рәсми имамнарга катгый мәмнүгъ ошбу нәрсәләрне иҗра итү дип: «Мәетләр юырга йөрү, тәһлил итүгә йөрү, никах уку, исем кушу, Коръән уку - бу эшләрне бар да мәчеттә уздырылып. Әгәр закон аңлатылганнан соң квартираларда иҗра ителсә, мөтәвәлият калдырып хөкем ителәчәк, хөкем – катгый. Бүгенге көннән гамәлгә куелыр», - диде.

Ошбуларга бинаән, шул көннән башлап мәхәлләдә дини эшләрне иҗра итү фәкать җамигъ хозурында гына булдырыла, игълан кылынса да, мөселманнарның әксәрияте мәхәлләгә итагатеннән баш тартып белдерми, гәйре рәсмиләр белән гамәл кыла башлады. Моңа һичкем тарафыннан бертөрле юл белән дә чара күрүче юк. Чара күрергә мөмкинлек тә юк. Үз араларында яшерен эшләп баралар. Әмма җәмәгать безне гаепли, Диния Нәзарәте тарафыннан рөхсәт булмый торып, үзлегеннән: «Бу эшне кабул иттек», - дигән сүзләр белән эшләнә дип әйттеләр. Бигрәк тә бу вакыйганың айлар буена тик безнең мәхәлләдә генә гамәлгә куелып, башка Мәскәү, Казан вә гәйре урыннарда гамәлгә куелмавы зур уңайсызлык тудырды, безне зур хәвеф астында калдырды, җәмәгать арасында иттифаксызлык тудырды.

Бу турыда һич урынга шикаять итүгә безнең хокукыбыз калмады, вә ләкин мөселманнар үзләре тарафыннан уполномоченныйга гаризалар җибәрсәләр

дә, игътибарсыз шул урында басылып калмактадыр. Бөтен гаеп безнең өскә ташланды.

Ноябрь 29 ында уполномоченный тәкрар мөтәвәлият белән бергә чакыртып: «Мин сезне гаеплим, ни өчен сез моңа кадәр Диния Нәзарәте тарафыннан ошбу ел 18 июньдә мәҗлес белән кабул ителгән фәтваны яшереп яттыгыз, белдермәдегез», - дип фәтва укый башлады. Ул фәтва шуннан гыйбарәт: «Балаларны сөннәт итү шәригатьтә булмау сәясендә катгый мәмнүгъ, корбан чалу мәмнүгъ, ишаннарны зиярәт итү мәмнүгъ, ифтар иттерү мәмнүгъ, хатыннарның мәчетләргә йөрүләре мәмнүгъ». Моның соңында мин: «Без үзебез шул мәҗлестә президиум булып узган идек, безнең хозурыбызда мондый фәтва кабул ителгәне юк. Без белмибез», - дидем. Уполномоченый: «Мин сезгә ышанмыйм, документка ышанам. Менә совет аркылы Башкириянең уполномоченные җибәргән документ-закон, сез алдыгызмы, юкмы?» - диде. Мин: «Фәтва булганы юк һәм алганыбыз да юк, бу фәтва кабул ителсә дә, ителмәсә дә, бәйләнеше дөрес түгел, чөнки хатын-кызларны мәчетләрдән мәнгы дөрес түгел. Шәригать хөкеме иргә, хатынга бәрәбәр хокук ислам динендә һәм хөкүмәттә ир вә хатыннарныкы бәрәбәр. Хатын-кызлар Рәсүлаллаһ заманында мәчетләргә йөрделәр, хәзер дә гарәп илләрендә йөриләр. Русиядә, бигрәк тә, Кавказ һәм Урта Азияләрдә аларны мәчетләрдән мәнгы итү ишаннар аркасында булган, димәк, ишанизмны гамәлгә кую була. Хәзердә шул ишаннарга ышанучылар: «Хатыннарның мәчеткә йөрүләре - хәрәм», - дип йөриләр, ишанизмны аякка бастыру була. Бер тарафтан ишанизм белән катгый көрәш булса, бу урында аларның фикерен шәригать итеп күрсәтү, халыкны ишанизмга чакыру була».

Шуннан соң уполномоченный: «Бу турыда Нәзарәттән белегез, аларда фәтва булган, сез аны требовать итегез», - дип әйтте. Тарткалаш күп булды, ләкин фәтва булган дип калды.

Практически бу айларда дини эшләрне иҗра итү йортларда мәмнүгъ булгач, дини эшләрне иҗра итү мәчетләрдә уздырыла, нәтиҗәдә шул эшләр нык сизелә.

Әүвәл никах, исем, корбан укулар йортларда мәҗлесләргә җыелган картлар, әбиләр арасында уздырыла иде, яшьләр кереп тә карамыйлар иде. Хәзердә никах укытуга яшьләр үзләре килә һәм яннарында яшьләр дә алып киләләр. Исем куштыруларны әби-бабайлары куштыра иде, хәзер яшьләр үзләре күтәреп килеп куштыра: «Балабыз беренче көннән мәчеткә керде», - дип шатлык изһар итәләр.

Коръән укыту квартираларда булдырылып барулар хакында: ата-бабайлар, балалары хезмәттә вакытта алардан башка булдыра иде. Хәзердә яшьләр

Коръән укытуга үзләре килә һәм балаларны да Коръән тыңларга дип алып киләләр.

Мәҗлесләргә барып җәмәгатькә Коръән уку мәмнүгъ дигән сүзне тойгач та, зур тавыш кубанды. Азлык белдерәләр: «Дини эшләрне ни өчен мөфти-хәзрәт гамәлгә куймый», - дигән сүзләр күп булып китә. Әл-хасыйл, бу эшләр җәмәгать өчен гаять күңелсез, ихтимал, башка диннәрнең йортларда дини эшләрне ижра итүләре яшьләргә тәэсир итәдер, чөнки алар үзләренең милләт телендә ижра итәләр, әмма әһле мөслиминнең дин эшләре ижра итүләре һичкемгә тәэсир итми. Бәлки без гарәп телендә ике минут Коръән укыйбыз, тик әһле мөслиминнең шуннан рәхәт табуы гына күңелләрен күтәрә иде.

Бу турыда Диния Нәзарәте, нинди тараф белән булса да, имамнарга юл күрсәтсә икән, لا سنه ме яки عليهسنه ме? Чөнки без хәзердә гаять бер ачык тотырдай саламга да мохтаж булып яшибез. Мондый бер дәвердә дәүләт тарафыннан чыгарылган канун хакыйкый булса, итагать важиб булу саясеннән итагать итәбез, гамәлгә куябыз, вә ләкин кулда катгый әмер булмагач, күңелгә шик килә, җәмәгать арасында да ачык сөйләргә урын калмыйдыр.

Имде шәргъ шәриф буенча бу эшнең зарары булмаса, Диния Нәзарәтенең бертөрле фәтва бирүе ләзем, без имамнар үз тарафыбыздан шәригатьне юргәләп йөртүдә хакыбыз юк һәм хозурларыгызда катгый җавабкарыбыз дип беләбез.

Түбәнчелек белән мәгал-ихтирам Ленинград областендә мөхтәсиб,<br>Ленинград җамигъ шәрифендә имам-хатыйб, Диния Нәзарәтенең тәфтиш<br>һәяте әгъзасе әл-хаҗел-хәрәмәйн әл-хафиз кәләмуллаһ Габделбари ибн<br>Низаметдин Исаев.<br>Декабрь 2

[Хосусый]

Һүвва-л-әүвәл вә-л-әхир вәз-захир вәл-батыйн вә һүввә бикөлли шәйин галим.

Мөхтәрәм имам-хатыйб Габделбари хәзрәт җәнабләре!

Гаиләгезгә ихтава сәлам мәснүннәремне ирсал бәгъдендә хәер-догагызны рижа идәрем. Бәгъдәс-сәлам, җәнабләрегездән 26нчы тарихлы мәктүбегез тапшырылды. Мәфиһасене аңладым. Җавабыгыз калдырсак, янә сезнең шелтәгә гирифтар булырбыз дип мәктүбегезгә җавап кайтару ләзем булып калды.

Әхмәтҗан мелла турында язганнарыгыз тугры, аның Нәзарәт тәкъдимен кабул итмәве ачыктан-ачык Диния Нәзарәте карарына итагать итмәве булып, бу гаять зур җинаять. Монда сүз бозылырга мөмкин түгел, ләкин хәзерге көндә имамнарны урыныннан газел итү яхуд мәхәлләгә имам тәгаен итү халыкның үз ихтыярында булып, халык иттифагыннан башка Нәзарәт бер мәхәллә имамын мәнсәбеннән чыгарып ташлавы яхуд, халык теләсен-теләмәсен бер имамны мәхәлләгә интихаб итү правасы Диния Нәзарәтендә юктыр. Моны сезгә аңларга вакыт иде. Гомуммилләт эшне асыл максат итеп тотмый, фәкать шәхси файдасын гына максат итү, бу инде дин хәдиме булудан әсас максат, фәкать корсак куптыру гына. Бу хосуста озак сөйләвенең хаҗәте булмаса кирәк.

Сезнең Диния Нәзарәте карарына итагать итүегез һәм ихтирамыгызга сүз юк, бу безгә ачык мәгълүм һәм сезгә тәшәккер. Әмма мине асыл ватанымнан, кардәш-ыругларымнан аерып Ленинградка, җәһәннәмгә китердегез диеп, Ленинград безнең Ватан түгелме? Совет дәүләтенең оҗмахы булган бер шәһәрне җәһәннәмгә охшатуыгызга тәгаҗҗеб иттем.

Сез мондый олуг шәһәргә нинди зур галимнәребезнең аяк баскан михрабына хүзә булуыгызга зур шөкеранә кылу урынына көфране, нигъмәт булмасмы икән? Моны уйлап, иншәАллаһ, бер тәүбәгә килерсез. Моны аңларлык фәһим гакыл сездә бар.

Ике-өч айдан соң булачак эшне көн борын аңлашаит итеп сезне чакыру мәсләхәт күрелмәде. Мәскәүдә торып Әхмәтҗан мелла да бу мәҗлескә иштиракь итмәде һәм хәбәре дә булмады. Бу хакта телефон белән бу хәбәрне белдерү фәкат Габделбари хәзрәткә генә насыйп булды.

Мәскәүдән хәбәр булмавы минем дәрәҗәне төшерергә сәбәп булды һәм төште дисез. Җөзьи бернәрсә белән дәрәҗәнең төшүе авып китмәсен дип кибәнне (?) инә белән терәтеп кую мәртәбәсендәге дәрәҗә булмыймы соң?

[...]

Бисмиллаһи тәгалә

Остаз мөхтәрәм вә голамаи кирам булган мөфти әл-ислам хәзрәтләре!

Җәнаб Аллаһтан хәерле гомер, хәерле сәламәтлек вә хәерле тәдбирләр теләп сагынып сәламнәребезне күндерәбез: әс-сәламү галәйкүм вә рәхмәтүллаһи вә бәрәкәтүһ.

Мә бәгъдә, абыстай җәнаб галияләренә һәкәза хәерле сәламәтлек, хәерле гомерләр теләп, сәламнәр язабыз.

Мә бәгъдә, мөхтәрәм казый хәзрәтләренә һәкәза – абыстайга хәерле сәламәтлек, хәерле гомерләр теләп сәламнәр күндерәбез.

Үзебез әһле гаялебез сау-сәламәт булып, хәер-догаларыгызны риҗа итеп калдык.

Мөхтәрәм хәзрәт, безнең әхвәл һаман шул көйгә гаять күңелсезлек белән дәвам итмәктә, мөселманнар арасында дини әҗраны теләсә кем үтәп килә. Мәхәллә гомумән таралды, хөкүмәттә нинди тарик белән уполномоченныйга мөрәҗәгать итсәк тә, закон дип җавап кайтара, башка һичнәрсә белми. Аның тарафдарлары булган Богданов булса, почти һәр көн безнең белән сөйләшеп: «Бергә уполномоченныйга керик, рөхсәт алып чыгабыз», - дип, бөтен дини эшләрне әҗра итүдә куя Богданов хуҗа булып йөри. Мәхәллә идарәсе һәм шундый кешеләр куйдылар – һичбер юл белән юлламый, «Миңа ярамый», - дип, тик торалар.

Мәхәлләдә әҗра кылынган дини мәрасимнәр, ашларга йөрүләр – һәркайсы уполномоченный кушуы буенча, полный регистрация ясалып бара, мәхәллә идарәсе регистрация ясап бара. Имам вә мөәззин кую эшендә алар теләге белән уполномоченный шаһәдәтнамә бирә, Нәзарәтнең шаһәдәтнамәсе кирәкми дип җавап бирде. Мәсәлән, мин быел сездән шаһәдәтнамә кирәк булырмы дигәч, аның кирәге юк, мөтәвәлият язып бирсә җитә, диде һәм мөтәвәлият язуы белән бер елга регистрация ясалдык. Бу инде ничек була, Нәзарәт мөфти имтихан соңында гына регистрация кирәк иде, ну хәзер имам һәм мөәззиннәрне мөтәвәлият имтихан итә булып чыга, бу шәрган дөрест түгел. Бу турыда хәрәкәт ләзем һәм шаһәдәтнамә бирелми торып регистрация ясалмаган имамнарны Нәзарәт танырга тиеш түгел. Имам булу өчен иҗазәт ләзем, монда хәзер шундый политика бара: Богданов Миңле Әхмәт һәм берничә башкалар, шулай ук, председатель мәхәлләгә ярдәмче имам куярга йөриләр, кайчан безнең шәһәрдә бер имамга химдәт юк, үзләренең планнары белән Мотыйгулланы куярга йөриләр дип ишетәбез. Халыкның һич теләге гамәлгә куелганы юк.

Сезгә мәгълүм, халык җыелып, җәй көне егермәлек сайлаган иде, протокол сездә бар. Богдановны чыгарып ташлаганнар иде. Уполномоченный ул егермәлекне, ягъни халык сайлаган егермәлекне, признавать итми. Үзе назначить итеп, шулар белән мөтәвәллият сайланды.

Кыскача, безнең монда җәфаланып торуда файда юк, безгә моннан котылу мөмкин, тик безне башка урынга күчергәндә. Ошбуның өчен сездән үтенәм, мине Уфага күчерүгезне. Анда хидмәт бирсәгез бирерсез, бирмәсәгез хидмәтсез торырмын, только күчерү дигән әмер кирәк. Бу көйгә ташласак зур җәфаларга очрау ихтималы бар, чөнки Богдановларның бөтен хезмәте – бездән үч алу өчен төрле юллар эзләп йөриләр, ну халыктан бераз шикләнә төшә, һаман уполномоченный аны урнаштыра бара.

Мин Ленинград шәһәрендә имам исеме күтәрәм, бәрәкәт Уфадан да начар, чөнки һәрбер тиенне хисап кылып баралар.

Менә налог хакында. Налог түлим 24 мең сумнан, шуның өстенә квартир өчен, су өчен, елыту өчен, телефон өчен, натуральный век (?) дип, налог түләп киләм, халыктан бер тиен ярдәм юк, мөтәвәллият булса, бездән көлүдән башка эше юк. Диния Нәзарәте мөфти-хәзрәт диеп сөйләсәк, мөфтинең монда эше юк, аның бездә катнашы юк дип, Нәзарәтне тәгъриф итмиләр, мөфти – үзендә мөфти, диеп кенә тора председатель.

Мәхәллә идарәсе тәмәке тарта торган бүлмә булып калды. Бар да тәмәке тарталар. Идарәне, внутренний замоктан тыш, әллә ничә йозак белән биклиләр, халык бездән хәтер саклап, аларга бер сүз әйтми. Халыкның монда эше юк, егермәлек хүзә дип торалар, ләкин аксаны халыктан алалар.

Ленинград мәхәлләсенә сезнең килмәвегез зур уңайсызлыклар тудырды. Ленинград мәхәлләсе икенче ел инде инкыйразга йөз тотып дәвам итә, Хода хәерлесен кылсын. Бербер бәлагә калмый, сәламәт котылып буламы юкмы, хәерле булсын. Нәзарәтнең шулкадәр көче бетүгә гаҗәп итеп торабыз, һичбер эштә хакы булмавы гына түгел, имам-мөәззин кую да Нәзарәттән башка булдырылу – бу инде гаҗәп кенә түгел, залим патша заманында ислам дине агрылык (=авырлык) белән барса да, губернатор мөфти шаһәдәтнамә бирми торып бирми иде, хәзер ирекле булсак та, бу турыда искитәрлек эшләр Нәзарәт шаһәдәтнамә бирми торып, ничек хөкүмәт регистрация итәргә мөмкин, мин гаҗәп итәм. Бәлки бу эшләр сезгә мәгълүмдер. Ну безнең уполномоченный: «Нәзарәтнең монда эше юк, халык сораганны без регистрация ясыйбыз», - ди һәм минем сездән шаһәдәтнамә булмый торып регистрациядан уздырды, мөтәвәлият язуы белән.

Димәк, сезнең көчтән өч кешенең көче югары дигән сүз.

Мөхтәрәм хәзрәт, менә бу турыда мөтәвәллияткә берәр төрле кулланма язарга хокукыгыз юкмыни? Әгәр булса, язар идегез. Мөтәвәллият тә берәр төрле фикердә булыр иде һәм бу эштә Нәзарәтнең шәрган хокукы барлыгын белерләр иде.

Бездә бит хәзер күп яңа мөтәвәллият, алар Нәзарәт хакында болай да сөү заннда, уполномоченныйларның да кайберләре нык рәвештә яман күрсәтә, шуның белән Нәзарәт һәм бер бәһале урын тота алмый.

Гафу итәсез, өйрәтеп язмадым, ләкин практически булганны яздым.

Мәгал-ихтирам Габделбари
1962 ел, 24 гыйнвар.

Мөхтәрәм мөфти-хәзрәтләре!

Әс-сәламү галәйкүм вә рәхмәтүллаһи вә бәрәкәтүһү!

Аллаһ Тәбарәкә гомерегезгә хәерле бәрәкәт биреп, мәканегезне мөбарәк итеп Европа мөселманнарының Кәгъба мөгаззәмә урынында булган Диния Нәзарәтендә чын туры хезмәтегезне тәкъдир итүләренә игътибарән, мин дә үз тарафымнан гаять шат-мәсрүр булып, сез гали җәнабләрнең соңгы вакыттагы хезмәтегезгә карата ошбу шигыремне тәртип итеп, сезгә һидия итәмен.

Мөхәммәдия көенә.

Исең киткеч гаҗәп хәлләр
Үтеп китте гомерләрдә
Ничә төрле фикерләр
Кермәде безнең күңелләргә.
Каюлар әйтә: «Мин – изге,
Ә башкалар – Явыз», - дип.
Шулай алар талашалар,
Гомерне уздыралар тик.
Фикерләре үтә ханән,
Ник аңламыйлар, белмиләр.
و اعتصموا بحبل الله
Юлына һич кермиләр.
Менә шундый тәрәккыйсез
Таралашкан дәверләрдә,
Каюлары һәлак булып,
Кереп китте каберләргә.

Болар бар да галимнәрдер -
Рәсүл, Хода варисләре,
Талашу да, таралышу –
Карап торсаң, бар эшләре.
Гомерләр үтәдер бушка,
Фикерләр килмидер башка,
Әсәр итми хәдис, Коръән,
Чын әйләнгәч караташка.
Теләсә нәрсә эшлибез.
Ходаның әмере безгә ни?
Кая хаклык, кая инсан?
Бар бездә ике яклы.
Күз алдында җылап, алдап,
Ышандыру халыкларны.
Менә шулай әзерлибез
Җәһәннәмгә азыкларны.
Мөселманның йөзен җырту,
Гаепләшеп сөйләү, хурлау,
Үзен-үзе «шәех, суфый»
Дигән исем белән зурлау.
Бу гадәтләр барысы да –
Имамнарда, галимнәрдә.
Тыш – якты, эче ялган
Булып йөргән залимнәрдә.
Белә микән бу галимнәр
Кыямәтнен киләчәген?
Хода хозурында, мәхшәрдә
Ничек җавап бирәчәкне?
Үлеп китсә бу дөньядан
Галим булган икейөзле,
Кыямәттә кубарылыр
Ишәк сыйфат кара йөзле.
Гафил булма, әй галимнәр,
Әҗәл килеп тотачак бер,
Исә алмаган фани дөнья
Күкрәк кереп ютачак бер.
Килеп житәр Хода әмере,

Менә шунда ачылыр йөз.
Нурын арттырыр иманлы,
Кара булыр монафикъ йөз.
Ләкин дөнья ирек бирмәс
Галим булган залимнәргә.
Хакыйкатен ачу өчен,
Җибәрде ир бу илләргә.
Җиһанга тугды чын тугры
Өйрәтүче Хода хөкемен.
Мөселманнар өчен якты,
Сәгадәтле, гали бер көн.
Чапан, чалма киеп тештәр,
Эченнән алдаган мулла
Җәһәннәмгә туры китте,
Гомергә калачак шунда.
Мөселманнар, кардәшләр,
Тугры китик без ихсанга,
Дога итик, – дөрес варис
Булып килгән бу инсанга.

# Мөхәммәд-Парса Ахатовка (Киев шәһәре)
## шәхси хатлар[1]

Бисмиллаһир-рәхманир-рәхим

Мөхтәрәм дустым, әл-Барса! Сезләргә, абыстайга һәм балаларга сәламәтлек, хәерле гомерләр теләп, уңышлар теләп, дога-сәламнәребезне күндерәм. Әс-сәламү галәйкүм вә рәхмәтүллаһ!

Мөхтәрәм дустым, үзем сау-сәламәт, әлхәмдүлиллаһ. Мөкаддәс хезмәтебезне бик гүзәл алып барабыз, әлхәмдүлиллаһ.

Хәдимнәребез дә барчалары да сау-сәламәт булып, өсләренә төшкән вазыйфаны бик яхшы ида кылып баралар. Хәзердә барлык хезмәткәрләребез яшьләр, 40 яшь тирәсендәге балалар, бик итагатьле хезмәт итәләр. Картлар үзләре суфыйга әйләнгән инде. Алар белән хисаплаштык, әлхәмдүлиллаһ. Барлык мәхәлләләребез дә бу көндә тыныч, имамнар белән тәэмин ителгән, бик күңелле торабыз.

Үзебезнең гаиләм, ягъни абыстай килгәне юк әле. Улым Гали ошбу кышта диплом язачак. ИншәАллаһ, яз башына килерләр. Минем өчен хәзердә алар булмау бик борчымый, чөнки мин күп вакыт сәфәрдә булам. Әле менә Ташкентта бөек мөселманнар конференциясе булды. Чит илләрдән мөселман галимнәре күп килгән. 2 октябрьдән 9ына кадәр булдырылды. Бик күңелле булды. Конференция гарәп телендә уздырылды. 13 октябрьдән 18енә кадәр шул делегатлардан кыйсман Уфада булып үттеләр.

Хәзердә эчке хезмәтләр белән утырабыз һәм хаж сәфәренә халыклар хәзерләп ятабыз. Мәдрәсәгә шәкертләр җибәрдек. Укып яталар, әлхәмдүлиллаһ.

Дустым, сезнең хат, гомумән, шул бүген алган хатлар бер ай йөргәннәр, хәерле булсын.

Инде улыгызның соравына җавап:

1. Әнәс (разый Аллаһү ганһү) бик күп хәдисләр риваять иткән. Сәхәбәнең исеме һәм әү гашәр мөбәшшәрәдер, ягъни рәсүлемез (салла Аллаһү галәйһи вә сәлләм) үзләре ун кешене: «Сез җәннәтлек», - дип, сөенеч белдерде. Берсе – Әнәс (разый Аллаһу ганһүмә). Улыгыз да җәннәт әһеленнән булсын. Әмин.
2. Әнәс - гарәп телендә адәм баласы дигән сүз. Бер булганда, Әнәс диленә, күп булганда, инсан диленә. Ягъни, дөрестә, адәм баласы һәм гашәр мөбәшшәрә булган адәм баласы.

---

1. Бу хатларны эзләп табучыга, ислам белгече Денис Брилевка, ихлас рәхмәтләребезне житкерәбез. Хатлар шәхси архивта саклана.

Көннәребез дә хәзердә салкын.

Мин Рамазанда ялда Ленинградта идем. Әле тагын 3 ноябрь 15 көнгә ялга киттем Ленинградка.

Мәгал-ихтирам, дустың мөфти Габделбари Низаметдин Гайса.
23 октябрь (77 ел)

Әс-сәламү галәйкүм!

Мөхтәрәм кардәшебез әл-Барса! Сезләргә вә абыстай-балаларга сәламнәр күндереп, сәламәтлек, хәерле гомерләр теләп калам.

Бәгъдә, үзем һәм хәдимнәр сау-сәламәт хезмәт итеп ятмактабыз. Әхвәлебез бердән-бер яхшы, әлхәмдүлиллаһ. Сирәк булса да, мәчетләр ачылып тора. Гыйбадәт йортлары да ачылып тора, әлхәмдүлиллаһ. Таләбәләребезне дә быел, иншәАллаһ, арттырачаклар дип шатланып торабыз. Тәмам итүчеләр җирдән имам ителеп тәгаен ителеп торалар, әлхәмдүлиллаһ. Бу көндә мөхтаҗлык юктыр. Мәчетебезгә алты ай куйдык 19 май, бәйрәм ителде. Хода дәвамын насыйп итсен.

Гаиләбез быел Рамазанга күчеп килә дип көтеп торабыз. Истикъбаль хәерле булсын.

Сезнең фидья турында соравыгызга җавап:

Бу турыда 1931 ел Нәзарәтнең 42нче санлык фәтвасында шулай диелгән: «Давыр итү дөрес түгел, шәригатьтә хәйлә юктыр. Фидья әгәр мәет малыннан васыять итеп калдырса, моннан бер кыйсемне вәлиләр фидья бирергә важибтер. Калганы руза, намазлар һәм витр намазы да шунда керә. Әгәр васыять итмәсә, бу вакытта вәлиләр теләсә бирә, әлбәттә, бирү күпкә хәерле эштер. Ләкин мәетне фидья бирми күмү – шәригать каршында дөрестер».

Мөфти Габделбари Низаметдин. 24 июль.

Икенче сөаль. Кирәк, аерым кеше малын урласын, кирәк җәмәгать малын урласын – хөкем бердер: وَالسَّارِقُ وَالسَّارِقَةُ فَاقْطَعُوٓاْ أَيْدِيَهُمَا аять кәримәсенә бинаән, дөнья хөкемендә хөкем ителергә тиешле. Моның соңында Аллаһ гафу кылачак.

Өченче сөаль. Китапларым тәмам язылып бетте, ләкин бастыра алмыйбыз.

1. Ислам динендә намазның хикмәт фәлсәфәсе. Иман игътикады, намаз, тәһарәт, догалар – һәркайсының хикмәтләре Коръән белән

тасдыйк ителеп тәртип ителде.

2. Айга сәяхәт мөмкинме? Ай нидән гыйбарәт, айда хәят булу мөмкинме? Коръән хөкеме буенча ай планетага керәме?
3. Йәһүдләр дине хакында
4. Гайсә пәйгамбәр хакында
5. Коръән хөкеме буенча ничә пәйгамбәр-әнбия Аллаһ исемендә вә гайреләр.

Тәфсир тәмам булып, рус хәрефе белән 30 җилд итеп хәзерләнеп бетте һәм хәзердә русчага кызым күчерә. Ул университетта гарәп теле укытып тора, аспирантура бетергән. ИншәАллаһ, тәмам итүе белән биреп карарбыз. Ничек карарлар. Минем тәфсир свободный тәфсир ителеп язылды.

Моның соңында хәдис ән-нәбәвия дигән бер заманга муафыйк хәдисләр китабы язып, русча хәм татарча тәрҗемә белән тапшырган идем. Зур түгел генә. Узган ел тапшырдым. Бүген дә җавап юк әле.

Менә дустым, минем әхвәлем шулар.

Моның соңында, мәүлид ән-нәби турында саф татар телендә киң рәвештә язган китабым бар. Моның соңында, бер ел эчендә була торган 53 җомга өчен хосусый хөтбәлек китабым бар. Ләкин болар басылмый, һәркайсы русчалаштырып, хөкүмәткә тапшырылган. Милләт телендә балалар кулында да саклана. Менә, туганкай.

Хуш, сәламәт булыгыз.
Дустыгыз мөфти Габделбари кари.
17 февраль

Бисмиллаһир-рәхманир-рәхим

Мөхтәрәм дустым әл-Барса, сезләргә һәм абыстай-балаларга сәламәтлек, хәерле гомерләр теләп, дога-сәламнәре бәгъдендә, әс-сәламү галәйкүм вә рәхмәтүллаһи вә бәрәкәтүһтер.

Әмма бәгъд, үзем, әлхәмдүлиллаһ, сау-сәламәт булып 3 апрель сәфәрдән килдем. 3 һәфтә сәфәрдә булдым. Мәскәү, Ленинград сәфәрендә хезмәт шул. Ошбу ел Мәскәүдә бөтен дөньядагы дин җитәкчеләренең олуглары тарафыннан булачак 1977 елда диннәр буенча киң күләмдә мирный конференциягә хәзерлек мәҗлес булып ун көнгә тартылды. Һәрбер мәмләкәттән һәртөрле дин әһелләре җыйналган иде. Русиядән дә мөселманнардан дүрт мөфти һәм ярдәмчеләр, секретарьләр дәгъват ителгән иде. Ошбу мәҗлестән арып кайтып,

без бер көн ял итеп, хәзердә рәсми мәхәлләләргә ашыгыч хәлдә мөрәҗәгатьнамә язып таратабыз. Бу инде Израильнең Мәсҗед Акъса бозып, анын урынына һәлак куюга чыгарган карарына караш була, протест.

Мәскәүдә дүрт мөфти телеграм бирдек. Хәзер инде мәхәлләләрә демонстрация формасында үткәреләчәк. Хәерле булсын. Инде сөальләрегезгә җавап шулдыр:

Коръән яки Йәсинне язу һәм укыту мәсләхәт һәм дөрестер. Салават әйткәндә, аягүрә кулны ялгау - ул ихтирам йөзеннән гадәт. «Коръән Кәрим аягүрә итегез», - димәгән. «Салават әйтегез», - дигән. Шулай булгач, Аллаһ Җәллә Җәләлә, ихлас күңелдән булса, аяк үрә бассаң да, басмасаң да, кабул итәр, иншәАллаһ.

Менә иганә турында минем киңәш: син ул эшне эшләмә. Аның ахыры яхшы булып чыкмас. Гомумән, мәҗлесләрдә иганә җыю мәмнүгътер. Бу турыда, иншәАллаһ, очрашканда сөйләшербез.

Мәгал-ихтирам, дустың мөфти Габделбари Гайса. 6 апрель.

Мөхтәрәм дустым, әл-Барса, абыстай һәм балалар!

Җөмләгезгә сәламәтлек, хәерле гомерләр теләп, дога-сәламнәремезне күндерәбез.

Әмма бәгъд, Диния Нәзарәтендә хезмәт итүчеләрдән җөмләсеннән сәламнәр күндерәбез. Үзем сау-сәламәт, әлхәмдулиллаһ, хезмәтемдә дәвам итәм. Гаилә әле килгәне юк. Торам һаман гостиницада. Күндермеш мәктүпне алдым, рәхмәт.

Сөальләргә җавап: тәкъвим хәзерге көндә генә булмас әле. ИншәАллаһ, истикъбаль игътиярга алырбыз.

Мәетне баш белән яки аягы белән чыгару турында. Ул дөрес китапларда аягы белән чыгаруны мәслихәт кылганнар. Булмаса, шәригатьтә аяк яки баш белән чыгару һич файда бирмәс, әгәр иман зәгыйфь булса. Ә бу бездә барыбызда да бар, иманнар саф түгел. Мәҗлесләрдә юк-бар сүз белән белер-белмәс фәтва бирү – үзе иманның зәгыйфьлеге. Надан булса да, үзен күрсәтергә тырышу. Бу инде катгый иман зәгыйфьлеге. Ләкин мин шуны әйтәм: баш яки аяк белән чыгару – кечкенә мәсъәлә, ләкин иҗма өммәт, ягъни бездән әүвәл булып узган өммәтләр, аяк белән чыгаруны мәслихәт тапкан.

Бу инде дин юлы белән түгел, бәлки, югары урыннардан мәетне төшергәндә, баш түбән булып, хөрмәт югалту булуы игътибар ителгән. Бу исә, Рәсүлемезнең:

«Мәетләрне терек хәлендә әкъбәр хөрмәт итегез, бәреп-сугып игътибарсыз йөртмәгез», – дигән хәдисеннән алынган. Шулай булгач, игътибар һәрхәлдә ләземдер.

Муса хәзрәтнең «Рәхмәт илаһия»не әле карарга бер дә вакытым юк. Хезмәт бик күп. ИншәАллаһ, истикъбаль сәфәрегездә бер-ике көн торып калсагыз, мин дә өйдә вакыт туры килсәм, иншәАллаһ, тәэмин итербез.

Мәгал-ихтирам, мөфти Габделбари Низаметдин.

24 февраль.

Вә биһи.

Хөрмәтле дустым, әл-Барса, абыстай һәм балалар. Җөмләгезгә дога-сәламнәр белән хәерле теләкләрдә калдым. Әс-сәламү галәйкүм вә рәхмәтүллаһ!

Бәгъдә, үземез сау-сәламәт булып, хезмәтләремезне алып барабыз, әлхәмдүлиллаһ. Язылмыш мәктүбегезне алдым, рәхмәт, ләкин сезләрнең моннан мокаддәм хатыгызга җавап бетерә алмый калуыма гаҗәпкә калдым. Хәерле булсын, хезмәт күп булып, ихтимал хәтердән чыккандыр, чөнки бу араларда бик зур хезмәтләр булып тора. Кунаклар да чит илдән уздырырга берничә тапкыр туры килде.

Бәгъдә, бу хәлләрдә дустым мин бер өч айлардан тәмам алып бара торган хезмәтемне эшләп бетәрмен дип өметтә идем. Хезмәтем шул хәзер инде, яшерен түгел. Мин шул 12-13 еллар Корьән тәфсир иттем, ике формада: берсе – тәртип белән, берсе темалар – белән (тематически).

Хәзердә шуны русча тәрҗемә итеп ятам, бәлки бастырырлар дигән өмет белән. Тәрҗемәм гарәп хәрефе белән дә эшләнде һәм хәзерге русча татар хәреф белән дә эшләнде. Менә шул хезмәткә көннең күп вакыты уздырыла. Ничек булып чыгар.

Аннан соң әхәдис ән-нәбәвиядән бер исборник язган иде. Аны һәм тәрҗемә иттем. Ничек булып чыгар.

Менә, туганкай, эшем шулай тора. Мәхәлләләр тыныч, әлхәмдүлиллаһ. Тик олуг имамнарыбыз үлеп тора. Челәби имамы вафат булды. Иҗәуски имамы вафат булды. Воткинский имамы вафат булды. Ишимбай имамы Габделбари казый, картлык сәбәпле, чыкты. Шулай итеп, бу хафта шундый зур эшләр булып китте. Хәерле булсын. Хуш сау булыгыз.

Хөрмәт белән дустың мөфти Габделбари кари

11 апрель

Хатлар алдым Ленинградта.

Әсгадәкә Аллаһ фид-дәрәйн!

Мөхтәрәм дустымыз әл-Барса, абыстай һәм балалар, җөмләгезгә дога-сәламнәр хәрле сәламәтлек теләп сәламнәремезне күндерәбез. Әс-сәламү галәйкүм вә рәхмәтүллаһи вә бәрәкәтүһ!

Үзебез, абыстай, балалар сау-сәламәт булып истикъбалебез фи әмриллаһтер.

Әмма бәгъдә, күндерелмеш мәктүбегезне алдым, рәхмәт. Сау-сәламәт икәнегезне белеп, мәсрүр калдык. Җәнәб Аллаһ җөмләбезгә сәламәтлек, тынычлык насыйп итсә иде. Әмин.

Соралган сөальләргә кыскача җавап язам, иншәАллаһ, аңлашырсыз.

Беренче: «һәрбер сөальгә сезнең фикерегез ничек?» - дип соралган. Мөхтәрәм дустым, әхкам шәргыяләр кешеләрнең фикерләренә мохтаҗ түгел. Ислам диненең дәстүр әл-гамәл булган Коръән Кәримдер вә хәдисән-нәбәвиядер. Әгәр дә аны аңлаучы-белүче булса. Менә шуны аңлаучылар булмаганлыктан, шундый урынсыз-мәгънәсез фәтвалар һәм вәгазьләр дә килеп чыгадыр.

Аллаһ Тәбарәкә Коръән Кәримдә قُلْ هَاتُوا بُرْهَانَكُمْ إِن كُنتُمْ صَادِقِينَ дип җавап бирәдер, ягъни шәригатьне сөйли икәнсен, Коръән Кәримнән яки Рәсүлебезнең сахих булган хәдисләреннән укып күрсәт диеп әйтәдер. Кабер җиргә кую Коръән хөкеме буенча ثُمَّ أَمَاتَهُ فَأَقْبَرَهُ аятьтер. Рәсүл икрам (салла Аллаһ галәйһи вә сәлләм)[1] اللحد لنا والشق لغيرنا димештер, ягъни: «Ләхеткә кую безнең ислам милләте өчен, шах – ягъни торга, табут – белән кую башка милләтләр өчендер», – димештер. Зарур булмаганда, ләхеткә кую әфсалдыр. Бу сөннәте адәм галәйһис-сәлам, сөннәте хәлил Ибраһимдер, сөннәте Нәби (салла Аллаһ галәйһи вә сәлләм). Зарури бу кушылыр, мәет машина асларында калып таралган, җыю мөмкин түгел булса, аерылган булып, ачарга рөхсәт ителмәсә, каберлекләрдә ләхет алырга мөмкинлек булмаган урыннарда булса, бу вакытта табут (гроб) белән куеладыр. Әл-хасыйл, һәр тарафта игътибар тотылып дәфен ителәдер. Гайс (катастрофа) заманда табут белән кую бигрәк зарурдыр, чөнки каберләрне күчереп торалар, мәетләрне күчерергә рөхсәт ителә. Табут белән булса, җиңелрәк буладыр. Нитәк, Муса пәйгамбәргә Аллаһ Тәбарәкә Йосыф пәйгамбәребезне Мисырдан күчерергә табут белән күчерүне боерды. Хәзрәт Гали кәррәмуллаһ вәҗһәһү сугыш сакларында үлгән иде. Балалары Хәсән, Хөсәен (разый Аллаһү ганһүмнәр) табут белән алып, Касрател-өмәрә дигән

1. Ибн Маҗә җыентыгыннан.

җиргә күчерде. Димәк, зарури булганда, дөрестер. Кадаклап кую турында бер зарар да юк, әгәр кирәк булса. Аллаһ Тәбарәкә вә Тәгаләнең кодрәте суырып алыр. Әмма кирәксенсә, ягаулап та куяр, Хода үзе сакласын.

Чәчәкләр һәм кара ленталар белән чорнау турында. Мөселманның үзе өчен, ягъни үз көче белән ихтыяры бу эшне эшләү дөрес түгел. Беренче – исраф. Исраф – хәрәм. Икенче: бездә чәчәкнең файдасы тими, доганың файда тия. Дога белән зиннәтләү, әҗер вә саваплыдыр. Агач вә чәчәкләрне каберләр өстенә утырту әҗерледер, чөнки يُسَبِّحُ لِلَّهِ مَا فِي السَّمَاوَاتِ وَمَا فِي الْأَرْضِ аять ягъни: «Алар зикер-тәсбих әйтеп утырырлар». Әмма хезмәт тарафыннан, ихтирам йөзеннән бизәкләнгән чәчәкләр, ленталарны мәнгы итәргә ярамый, рәхәтләнеп куйсыннар. Аларның безнеңчә әйткән догасы шулдыр. Әһле дин булмаган кешеләрнең бу чәчәкләреннән мәеткә зарар юктыр, иншәАллаһ.

Фәхриләрнең һәм мөстәфтиләрнең вәгазь сөйләвенә карап, шәригатьне аңлаган кеше гамәл кылырга ярамый, чөнки алар нинди китап ягъни хорафатбидгать китабы күрсәтә, шуны шәригать дип беләләр. Үзләрен надан халык арасына күрсәтүгә шул да җиткән. Хәдис рәсүлгә һәм Коръән аятьләренә кайтып гамәл итүгә буйлары җитмидер. Шулай, аларның фикерен шәригать итеп тану – зур хатадыр һәм дә гөнаһтыр.

Уфадан килгән Терегулов хакында. Ул Ризаэддин Фәхреддин хәзрәтләренә кардәше булуы мөмкин түгел. Хәзрәт мәрхүм башкорт таифәсеннән иде, ә Терегуловлар – алар, Уфада торса да, Пенза мөселманнары. Мин шуны беләм. Ризаэддин хәзрәтнең дворяннар нәселеннән Терегуловлар дуслары бар иде. Шулар нәселе булса кирәк. Сүзнең кыска, Ризаэддин хәзрәт тә, һәрбер әһле галим һәм без дә, әлхәмдүлиллаһ, Рәсүлемезнең хәдисенә һәм Коръән Кәримгә әсасланып җавап бирәбез. Үз фикеребезне дин итеп сөйләргә һичкемнең хакы юктыр һәм олуг гөнаһтыр. Үзегезне, әстәгыйзүбиллаһ, Аллаһтан олуг тоту буладыр. Хода сакласын.

Кәферләргә садака дөресме хакында.

Садакалар хуҗасына бирелү ләземдер وَ آتِ ذَا الْقُرْبى حَقَّهُ وَ الْمِسْكِينَ وَ ابْنَ السَّبِيلِ وَ لاتُبَذِّرْ تَبْذِيراً аять шулай булгач, садака сахибе булган кеше ризыкланырлык башка җирдән килүләре булмаса. Хезмәт кылып тамак туйдырырга көче җитмәсә, ягъни садака иясе үзенең хәятен саклау өчен садака алгач. Бу инде синең садакаң, дингә карамый, кешенең хәятен саклау өчен буладыр. Димәк, бирергә дөрестер. Әҗерең – гамәлдәндер.

Кәфер юк бит ул. Алар бар, ләкин алар садакага мохтаҗ түгел. Садака алмыйлар да, әмма башка диннәр халыклар, мөшрикләр, мәҗүсиләр - боларның

садакасы дөрес булмаган. Будда динендә булучылар, марилар һәм йәһүдиләрдер. Алардан башкалар китаби диеленәдер, ягъни Аллаһны тәгъриф кыла, ләкин вәхдәният турында башка китапка ышана. Менә боларга дөрестер. Әмма хәзер дә шуны нык сакларга кирәк. (أفضل الصدقة على أهله) Хәдис шулай булгач, әҗере күп булганы – ислам динендә булучыларга бирүдер.

Витр намазы турында. Җәмәгать бүлеп укыганда, имам торучы Рамазан шәриф аенда өч рәкәгатьтә кыйраәтне кычкырып укыйдыр. Имам Әгъзам Әбү Хәнифә хәзрәтләренең фикеренә бинаән безләр хәнәфи мәзхәбе, ягъни безләр Рамазанда җәмәгать белән укыганда, кычкырып уку ләземдер (مذهب الاربعة беренче җилд китабында).

Мәетнең өстендә хәтме Коръән хакында.

Мәетнең өстендә дә, артында да, кайда да хәтме Коръән дөрестер, хәтта ләземдер. Кирәк мәет пакьләнгән булсын, кирәк пакьләнмәгән булсын – Коръән хәтем ителер. Рухларга рухлар пакьтер. Әгъзаларга хәтем ителмидер, ягъни рухларга җиңеллек булсын өчен, хәтме Коръән ителәдер. Ләкин әйтелмеш хәтме Коръән акча бәрәбәренә булмасын, сатулашып мал алу – хәрәмдер, монафикълык сыйфатыдыр. Ихтыяры бирсә, садака бүлү белән дөрестер.

Рәсүл икрам заманында Коръән укып, башка милләт халыкны да өшкергәннәр. Садака алганнар. Рәсүлебез дөрес дигән хәдис: إن أحق ما أخذتم عليه أجرا كتاب الله (Бохари) һәм خُذْ مِنْ أَمْوَالِهِمْ صَدَقَةً تُطَهِّرُهُمْ وَتُزَكِّيهِم بِهَا وَصَلِّ عَلَيْهِمْ ۖ إِنَّ صَلَاتَكَ سَكَنٌ لَّهُمْ ۗ وَاللَّهُ سَمِيعٌ عَلِيمٌ

Мәетне ачып карау турында.

Дөрес, халык арасында сөйләнгән «тәһарәте сына» дигән сүзләр – болар хата сүзләр. Һич зарар юк, рәхәтләнеп карасыннар. Ул хәбс әгъза, аңа һич зарар килмидер. Башка милләтләрнең мәетләрен карау, мәет узганда тәгъзия өчен басып тору – Аллаһны, Аллаһның әҗәлен ихтирам итү буладыр (نهجة البلاغة 3 нче җилд).

Мәетләрнең өчләрен, җиделәрен уздыру турында.

Бу уздыру әсхаб кирамнар заманында хасыйл булган (=барлыкка килгән), ләкин Рәсүлемез (салла Аллаһү галәйһи вә сәлләм): «Мәетләрне беренче елларында ешрак искә алыгыз», - дигән хәдисне әйтәдер. Ошбуга бинаән уздырыладыр, ләкин 3-7-40 көн булу шарт түгел. Уздыру – шарттыр. Димәк кайчан җитешсәң, шунда уздыру дөрестер. Моннан максат – Коръән укылып, моның соңында мәетнең сәламәт вакытын күз алдына китереп, ахыр вакытта Аллаһның әмере белән менә бу хәлгә калуына игътибар ителеп, бүген барлык

адәм балаларына да киләдер. Гафил тормагыз, сезгә дә бу хәл киләчәк. Ошбуның өчен ошбу мәҗлестә Аллаһка истигъфар итик, бер-берләребез белән бәхилләшеп китик, дигән тәртиптә вәгазь ясалырга тиешледер. Шулвакытта гына укылган Коръән рухларга ирешеп, аларны шатландырыр. Булмаса, мәҗлескә җыелып Коръән укып, садака алып кына китү - хәтта хәрәмдер, әстәгыйзүбиллаһ.

Хуш, сәламәт булыгыз. Ихтирам белән Габделбари кари хәзрәт.

Мөбарәк булсын Рамазан шәриф.

8 сентябрь

9 февраль

Әсгадүкә Аллаһ тәгалә фид-дәрәйн

Бәрәдәр мөхтәрәм әл-Барса!

Сезләргә Хак Сөбханә вә Тәгаләдән сәламәтлек, хәерле гомерләр теләп, сәламнәребезне күндерәбез. Әс-сәламү галәйкүм вә рәхмәтүллаһи вә бәрәкәтүһ!

Әмма бәгъд: абыстайга һәм балаларга сәламәтлек хәерле гомерләр зур уңышлар теләп калабыз. Үзебез һәм әһле гаиләбез бу көндә чок сәламәт, әлхәмдүлиллаһ. Истикъбаль фи әмриллаһ. Күндерелмеш мәктүбегезне алдым, рәхмәт.

Дини мәсъәләләрдә мохтаҗ эшләрегез булса, сорагыз, иншәАллаһ, изахы җавап бирербез.

Коръән Кәримдә, әстәгыйзүбиллаһ, **فَاسْأَلُواْ أَهْلَ الذِّكْرِ إِن كُنتُمْ لاَ تَعْلَمُونَ** аять кәримәсенә бинаән шәригать хөкеме нык дөрес белүчеләрдән сорау – намаз кеби фарз дәрәҗәсендәдер. **فَاسْأَلُواْ أَهْلَ الذِّكْرِ** дәге фа **فاء معجل** диленә, ашыгыч хәлдә сорау – фарз гамәленнәндер. Сорауларга җавап бирү - сәламне кайтарган рәвешле фарыздыр. Әл-хасыйл, әһл булган кешеләргә җавабымыз һәр сәгать хәзердер, иншәАллаһ.

Мәгал-ихтирам әл-хафиз кәләмүллаһ әл-хаҗел-хәрәмәйн

Габделбари Гайса.

Әс-сәламү галәйкүм!

Мөхтәрәм дустым әл-Барса, сезләргә, абыстай вә балаларга, шулай ук бик хөрмәтле әнкәгез шәрифләренә безләрдән сәламнәр белән хәерле теләкләр җибәрәбез.

Мөхтәрәм дустым!

Сорауларга җаваптан алда шуны белдерәм. Сез бик бәхетле икәнсез, әлхәмдүлиллаһ. Сезләрнең йәүм кыяматтә ярдәмчегез бар икән, әнкәгез бар икән. Беренче, аның кыямәт ярдәме булуы хакында Рәсүлебез (салла Аллаһү галәйһи вә сәлләм) хәдисләрендә ачык белдергән: فإذا بلغ تسعين غفر الله له ما تقدم من ذنبه وما تأخر، وسُمي أسير الله في أرضه، وشفع لأهل بيته ягъни: «Бер бәндә туксан яшькә ирешсә, аның гөнаһларын Аллаһ гафу итә, гөнаһ кылса да язылмый, әһле бәйтенә шәфәгате тия. Аллаһның рәхмәт фәрештәләре: «Бу кеше дөньяда плен булып калган», - диячәкләр». Әлхәмдүлиллаһ, шәфәгате тиячәк.

الجنة من تحت الاقدام امهات хәдис: «Җәннәт – аналарны ризаландыручыларга хастыр».

Бер кеше карт көнендә өгъми (=сукыр) булып шуңа разый булса, тәхкыйк, җәннәт әһеле. Инде өгъми кешегә ярдәм итүче дә җәннәт әһеле, ягъни өгъмәне кырык адым атлауга ярдәм итүче дә җәннәт әһеле.

Бәгъдә Коръән Кәрим ادْخُلُوا الْجَنَّةَ أَنتُمْ وَأَزْوَاجُكُمْ تُحْبَرُونَ ягъни «Син үзең җәннәт әһеле булсаң, Аллаһ әмер итә: үзең һәм әһле бәйтеңне бер дә курыкмыйча җәннәткә алып кер», - дип менә, туганкай, дөрес рәнҗетми тәрбия бирә алсаң, син һәм әһелең җәннәт әһеле булачаксың, иншәАллаһ.

Бәгъдә, сөальләргә җаваплар:

Хур кызлары каршы алу хакында Коръәндә бер генә аять түгел. Алар ирләр өчен дә, хатыннар өчен дә иңгәндер. Голамаи көббар Мөхәммәд Габдүһ Мисыр мөфтисе «Әл-Манар» дигән тәфсирендә шул дөнья хәятендә хәләл булып, гамәл кылучы ир вә хатын – хур кызлары, хур егетләре булачак дип изах бирә, чөнки язып узган идем, ادْخُلُوا الْجَنَّةَ أَنتُمْ وَأَزْوَاجُكُمْ تُحْبَرُونَ, ягъни бер дә куркусыз, бер-берләренә, җәннәткә керү өчен, ярдәм итәчәкләр, иншәАллаһ.

Әсгадүкә Аллаһ тәгалә фид-дәрәйн!

Мөхтәрәм әхбәбем, әл-Барса, сезләргә һәм абыстайга, балаларга сагынып сәламнәр белән сәламәтлек, хәерле гомерләр теләп калабыз. Мәгълүм дустыгыз Габделбари кари, абыстай, балалар. Әс-сәламү галәйкүм вә рәхмәтүллаһи вә бәрәкәтүһ вә хәсәнәтүһтер.

Әмма бәгъд, мөхтәрәм әхбәбем, күндерелмеш мәктүбегез алдым, рәхмәт булсын. Үзем бу хаттан мөкаддәм хат язган идем, иншәАллаһ, тапшырылгандыр. Гарәп кардәшебез Мөхәммәд әл-Мөхсини артыннан һәм хат җибәргән идем.

ИншәАллаһ, тапшырылыр дип калабыз.

Үзебезнең әхвәлгә килсәк, бу көндә, әлхәмдүлиллаһ, сау-сәламәт булып, киләчәк фи әмриллаһтер.

Әмма бәгъдә, соралган сәальләргә җавап ошбудыр: ислам диненең әмере дүрт нәрсәгә тәмәссек итәдер: китап, сөннәт, иҗмаи өммәт, кыяс. Китап – Коръән Кәримдер, бу турыда Коръән Кәримдә хәбәр бармы? Сөннәт нәбийина мөхтәрәмебезнең сәхих булган хәдисләредер. Бу турыда берәр төрле хәбәр бармы? Иҗмаи өммәт әүвәлдәге голамаләребез бу турыда ничек гамәл кылганнар? Кыяс – үлчәп карау, ягъни берсендә белмәсәң, гакыл мизанына салып карыйсың. Шул эшли торган эшең ислам диненә зарар китерәме, юкмы. Башка адәм балаларына зарар китерерлек түгелме, төрле тарафлардан үлчәгәннән соң, гакылга муафыйк булганы шәригать итеп таныладыр. Менә бу турыда да ягъни мәетнең ләхәткә куйгач битен ачык кую беленде. Бәйләгән бавын чишү, бу ихтыярлы эш: теләсә ачып куя, теләсә юк. Үзегезгә мәгълүм, әгәр кирәк булса, ягъни ачарга кирәк булса, Ходаның кодрәте ул чүпрәкләргә генә көче җитәдер. ИншәАллаһ, хәтта йәүм мәшхәрдә каберләребездән кубарып гарасат майданына итәчәк. Шаять, кәфеннәрне ачарга кодрәте җитәдер. Шулай булгач, бу турыда дингә һич зарар юк, ләкин битне ачу һәм билне чишү гадәт буенча гына булса, бер зарар да юк, тик эшләсеннәр. Әмма, чын күңелдән, билен чишә алмый, битен ача алмый калыр дип ачып кую – мөшреклек буладыр, ягъни Аллаһ кодрәтеннән үзеңнең фикерне өстен тоту була. Болай булганда, әстәгыйзүбиллаһ, Аллаһтан үзеңне югары тоту була, бу бик хәвефледер. Ошбуның өчен мөселманнарны төшендерү юлы белән бу эштән калдыру хәерледер, чөнки бәндәләргә ул көннәр килгәндә, ягъни якыннарыннан кем булса вафат булган вакытларда, күңелләрнең нечкә вакытларында бу турыда сүз кузгатырга кирәкми, башка очрашкан вакытларда мәҗлесләрдә "менә безнең араларда бераз кимчелекләр бар, ул да булса гадәт булып килеп кергән, ислам динендә бу бик хәвефле гадәт" дип төшендерү – иң бөек бурычлардандыр.

Мәгал-ихтирам, Габделбари кари.<br>Декабрь 16

Хөрмәтле дустым, әл-Барса, сезләргә һәм абыстай-балаларга дога-сәламнәрем белән сәламәтлек, хәерле гомерләр теләп, әс-сәламү галәйкүм вә рәхмәтүллаһи вә бәрәкәтүһ!

Үзебез һәм идарәдәге хәдимнәр сау-сәламәт булып, әлхәмдулиллаһ, мөкаддәс хезмәтләребездә дәвам итәбез. Күндерелмеш мәктүбегезне алдым, рәхмәт! Сәламәтлегезне белеп мәсрүр булдым.

Дустым, дини тәкъвим июль аенда ук өлгергән иде, ләкин шул бастыру эшләре авыр булу сәбәпле, менә бу көннәрдә фәкать басылды. Хәзердә көтеп торабыз. ИншәАллаһ, сезләргә тапшырырбыз.

Бәгъзе бер сөальләргә җавап: сәламәт вакытында чыгару һәм башларда зарар юк. Аллаһ беләдер. Синең нинди ният белән эшләгән гамәлеңне аның туры йәүм кыямәт, иншәАллаһ, туктамас.

Мәетне озатканда истигъфар ләзем, тәкъбир түгел, ләкин кычкырып тәкъбир әйтү мәсләхәт түгелдер. Шәрган вә канунан ярамыйдыр.

Сорауларыгыз булса языгыз, оялмагыз. Минәл-хәсыйл, үзегезнең олуг агагыз танып, тәгъриф кылыгыз.

Мәгал-ихтирам мөфти Габделбари кари.
11 гыйнвар.

Вә биһи

Әхбәбел-әгъза әл-Барса!

Сезләргә һәм мөхтәрәмә абыстайга Хак сөбханә вә Тәгаләдән хәерле сәламәтлек теләп, чок сәламнәребезне күндерәбез. Мәгълүм әхбәбегез Габделбари кари, абыстай-балалар. Әс-сәламү галәйкүм вә рәхмәтүллаһ!

Әмма бәгъдә, дустым әл-Барса, сезләргә мәгълүм итәмен, ошбу көн бер гарәп кардәшебезгә сезләрнең адресны һәм бер хат тапшырдык. ИншәАллаһ, истикъбаль итәрсез. Бу Мөхәммәд әл-Мөхсини туташ Хамутның мүзесене йөртә, Ленинградта 4-5 айлар булдылар. һәр җомга безгә зиярәт иттеләр. Бездән сорап калды: «Киевта мөселманнар бармы», - дип. Мин шулвакыт сезләрне белдердем һәм адресыгызны тапшырдым. Гафу итәрсезләр.

Әмма бәгъдә, безгә күндерелгән мәктүбегезне йолкып алдым, ләкин сезләр безгә икенче кардәшегезгә язган хатны салып җибәргәнсез. Шул сәбәптән, ул мәктүбе кайтармын.

Хуш сау булыгыз.
Мәгал-ихтирам, Габделбари кари.
7 декабрь.

Бисмиллаһир-рәхманир-рәхим.

Әхбәбенә әл-мөхтәрәм әл-Барса-әфәнде, сезләргә һәм абыстай вә балаларга Хак Сөбханә вә Тәгаләдән сәламәтлек, хәерле гомерләр теләп сәламнәребезне күндерәбез. Мәгълүм дустыгыз Габделбари кари, абыстай вә балалар. Әс-сәламү галәйкүм вә рәхмәтүллаһи вә бәрәкәтүһ!

Үзебез, әлхәмдүлиллаһ, бу көндә сау вә сәламәт вә тыныч булып, истикъбаль фи әмриллаһтер.

Мөхтәрәм дустым, әл-Барса!

Күндерелмеш мәктүбегез тапшырылды, тәшәккерләр булсын.

Беренче, әд-дүктүр әл-Мөхсин хакында. Әгәр ул кадәр нык тәфтиш була торган булса, игътибарсыз калдыруыгыз хәерле булыр. Үзләре кирәкле хисап итсәләр, вакыт табып зиярәт итәрләр, иншәАллаһ.

Әмма бәгъдә, сорауларга җавап йөзеннән түбәндәгеләрне язам. Әлбәттә, сезләр гафу итегез, минем табигатем шул, бер дини сөаль булса, киң итеп язудыр.

Беренче: кешенең бик галим идегене белү өчен, аннан күбрәк белүче булу кирәк. (Ягъни диңгезнең тирәнлеген белү өчен, шул диңгез тирәнлеге кадәр үлчәү дә ярамыйдыр, үлчәүнең тирәнлектән артык булу ләземдер. Шул вакытта гына тирәнлекне белеп буладыр.) Бу һәм шулайдыр. Ул хатын өчен бик галим саналгандыр, ошбуның өчен бабай хатынга караганда галимрәктер. Шулай булгач, ул аның гыйлемен үлчи алмагач, галим дип әйтә дә алмый. Вакыйгадә, сүзләренә караганда, ул бик надан яки үзен галим дип хис кылучы бер мөтәгассыйб булып чыга.

Бу хатынга бик күп сөйләсә, бер сөаль җитә авызын капларга. Сез аңа сөйләгән сүзе турында: «Бу Коръәндә кайсы аятьтә язылган, сез шуны әйтеп бирегез, аннан соң шәригать дип белербез», - диегез. Коръән Кәрим моны үзе теләп итә: قُلْ هَاتُوا بُرْهَانَكُمْ إِن كُنتُمْ صَادِقِينَ («ән-Ниса», 103), ягъни шәригать хөкемнәренең дөреслеген тасдыйкъ өчен, Коръәннән бер аять яки Рәсүлебезнең (салла Аллаһү галәйһи вә сәлләмнең) сәхих булган хәдисләрне әйтеп бирергә кирәктер. Шулай булгач, бу хатын үзе түгел, галим дигән кеше дә Коръән Кәримдә намаз турында ничә аять барлыгын әйтеп бирә алачак түгелдер. Бәгъзе бер аятьләрне белсә дә, чөнки ул аны белергә мөмкин татар телендә (ибтидаи сыйныфлар өчен намаз, руза, зәкят, хаҗ дигән китап бар иде). Анда, дәлил йөзеннән, намаз турында бәгъзе аятьләр язылган иде. Ул да изахи түгел, ягъни аңлатып язылмаган иде. Коръән Кәримдә булган һәрбер аятьнең сәбәп нөзүле бар. Моны белү, әлбәттә, ләзем, әмма безнең татар тәфсирләрендә

берсендә язмаганнар, чөнки аны белмәгәннәр. Тәфсирләр шуның өчен гаять зәгыйфь, һичнәрсә аңларга мөмкинлек юктыр. Тик бу сүз татарча ничек була икән рәвешендә генә язылган. Хәтта рус тәрҗемәләре Казимирский, Саблуков, Крачковскийлар Коръән Кәрим аятьләрнең сәбәб нөзуле язылган тәфсирләр – гарәп тәфсирләре: “Тәфсир Мәнар”, “Тәфсир Кәбир”, Җәләләйн, Хазин, Бәйзави һәм башкалар. Бу тәфсирләр 20-30 томнан гыйбарәттер.

Асыл сүзгә күчәм: Коръән Кәримдә намаз бабында 141 аять бардыр. Ошбулардан безнең өчен, хәзерге заман хезмәт халкы өчен, иң мөһим булган бер генә аять җитәдер. Бу аятьнең сәбәп нөзуле – җиһад фи сәбили Аллаһтер. Ләкин җиһадтан максат – кылыч, мылтык күтәрү генә булмыйдыр. Дөнья мәгыйшәтендә барлык иҗтиһадлар, хезмәтләр – җиһад фи сәбили Аллаһ буладыр (Мөхәммәд Габдо, «Тәфсир Мәнар», 5 нче җилд).

Тәрәкес-саләт: гозерсез намаз калдыру – мөшриклек хәтта көферлек сыйфатыдыр. Намаз һичвакыт мөэминнең өстеннән сакыт булмыйдыр, төшмидер. Шулай булгач, намазны нинди хәлдә дә үтәргә тиешледер. Ләкин дөнья мәшәкате барлыгы һәркемгә мәгълүмдер. Аллаһ раббел-галәмин мондый хәлдә җир йөзенең төрле әкалимнәрендә яшәгән адәм балаларына муафыйк аятьләр индергәндер. Бар кеше дә вакытында намазын үтәү мөмкин түгелдер. Вакыт мөсәгадә кылмыйдыр. Менә мондый хәлдә шәригать мөкаддәсемез намазны нинди вакыт таба аласың, шул вакытта үтәргә рөхсәт итәдер, чөнки аять кәримәгә бинаән, мәшггуль кешеләргә намазны үтәү өчен вакыт шарт түгелдер, бәлки намазны үтәү шарттыр. Ягъни нинди вакыт булуга карамастан, намазны өстеннән төшерү шарттыр, моңа каза диленәдер. Аллаһ Җәллә Җәләлә мәшггуль кешеләргә кай вакытта каза кылса да, нинди хәлдә дә ишарә белән укыса да, утырып укыса да, йөргән хәлдә күңеленнән укыса да, намаз үтәлүгә керәдер, дип белдерде. Чөнки намаз Аллаһ тарафыннан, тәзкиятүн-нәфәс өчен, калебне пакьләү, иманны ныгыту өчен, боерылгандыр. Димәк, Аллаһны зикер, тәзкиятүн-нәфәс булган гамәл нинди генә юлы белән булмасын, үтәлергә тиеш. Нәфесне пакьләү, әхлакны тәрбияләү, Аллаһны тәгъзыйм, Аллаһны зикер буладыр. Хәтта мөэмин бәндәләр башка адәм балаларына файдалы гамәлләрдәндер. Бу әҗәрләрдән белми мәхрүм калу – зур наданлыктыр. Ошбу аять кәримәгә бинаән: فَإِذَا قَضَيْتُمُ الصَّلَاةَ فَاذْكُرُوا اللَّهَ قِيَامًا وَقُعُودًا وَعَلَىٰ جُنُوبِكُمْ ۚ فَإِذَا اطْمَأْنَنتُمْ فَأَقِيمُوا الصَّلَاةَ ۚ إِنَّ الصَّلَاةَ كَانَتْ عَلَى الْمُؤْمِنِينَ كِتَابًا مَّوْقُوتًا («ән-Ниса», 103). Ошбуның өчен мәшгуль булган мөэминнәр Аллаһны зикер итүне нинди юл белән булса да, нинди хәлдә булса да булуы ләземдер. Ошбуның өчен калган фарыз намазларны каза кылу ләземдер. Фарыз үтәлми торып нәфел дөрес түгелдер. Нитәк, имам Әгъзам Әбү Хәнифә рәхмәтуллаһи галәйһи мәзһәб башлыгыбыз фарыз-

ны каза кылмый торып, нәфел дөрес түгелдер, димештер (الفقها على مذاهب الاربعة باب قضاء الصلوة) дигән китабында язылгандыр.

Дөрес вакытның булып, вакытында укылган намазларның әҗере күптер. Нитәк, рәсүлемез салла Аллаһү галәйһи вә сәлләмнән Әбү Һөрәйрә күчерәдер: الوقت الاول من الصلوة رضوان الله و الوقت الاخر عفو الله (ابن ماجه), ягъни намаз әүвәл вакытында укылса, Аллаһны ризаландыру буладыр, кичектерелсә, каза кылынса, Аллаһның гафуын үтенү буладыр.

Аятьнең соңгы бүлеге: فَإِذَا اطْمَأْنَنتُمْ нан башлап, бу инде эшсез кешеләр өчен хас аятьтер. Эш булмаган, мәшгуль булмаган мөэминнәр бертөрле хәлдә дә намазны калдыруга хаклары юктыр һәм вакытында җиренә җиткереп үтәү катгый боерылгандыр. Менә мондый хәлдә намазны калдыручыларга каза гына ярдәм итмидер, чөнки бу әмер мөтмәиннел-көлүб, ягъни эшсез халыкларга намазны үтәү шарт булган кебек вакытында үтәү дә шарттыр, ләкин моңа карамастан нинди хәлдә дә каза ләземдер.

Әгәр бер мөэмин бер ел намаз калдырса, фәкать фарыз намазлар гына 1800 вакыт каладыр. Әгәр өч ел, 18000 вакыт каладыр. Бик хәвефле эштер. Бу кадәр калганны үтәп бетерү мөмкин түгелдер. Шулай булса да, үти торырга кирәк, каза кылырга кирәк. Ташларга кирәкми. Нитәк, Рәсүлебез (салла Аллаһү галәйһи вә сәлләм) أحب الأعمال إلى الله أدومها وإن قل димештер (Бохари), ягъни Аллаһка сөекле гамәл аз булса да булып торганы да, бәлки Аллаһ Җәллә Җәләлә безнең иҗтиһадымыз өчен, ягъни каза кылырга тырышубыз өчен калган кимчелекләребезне гафу итәчәктер. Бер дә каза кылмый торып: «Аллаһка тапшырдым, Аллаһ гафур, рәхим», - дию дөрес түгелдер. Нитәк, Рәсүлебез (саллә Аллаһү галәйһи вә сәлләм) اعقلها وتوكل димештер (Бохари), ягъни «Хайваныңны богаулап куй, аннан Аллаһка тапшыр», - дип боергандыр. Богаусыз Аллаһка тапшыру дөрес түгелдер, гамәл кылмый торып, Аллаһка тапшыру урынсыздыр. Бу турыда сүзләр күптер, ләкин хәзергә тәмам итәм.

Гамәл дәфтәрләре ябылуы турында бу дөрестер. Дөрес, үзең өчен нинди булса да гамәлне кылу сәламәт хәлеңдә ләземдер, ләкин изге гамәл-гыйбадәтләрне кылып бетерү һичкемгә насыйп булмыйдыр. Ошбуның өчен бәндәләрнең гөнаһлары булган өчен йәүм кыямәт барлык инсан-мөэминнәр дә, кәферләр дә җәһәннәм хозурында хәзер булырлар. وَإِن مِّنكُمْ إِلَّا وَارِدُهَا ۚ كَانَ عَلَىٰ رَبِّكَ حَتْمًا مَّقْضِيًّا («Мәрьям», 23), ягъни «Сезнең һәркайсыгыз җәһәннәм хозурында хәзер булырсыз». Бу хөкем - Аллаһның әмередер. Әмма мөттәкыйн булган бәндәләр җәһәннәм хозурында хәзер булмаслар, ягъни يوم نحشر المتقين إلى الرحمن وفدا

(«Мәрьям», 85), ягъни мөттәкыйннәр Аллаһның бөек рәхмәтләренә ирешерләр. ونسوق المجرمين إلى جهنم وردا (Мәрьям, 86), ягъни монафикълар, мөҗриминнәр, ялганчылар җәһәннәмгә кертелерләр. Менә бу вакытта «гамәл дәфтәрләре китер, күр» һәм укырга әмер ителер. اقْرَأْ كِتَابَكَ كَفَىٰ بِنَفْسِكَ الْيَوْمَ عَلَيْكَ حَسِيبًا («Бәни Исраил», 14). Ошбу вакытта шәфәгатьче, ярдәмче кирәк булыр. Ошбу шәфәгатьчеләр, ярдәм итүчеләр Аллаһның изене белән шәфәгать итерләр: Аллаһ хозурында туры булган, мөттәкыйн булган бәндәләр, хәер ихсан садакалар, ата-аналар, Коръән Кәрим һәм мөбарәк Рәсүлебез ярдәм итәр, шәфәгать итәр.

لَّا يَمْلِكُونَ الشَّفَاعَةَ إِلَّا مَنِ اتَّخَذَ عِندَ الرَّحْمَٰنِ عَهْدًا («Мәрьәм», 87), ягъни менә бу көндә кемнәрнең гамәл дәфтәре ябылганы мәгълүм булыр. Рәсүлебез (салла Аллаһү галәйһи вә сәлләм) хәдисләрендә إِذَا مَاتَ الإِنْسَانُ انقَطَعَ عَمَلُهُ إلا مِنْ ثَلاثٍ : صَدَقَةٍ جَارِيَةٍ ، أَوْ عِلْمٍ يُنْتَفَعُ بِهِ ، أَوْ وَلَدٍ صَالِحٍ يَدْعُو لَهُ (Бохари, Мөслим, Тирмизи вә гайреләрдә бар), ягъни адәм баласы үлү белән гамәлләре туктыйдар, иллә өч төрле кешенең гамәл бер дә туктамыйдыр: үзе соңында адәмнәр файдаланырлык эш эшләп калдырса – кое казыту, юл ясау, күпер салу, мәктәп-мәчетләр бина кылу кебекләр; галим кеше белемен калдырса, адәм балалары шуннан файдаланса; изге догачы бала калдыручы, әгәр баласы догачы булса. Шулай булгач, догалар кылучыларыбыз калса, гамәл дәфтәрләребез ябылмыйдыр һәм ябылган тәкъдирдә дә җәһәннәм хозурында шәфәгать итәдер. Әгәр догалар, укылган Коръәннәр мәетләргә ярдәм итмәсә, Нәбиййинә мөхтәрәмебез ошбу хәдисләрне әйтмәс иде: من زار قبر أبويه أو أحدهما كل جمعة مرة غفر الله له وكتب براً (Байхакы), ягъни бер мөэмин ата-аналарының каберен зиярәт кылса – һәр җомга бер мәртәбә, Аллаһ Тәбарәкә гөнаһларны гафу кылыр, изгеләрдән яза. Дога кылучыларга да Коръәннең әҗере шул кадәр күптер, әлхәмдүлиллаһ. Яки ошбу хәдис: من مر على المقابر وقرأ (قُلْ هُوَ اللَّهُ أَحَدٌ) إحدى عشر مرة ، ثم وهب أجرها للأموات أعطي من الأجر بعدد الأموات (...), ягъни бер кеше каберлекләргә барып, унбер мәртәбә قُلْ هُوَ اللَّهُ أَحَدٌ ны укыса, Аллаһ Тәбарәкә әҗерне һәрбер мәетләргә тоташтырыр, димәктер. Ягъни Коръәннең әҗере мәетләргә тоташадыр. Йәүм кыямәт шәфәгать итәдер. Рәсүл икрам салла Аллаһү галәйһи вә сәлләм әгәр дә рәсүлебезнең һәр сөннәтләрен әҗрән кылса, йәүм кыямәт шәфәгать итүгә иҗазәт бирелгәндер. وَلَسَوْفَ يُعْطِيكَ رَبُّكَ فَتَرْضَىٰ («әд-Доха», 5) – Аллаһ Җәллә Җәләлә Рәсүлебезнең сораганны риза кылганны белдергәндер.

Ата-аналарның шәфәгате булачак, әгәр дә Аллаһның ризалыгын ала алсак,

аларның: «Дөнья-ахирәт бәхетле бул», - дигән сүзен ишетә алсак. Коръән Кәрим ادْخُلُوا الْجَنَّةَ أَنتُمْ وَأَزْوَاجُكُمْ تُحْبَرُونَ («әз-Зөхрүф», 70), ягъни җәннәт әһеле булган кеше барча әһле җәмәгатьне хәвефсез җәннәткә кертү белән боерылгандыр. Рәсүлебез الجنة تحت أقدام الأمهات (Дәүд). Әһле гыйлем шәфәгать итә алыр, әгәр дә хакыйкый әһле гыйлем булса, Коръән буенча гамәл кылучы мөттәкыйннәрдән булса һәм башкалар.

Менә шуның соңында гына җәннәт әһеле булу мөмкин, бер дә газап кылынмыйча, булмаса, намазларны каза кылмасак, Коръән Кәримне хөрмәт кылмасак (хөрмәттән максат – укудыр, Аллаһның кәламе дип укудыр, ничек белсәң дә яки Коръән укыту, хәйр ихсаннар нинди юл белән булса да, садака кылу, корбан чалу вә гайрә, зәкятләр бирү кебекләр.

Димәк, нәфел укып кына, һич эш эшләп булмыйдыр. Бурычны түләргә кирәк, аннан соң көтәргә, бирергә кирәк. Бу турыда аятьләр вә хәдисләр күптер, иншәАллаһ вакыты белән язып күндерербез.

Хуш, сәламәт булыгыз. Әл-хаҗел-хәрәмәйн вәл-хафиз кәләмуллаһ
әл-кадим Габделбари Низаметдин Гайса.
Гыйнвар 18.

Нәфелне укырга кирәк, күп укырга кирәк, ләкин фарызны үтәп җиткән соңында. Аллаһның әмере وَمِنَ اللَّيْلِ فَاسْجُدْ لَهُ وَسَبِّحْهُ لَيْلًا طَوِيلًا («ән-Ниса», 26) ягъни «кичләрдә, озын төннәр буе сәҗдә кылу» боерылгандыр.

Әс-сәламү галәйкүм!

Мөхтәрәм дустым әл-Барса әхда җәнабләре, сезләргә һәм абыстай вә балаларга дога-сәламнәрем белән хәерле сәламәт, гыйбадәт гомерләре теләп калабыз. Дустыгыз Габделбари хәзрәт, абыстай, балалар. Мәктүбегез тапшырылды. Аллаһ сәламәтлек бирсен.

Үзебезнең әхвәлгә килсәк, әлхәмдүлиллаһ бу көндә, истикъбаль фи әмриллаһтер.

Абыстаебыз һәркәзә сәламәтлеккә ирешә алмый, хәерле булсын. Үзебез, шул ике сырхауны һәм кечкенә оныгымыз Гомәрне карап, өйдә генә утырам, һичкая бара алмыйм.

Әлхәмдүлиллаһ, һәр көн Коръәнне үтә укып торам, хифземне бик мөкәммәл саклый алам, моннан зур бәхет булу мөмкин түгел дип бик шатланам, чөнки Коръән Кәримдә алты мең алты йөз алтмыш алты аять, һәр көн шул кадәр

Аллаһның кәләмен башымнан кичерә аламын. Бәгъзе бер көндә ике тапкыр да укып чыга алам, әлхәмдүлиллаһ.

Һәр елда өч миллион кадәр «Аллаһ» каләмен зикер итү - гаять олуг бәхет-сәгадәт. Аллаһ Җәллә Җәләләнең سَابِقُوا إِلَىٰ مَغْفِرَةٍ مِنْ رَبِّكُمْ وَجَنَّةٍ عَرْضُهَا كَعَرْضِ السَّمَاءِ وَالْأَرْضِ أُعِدَّتْ لِلَّذِينَ آمَنُوا بِاللَّهِ وَرُسُلِهِ ۚ ذَٰلِكَ فَضْلُ اللَّهِ يُؤْتِيهِ مَنْ يَشَاءُ ۚ وَاللَّهُ ذُو الْفَضْلِ الْعَظِيمِ аять кәримәсенә бинаән зикер әйтүдә, әлхәмдүлиллаһ, Аллаһ кабул итсен, өстенлек алуга иҗтиһадым гаять зурдыр.

Бәгъдә, мөхтәрәм дустым, шушы май ахырларында, иншәАллаһ, дачага күчәрбез инде дип торабыз, ләкин мин үзем һәр көн шәһәргә кайтып йөрим, чөнки ялгыз укуны яратам.

Көннәр хәзердә салкын, әле 10 дәрәҗәдә тора. Үзем дачага барып йөргәнем юк, балалар барып торалар.

Дустым, менә сезләргә мөбарәк Рәсүлебез турында шаһәдәтем булган шигыремне бүләк итәм. Үзегезнең каләм белән күчереп язарсыз, чөнки العِلمُ صَيدٌ والكِتابةُ قَيدُهُ – гыйлемлек алу - арслан аулау белән бәрәбер, аның авы – язудыр.

Мәхәлләбез тыныч кына дәвам итеп килә, имам Җәгъфар әфәнде хәлебезне белеп тора, Аллаһ рәхмәт итсен. Шәех каенлык килеп килде, хәерле булсын. Быел 81 яшебез булып калды. Дөнья хәлен белеп булмый. Дөньядан күчкәнебезне ишетә калсагыз, догадан мәхрүм итмәгез, яхшылыгым белән яд итәргә тырышыгыз.

Хуш, сәламәт булыгыз.
Дустыгыз Габделбари хәзрәт.
19 март, 82 ел.

Бисмиллаһи Тәгалә

Мөхтәрәм мөселман кардәшебез әл-Барса, абыстай һәм балалар! Барчагызга да сәламәтлек, хәерле гомерләр теләп, сәламнәребезне җибәрәбез: әс-сәламү галәйкүм вә рәхмәтүллаһи вә бәрәкәтүһ.

Үзебез һәм гаиләбез сау-сәламәт, әлхәмдүлиллаһ. Ошбу ел рамазан аенда ялда булып Ленинградта гаиләм янында уздырдым, әлхәмдүлиллаһ. Гаиләмне Уфага алып килеп күрсәтеп, алар инде кайттылар Ленинградка.

ИншәАллаһ, тиз вакыт эчендә күчеп килерләр. Ленинградта квартирабызда улыбыз кала, ул институт бетергәч, шунда тәгаен螺 ителде. Хәзердә аны

өйләндерү белән мәшәкатьләнәчәкбез.

Абыстайларны күчерү, әгәр бара алсам, хәҗ сәфәреннән соң булыр. Ошбу ел хәзерләндем, Аллаһ насыйп итсә. Мәхәлләләрдә тынычлык, яңа мәчетләр ачылып тора, әлхәмдүлиллаһ, Әлмәт шәһәрендә, Магнитогорскта, Можга шәһәрләрендә һәм башкалар хезмәтләр күбәеп калды, хәерле булсын.

Алдагы ел өчен тәкъвимне бастыруга тапшырдык. ИншәАллаһ, кулга төшү белән сезгә дә җибәрербез.

Соравыгызга җавап. Намаз, фарсы теле.

Аллаһ тарафыннан әхлакый, әдәби тәрбия өчен, рухани вә җисмәни сәламәтлек өчен, Аллаһны зикер итеп беркетелгән Аллаһка буйсыну, гыйбадәт – اقم الصلاة нең мәгънәсе буладыр. Инде намаз турында сөйләсәк, сүз күп. Кыскача шулай аңлау хәерле, чөнки намаз турында турыдан-туры Коръәндә 141нче аять бардыр. Һәркайсы ачык рәвештә намаз гыйбадәтнең хикмәт фәлсәфәсен изах итәдер.

Хуш сәламәт булыгыз.
Мәгал-ихтирам дустыгыз мөфти Габделбари кари.
26 сентябрь

Мөхтәрәм әл-Барса, абыстай һәм балалар,

Җөмләгезгә дога-сәламнәр белән әс-сәламү галәйкүм вә рәхмәтүллаһи вә бәрәкәтүһ.

Бәгъдә, үзебез абыстай, балалар җөмләбез сау-сәламәт, әлхәмдүлиллаһ. Хезмәтебездә дәвам итәбез.

Сорауларга җавабыбыз ошбудыр. Кәгъбатуллаһның ишеге турында, тәмам алтыннан булуы хакында һичкем хәбәр бирергә мөмкин түгел. Ишек гаять зур һәм алтын белән тышланган. Анда һәркем кереп йөрми. Төн вакытларында баскыч китереп кертәләр, ләкин бу турыда һичкем һичкемгә сөйләргә тиеш түгел. Шулай булгач, ишек турында да бер хәбәр дә биреп булмый.

Кәгъбатуллаһның түбәсе һәм алтын белән яплаган, бер тарафка алтын аулак. Бу тарафны алтын улак тарафы дип йөртелә. Әл-хасыйл, Кәгъбатуллаһның серый гранит белән тышланган аралары семент түгел, көмеш белән салынган һәм, шулай ук, хәҗәре әсвәд тә көмеш белән җитләнгән. Шулай булгач, ничә пут алтын барлыгын Аллаһтан башка белү мөмкин түгел һәм һич урында язылмаган.

Бәгъдә, быел булачак һиҗри 15 гасырга күчү юбилее 9-11 сентябрь Ташкент

шәһәрендә булачак. Безнең Нәзарәттән 40 делегат барачак. Безнең һәр делегат бер формада киендерәләчәк: башларында – кызыл фәс, ак чалма, өсләрендә бер төрле җөббия булачак. Бу киемнәр хәзерләнеп ята, ателье эшләп бирәчәк. Бер айдан эшләп бетерәчәкләр.

Чыгыш хәзерләнде. Март азакларында җибәрелер. Хәзердә төрле телләрдә тәрҗемә ителеп ята. Имам Тирмизи каберстаны төзетелер. Ул Тирмиз шәһәрендә һәм аның ике җилд хәдис китабы Тирмизи бастырылыр һәм башка хәзерлекләр.

Бәгъдә, безнең Диния Нәзарәтенә 82 елда 20 ел тула. Моңа нык хәзерлек бара. Беренче, 200 кешелек конференция залы эшләп ятабыз. Бәгъдә, ике йөз еллык тарихы альбомнар эшләп ятабыз. Казан басмасы Коръән бастыралачак вә гайреләр. Хәзердә Нәзарәткә бер автобус бирделәр. Тагын ике “Волга” бирергә булдылар. Моннан соң, Ташкент Ислам институты янында 40 кешелек имамнар хәзерләү курсы ачылачак. Бездән – 10, Ташкенттан – 20, Баку һәм Дагестаннан 10 кеше укыячак. Әл-хасыйл, әлхәмдүлиллаһ.

Бу көннәрдә идарәдә хезмәт бик күп, һичбер вакыт табып булмый. һәртөрле корреспондентлар килеп тора. Газеталарда, журналларда төрле мәкаләләребез чыгып тора. Инде, әлхәмдүлиллаһ, ахыры хәерле булсын.

Догаи сәламнәр белән, дустың мөфти хәзрәт.

5/III 80

Әл-хат нисфел-мөләкәт

Мөхтәрәм дустым әл-Барса (!), абыстай вә балалар!

Җөмләгезгә хак Сөбханә вә Тәгаләдән сәламәтлек, хәерле гомерләр, хәерле уңышлар теләп калабыз. Мәгълүм дустың Габделбари кари, абыстай вә балалар.

Әс-сәламү галәйкүм вә рәхмәтүллаһи вә бәрәкәтүһ.

Бәгъдә, үзебезнең әхвәлебез бу көндә канәгать итәрлек, башларыбызга караганда, әлхәмдүлиллаһ, йөреп ятабыз.

Абыстаебыз быел җәй буе сырхау булып, бу көннәрдә, әлхәмдүлиллаһ, йорт эчендә хәрәкәт итә башлады. Йөрәк сырхавы шулай каты һәм куркыныч булды. Балалар тарафыннан, әлхәмдүлиллаһ, әлхәмдүлиллаһ, бу көндә тынычлык, истикъбаль фи әмриллаһтер.

Шулай көннәр үтә, һәр көн иртә намазга бер Коръән төттерәп хәтем итә алам. Аннан чыгып истирахәт итәм. Шулай итеп бу изге гамәлне кыла алуыма бик шатланам. Коръән Кәрим - Аллаһ Сөбханә вә Тәгаләнең 6666 аятьтер. Бу

- зур сәгадәт, зур бәхеттер. Истикъбаль Ходаның үзенә тапшырыладыр.

Сез, дустым, «Мәүлиден-нәби» китабы булмасмы?» - дип язасыз. Дөрес, үземдә юк, әмма хифзән (=яттан) беләм. Теләсәгез, язып җибәрәм. Сезгә гарәп телендәме яки милләт телендәме, белдереп языгыз. ИншәАллаһ, язып тапшырырмын.

Гарәп телендә برزنجي, татар телендә حمد بحد касыйдә тәртибендә була. Моннан башка да байтак мәүлид китаплары ядымызда сакланадыр, әлхәмдүлиллаһ.

Бәгъдә, Мәскәү турында сөалегезгә җавап.

Мин ул хәлне сезнең хат аркылы ишеттем. Моннан соң сораштым, вакыйгән, дөрес булган икән. Хәерле булсын. Һәркем үз эше турында үзе мәсьүлдер. Безнең эшебез ان لله و ان اليه راجعون дип дога кылудыр.

Мәүлиден-нәби ае декабрь 27дә башлана. Мәүлид кичәсе гыйнварның 6сында булачак. Мәхәллә белән эш тотмыйм. Җәгъфәр әфәнде шалтыратып, хәлебезне белеп тора.

Бик тыныч яшәп торам, киләчәген Аллаһ хәерле кылсын дигән мөкаддәс догалардабыз.

Мәгал-ихтирам, дустың Габделбари хәзрәт.
28 ноябрь

Бисмиллаһир-рәхмәнир-рәхим

Мөхтәрәм дустым, абыстай вә балалар.

Барчагызга да Хак Сөбханә вә Тәгаләдән сәламәтлек, хәерле гомерләр, хәяттә уңышлар теләп, сәламнәр күндерәбез. Әс-сәламү галәйкүм вә рәхмәтүллаһи вә бәрәкәтүһ.

Дустың мөфти хәзрәт, абыстай вә Булат.

Бәгъдә, үзебез бу көндә, әлхәмдүлиллаһ, сау-сәламәт хезмәтебездә дәвам итәбез. Истикъбаль фи әмриллаһ.

Җәнаб дустым, күндерелмеш мәктүбегез тапшырылды, рәхмәт. Әхвәлегездән хәбәрдар булдык, истикъбаль хәерле булсын.

Бәгъдә, сөальләргә җавабым.

1. Ат ите хакында. Бу турында Корьән Кәримдә «ән-Нәхл» сүрәсе 5нче аять, әстәгыйзүбиллаһ: وَالْأَنْعَامَ خَلَقَهَا ۗ لَكُمْ فِيهَا دِفْءٌ وَمَنَافِعُ وَمِنْهَا تَأْكُلُونَ нан башлап 8нче аять ат кебек хайваннарны матурлык өчен, йөкләрегезне күтәрү һәм атлану өчен хәлык кылдым дигән сүздер.

Мәзһәбләр арасында мәкруһ күрүчеләр бар. Әмма имамыбыз Имам Әгъзам Әбү Хәнифә рәхимәһуллаһ Хәнәфийа мәзһәбендә бишенче аятьне файдаланып, وَمِنْهَا تَأْكُلُونَ дигән сүзгә атлар керә дип, дөрес тапканнар. Тагын да, اللَّهُ الَّذِي جَعَلَ لَكُمُ الْأَنْعَامَ لِتَرْكَبُوا مِنْهَا وَمِنْهَا تَأْكُلُونَ («әл-Мөэмин», 79), бу инде ачыктан-ачык хайваннарның атлану өчен булганнарыннан ашарга дөрес икәнлеген белдерәдер. Ошбуны тасдыйк өчен яки изах өчен Рәсүлебез салла Аллаһү галәйһи вә сәлләмнән Әсма разый Аллаһү ганһүмә ошбу хәдисне күчерә: قَالَتْ نَحَرْنَا فَرَسًا عَلَى عَهْدِ رَسُولِ اللَّهِ صَلَّى اللَّهُ عَلَيْهِ وَسَلَّمَ فَأَكَلْنَاهُ (Бохари), ягъни Рәсүлебез ашаганны риваять итәдер. Тагын да изах өчен: мәкруһ диючеләр «әл-Әнгам» сүрәсендә 142-144нче аятьләрдә ат ите хакында: «Аллаһ зикер итмәгән», - дип дәгъва итәләр. وَمِنَ الْأَنْعَامِ حَمُولَةً وَفَرْشًا дигән сүздән соң كُلُوا مِمَّا رَزَقَكُمُ اللَّهُ дип менә шушындагы حَمُولَةً дигән сүз йөк йөкләүче булып, ат хакында дип хөкем ителәдер. Менә шуларны ашау дөрес икәнне كُلُوا مِمَّا رَزَقَكُمُ اللَّهُ тасдыйк итәдер. Ягъни шул сезләрнең йөкләрегезне йөкләгән хайваннарны да Аллаһ сезгә хәләл итте, ашарга боергандыр. Димәк, хәләлдер. Инде ашамаган кеше ашамасын, әмма хәрәм дә, мәкруһ тә түгелдер.

2. Дуңгыз ите хакында. Җавап: Аллаһ тарафыннан катгый хәрәм ителгән. Коръәндә бу турыда күп урыннарда зикер кылына. Җөмләдән берсе Маидә сүрәсе - 3нче аять, әстәгыйзүбиллаһ: حُرِّمَتْ عَلَيْكُمُ الْمَيْتَةُ وَالْدَّمُ وَلَحْمُ الْخِنْزِيرِ кыскача әйткәндә, Аллаһ тарафыннан хөкем ителеп кертелгән нәрсәне тикшерү катгый мәмнүгътер, хәтта Аллаһка ширкать, Аллаһтан үзеңне күп белүчелек итү буладыр. Аллаһ сакласын! Изах өчен: әһле голамабез әл-мөфти әл-Мысри Мөхәмәд Габдо хәзрәтләре «Тәфсир әл-Манар»да бу турыда бик озын изах бирә. Шунда ул күрсәтә, хинзир итендә микроб барлыгы, испираль формада микроб барлыгы, хинзирның һәртөрле пычраклар ашавыннан хасил була торган микроб. «Менә шул микроб тиз арада заразный авыру тарата», - дип яза. Тагын да, һәрбер үлексә ашый торган хищник шәрган хәрәм ителгән, хәтта шул җөмләдән налим дигән балык та, хищник булып, хәрәмдер. Кыскасы, туган, мин сезгә үзем беләсем килә дигән өчен, аңлату өчен кыскача изах

бирәм, ләкин Аллаһ хәрәм иткән нәрсәләр - катгый хәрәм, хәрәм ашау – гөнаһтыр һәм күңелнең каралывына сәбәптер. Һәрнәрсәне җиңелгә санап йөртү күңел каралыктан киләдер. Әгәр шуны истигъмал кылсак, күңел тәмам бикләнәдер. Нитәк, әстәгыйзүбиллаһ: خَتَمَ اللَّهُ عَلَىٰ قُلُوبِهِمْ وَعَلَىٰ سَمْعِهِمْ ۖ وَعَلَىٰ أَبْصَارِهِمْ غِشَاوَةٌ. Бу менә шундый белер-белмәс шәригатьне боргалаган кешеләр хакындадыр.

3. Коръән багышлау хакында сөаль. Җавап: Коръән багышлауның догасы һәрбер Коръәннең ахырында язылгандыр. Шуннан артыкның хаҗәте юктыр. Без бит догаларны, Аллаһтан кабулиятне сорап кылабыз һәм һәрбер нәрсәне белүче һәм ишетүче мәрхәмәт иясе булган ялгыз Аллаһка ялварып кылабыз. Әгәр күңелеңнән дөрес булсаң, илаһи кабул итеп вә Рәсүлебезгә, җәмигъ пәйгамбәрләргә әүлия-әткыяләргә, ата-аналарыбызга ирештер дисәк, кабул булыр, иншәАллаһ һәм җәмигъ мөэмин-мөэминәгә һәм ирештерер. Шулай булгач, дилбегә буе сузып, асыл булмаган дүрт кабер әһелләренә хәтта тавык-әтәчләренә дә сорап доганың хаҗәте юк. Бәлки Аллаһка чын күңелдән тапшырып, кыска гына укысак та, барына да ирешер. Һәм кабул булуына һәм шик юктыр. Нитәк, فَلْيَسْتَجِيبُواْ لِي дип ашыгыч хәлдә кабул итүне җәнаб Рабб белдергәндер. Димәк, әдәп тарикы (=юлы) белән кыска гына укып, Ходага тапшырсак, кабул булачак, иншәАллаһ.

4. Инде Коръән эчендәге хәрәкәләр турындагы сөальгә җавап. Рәсүл әкрам салла Аллаһ галәйһи вә сәлләмнән соң Коръән язылган вакытта җиде кари булган. Боларга корра сәбгә (قرآ سبع) дип йөртелә. Шушы корра сәбгәнең фикерләре белән галәмәтләр вә хәрәкәтләр хөкем ителгән لا ج ط болар бар да дөрес, барысында да тынарга рөхсәт ителгән. Шушы галәмәтләр – кирәк тыныш өстендә булсын, кирәк тыныш галәмәте булмыйча аять уртасында булсын, тынарга тиешле. Бу галәмәтләрнең фәкать тыну дөрес идегене белдерәм, башка хөкемнәрне язуның лөзүме юк.

Сәламәтлек теләп, мөфти Габделбари кари

Әс-сәламү галәйкүм, дустым әл-Барса, абыстай һәм балалар.

Сезләргә сәламәтлек, хәерле гомерләр теләп, дога-сәламнәремне тапшырам. Әс-сәламү галәйкүм вә рәхмәтүллаһи вә бәрәкәтүһ.

Үзебезнең әхвәлебездән сөаль калса: ошбу рәвештә мин, гомумән, анда эшләргә теләми идем, хәтта гаиләм дә Ленинградтан учеттан төшмәделәр. Ләкин мине җибәрмәделәр. Ошбу ел апрельдә кичерәк кызым кайсы Мәскәүдә улым белән советка барып таләп иттеләр: «Ата-анабыз тугансыз, сырхау. Алар ялгыз, бер хезмәт кешесе, бара алмыйбыз. Кайтарыгыз», - дип, катгый куялар. Ошбу ел урталарында минем сорау кабул ителеп, 18 июнь хезмәттән бушап, 120 сум пенсия тәгаен ителеп, Ленинградка күчтем.

Сәламәтлегем начарланган иде, башка приступлар бик еш була иде. Ленинградка кайтып, 13 ай дачада тордым. Балалар, табиблар лечить иттеләр. Әлхәмдүлиллаһ, хәлем уңайлана бара, бигрәк һава кирәк. Дача үзебезнеке, кыш торырлык. Теләсәк, анда торабыз, ләкин шәһәрдә дә без зур сад янында. Анда чыгып йөрибез.

Хөкүмәт бик зурлап озатты, ярдәм иттеләр.

Бөтен нәрсәбезне алып кайттык, иске квартирабызда. Миңа квартир бирәләр, көтеп торабыз, иншәАллаһ. Балалар анда чыгып, үзебез шул иске квартирада калырбыз. Менә сезгә кыскача җавабым.

Хат язып торыгыз, әхвәлемне белеп торыгыз. Әгәр дөньядан күчүемне ишетеп калсагыз, догадан калдырмагыз. Тәкъдир илаһине белеп булмый. Ләкин баш авыруым көчле, хәерле булсын.

Дустың Габделбари кари.

11 октябрь

Мәчеткә чыга алмыйм. Ялгыз йөрергә хәзергә булмый эле.

Вә биһи нәстәгыйн

Бәрәдәри кирам әл-Барса, абыстай!

Сезгә Хак Сөбхәнә вә Тәгаләдән сәламәтлек, хәерле гыйбадәт, гомерләр теләп, сәламнәребезне тапшырам. Әс-сәламү галәйкүм вә рәхмәтүллаһи вә бәрәкәтүһ.

Бәгъдә, үзебез гаиләбез һәм идарә хезмәткәрләре сау-сәламәт, әлхәмдүлиллаһ.

Мөхтәрәм дустым, язылган мәктүбегез тапшырылды.

Вакытыбыз гаять косур булса да, сөальләргә җавап бирәмен. Хәзер вакыт - еллык хисабат вакыты, бәгъдә юбилейга зур хәзерлек барадыр. 200 кешелек

конференция залы хәзерләү өчен рөхсәт бирелде. Шул идарәнең двор ягына өстәп, ике катлы кирпич бина эшләтергә хәрәкәт итәбез. ИншәАллаһ, яз башында тәгъмирәт башланыр дип, өмет итәбез. Хезмәт кайный тора. Истикъбаль хәерле булсын.

1. Кояш чыкмый яки батмый торган вакытларда руза керсә, руза тотылмый һәм түләнми, чөнки мәгълүмдер ки Аллаһның әмерендә ифтар вә сәхәр вакытлары ачык тәгаен ителгән. Нитәк, كُلُوا وَاشْرَبُوا حَتَّى يَتَبَيَّنَ لَكُمُ الْخَيْطُ الأَبْيَضُ مِنَ الْخَيْطِ الأَسْوَدِ مِنَ الْفَجْرِ ثُمَّ أَتِمُّوا الصِّيَامَ إِلَى اللَّيْلِ димәк аклыкның хасыйл булуына кадәр сәхәр булып, кояш бату белән – ифтар. Менә шушы ике галәмәт булмаган урында шул вакытларда рамазан ае туры килсә, руза сакыт буладыр. Сакыт булу өчен дәлил: шәһр шөһүд булу ләзем, ягъни шул галәмәтләр булган вакытларда, ягъни таң беленү һәм кояш ябылган вакытта, рамазан аенең керүе шарттыр.فَمَنْ شَهِدَ مِنْكُمُ الشَّهْرَ فَلْيَصُمْهُ әмердер, ягъни кайчан шушы ике галәмәт, ягъни таң беленү, кояш бату галәмәтләре булып, рамазан ае керсә, әлбәттә, руза булыр димәктер. فَلْيَصُمْهُ сүзе белән фарыз ителгәндер. Димәк шәһр шөһүд булмаган урында руза тотылмый һәм түләнмидер. Бу инде Аллаһның әл-вәһийат сыйфатының иң бөек сыйфатыдыр. Димәк, Аллаһ Җәллә Җәләлә көррә ардның икълимнәре хакында барчасында шушы ике аятькә сыйдыргандыр. Әлхәмдүлиллаһи раббел-галәмин.
2. Мәсьәлә бабайның мәет өстендә, терекләргә дә, үлгәннәргә дә кылган догасы дөрестер. Бу турыда җәназа догасы укып карыйк: اللهم اغفر لحيينا و ميتنا الخ дип башлана, ягъни: «Терек булганнарын да, үлгәннәрен дә мәгъфирәт кыйл», - дип укыладыр.
3. Коръән укыгач, багышлау хакында. Әлбәттә, хәтмел-Коръән догасыны укып карарга кирәк. Догада бит хәтта Рәсүлемездән башлап, җәмигъ пәйгамбәрләргә ата-аналарга, җәмигъ мөселманнарга дога кылына, бәгъдә хәссәтән фүлән бине фүлән диленә. Димәк, бу һәм терекләргә, үлгәннәргә барчасына җитәдер. Нитәк, Рәсүлебезнең хәдисеннән فَقَدْ وَقَعَ أَجْرُهُ عداد الاموات әҗере һәрбер мәеткә ирешәдер, терекләргә юлдаш буладыр.
4. Мәүлид китабы хакында. Бу турыда хәзергә һич вакыт юк, иншәАллаһ, истикъбаль игътибар ителер.

Мәгал-ихтирам мөфти хәзрәт.

Хөрмәтле туганнар әл-Барса һәм башкалар.

Җөмләгезгә сәламәтлек, хәерле гомер теләп, сәлам җибәрәм. Әс-сәламү галәйкүм.

Мәктүпләрегез тапшырылды. Рәхмәт, ләкин мин быел хаҗ сәфәрендә идем. Уфага кайттым фәкать 4 декабрь. Әл-хасыйл 5 атна йөрдем. Аллаһ кабул итсен. Гаиләм Ленинградта торды.

Ләкин бер зур кайгыбыз булып китте. Зур кызымның кияве профессор Асаф Османович киявем вафат булган, ләкин мин, Хода туры китереп, җеназасына өлгердем. ان لله و ان اليه راجعون Хәерле булсын.

Кролик турында. قواعد فقهيه һәм مذهب اربعة да باب الارنب бар. Шунда дөрес табылган, дүрт мәзһәбендә дөрес тапканнар.

Мәүлиден-нәби хакында эш болай тора: минем китаплар килде Уфага, ләкин әле, хосусый эшкафлар булмагач, таратканы юк. ИншәАллаһ, килеп чыкса, игътибар итәбез.

Яңалыклар булып тора, әлхәмдулиллаһ. Мәчетләр рәсмиләштерелә, шәкертләр саны артты һәм башкалар.

Сәлам белән Габделбари кари.

Әс-сәламү галәйкүм

Әхбәбәнә әл-мөхтәрәм әл-Барса һәм абыстай вә балалар.

Җөмләгезгә дога сәламнәрем белән әс-сәламү галәйкүм вә рәхмәтүллаһи вә бәрәкәтүһ.

Бәгъдә, үзебез һәм әһле бәетебез вә идарә хәдимнәр сау-сәламәт, әлхәмдулиллаһ. Истикъбаль фи әмриллаһтер.

Бәгъдә, күндерелмеш мәктүбегез тапшырылды. Сәламәт идегезне белеп, мәсрүр калдык, Хак Сөбхәнә вә Тәгалә истикъбаль хәерле сәламәтлек вә тынычлык насыйп итсен.

Бәгъдә, соралмыш сөальләргә җавабым:

Исме Аллаһ язылган дини китап битләре гамәлгә ярарлык булмаса, яндыру мәсләхәт. Әмма гамәлгә ярарлык булган тәкъдирдә нәзарат китапханәсенә күндерү әҗер вә саваплы гамәлләрдән булыр.

Сөаль: «аятуллаһ» ул шиитларда изге дигән сүз урынына йөри, ләкин шәрган инде исем итү дөрес түгел, ягъни Аллаһның бер билгеле кешесе булу пәйгамбәргә генә хастыр. Хәерле булсын. Безнеңчә, дөнья тыныч булсын, аятуллаһ булмаган шайтан булсын. Йәүм кыямәт һәркем үзе өчен мәсъүл

булачак (لَهَا مَا كَسَبَتْ وَعَلَيْهَا مَا اكْتَسَبَتْ)тер. Хәзерге көндә шул булачак, конференция өчен зур зал эшләтү хезмәтендә хәрәкәт итәбез. Барча инстанцияләрдән яхшы үтте. Инде шәһри план төзүче, эчтәлек һәм тышталык формаларын бездән алып, төзеп ята. ИншәАллаһ, икенче ярым елда, планга кертелеп, хәрәкәт башланыр. Догада булыгыз.

Мәгал-ихтирам, әхбабыгыз мөфти Габделбари кари.

Мөхтәрәм әл-Барса әфәнде, абыстай һәм балалар.

Хак Сөбхәнә вә Тәгалә җөмләгезгә сәламәтлек, хәерле уңышлы гомерләр насыйп итсен дип, догаларда калдык. Сәламнәребез белән әс-сәламү галәйкүм вә рәхмәтүллаһ.

Күндермеш мәктүбегез тапшырылды, рәхмәт.

Сөальләрегездән берсе - җыелып җомга вә гает уку мәсьәләсе. Һәрвакытта да, рәсми мәхәллә булганда да аерым ачык җирдә үтү мәмнүгъ. Сездә рәсми мәхәллә юк. Әгәр дә халкыгыз бер 20-30 кеше булса, шәһәрдә булган уполномоченныйга барыгыз, рөхсәт сорагыз. Алар сезгә иcписок китерегез, кемнәр йөри дип әйтерләр. Һич куркусыз әйтегез. Шуннан соң бер йорт араларга кушарлар. Шул йортта җомга вә гает укырга рөхсәт ителер. Бу рәсми мәчет булмаса да, урындагы хөкүмәтнең рөхсәте белән җомга вә гает укылыр. Арагыздан бер имам тәгаен итәрсез, аны да белдерерсез. Һич курку юк. Мондый хәлләр соңгы вакытларда күп кенә булып калды. Калинин шәһәрендә шулай укыйлар, Похвинский дигән Ульян областенда укыйлар. Һәм күп кенә урыннарда хәзердә күпчелекнең сүзен кире кайтармый, укырга кушалар. Мондый гыйбадәт йортларына без имам бирмибез, үзара алып баралар. Зиярәт өсләрендә намаз уку дөрес түгел, чөнки Рәсүлебез мунча белән зиярәт өстендә укуны дөрес күрмәгән.

Аллаһ хөрмәтле балагызга сәламәтлек насыйп әйләсен, истикъбаль бала булуны насыйп әйләсен. Хатыннарның ирләр белән бергә утыруында һичбер гөнаһ юк. Билгакес (киресенчә – ред.), алар - бала тәрбияләүче аналар, вәгазьнәсыйхәт ишетүләре мәсләхәт.

Рәсүлебез салла Аллаһ галәйһи вә сәлләм لا تمنعوا إماء الله مساجد الله дигән. Әһле мөфәссирин فى كل مكان дип: «Кай урында да вәгазь-нәсихат булган урыннарда хөрмәтле аналарыбызның булуы әфзальдер».

Бәгъдә, Ленинград вакыйгасы - ул шундый бер әдәпсез хатын булды. Ул

үзе күп кешене кыйнады һәм кыйнатты. Үзе шәбәкле, эчкече, грубая, җыеп дөнья җимермәкче булды. Анның хәлләре хакында, килә алсагыз, күрешсәк, сөйләрбез. Ул хәтта ире Хафизне эштән чыгарды. Хафизнең Ленинградтан китүе шуның өчен булды. 18 июль хезмәттән бушатылды. Бүген беренче ноябрь ул һаман квартирдан чыкмый, судлашып талашып, сугышып ята. Менә бүген Хафиздан телеграм алдым. «Ноябрь урталарында Ижевскига барачакмын», - дип язган. Мин аны анда җибәргән идем. Шул явыз хатын: «Мин Ленинградтан китмим» - дип дөнья аулата, ләкин алар анда калачак түгел. 10 ноябрь квартирадан катгый бушату әмер ителгән.

Хәзер Ленинградта Җәгъфәр шәкертебез имам булып тора. Август башыннан башлап һәм быел хаҗга барачак. Мин быел бара алмыйм. Бер кимчелегем бар, кечкенә, ләкин юлга чыгудан мәнгы итә. ИншәАллаһ, күрешсәк, сөйләрмен.

Хуш, сәламәт булыгыз.
Мәгал-ихтирам мөфти Габделбари Гайса.

Бисмиллаһи Тәгалә

Мөхтәрәм дустым әл-Парса, абыстай һәм балалар.

Сезләргә сәламәтлек, хәерле гомерләр телә, сәламнәремне тапшырам. Әс-сәламү галәйкүм вә рәхмәтүллаһ.

Үзебез сау-сәламәт, әлхәмдүлиллаһ. Абыстайлар да сәламәтләр. Хәзердә үзебезнең дачадалар. Ленинград янында. Улым институтны тәмам итте, әлхәмдүлиллаһ. Хәзер җәмәгатьләндерү мәсьәләсе куелыр.

Үзем менә шушы көннәрдә генә Мәскәүдән конференциядщн (кайттым), хезмәтем бик яхшы барып ята, әлхәмдүлиллаһ.

Хөрмәтле дустым, сезнең сорауларга кыскача җавап язам:

1. Балаларга дини тәрбия, дини хис бирү кәлимәи таййибәне өйрәтү - мәктәпкә барганга кадәр ата-ана өстендә бөек бурычлардан, димәк кече яшеннән аңа дини тәрбия аз булса да, кереп калу ләзем. Әгәр тәрбиячеләр динне үзләре тәгъриф итсә. Гомумән белем алу – бу ислам галәме өчен яңалык түгел, чөнки Аллаһ Җәллә Җәләлә беренче вәхидә ук «икъра» белән боерды.
2. Җавап: гомумән, мәет дәфен ителгәч, талкыйн дөрес диюче галимнәр бар. ИншәАллаһ, моннан мәеткә зарар булмас. Бу - Нәзарәтнең фәтвасыдыр. Рәсүл икрам салла Аллаһү галәйһи вә

сәлләмнең хәдисе: إِذَا فَرَغَ مِنْ دَفْنِ الْمَيِّتِ وَقَفَ عَلَيْهِ فَقَالَ اسْتَغْفِرُوا لِأَخِيكُمْ وَسَلُوا لَهُ بِالتَّثْبِيتِ فَإِنَّهُ الْآنَ يُسْأَلُ кайчан дәфен кылып беткәч, рәсүлуллаһ шунда туктап калды һәм әйтте: «Кардәшегез өчен Аллаһтан ярлыкавын сорыгыз, аңа сорау җиңелрәк булыр. Менә хәзер аннан сорау буладыр», - диде. Шушыңа бинаән һәрбер мөселман мәеткә Аллаһтан ярлыкау сорау бурычлыдыр. Ялгыз бер бабай гына түгел. Ләкин акча өчен кылса, һич файдасы юктыр, бәлки гөнаһтыр. Каберләрдә һичбер тавыш ишетү мөмкин түгелдер. Нитәк, Коръән Кәрим إنك لا تسمع من في القبور: син каберләрдән һичбер нәрсә ишетүче түгелсеңдер. Димәк, барчамыз да мәеткә мәгъфирәт сорап калу тиешледер. Дәфеннән соң тиләвәтел-Коръән, гомумән, сүрәтел-Мөлк Рәсүлебездән ачык хәдисләр бардыр. Сүрәтел-Мөлк газапларны мәнегъ итер һәм ут газабыннан коткарадыр (Тирмизи, 2 җилд, 112 с.). Ошбуның өчен мәетнең яңа вакытында кырык көненә йөрү, 3 һәм 7, кырыкларын уздыру гадәт булган, ләкин ни Коръән Кәрим, ни Рәсүлебез тарафыннан тәгаен көннәр күрсәтелмәгән. Бу 3-7-40 башка милләтләрдән кереп калган. Вә ләкин мәетне яд итү ләзем. Әгәр Аллаһ тарафыннан яки Пәйгамбәр тарафыннан вакыт билгеләнгән булса иде, бу вакыт житешә алмаган кешеләр өчен авыр булыр иде. Ислам дине Коръән кычкырып тора: وما جعل عليكم في الدين من حرج, «Сезләр өчен дин эшләрендә бер дә авырлык юктыр», - дип. Димәк, кай көндә җитешә, шунда яд итү, тиләвәт Коръән уку газаплардан мәнегъ итер. Кырык көн йөрү, 3-7-40 барчасы шул җөмләдән. Әл-хасыйл, сүзнең кыскасы: дин эшләре турында үзара тарткалашырга, көрәшергә кирәкми, бәлки, шәригатьне нык һәм дөрес белүчедән сорау – намаз шикелле, фарыздыр. فَاسْأَلُواْ أَهْلَ الذِّكْرِ إِن كُنتُمْ لاَ تَعْلَمُونَ – Белмәгәнне нык белүчедән сорау боерылган. Сорау – илаһи бер канундыр. Рәсүлебезнең ошбу хәдисе һәрвакыт гамәлдә булсын. إِيَّاكُمْ وَالْغُلُوَّ فِي الدِّينِ ، فَإِنَّمَا أَهْلَكَ مَنْ كَانَ قَبْلَكُمُ الْغُلُوُّ فِي الدِّينِ Моннан максат шулдыр: «И сезләр, дин турында тарткалашасызмы? Хәтерегездән чыгармагыз, сездән элекке халыклар шул дин турында тарткалаш өчен һәлак булдылар». Димәк белер-белмәс таркалаш сүз көрәштерү динебезнең һәлак булуына хезмәт итәдер. اللهم احفظ من هذه الافات آمين

Ихтирам белән, мөфти Габделбари кари. 16 июнь.

Әсгадүкә Аллаһы тәгалә фид-дәрәйн.

Мөхтәрәм дустым әл-Барса, абыстай, балалар! Җөмләгезгә сагынып сәламнәр белән хәерле гомерләр, сәламәтлек теләп калабыз. Әс-сәламү галәйкүм вә рәхмәтүллаһи вә бәрәкәтүһ.

Мә бәгъдә, үзем сау-сәламәт, әлхәмдүлиллаһ. Хезмәт биреп ятам. Абыстай, балалар да сәламәтләр. Командировка барып, анда да булдым. Мин 19 ноябрьдән командировкага бардым. Кайттым 6 декабрь. Баку-Ленинград-Мәскәү.

3 җомга узды, берсе – Бакуда, берсе – Ленинградта, берсе – Мәскәүдә. Һәркайсында муафыйк вәгазь ясадык. Хаҗ сәфәренә озаттым. Сәламәт йөреп кайтуларын телибез.

Әл-хасыйл, дустым, хезмәт күп, ләкин бик күңелле хезмәт. Хода әҗерне насыйп итсен. Ошбу ел «Сахих әл-Бохари» басылып таратылды. Коръән басылып таратылды. Әле яңадан 50 мең Коръән бастырырга рөхсәт алдык. «Шәрык мөселманнары» дигән журнал чыгып тора. Бу эшләрне гамәлгә куюда дүрт Нәзарәт тарафыннан Мәскәү шәһәрендә отдел бар. Чит илләр белән мөнәсәбәт отделы. Шул отдел аркылы кемгә теләсә, шуңа бирер. Эш алып барыла, ул отделның рәисе мөфти Бабаханов. Без - беренче зам. Хезмәткәрләр күп һәм барча эшне җиңел алып баруга шулар күп ярдәм итә. Отделның шөгъбәләре Диния Нәзарәтендә бездә Рәшид Гыйльманов алып бара. Ул безнең беренче ярдәмче булып йөртелә. Хизри бер урында да эшләми, бушатылды.

Янымда шәкертләрем бар. Мәсъүл кәтиб Җәгъфар, Сириядан кайткан шәкерт Уфабыздагы мәхәлләдә имам – Габбас хәзрәт Әбү Бәкер – хәзер бер шәһәргә җибәрәм, Сириядан кайткан шәкерт. Бохарада алты, Ташкентта – 4, Сирияда 3 шәкерт бар, Аллага шөкер. Әл-хасыйл, кадрлар хәзерләп торабыз.

Тәкъвим турында мин, иншәАллаһ, бу елгы тәкъвимне күндерермен.

Ташкент белән арада тәфүт булу мөмкин. Бүген туу-батуларда аерма булган җирләрдә була торган эш. Әмма безнең Нәзарәтнең тәкъвиме дөрес түгел, Хизри бутап бетергән. Бу турыда башка вакытта язармын. Хуш, сәламәт булыгыз.

Әхбабыгыз мөфти Габделбари Низаметдин Гайса.

7 декабрь.

# [Габделбари хәзрәтне Ленинград мәчетеннән төшерү турында] Мөнәҗәтләр

Хәзрәт безгә җибәрелде илле алтынчы елда,
Азып-тузган халыкларны барын да салды юлга.
Хәзрәт килеп юлга салды, мәчетебез ачылды,
Мәчетебез ямьле булгач, дөньяга нур сачылды.
Җир йөзенә нурлар сибә, безнең мөселманнарга,
Бик зур дәүләт, зур һидаять мөселман булганнарга.
Кайсыберләре аңламый шул кадәр һидаятьне,
Кадерен белеп, тора алмыйбыз шушы матур милләтне.
Төрле яктан тәҗрибә, туры юллар күрсәтә,
Сабырлык бир хәзрәтебезгә, безне аңламау йадаткан (=адаштырган)
Читтән килгән кунакларны хәзрәтебез каршы ала,
Мәчетебез ямьле, әлеге кунаклар хәйран кала.
Шул кадәр халык күп мәчеттә, тыңлыйлар, колак сала,
Яхшы сүзләр ишетәбез, мәчеткә генә барып.
Тырыша ислам дине өчен, кем икәне беленде,
Туры юлдан барганлыкка, казый исем бирелде.
Казый дигән бик зур исем бирелмәгәндер юкка,
Барчабызның ис китә хәзрәт турлыгына. //
Ислам дине өчен тырыша, чын күңеле белән өйрәтә,
Кәламе шәрифтән алып, укып күп гыйбрәтләр күрсәтә.
Зур бәхетләр килде безгә, мәчетебез ачылды,
Ислам дине чәчәк ата, дөньяга нур сачылды.
Ходай бирсен күркәм сабырлык шушы имамыбызга,
Ислам дине өчен тырыша инде күз алдыбызда,
Кайсыберсе аңлый алмый, күп эше аның башында.
Безгә өйрәткән гамәлләре булсын Ходай каршысында.
Азып-тузган маллыкларны барын да кулына алды.
Әрәм ителгән мәчетебезне – барын да юлга салды.
Төзәтә башлады хәзрәт җитешмәгән төшләрен (=урыннарын),
Хәзрәт бик якын күрә күп мәхәллә кешеләрен.
Мәчеттә күп иде җитешмәүлек, хәзрәт тотынды ныклап,
Мәчет кемгә дә кирәкмәде, әлегә тордылар йоклап.
Килеп кергәч үк хәзрәт, ныклап тырыша башлады,

Кабахәт кешеләр бар иде, хәзрәт алып ташлады.
Бөтенләй әле бетмәгән калганнары  да җитәр,
Хәзрәт башын әйләндерәләр Миңвәли белән Зөфәр.
Корыкмый алардан хәзрәт, барын да якын күрә,
Хәзрәтне яратмаганнар утырып торсын өйдә.
Хәзрәткә тыгызланаалар, туры юлдан барганга,
Хәзрәткә тыгызланган өчен, халык кала хәйранга.
Барыбыз да дин исламга ихлас күңелебезне салдык,
Гамәл кылып йөри идек, хәзер хәзрәтсез калдык.
Хәзрәт булмагач, мәчеткә бөтен халык тукталды,
Шатланып барган мәчетебез караңгы көнгә калды.
Хәзрәт һаман данлы булыр, беркемнең дә юк эше,
Дөнья ахирәтенә югалмас унөч тел белгән кеше.
Бик аптырамас хәзрәт, төкермәс өсләренә,
Кая барса да хур булмас, ышана көчләренә.
Габделбари хәзрәт тырыш булды эшендә,
Бөтен җирләрне җәйләде шушы 11 ел эчендә.
Унбер ел өйрәткән хәзрәтнең белә алмадык кадерен,
Шунда белербез кадерен – ача алмабыз каберен.
Очып төшкән кошын шикелле хәзрәтнең юк гаебе,
Үзе куйган мөтәвәллиләр барысы да байыды.
Хәзрәт туры юлдан барды, күптән терделәр күзләр,
Хәзрәт өстеннән йөриләр йомыркадан ю (?) эзләп
Хәзрәт тикшермәде аларны, хуҗа булып беттеләр,
Колхоздан качкан муллалар күптән шуны көтәләр.
Указы юк, “Мин - мулла”, -  дип, бар да чалма чорнаган.
Эчләре яна барсының да, алар мулла булмаган.
Барахолка бар чагында, бар да анда сүрделәр,
Барахолка ябылгачтан, мәчеткә ергә ....
Чалма чиргәп утыралар ...
Колхоздан куган муллалар чыгаралар законнар. //
Чалма киеп утыралар әтрәснә (?) суфилар,
Чалма киеп гайбәт сөйлиләр, нигә намаз укыйлар?
Министр булма килиләр, бар да мәчеткә йөреп,
Хәзрәт ничек китте икән, шул кабахәтләрен күреп.
Колхоз муллаларына җыеп председатель тилертте,
Алар теләмәсәләр иде, хәзрәт үзе симертте.

Унбер ел эшләгән хәзрәт кассына ярамадан.
Ярамаган булыр иде аларга хәзрәт карамадан.
Госман, Зөфәр, Миңлевәли усалга терәнеп беттеләр,
Артык симерә башлагач, юлдан җиңеп киттеләр.
Белмәгән кешеләр сорыйлар: “Председатель кем?”, - диләр,
Председатель Миңлевали - гакылдан сашкан җүләр.
Мөселманнар арасында авторитетын югалтты,
Особенно Миңлевали нинди эшләр кузгатты:
Зиннәтле мәчетебезнең бетерде ямьлеген,
Миңлевали уйлый микән кабахәт мәңгелеген.
Миңлевали кабахәт суга барсалар да акмас,
Батса да, хәзрәтне яманнар анда да, тыныч ятмас.
Мулла сорап барам дип, подпись җыйган иртән,
Хатлар язып, мулла сорап, ул мөфтине йадаткан (сихерләп адаштырган).
“Мулла безне укытмый”, - дип төрле хатлар язганнар,
Госман, Зөфәр, Меңлевәли – ну каһәрләр, азганнар.
Бәдретдинов председатель ничә барган мөфтигә,
Өскә киде, мал да таба, хәзер хәзрәт нигә?
Мөфтине аптыраткачтан, үз шоферын җибәргән,
Бәладән котылырмын дип, тиз өстеннән тибәргән.
Шофер аңсыз булган өчен, бичара йадап беткән,
Кая булса да урын булмасмы дип, тизрәк киткәнен көткән.
Мөфти әйткән: «Шофер киткәч, мин калырмын тынычлап»,
Тыныч яшәтмәбез сезне, без язарбыз борычлап.
Мөфти барыбыздан да зур, Ленинград көчлерәк (?)
Үзсүзле икән, карт булса да, мөфти безгә өчлерәк.
Төрле нужалар без күрдек сугыш вакытларында,
Тынычлап гамәл кыла алмадык гомер ахтыкларында.
Тынычлап гамәл кылырга Ходай бездән кызганды,
Нишли дә алмады халык, аждаһалар кузгалды.
Хәзрәтебез булмагач, мәчеттә ямьләр бетте,
Бинабызның ямьлелеген хәзрәт алып китте.
Мөселманнар бар да ... мондый авыр хәл салмый,
Теләгән морадыбызга ирешербез, иншәАллаһ.
Төрле авырлыклар күргәннәр Йосыф пәйгамбәрләр,
Вакыт житми чәчәк атмый бахчадагы гөлләр.
Мәчеттә бу каһәрләрне бик озакка тотмабыз,

Бетерәбез барчасын, берегез дә курыкмагыз. //
Уфадан бер кара малай бер карт китерде тотып,
«Менә сезгә мулла», - дигәч, басып тора ут йотып.
«Синең муллаң кирәкми», - дип, кычкыра бөтен халык,
Карт үзе дә белми нишләргә, баскан хәйранга калып.
Мөфти әйткән: «Алып кайтма, урамда калсын басып»,
Картка әйтәләр алда: «Кит! - дип. - Ул чемоданны асып».
Бөтен халык картка әйтә: «Безгә аның юк кирәге»,
Сүз дә әйтә алмый, карт картайган, кыса аның күкрәге.
Тыныч кына үтсен дип, хәзрәт үзе теләде,
Бөтен халык еладылар, хәзрәт вәгазь сөйләде.
Карт белән бу малай баскан, әйтергә юк сүзләре,
Бар мәчет халык кычкыра: «Булмасын, - дип, - эзләре».
«Безгә мулла кирәкми, - диләр, - алып кит», - диләр картка,
«Ярар-ярар», - дигән була, куркып басадыр артка.
Карчыклар югарыдан төште, дау-шау китте мәчет,
«Тавышланмагыз», - ди хәзрәт, туктата алмый һаман.
Җомга да үтте, хәзрәт сорап туктата алмыйлар ялан,
Тынычка кала алмый халык, барысы да кычкыра.
Янә дә шушы хәл булгач, милләт яме ычкына,
Кайсы алар, кайсы болар, мәчет шаулап кайныйдыр.
Мәчеттә тавыш түгел, ахыр заман алныйдыр //
Берни сөйләтергә хәзрәт ирек бирмәде,
Хәзрәт үзе чыгып алмыйча, председатель кермәде.
Меңливәлине хәзрәт нигә соң чыгып алды?
Хәзрәт чыгып үзе алуга, мәхәллә хәйран калды.
Хәзрәт аркылы сугалар кизтек белән пәрдәләр,
«Чык мәчеттән син кабахәт, теләсәң кая бардылар».
Меңливалигә эләгә иде, тизрәк атламаса,
Ул көн бер хәл булыр иде, хәзрәт якламаса.
Биргәләргә булган икән каршында яшь мулланы,
Мулла калыр монда дип, уйламадык без аны.
Хәзрәт машинага утыртты, исе китте халыкның,
Ачтык күзен, барып чыгар аңламаган сарыкның.
Машина киткәч, бөтен халык бик бәддога кылдылар,
Ни булалар дип, миличләр килеп карап тордылар.
Миңлевалине хәзрәт утыртты машинага,

«Нәрсәдер бар», - диләр, әллә китте әзрәк башына да.
Меңливали кая да китмәс, суга акса да туктар,
Случайный агып китсә, яшь мулласы михнәте.
Яшь мулла, әгәр йомыш булса, кеше урынын алма,
Күптән түгел килүнә өстенә пальто киде.
Кырык яшенә дә җитмәгән, кул сузырга бик иртә,
Тизрәк юлын карамыйча, нәрсә ул монда көтә? //
Картка әйтәләр: «Ал да кит, - дип. - Синең мулла кирәкми,
Хәзрәт үз урынында калсын, үти безнең теләкне».
Ни әйтергә сүз калмады, карт үзе дә аптырады,
«Ярый-ярый», - дия-дия, куллары калтырды.
Яңа мулланы кугачтын, басты минбәргә аягы,
Картларга кизәнә башлады, алып ишан таягын.
Ишан таягын тиз генә хәзрәт кулыннан алды,
Ишан таягын кулыннан алгач, күзен әйләндереп салды.
Халык тарткалый башлагач, янә түрләде минбәргә,
Шушы тавыш вакытында, кем кушты аңар минбәргә?
Килгән сагатук яшь мулла чалма киде башына,
Кыргызлар тик караланып баскан халык каршына.
Казаннан да үзен куганнар, Уфада тукырамаган,
Ленинградка җибәрделәр, аслан укымаган надан.
Килгән көннең мәчеттән куырга булган үзләрен,
Халык бар да кычкырды, тыңламады сүзләрен.
Мәхәллә халкы тирсә карый хәзер яңа муллага,
Кудыгын белеп җибәрегез, тапшырыгыз Аллага.
Наданлыгы күренеп тора, бөтен халык яратмый,
Егерме кешене кулына алды, берсен якка каратмый.
Алдап кына алдыра алмас, тирәк юк укымыш,
Күзен әйләндереп сала, әтрәсенә карт мокыш (?) //
«Хәзрәт урынында калсын», - дип, бөтен халык телиләр,
Хәзрәт булмагач, мал җыелмый, ничек налог түлибез?
Фидья малын картлардан сорыйлар икән, үлгәнчә,
Фидья бирмиләр иде элгәре, үлеп, гүргә кермичә.
Дөньяда чакта, кешедән фидья сорый җүләрләр,
Мәчет җир өстендә ятмас, үлгәч, аны күмәрләр,
Фидьяны өстеңә алгач, намазын укырга кирәк,
Яшь мулла акча сорарга өстенә булды бигрәк.

Ленинград мөселманнары тыңламыйлар сүзләрен,
Эшләре хиләр булганга, гел куалар үзләрен.
Бу эшләрне кузгатканчы, уйларга иде элгәре,
Налог түли алмый, чилтән ташлап качырлар әле.
Мулла вакытында кермәгән картлар тавыш күтәргән,
Картларга ачыланып, чалмасын башыннан алып бәргән.
Азан әйтергә тотынган, халык шәүлә башлагач,
Мулла азан әйтәме инде? Ул акылдан шашкан.
Мулла азан әйтә башлагач, мәзиннең акылы ауган,
«Минем урынымда кала», - дип мәзин мәсхәрәткә калган.
Икенче җомгада мәзин алдан әйткән азанны,
Халык карап әйткән: «Мәзин әллә акылдан язганмы?»
Алда җомга җитмәгән дип, карыйлар ди,
Бу мулла барын тиләр дә наданлыгы сәбәптән //
Бер җомга көн бу яшь мулла карчыклар янына менгән,
Алдап сөйләп, карчыкларны ышандырам дип белгән.
«Мин - хәзер имамыгыз», - дип, мактаганнарын көткән,
Карчыклар шәүли башлагач, тизрәк төшеп киткән.
Хәзер ул аңлый башлады нигә монда килгәнен,
Карчыклар үзенә әйткәннәр: «Күрсәтербез кирәген».
«Икенче кат күренмә», - дип карчыклар күтәрелгән,
Тизрәк төшим дигән чакта, баш ишеккә бәрелгән.
Бөтенесе шаулагачтан, төрле уйларга баткан,
Белде дә, басып тора ди, уйлый-уйлый шаккаткан.
«Кусагыз да, китмим», - дип, кычкырды төшкәчтән,
Үзе ташлап качар әле, әзрәк үзе пешкәчтән.
Үзләре дә аптыраган, садака бирми халык,
«Налог ничек түләрбез?» - дип, торалар хәйран калып.
Бу Зөфәр тармакчыгын каян килеп эләккән?
«Коверлар сатып түләрбез», - дип, Муса мулла өйрәткән.
Хәер җыелмый, кем дә белми аларның кайгыларын,
Сатарга тотынганнар инде мәчетнең коверларын.
Меңливәли председатель яхшы костюмнар киде,
Ишан таягы алтын булса, урлап, сатарлар иде.
Начар кешеләргә бәйләнде председатель, бозылды,
Ахирәтен исәпләми, хәрәм малга кызынды.
Хәзер яңа мулланы да эзләргә өйрәтәләр,

Егермә сум председательдән штраф түләттеләр.
Карак дип, тотарлар иде, алар кисәгә керми,
Кисәгә кермәсә дә, урлау, алар хәрәмне белми.
Хәмер салган шишәләрне кинчәләрдән (?) таптылар,
Мәчет йортында хәмер эчеп, ислам динен саттылар.
Яшь мулла да өйрәнде алар белән эчәргә,
Мулла юк мәчеттә, көтәләр яхшы бәйрәм кичләрен.
Мулла әйткән: «Меңвалигә хоть бирегез пивога,
Пивога бирмәсәгез, минем күңелем боега».
Председатель әйткән: «Акча җыегыз, китәм», - дип авылга,
Мәчеткә халык йөрми, акча җыю авырыла.
Ике җомга хәер җыйганнар председатель юлына,
Моны бүлеп булмый дигән, алгачтан үз кулына.
Аз җыелган ахырысы, киткәнче үк туздырган,
Мулла бүлгәннәрен көтеп, ясигъ вакытын уздырган.
Меңлевали тагын килгән юлына акча сорарга,
Зөфәр анарга күренмичә, киләгән качып чыгарга.
Зөфәр әйткән: «Әбием, бирә алмыйбыз тагын да,
Үзебезгә дә калмады, җыеп бирдек барын да».
Мәчеткә дип хәерне надан кешеләр бирәләр,
Алар киткәч, 20 чаткы көлеп-көлеп бүләләр.
Укытып бетермичә, мулла әйләнеп карый ди,
«Мәхәллә, дога кылабыз, бетмичә дә, ярый», - ди.
«Урынны алып китәрләр», - дип, Файзрахман куркыткан,
Мәлгуньнәрне куарга кирәк тизрәк мәчет йортыннан.
Гөнаһы дип уйламыйлар, искә алмыйлар Аллаһны,
Шул кадәр гаҗәп эшләргә инде наказ (?) калмады.
«Аллаһү әкбар», - дия алмый, «акъбар» дип акыра.
Надан кеше мулла дип, яхшы ашына чакыра.
Чалма кисә, мулла була безнең кебек хайванга,
Белгән кеше без күргәчек карап кала хәйранга.
Бер ел инде башыбызны әйләндереп бетерде,
Хәзрәт урынына надан килде: Ходаем бәла китерде.
Дәвер нык тыгызлаган өчен, аны да чыгарганнар,
Дәвер нык барында, бәла кругом җуалганнар.
Миңлевәли бигрәк ятсыз, кыйнаган Сәгадәтне,
Мескенне ник кыйнаган икән, нәрсә булса сәбәпле?

Ничек кулы күтәрелгән кыз-хатынны сугарга,
Кеше күргән булыр иде кирәк иде чыгарга.
Кеше рәнжеткән өчен кулы-аягы корысын,
Кеше рәнжетүне белер, үзе дә мактанып (?) торсын.

## Мөфтигә мөнәҗәтләр

Ленинградка килүегез мөфти сорыйбыз сезне,
Бер дә килеп чыга алмыйсыз, ташладыгыз сез безне.
Әллә гомерләр бар, әллә юк, калыр идек күрешеп,
Бер килерсез дип уйлыйбыз, Ходайдан вәгъдә ирешеп,
Яхшы мулла җибәрү белән, бөтенләй ыргыттыгыз,
Унбер ел хезмәт иткән хәзрәтне мөфти сез оныттыгыз.
Хәзрәтне төшердегез сез, килеп тикшермичә,
Сез килеп тикшерергә иде, хәзрәтне төшергәнчә,
Рөхсәт бирдегез аларга, барсы да бер булды.
Мәчетебезнең башына җәза кошлары кунды.
Бу Файзрахман гайре булмадымы башкарак?
Ерактан карарга караңгы, килмәдегез баштарак.
Яһүдиләрне тыңладыгыз, үзегез килмәдегез.
Габделбари хәзрәтне бигрәк кимләдегез.
Килсәгез, күрер идегез, монда ниләр булганын.
Габделбари хәзрәтнең бер гаебе юк аның.
Вакыт җитә, төшеп китә яфраклар да агачтан,
Юкны табып күрсәтәләр дошманнар буталгачтан,
Туры юлдан барган кешене таптыгыз тикшерергә.
Хилаф эшләре булса да, мөмкин иде кичерергә.
Мөфти ишан бик зур кеше, Аллаһ кушса, килерсез,
Мондагы булган хәлләрне күзегез берлән күрерсез,
Зур бәхетләр булыр иде, әгәр килеп чыксагыз,
Әллә кайчан килер идегез, безнең сүзне тотсагыз.
Без үткәрдек бәрәкәтне, бик күп нужалар күрдек.
Хәзрәт безгә җибәрелгән, тынычланмак дип белдек.
Эшләп барган хәзрәтне кузгаттыгыз урыныннан,
Башта килеп чыкмадыгыз, ни сөйләргә соңыннан?
Ленинградта нужа күрдек сугышы вакытларында,
Тынычлап гамәл кыла алмадык гомер актыкларында.

Тынычлап гамәл кылырга Ходай бездән кызганды,
Мәхәллә нишли дә алмады, әждәһәләр кузгалды.
Хәзрәтне яманлап, сикерәләр бик артык.
Үзләренең дә исенә төшәр, килеп җитәр бер вакыт.
Сырхау булды ул, эшләде, һич җәлләмәде көчен.
Эшләп яраган хәзрәтне гаепләдегез ни өчен?
Ярагын кулына тотып керә иде мәчеткә,
«Сырхау йөрмә, хәзрәт», - дисәң дә тыңламады атып та (?).
Мәчеттә намазлык юк иде, кәгазь җыеп укытты,
Мәхәлләне туздырмады, ныклап кулында тотты.
Зиярат тирәсен тоттырды, куаклар утыртырды:
Хәзрәт эшләгән вакытта зиярат нурланып торды.
Габделбари хәзрәт тырыш иде эшендә,
Булган төшләрне җәйләде шушы 11 ел эчендә.
Хәзрәтнең изгелеге булсын Ходай каршында
Гарәпчәме, төрекчәме аңлата иде барысын да.
Мәхәлләбез мәхрүм калды, адаштык юлыбыздан,
Унбер ел рәттән хәзрәтне очрадык кулыбыздан.
Һич күңелләр күтәрелми, күзләребез капланды.
Безнең күзләр капланганга яһүдиләр шатланды.
Ахыр заман алды микән, фиргавеннәр юл алды.
Шундый матур мәчетебез караңгы көнгә калды.
Читтән килгән халыклар да җәлли иде Питерне,
Хәзрәт урынына надан килде, Ходаем бәла китерде.
Ничек Ходай Тәгалә житте менә шундый эшләргә?
Бер ел башны кайнаталар, инде хәзер нишләргә?
Яза-яза ядатлар мөфтигә ялган хатлар,
Ялган дөрескә әйләнмәс, Ходаем үзе саклар.
Мөфти, сез бер дә тыңламыйсыз безнең теләгебезне,
Хәзер инде кемнәр җыяр, үлгәч, срогыбызны?
Кабахәтләр сүзенә карап, хурладыгыз сез аны.
Унбер ел торды хәзрәт, ничек онытыйк без аны?
Хәзрәт куйган мөтәвәллиләр бик үрләде югары,
Яман халык арасында төрле хәлләр булгалый.
Төрле нахак-бәла ябалар хәзрәтнең өстенә,
Хәзрәт тугры булган өчен, кайбере киресенә.
Гакыллы булган халык бу эшләргә чуалмас.

Хәзрәтне рәнжетүгә, Ходай ныклы, чыдамас.
Казый дигән бик зур исем бирмәгәнсез сез юкка,
Күркәм, сабыр, ныклы кеше чыдый, мескен, хурлыкка.
Ул начарга әйләнмәде, аждаһалар бәйләнде.
Без начар җирен белмәдек әле, ничек санагыз.
Күркәм сабырлыклы кеше иде, уйлап кара,
Сез йибәргән хатны да укыдылар халыкка.
Бу хәл историягә калыр, әгәр язсак тарихка,
Колхоздан качкан муллалар хөкем төзи мәчеттә.
Кайсын сата, кайсын ала, бар да үзләре кассада.
Мәчеткә җыелып, хөкем төзиләр, бар бигрәк начар калалар.
Налог түли ала алмагач, кайчан ташлап качарлар?
Үтә безнең теләгебезне: хәзрәт урынында калсын!
Хәзрәткә хилаф кешеләрне алып ташла барысын!
Иностранецлар килгәч, эзлиләр хәзрәтне,
Хәзрәт урынында булмагач, алар да хәсрәтле.
Мин укыган кеше түгел, монда язам барысын.
Хәзер ни дә әйтә алмыйбыз, үз уңаен карыйсың.
Мөмкин булса, языгыз каршы, бик шатланып китәбез.
Көтүдән тозган терлек кебек шулай гомер итәбез.
Яза-яза күп тә яздым, бармакларым талды инде.
Гөрләп барган ислам дине шушы көнгә калды инде.
Хәзрәтнең кадерен белмәдек, унбер ел эшләгәнен.
Унөч тел белгән хәзрәтне калдырдык шул көннәргә.
Сез дә ерак, эч серләрен ул сөйләсен кемнәргә.
Ленинградта бер ялгызы очып төшкән кош кебек,
Кемгә дә хәсрәтен белгертми, кешегә сүз куша килеп,
Язылган мөнәҗәтләрем, зинһар, гафу итегез.
Рамазан гаетенә үзегез килеп китегез.
Председатель ызышка яши мулла үз шоферың.
Монда инде бик эшләр, Ходай кылсын гафуны.
Мөфти - безгә бик зур кеше, Лениград көчлерәк,
Безнең теләкне үтәмисез, ник сез безгә очлырак?
Бәдретдинев - безгә кардәше Йәбин баба ягыннан,
Бу нахальный таба алмассыз, эзләсәк Рәсәй тагыннан.
Минвәли Бәдретдинев - бигрәк нахал татар ул.
Дөнья малын күрсәтсәләр, иманын да сатар ул.

Ул дин өчен тырышмый, малга була саташа,
Явыз икәнлеген белми, намаз укып маташа.
Ленинградта суткасына ничә меңләп кеше үлде,
Шул кешеләрнең малын җыеп, Миңлевәли көн күрде.
Булган яхшы әйберемне төяп китте барын да.
Миңлевәли баеп калды блокада чагында.
Бер әйберемне бирмәде, бәхиллегем юк минем.
Мәчеткә кертмәсләр иде, халык белми кемлеген.
Ике оланым күтәреп бардым, әйберләремне сорап,
Малае сүгеп чыгаргач, борылып киттем елап.
Елый-елый чыгып киттем, шул хәт ерактан килеп
«Яңа шкафымнан абыйга гроб ясагыз», - диеп.
Дөнья малы – дуңгыз каны. Бер булыр да бер бетәр.
Бер вакытны аңарга да җавап бирер көн җитәр.
Браты-аты аңарга бәхилләми кыз туганын.
Динле булсаң, уйлап кара ахыры ниләр булганын.
Бирер идем мин сутка, туганым бирдертермәде.
Аты аны сутлашмаган ....

## Ленинград мәчетенең тамашасы

Хәзрәт мәчеткә кергәндә, нур сачыла йөзендә.
Меңләп фәрештәләр саф-саф, «әлхәмдүлиллаһ» дигән сүзендә.
Мәчетебез бигрәк матур, җәүһәр кебек ялтырый.
Хәзрәт төшкән көннән бирле йөрәгебез калтырый.
Дошманнар хәзрәтебезгә бигрәк начар карады.
Мәчетне ялтыратты, яшәсен Габделбари!
Яшь мелланы китерделәр мөбарәк Кадер кичендә,
Йәүм мәшхәр көне булды мәчетебез эчендә.
Хәзрәт урманнар утыртты, кошлар сайрасын дип,
Госман бу эшләрне кылды, мелла булырмын дип.
Госман, усаллык кылсаң да, Аллаһ дигәнчә булыр.
Хәзрәтнең дәрәҗәсе, иншәАллаһ, шул ук булыр.
Муса мулла, кул куйганда, уйласын тирәнрәк
Синең дә инде бу эшләр ошамыйдыр бигрәк.
Мелланы төшерер өчен, Муса мелла кул куйдың,
Дөнья малына сокланып ахирәтеңне уйлаң,

Мәчет аз барында урман ямьләнә, кошлар кунгач,
Дөньяда торырлык ник булсын, меллалар болай булгач?
Төрле төстә ялтырыйдыр мәчетебез, башы двадцаткаларга
Ирешсен карчыкларның күз яше.
Миңневәли күзең күрми, очкилар ки күзеңә!
Бу кылган усаллыкларың бар да төшәр үзеңә.
Сәлах, зураеп йөрмә, бар да халык беләләр.
Атаңны азап күрсәттең, бар да халык беләләр.
Однобортный, күп сөйләмә, уйлап сөйлә баш белән.
Бу сүзләр карышка килер, үкенерсең яшь белән.
Буең кечкенә булса да, Госман, усаллыгың-телең зур.
Халык Коръән укытмыйдыр, үзең дә бит булган хур.
Качып йөргәндәме, бу эшләрне уйладың?
Мәчеткә итеп ковер саттың, Аллаһтан да курыкмадың!
Госман бик каты белеп тор! Бик монафикъ булдыгыз!
Акча урларга бирмәгәч, сез бу эшне кылдыгыз!
Мелланы төшерер өчен, Госман күптән уйлаган,
Ситдыкны гаеп итмәгез, ул арада булмаган.
Госман тирән бас, казыйсын дөрес түгел китапта
Изге халыклардан сураны әйтерләр бу хакта.
Әле нинди сырхау чыккан: бар да халык үләләр,
Бәхетсез мәетләр икән, җаназасыз күмәләр.
Әй туганнар, мөселманнар, нинди көннәргә калдык!
Хәзрәт минбарында булсын диеп мөфтигә хатлар салдык.
Миңле Әхмәт, коверчы Госман, халыкка кайгы салдыгыз!
Ленинград халкына дошман булып калдыгыз.
Бисмиллаһ дип языладыр каберләрнең ташына
Хатыннарның елавы көндә – Миңле Вәли башына.
Мәчет аз барында кар күп, кояш күргәч эреде.
Шул кылтый Исхакый да киселеп арада йөрде.
Ай тотарсыз, тотарсыз, бер-берегезгә ук атарсыз.
Сезгә дә булыр шундый көннәр кызган утка басарсыз.
Сәлах белән ямьсез Билал, йөрмә мәчет юлына!
Мөбарәк Кәгъбәтуллабыз монафикълар кулында.
Однобортный Миңлевали канторга Шакирне кертегез.
Кантор ишекләрен бикләп, кеше кыйнап бирдегез.
Однобортный, беләсеңме яшькә сиксән яшендә

Шакирне кыйнап бирдегезне әйтерсез Хода каршында!
Зөфәр портфель тотып йөри, бөтен хәлләрне белә.
Йөзе кара, озын Зөфәр хәзрәткә каршы килә.
Зөфәр портфельдән йөридер бик зур укыган кебек.
Бөтен эшкә катнашадыр Иблис мәлгунь кебек.
Безнең халык бик сабырлар, бөтен эшкә түзәләр.
Килер бер көн, озын Зөфәр буеңны да өзәрләр.
Яшь мелла кичерәк күренә мәҗлестә утыргач,
Шунда гына мелла булыр, тагын ун ел укыгач.
Бөтен халыкка кайгы төште, бар да кайгырып сөйли.
Бәләкәй Госман Мәскәүдә мелла эзләнеп йөри.
Госман пожарныгым керден, билеңдә иде көрәгең
Хәзрәткә дошман булдың, кабул булмый теләгең.
Однобортный хәтем укый, бисмилланы кушамы?
Мелланы сорап чыгарды Нуралинең Мусасы.
Муса мелла азан әйтә, ханым васифе сөенә.
Хәзрәткә каршы килүенә хәзер Муса үкенә

Язамын мөнәҗәтләрем, хәзрәттән рөхсәт сорамыйча,
Укысагыз мөнәҗәтем, түзә алмассыз еламыйча.
Илен-суын ташлап килде Ленинградка хәзрәт,
Хәзрәт тугры юлга салды, гыйлем алып калдык әзрәк.
Хәзрәт орышмас микән шушы язган мөнәҗәткә,
Ишетәсез, нинди хәлләр, инде калдык без гаҗәпкә.
Хәзерендә күбәйделәр Яхъя мулла фариләре.
Әлек күбәю түгел иде, яшерен сөйләр иде элгәре.
Хәзрәт уйламаган эшләрне кайдан казып чыгаралар.
Дошман аяк асты тулган, бар да бергә чуалалар.
Яшь мелла укыган вакытта, үзе карый тәрәзәгә,
Күңелләре шатланадыр, мендем дип тә чага.
Дәрәҗәсен тиз төшерәбез, бик озакка яшәтмәбез.
Үзе ташлап качар әле, зинһар, бер сүз дә әйтмәгез!

# Габделбари Исаевның мөфти булуы хакында[1]

Габделхәбир хәзрәт Яруллин

1395 һиҗри 25 шәвваль

1975 милади 31 октябрь, җомга көн

**بسم الله الرحمن الرحيم**

**الحمد لله رب العلمين على كل حال و الصلوة و السلام على سيد المختار و على آله و اصحابه الكرام**

Һәртөрле изге теләкләр белән мәсҗед җамигъка килгән мөхтәрәм мөселманнар! Әс-сәламү галәйкүм вә рәхмәтүллаһи вә бәрәкәтүһ!

Дин исламның бөек фарызларыннан вә **شيعار اسلام** булган җомга көнебезне җомга гыйбадәтләребезне күпчелек белән кылган дога вә теләкләребезне җәнаб Хак барчаларыбыз өчен кабул вә мөбарәк кылсын. Киләчәк көннәребездә дә күп кенә **سيد الايام** булган җомга көннәрен ил-җан тынычлыгы шатлык белән каршылап, өлфәт, мәхәббәт, дустлык нигезендә, дин вә дөньябыз төзек булган хәлдә, мөкаддәс динебезне дәвам иттерүне җәнәб Хак барчаларыбызга насыйп вә мияссәр кылсын.

**آمين يا مجيب السائلين**

Мөхтәрәм мөселманнар! Бүгенге көнебездән 17 ай мөкаддәм 74 нче елның 12 июнендә **يَا أَيَّتُهَا النَّفْسُ الْمُطْمَئِنَّةُ ارْجِعِي إِلَى رَبِّكِ** дигән әмер җәлиленә имтисәлән Уфа шәһәрендә мөселманнарның Диния Нәзарәтендә рәис вә мөфти булып 20 ел хезмәт иткән хафиз кәләмуллаһ булган галим фазыйл мөхтәрәм Шакир хәзрәт вафат булган иде. Аллаһның рәхмәтендә булган иде. Мөфти хәзрәтнең арабыздан китүе белән күмү мәрасимендә катнашкан казый вә имам-хатыйблар вә мөгътәкәд мөселманнарның киңәше белән, шул ук вакыт Мәскәү имам-хатыйбы Әхмәтҗан хәзрәт Мостафин, шул ук җәмгыятьтә катнашкан мөселманнарның үтенүе буенча, мувәкъкать (вакытлы – ред.) рәвештә мөфтилекне кабул иткән иде. Әхмәтҗан хәзрәтнең даими рәвештә шушы зур мәсъүлияте хезмәтне кабул итүен үтенсәләр дә, ниндидер сәбәпләр белән, Әхмәдҗан хәзрәт бу бөек хезмәтне кабул итәсе килмәү сәбәпле, шушы хезмәтне өстенә алырлык муафыйк, лаякәтле, мөстәхак адәм табылмау сәбәпле, мөфти Шакир хәзрәтнең вафатыннан ел ярым кадәр вакыт үтеп тә китте. Андый адәмнәр

1. Бу вәгазьнең кульъязмасы Наиль хәзрәт Яруллин шәхси архивында саклана. 88нче номер, 4 бит.

сирәк кенә булса да, кабул итмәделәр. Аллаһ тарафыннан вәгъдә көне житүгә каршыдыр. Шушы эшкә лаякәтле, шушы бөек җаваплы хезмәтне үти алырлык имам булган бер адәм хакында мөгътәкад мөселманнар, игътимадлы галимнәр киңәшеп, шул адәмне бөек җаваплы хезмәтне кабул итүен үтенәләр. Мөселманнарның үтенечен кабул итеп, авырлык белән генә мөфтилек ләвазименә ризалык биреп кабул итә һәм 1975 елның 24 октябрендә шушы бөек дини тарихи булган пленумны үткәрергә карар кылынып, Ватаныбызның төрле тарафында яшәүче имам-хатыйбларга мөфти һәм Нәзарәт әгъзаларына белдерү ясап, чакыру кәгазьләре җибәрәләр. Шул исәптән, Казан имамнарына да чакыру кәгазе килеп, безгә дә шушы бөек мәҗлестә иштирак итәргә Аллаһ насыйп итеп, сез мөселман кардәшләребезнең догасы бәрәкасендә, сау-сәламәт әйләнеп кайттык. Шушы хакта сез, мөселман кардәшләремә көчем житкән кадәр мәгълүмат бирәмен. Коръән Кәримнең “Али Гыймран” сүрәсендә 104нче аятенә җәнаб Хакның әмеренә бинаән وَلْتَكُن مِّنكُمْ أُمَّةٌ يَدْعُونَ إِلَى الْخَيْرِ وَيَأْمُرُونَ بِالْمَعْرُوفِ وَيَنْهَوْنَ عَنِ الْمُنكَرِ ۚ وَأُولَٰئِكَ هُمُ الْمُفْلِحُونَ һәр мәмләкәткә, һәр урында гасыр сәгадәттән бирле дини эшләрдә җитәкчелек иткән оешмалар булдырылып, шул идарәләрдә булган рәисләр ислам мәмләкәтендә “шәехел-ислам” дип аталганнар. Безнең Русия җирендә яшәүче мөселманнарның иҗтиһады белән 1789 елда 4 декабрьдә Уфа шәһәрендә дини эшләрендә идарә итүче (ادارة الدينية)не ачарга рөхсәт бирелә. Шул вакыттан бирле Уфа шәһәрендә дәвам итеп килгән Диния Нәзарәтендә мөфти рәислек кылып, һәркайсы хәленә, заманына карата зур тырышлык белән хезмәт кылалар. Һәркайсы Аллаһының рәхмәтендә булсалар иде.

Шушы мәҗлестә катнашучылар: Шимали Кавказдан (Дагестан) – мөфти Габделхафиз Гомәров, Ташкент Диния Нәзарәтеннән вәкилләр – мөгавен-мөфти Габдуллаев Ганижан, Әсраркол Моллаколов, илебезнең зур шәһәрләреннән Ленинград, Мәскәү, Горький, Саратов-Куйбышев, Әстерхан, Ишембай, Чиләбе, Оренбург, Казан, Бөгелмә, Октябрь шәһәре һәм Пенза областьларыннан һәм бәгъзе бер авылларыннан казыйлар, имам-хатыйблар, берничә мөтәвәллият әгъзалары да чакырылган иде.

23 октябрьдә чакырылган вәкилләр һәркайсылары килгән иде. Шул көндә пәнҗешәмбе көн булачак мөфти хакында фикер алышулар булды һәм 24 октябрь җомга көн сәгать тугызда тарихи бөек мәҗлес башланып, президиум сайланды. Мәҗлестә, әүвәлән Уфа имамы Габбас тарафыннан Коръән укылып, Нәзарәттә хезмәт иткән мөфти, казыйлар, имам-хатыйблар рухына дога кылынды.

Вакытлы мөфти Әхмәтҗан хәзрәт ел ярым кадәр вакыт эчендә Нәзарәттә эшләнгән эшләр хакында сөйләп узды. Нәзарәткә караган унбиш мәхәлләдә үлгән һәм авыру-картлык сәбәпле истигъфа кылынган имамнар хакында һәм шулар урынына имамнар билгеләү һәм Нәзарәттән быел унлап шәкертнең укырга җибәрелүе һәм Нәзарәтнең бинасының гыймәрәте (төзелеше – ред.) хакында мәгълүмат бирде.

Моның соңында, Нәзарәтнең бухгалтеры Нәзарәтнең кереме-чыгымы хакында сөйләп узды, тотылган расходлардан хисап бирде. Шушы докладлар тыңланганнан соңында Нәзарәт хәдимнәренең эшләре канәгатьләнерлек дип карар кабул ителде. Беркадәр тәнәфестән соң, төп мәсьәлә - мөфти сайлау мәсьәләсе каралды. Монда да баш докладчик мувәкъкать мөфти Әхмәджан хәзрәт булып, ул үзенең төрле гозерләрен күрсәтеп, шушы хезмәтне даими рәвештә кабул итә алмавын һәм үз тарафыннан булачак мөфти Габделбари хәзрәт Низаметдин углы Исаев (Ихсанов) тәкъдим итеп: “Хәзерге вакытта шушыннан мувәкъкать ләякатьле адәм булмас”, - дип сүзен тәмам итте. Бу булачак мөфтинең кандидатурасын яклап Нәзарәттә күп еллар казый булып эшләгән иң карт имамнардан Ишимбай имамы Габделбари хәзрәт чыгыш ясады һәм Ленинград имамы казый Габделхафиз һәм Горький имамнары булачак мөфти хакында кыскача гына мәгълүмат биреп: “ИншәАллаһ, бу адәм безнең ышанычыбызны аклар, Коръән-хәдис буенча гамәл итеп, динебезнең рәваженә тырышыр”, - дип, сүзен тәмам итте. Бәгъдә, тавышка куеп Габделбари Низаметдин углы Исаевның мөфти булуы бер тавышыннан кабул ителде. Каршы килүче булмады.

Икенче мәсьәлә: Диния Нәзарәтенә әгъзалар (казыйлар) сайлау мәсьәләсе хакында булып, Нәзарәтендә күп еллар әгъза булып торган Пенза губернасыннан Ярулла хәзрәт Йосыфи, Әстерхан имамы Фарук хәзрәт картлык сәбәпле истигъфа кылынса, имам-хатыйб, казыйлар Ульяновски Хәлил хәзрәт һәм башкалар урынына казый-әгъзалар сайланды. Жиде кешедән гыйбарәт шушы кешеләр Нәзарәткә әгъза итеп билгеләнделәр. Ленинград имамы, Мәскәү имамы Әхмәтҗан, Казан шәһәре, Горький имамы Назыйров, Саратов имамы Габдулла хәзрәт Альмакаев, Ишимбай имамы Габделбари хәзрәт һәм Уфа имамы Габбас хәзрәтләр бертавыштан Нәзарәткә әгъза-член итеп, ике кеше – Оренбург имамы Яхъя хәзрәт Имамиев, Ижевски имамы Фатих хәзрәт Салихов Нәзарәткә әгъзалыкка кандидат итеп билгеләнделәр.

Уникенче мөфти итеп, шушы баруыбызда Габделбари Низаметдин улы Исаев дигән кеше сайлана. Бу адәмнең кыскача гына тәрҗемәи хәле шуннан гыйбарәт: 1907 елда Уфа шәһәрендә дөньяга килә, Хәйрулла хәзрәт Госманов

мәдрәсәсендә һәм беркадәр вакыт Уфа шәһәрендәге мәдрәсәи Галиядә белем ала һәм хосусый рәвештә белемен 20 яшьләренә кадәр дәвам иттерә (үзенең әйтүенә караганда). 19 яшьләрендә Коръән хифз кыла. 20 яшьләрендә Уфа вилаятендә бер авылда имам була. Аннан Уфа шәһәрендәге икенче мәхәлләдә имам булып хезмәт итә, Уфада булган вакытында Диния Нәзарәтенә дә күп кенә хезмәтләр күрсәтә. Габдерәхман Рәсүли мөфти булган вакытта, Казанда имам булып дөньядан үткән Исмәгыйль Мөштәри, Исмәгыйль Рәхмәтуллин, Ишимбай Габделбари хәзрәт, Ташкент Диния Нәзарәтендә әгъза булып эшләгән соңгы мөфти Шакир хәзрәтләр белән хаҗга бара.

Сугыштан соң, Ленинград мәчете ачылганның соңында, анда имам итеп җибәрелә. Ничә еллар хезмәт иткәннән соң, яңадан Уфа Диния Нәзарәтенә баш казый итеп чакырыла, ләкин гаиләви сәбәпләр белән Уфага кайтмый. Ниндидер сәбәпләр белән берничә еллар Ленинградта имамчылык истигъфа кылынып тора. Бу яңа мөфти хакында күп еллардан бирле Нәзарәттә әгъза булып торучы 87 яшьлек Ишимбай имамы Габделбари хәзрәт Юнысов һәм Горький имамы – Нәзарәт әгъзасы Һидаятулла хәзрәт, Омски имамы Нәзарәт әгъзасы - һәркайсы шушы булган мөфтинең Нәзарәттә эшләгән файдалы хәзмәтләреннән һәм хөкүмәтебезнең кануннарына муафыйк [икәнлегенә] шаһәдәт бирделәр. Гарәбияттән, русчадан белеме яхшы, урыны-вакыты белән җәсүр, батыр адәм, шушы эштә җитәкчелек итәргә икътидары бар дип, күп кенә кешеләр: “Хәзерге вакытыбызда аннан да муафыйк, мөстәхак адәм булмас, иншәАллаһ, шушы мәсъүлиятле зур вазыйфаны Коръән Кәрим вә Рәсүл әкрам хәзрәтләренең сөннәтенә муафыйк рәвештә үтәр дип ышаныбыз”, - дип, таныклык бирделәр.

ما رآه المؤمنون حسناً فهو عند الله حسنٌ күркәм булыр, иншәАллаһ. Хәерле булыр дип, хөсне занн кылабыз”, - диделәр.

Җәнаб Раббел-галәмин хәзрәте шушы тарихи дини нөдүвәләребезне мөбарәк кылып, хәерле нәтиҗәләр насыйп итсен. Дини вә дөньяви юлбашчыларыбызга сәламәтлек белән дин вә дөньябыз әбәд (мәңгелек – ред.) булып, динебезнең киләчәгенә рәваҗенә (таралуна – ред.) файдалы хезмәтләр итәргә насыйп вә мияссәр булса иде.

# [Тәрҗемәи хәлем]

**اعوذ بالله من الشيطان الرجيم بسم الله الرحمن الرحيم**
**الحمد لله رب العالمين الصلوة و السلام على رسول سيد المرسلين**

Мин үзем Уфа шәһәрендә 1907 ел һиҗри берлән ...нче ел гает корбан көнне ягъни 28 гыйнвар сишәмбе көн дөньяга килдем. Атам Низаметдин Салих углы Уфа шәһәрендә сатучы була. Әнкәм Фәхрелҗамал Мөхәммәд Хафиз кызы мөселманнар киеме сатучы баласы була.

Миңа исем бирүче Уфа шәһәре өченче мәчетендә имам-хатыйб, Диния Нәзарәтенең әгъзасы Сабирелмөхсин хәзрәтләре була.

Бала вакытында алты яшьләрдә мине земский ышкулга укырга бирәләр. Ул ышкулада иртән бер сәгать дин укытыла, аннан падишаһка дога булып, дәрес башлана иде. Моның соңында унбер яшемдә мине әнкәй Башкортостанның Әсән мәдрәсәсенә Коръән хифз итәргә илтеп куя. Анда, исемен белмим, әгъма (=сукыр) бер кари була. Ул бик усал, бик кыйный торган була.

Бу авылда бер атна, ун көннән соң, качамын. Шул җирдә 18-20 километр чамасы Туйләгән дигән авылга Хәбибриҗал Габделкадыйри кари хәзрәткә илтеп тапшыралар. Ул 35 яшьләрендә була. Бик гайрәтле һәм требовательный була. Әлбәттә, ул вакыт гамәлгә куелган кыйнау монда һәм бар иде, ләкин мин үзем бер генә мәртәбә кыйналдым, бәлки әткәйнең ярдәмле булуы файда иткәндер. Анысын ачык белмим, тик бер генә кыйналуымнан шулар дип шәкертләр әйтә иде.

Бу авылда дәрес тәртибе. Мин үзем бик фәкыйрь һәм бик миһербанлы Хәйрулла бабайларда тордым. Алар әби берлән икәү генә иде, ләкин мине балам дип йөртәләр иде. Хәзер дә, әлхәмдүлиллаһ, аларны һәр көн догадан калдырганым юк. Аллаһ кабул итсен. Иртә намаздан соң Коръән тыңлату, аннан дәрес алып кайтып китү. Дәрес һәр көн Коръәннән ике бит, бер сөмен бирелә иде, ягъни Коръәннең беренче яртысы 240 көндә узылды. Аннан соң икенче ярымы башланды. Ләкин инде бу вакытта әүвәлге ярымы тагын да бер әрбагъ – дүрт бит – берлән тәкрар башланды, ягъни алты бир хифз /16/ итергә туры килде. Бик авыр иде, хәтта хәзрәтемез миңа: “Бик авыр бара, син әллә туктыйсыңмы?” – диде. Мин: “Юк, Ходайга тапшырдым”, - дип дәвам иттем һәм дәвам иттем. (Шуны әйтергә кирәк, мин унбер яшемдә сарыф, нәһү укыган идем. Миңа бераз шул ярдәм бирде). Шулай итеп, беренче ярымы тагын алтмыш көндә тәкрар ителеп, икенче ярым әле ерак китмәгән иде.

Моның соңында, беренче ярымны ярты пара берлән тәкрар башланып

икенче ярым яртылаша башлаган иде. Бер айдан беренче ярым бер пара берлән тәкрар башланып әл-хасыйл, беренче ярым нык күңелгә беркетелгәч, икенче ярым бер мәртәбә хифз ителеп чыкты. Менә моннан соң кичке белем алу дәресе башланды, ягъни кем ясигъ намазыннан соң, хәтта ярты төннәр узганчы, тәфсир, хәдис, гыйльме фикх һәм башка дәресләр кертелә башлады.

Әл-хасыйл, 14 яшемдә беренче хәтем ителде, ягъни Коръәнне өч ел дигәндә хифз итә алдым, әлхәмдүлиллаһ.

Моның соңында Уфа шәһәре Зияэтдин Камали хәзрәтләреннән Галия мәдрәсәсенең программасы буенча дәрес алып, 1926 ел Дихния Нәзарәте хозурында Ризаэддин Фәхреддинов мөфти хәзрәтләренә имтихан иттем. Имтиханда Зияэтдин әл-Камали, Мәһди Мәгъкүли, Җиһангир Абызгилдин, Кәшшаф Тәрҗемани, Мөхлисә Бубый һәм башкалар катнаштылар. Ошбу имтиханда имамлык дәрәҗәсенә шаһәдәтнамә бирелде һәм шул ел Башкортостан Чакмагыш нәхиясенә табигъ Каряуды авылында хәтме Коръән итеп, шул җиргә имам булып калдым.

Шул Каряуды кариясендә имам булып торган вакытымда үзебезгә кода булган ихтисаб идарәсендә мөшәвия булып хезмәт итүче Байбулат авылының имамнары булган Шаһигәрдән Хәмзин аркылы Иске Биккинә авылында мөәззин ихтисаб идарәсенең хәзинәдәре булган Мирза Шәриф Валидан углы Валиданов хәзрәт берлән танышлык иттек. Бәлки авыл арасы ерак кына булса да, һәр көн очрашулар булып торды. Ул зат Аллаһның рәхмәтендә булсын. Үткен фикерле, киләчәкнеерактан тәкъдир итүче зат булды.

Шулай танышып йөри торгач, Шаһигәрдән хәзрәт аркылы үзләренең беренче хөрмәтле баласы булган Гафифә һәм гакыл сахибе булган яңа гына бәлагатькә ирешкән кыз-баласыны безләргә мәңгелек юлдаш, бәхет-сәгадәткә житәкче булган Мөсәүвәмәне Мирза Шәриф хәзрәт безгә җефетләндерергә разый булып, без фәкыйрьны бу бәхетләргә мәшрәф итте. Аллаһның рәхмәтендә булсыннар. Аны ошбу ел 1927 ел ахырлар, 1928 ел башлары иде. Әл-әҗил җәләлә бу бәхетенә безләргә һәдия итте.

Ләкин һәркемгә мәгълүм, ул еллар аз вакытлар иде. Хәлебез бертөрле төзелештән икенче төрле төзелешкә күчү өчен, күп көчләр кирәк һәм корбаннар да булуы мөмкин, чөнки авыр тормыш булса да, адәм баласы суга кунган, канына шул сеңгән булу сәбәбендә аны каннан чыгарып, яңа фикер кертү өчен көрәш-корбансыз булмыйдыр.

Безләр дә шушы кампаниягә туры килеп, 1929–30 елларда бераз авырлык күрергә туры килде.

Бу вакытларда Диния Нәзарәтендә мөфти Ризаэддин Фәхреддинов

хәзрәтләренә барып иттифак иткәннән, соң бу затлар: “Сез – яшьләрсез, сезгә киләчәк вакытында күп хезмәтләр йөкләтелер. Ошбуның өчен, саклану өчен Урта Азиягә китеп торыгыз”, - диде. Һәм шул киңәш берлән Урта Азияга барып урнашып, анда да зур галимнәр аркылы хисап эшләре хезмәтенә кереп, имамлык эше дә алып барылды.

1934 елларда דиния Нәзарәтенең Ризәэддин хәзрәт берлән очрашу булып, Нәзарәтнең әгъзасы ителеп үткәрдем. Аллаһның рәхмәтендә булсын. Мин, дингә ихласлыклары ирешсен өчен, ошбу быел вазифаны йөкләнгән икән.

1936 ел мәрхүмнең дәфенендә әнзәл кылып һәм Габдрахман Рәсүл хәзрәтенә мөфти тәгәййин иттегендә инзәл итә алдык. Әлхәмдү-ли-Лаһ.

Бу вакытларда дәүләт хезмәтен дә һәм Нәзарәт хезмәтен дә алып бардык. Ошбу тәртип берлән 1941 ел Ватан сугышына барырга туры килде. Ватанны яклау юлында ике мәртәбә мәҗрух булып, шушы ике арада, ягъни 1942 ел госпитальдән Уфа шәһәренә училищега җибәрделәр. Аннан мөхәррәбә сугышка тәкрар кереп, 1943 ел март аенда Ватан сугышы инвалиды булып кайттым.

Бу вакытта Диния Нәзарәтенең әхвәле начар иде. Халыкара ярдәм ясап, Нәзарәттә тәртип итү хезмәтенә, архивларны тәртипкә кую, китапханәне тәртипкә кую хезмәтләре алып бардык. Уфа беренче мәхәллә мәчетендә рәис һәм ярдәмче имам булып хезмәт алып бардык.